ISSN 0206–4189
Индекс 73210

12+

# КАЗАН УТЛАРЫ

7.2013



# УЛ КӨН КИЛЕП ҖИТТЕ!

6-17 ИЮЛЬДӘ КАЗАНДА УНИВЕРСИАДА –
СТУДЕНТЛАРНЫҢ БӨТЕНДӨНЬЯ СПОРТ ЯРЫШЛАРЫ УЗА





















**Казан утлары**

**Qazan utlari**

2013

**7**

**(1089)**

*ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:*
*«ТАТМЕДИА»*
*ачык акционерлык җәмгыяте*

татмедиа

*БАШ МӨХӘРРИР*
**Равил Габдрахман улы Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Рәдиф Гаташ**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Рафис Корбан**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Айрат Сибагатуллин**
**Рафикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Марат Закир, Әлфәт Закирҗанов, Камил Кәримов.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер).

---

✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎: *Баш мөхәррир — 562-10-62.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге — 222-09-83 өст.1612.*
*Исәп-хисап бүлеге — 222-09-80.*

**Факс** — (843) *222-09-83 өст.1612.*

**E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. Замана балалары. *Истәлекләр.* ...5
Луиза ЯНСУАР. Дөньялыктан саркыламы сагыш... *Шигырьләр.* ...67
Марат ӘМИРХАНОВ. Ир-Мамай. *Тарихи бәян.* ...71
Илдус ДИНДАРОВ. Саный татар вакытын... *Шигырьләр.* ...99
Зәки ЗӘЙНУЛЛИН. Курск дугасы батыры. *Документаль бәян.* ...102

**ТАТАР ГАЛӘМЕ**

Рәфикъ ЮНЫС. Кытайдан зәңгәр тауга кем яулык болгый? ...137

**ХӘТЕР**

Алсу МОСТАФИНА. «Зәңгәр күлгә ташлар аттың...» *(Марс Шабаевның тууына 80 ел).* ...143
Марс ШАБАЕВ. Мизгел. *Шигырьләр.* ...149
Нурихан ФӘТТАХ. Четерекле булды безнең заман. *Истәлекләр.* ...172

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ. «Шундый матур аның шигырьләре...». ...154

**СӘНГАТЬ**

Гөлзадә БӘЙРӘМОВА. «Мин арый торган кеше түгел». ...159

**ТОРМЫШ ЯЗГАН ХИКӘЯЛӘР**

Марс МАКАРОВ. Ике төр бәндәнең үлеме. ...161

**ФӘН**

Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. ...166
«Татар энциклопедиясе» битләреннән. ...169

**ШИГЪРИ ХӘТЕР**

Фәннур САФИН. Сагынам. *Шигырьләр.* ...179

**ШӘХЕСЛӘР ҺӘМ ШӘРЕХЛӘР**

Госман ГОМӘР. Фәйләсүф җан. ...181

Татарстан язучылары җыены. ...187
«Казан утлары» архивыннан. ...152
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ...190

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: воспоминания Т.ГАЛИУЛЛИНА «Дети своего времени»; историческая повесть М.АМИРХАНОВА «Мамай»; документальная повесть З.ЗАЙНУЛЛИНА «Герой Курской дуги»; стихи Л.ЯНСУАРА, И.ДИНДАРОВА, Ф.САФИНА.
«Татарский мир»: Р.ЮНУС. «Татары в Китае».
«Память»: статья А.МУСТАФИНОЙ, посвященная 80-летию поэта М.ШАБАЕВА; стихи М.ШАБАЕВА; Н.ФАТТАХ. «Мы жили в непростое время».
«Литературная критика»: Р.ШАРАФИЕВ. «Ее стихи прекрасны».
«Искусство»: беседа Г.БАЙРАМОВОЙ с режиссером Р.ТУМАШОВЫМ.
«Рассказы из жизни»: М.МАКАРОВ. «Смерть двоих».
«Наука»: Ф.ГАРИПОВА. «История наших деревень».
Страницы из «Татарской энциклопедии».
Итоги литературного года Союза писателей РТ.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: новый стадион «Казань-Арена»; писатель Николай АЛЕШКОВ.

# IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and Poetry»: Memoirs by T.GALIULLIN «Children of their times»; historical novel by M.AMIRHANOV «Mamay»; documentary novel by Z.ZAYNULLIN «Hero of Kursk Bulge»; poems by L.YANSUAR, I.DINDAROV, F.SAFIN.
«Tatar World»: R.YUNUS. «Tatars in China».
«Memory»: article by A.MUSTAFINA dedicated to 80th anniversary of poet M.SHABAEV; poems by M.SHABAEV; N.FATTAH. «We lived in difficult times».
«Literary Criticism»: R.SHARAFIEV. «Her poems are beautiful».
«Art»: Conversation of G.BAYRAMOVA with director R.TUMASHOV.
«Stories of Life»: M.MAKAROV. «Death of two people».
«Science»: F.GARIPOVA. «History of our villages».
Pages from «Tatar Encyclopedia».
Results of literary year of Writers' Union of Tatarstan.
From photo archives of magazine.
Diary of social-cultural life.
On our covers: new stadium «Kazan-Arena»; writer Nicholay ALESHKOV.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән житешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 01.07.2013, график буенча 01.07.2013.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 $^1/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ С-1561. Тираж 4008.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча Федераль хезмәтендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«ПИК «Идел-Пресс» ААҖ «ТАТМЕДИА» филиалы типографиясендә басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2013 ел.



Тәлгат
Галиуллин

# ЗАМАНА БАЛАЛАРЫ

ИСТӘЛЕКЛӘР

*Икенче кисәк*

**Тарих безне кат-кат сыный...**

Үткән гасырның 60-80нче елларында Алабуга педагогия институтында укытканда, башымнан узган хәл-әхвәлләр, күргән-белгәннәр, шул чорда аралашкан кешеләр турында, үзем аңлаганча, арттырмаска, өстәмәскә, дөреслеккә хилафлык китермәскә тырышып, «Замана балалары» исемле истәлекләр китабымда язып чыккан идем. Ул әүвәл «Казан утлары»нда басылды. 1993 елда 25 мең тираж белән Татарстан китап нәшриятында дөнья күреп, тиз арада таралып бетеп, публицистика киштәсендә үз урынын тапты дип уйлыйм. Чөнки мин бу истәлек язмамда, шәхси уйлануларымда кешене рәнҗетүгә корылган җәмгыятьнең асылын хәл кадәри ачып бирергә тырышкан идем.

Шуннан соң узган егерме елдан артык вакыт эчендә иҗтимагый, сәяси, икътисади һәм рухи тормышыбызда гасырларга торырлык үзгәрешяңарышлар булып алды. СССР империясенең юкка чыгуы, унтугыз миллион әгъзалы коммунистлар фиркасенең эреп таралуы нәтиҗәсендә яңартылган илдә демократик үзгәрешләр пәйда булуы вак, буйсынган милләтләргә иркенрәк сулыш алырга, үз хокукларын даулап урамнарга ташып чыгарга мөмкинлек бирде. Узган гасырның 90нчы еллары халыкны җөмһүриятебезнең олуг мәсьәләләре тирәсендә берләштергән юнәлешләрне, киләчәк яшәешебез турында фикерләрне ачыклауны таләп иткән чор булды. Тиз арада ике хакыйкать ачыкланды. Берсе — акырыпбакырып, күкләргә кизәнеп, Мәскәү тарафларына йодрык күрсәтеп кенә мөстәкыйльлеккә ирешеп булмавын аңлау. Аерылып чыгу, югалткан дәүләтебезне торгызу турындагы изге хыяллар мавыктыргыч булса да, аны гамәлгә ашыру өчен көрәшү үзәкне котырту гына икәнлегенә төшенү иде. Икенчесе — сәяси дилбегәнең йомшаруы кыска вакытлы булып, үзәк белән төбәкләр арасындагы мөнәсәбәтләрне соңгылары файдасына үзгәртеп

---

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН (1938) — *тәнкыйтьче, прозаик, әдәбият галиме; филология фәннәре докторы, КФУ профессоры, Татарстанның һәм Россиянең атказанган фән эшлеклесе, ТФАның әгъза-мөхбире. «Сәет Сакманов» роман-трилогиясе авторы. Казанда яши.*

калу мизгелләренең чикләнгәнлеген, тарих биргән форсатның шәһрин тиресе кебек кысыла баруын күзаллау иде. Яңалыклардан һәрвакыт зурны көтәсең, мәгәр күп очракта азы белән каласың, соңыннан чыланган мыекны сыпырып утырырга мәҗбүр буласың! Гомуми шатлыкның гомере умырзая чәчәгенеке шикелле кыска була шул. Кинәт ингән хөрриятттән тулырак һәм киңрәк файдаланып, халык мәнфәгатьләренә буйсындыра алу үзебездән, бигрәк тә хакимиятне кулларына төшергән түрәләрдән торды. Кешеләрне мәйданнарга чакырып, дәртләндереп, тавышларын янгыратып йөрүче милли хәрәкәт лидерларының кулында шигарләр язылган плакатлардан, әләмнәрдән башка нәрсә юк иде. Күчеш чорында, президентны яклап күтәрелеп, үз бурычларын үтәгәч, аларны да берәм-берәм сәхнәдән «тартып төшерә» бардылар. Чынлыкта М.Мөлеков, З.Зәйнуллин, Ф.Бәйрәмова, Рәшит һәм Илдус Әхмәтҗановлар, Ә.Кәримуллин кебек чын һәм батыр көрәшчеләр дә бармак белән генә санарлык иде.

Тарих сәхифәләре кабатлана тора диләр. 90 нчы елларга үрнәк-өлге эзләп ерак барасы булмады, шул ук гасырның башына гына күз салу да җиткән иде. 1906-1916 еллар арасында, инкыйлаб чуалышлары басымы тәэсирендә, патша хөкүмәте шактый сәяси һәм икътисадый чигенешләр ясый. Русия империясендә яшәүче милләтләр, бигрәк тә татар укымышлылары, каләм тибрәтүчеләре, хәзергечә әйтсәк, эшкуарлары матбугат, нәшрият, мәгариф өлкәсендә, сату-алуда (Русия мануфактурасының яртысы татарлар кулына күчә), сәнәгатьчелектә гаҗәеп бер сикереш ясыйлар. Сугышта җиңелүгә, корылыкка сылтау итеп яисә башка сәбәпләр табып, кара көчләрнең (ул октябрь инкыйлабы булып чыкты) бу мөмкинлекләрне тартып аласыларын эчке тоемнары һәм тарих сабаклары буенча сиземләп, татар зыялылары, дин әһелләре бирелгән мөмкинлекләрдән тулы көчкә файдаланып калырга тырыштылар.

Гасыр ахырында, ягъни 90 нчы елларда шуңа якын вәзгыять кабатланды. Ике унъеллыкта да халкыбыз җилкәсен киереп, аркасын турайтып, үзен мөстәкыйль, ирекле милләт итеп тоеп, туган телендә авыз тутырып аралашып, иҗтиһат итеп кала алды.

XX гасырның 1917 елында төрмәләрдән чыккан, чит илләрдән кайткан әрсезләр Русия армиясенең җиңелүеннән, халыкның канәгатьсезлеге тудырган чуалышлардан, гавамның аң дәрәҗәсе түбән булудан ифрат оста файдаланып, ялган һәм алдавыч шигарләре, вәгъдәләре белән хакимиятне кулларына төшергән большевиклар милләтләрне, шул исәптән урыс халкының үзен дә изүне, кысуны тизләттеләр һәм утызынчы еллар ахырында акыллы, белемле, нәселле кешеләрне юк итүдә, төрмәләрдә, сөргеннәрдә черетүдә урта гасыр инквизициясеннән дә уздырып җибәрделәр. Большевикларның асылын вакытында аңлаган зыялыларның беришесе мөһаҗирлеккә чыгып китеп исән калды, аларның ирек, тигезлек турындагы төче сүзләренә ышанганнар каберләрен вакытыннан иртә туган илләрендә тапты.

Татарстан хакимиятен кулларыннан ычкындырмаган элеккеге коммунистларда туксанынчы еллар башында милли хисләре уянып алгандай булды, беренче мәлне халык мәнфәгатьләре турында кайгырттылар, динне кайтаруда, мәчетләрне ачуда булыштылар, иҗтимагый оешмалар белән элемтәдә яшәделәр, кулга кул тотынышып мөстәкыйльлек өчен көрәштеләр. Ул чорда ачылган гимназияләр, югары уку йортларында, көллиятләрдә күтәрелгән, үз туган телебездә белем алучы яшьләр милләтнең киләчәге буларак кабул ителде. Әдәбият, сәнгать, нәшрият үсешендә, XX гасыр башы казанышлары белән янәшә куярлык, чагыштырырлык уңышларыбыз булмаса да, Тукай, Исхакыйларны үстерә алмасак та, гомуми рухи, әхлакый, милли күтәрелеш һәр өлкәдә үзенең җимешләрен бирде.

Кыскасы, үткән гасырның соңгы унъеллыгында халыкның дәрте, сүнеп бетмәгән пассионарлык көче уянып, кара болытлар арасыннан кинәт килеп чыккан яшен кебек, ялтырап алды. Үзен мөстәкыйль, үзкөчле милләт итеп күтәрүгә омтылыш туган телебезнең аралашу даирәсен киңәйтеп җибәрде. Мәгәр күктән ингәндәй, көтмәгәндә халкыбызны азга гына булса да канатландырып алган хөррият озакка бармады. Аны төрле яклап кысу, буу башланды. Теге яки бу хәреф турында галимнәр уртак тел таба алмадылар дигән сылтау белән, дөресрәге, Мәскәүнең тыюлы кычкыруын көтеп вакыт уздырып, латин әлифбасына — яңалифкә күчә алмау, татар телле гимназияләрнең ябылуы, югары кимәлле белем биреп яткан төрек укытучыларының куылуы, бөтен фәннәрне татар телендә укытып яткан гуманитар институтның юкка чыгарылуы, иң соңгы дәвердә исеме «татар» сүзе белән башланган университетның яшәүдән туктавы, кушылу дигән сылтау белән татар факультетларының бүлек дәрәҗәсенә төшерелүе милли күтәрелеш, янарыш дигән өметләрнең соңгы учакларын сүндерү булды.

Ике гасыр кисешкән чорда төрле дәрәҗәдәге хакимият хуҗаларының да психологиясе үзгәрде, күбесе «аңнарына» килеп, бюджет, нефть, каучук акчаларына бар халыкны бәхетле итеп булмас дип, байлыкны үзләренә, нәсел-нәсәбенә туплый башладылар. Олырак шәһәр түрәләренең (кара алтын чыгару хуҗалары турында әйтеп тә тормыйм), авыл районнары хакимияте башлыкларының да төрле калаларда фатирларга, затлы машиналарга ия булуларын читтән күзәтеп торудан уза алмадык.

Мөстәкыйльлек юлында ирешкән уңышларны югалта баруыбызны, «аның каравы бездә кан коеш булмады», дип үзебезне юатырга тырышабыз. Татар халкы империя чикләрен саклауда үзен җәлләми. Милли интересларны яклап кискен адымнарга баруга татар инде күптәннән сәләтле түгел. Шул ук чечен халкы көрәш аша үзен хөрмәт иттерүгә, үзе тапкан байлыгына үзе хуҗа булуга, тулы мөстәкыйльлеккә ирешмәсә дә, тук тормышка ирешә. Бөтен ил акчасына шәһәрләрен торгызды, авылларын аякка бастырды.

Татарстан җир асты байлыкларына беркадәр үзе хуҗа булган чорда нәфес дигән шайтан коткысына бирелү, тормыштан мөмкин чаклы күбрәк ләззәт алуга омтылу малга, байлыкка төкәнеп калу күпләрне азындырды. Фани дөньяда без кунак кына, типтереп, онытылмаслык итеп яшәп калу фәлсәфәсе илаһият, матурлык, гүзәллек, рухи ихтыяҗлар турында оныттыра. Яшәешебездәге бу үзгәрешләр әдәбиятка, сәнгатькә, гомумән, мәдәниятка мөнәсәбәттә ачык күренә. Таң ата да, кич була, узган көннәр яхшы була дигәндәй, хакимият җитәкчеләре арасында, хәтта совет чорында да, бигрәк тә туксанынчы елларда, язучылар белән очрашуларны милли бәйрәм дәрәҗәсенә күтәргән, язма-басма китапка мөкиббән киткән олы затлар шактый иде. Үзләре иҗат эше белән мавыгучылары да очраштыргалады. Хәзерге район, шәһәр хакимияте башлыклары арасында фәнне, динне, сәнгатьне бертигез дәрәҗәдә якын күргән, милләтнең киләчәге турында ихластан кайгырткан шәхесләр азайганнан азая бара. Һәркемнең булдыклылыгы гына түгел, намусы, рухи дөньясының тирәнлеге дә сынала безнең заманда. Югарыдагылар белән «җирдәгеләр» арасындагы чик ерагайган, берәүләр баеган, икенчеләре хәерчелек базына тәгәрәгән саен җәмгыятьтә мөкамәл әхлак тәртипләре урнашыр дигән хыял, күз алдында сүнә барган йолдыз кебек, караңгылыкка төшеп югала...

XXI гасыр башы, бигрәк тә аның икенче унъеллыгы киеренке халәте, тынгысызлыгы, хәвефләре, буйсынган милләтләргә каршы алып барылган шовинистик махмырга манчылган сәясәт, милли телләрдә укытуны тыйган 309 нчы фәрман, татар бүлегенә керү өчен урыс әдәбиятыннан БДИ бирү

мәжбүрияте кебек милләтләрне ачыктан-ачык күрәлмау, тыю, куркыныч, шөбһәле. Мәче тырнагында сандугач сайрамас дигәндәй, шәһәрләрдә, авыл, район үзәкләрендә татар телле мәгърифәт учаклары ябылу, кечкенә мәктәпләрне зуррак салаларда урнашканнарга кушу, анда укытуның урыс телендә генә алып барылуы буйсынган милләтләрне «телсез» калдыруның сыналган алымы. Әдәбиятыбызга үтеп кергән өметсезлек, чарасызлык милләтебезнең киләчәге, язмышы өчен борчылудан, җан әрнүеннән килә.

Узып киткән чирек гасырда минем биографиямдә, язмышымда шактый үзгәрешләр булды. Дөресе, мин дә шул чорның үз баласы идем. Бер яктан, милләтебезнең яшәеше, үсеше өчен әһәмиятле юнәлешнең — мәгърифәтнең, яңа буын зыялыларын, укымышлыларын әзерләүнең үзәгендә кайнасам, икенче тарафтан, инсульт дигән иң зәһәр, явыз чиргә тарып, бер үлеп, яңадан терелеп, тормышның һәр көнен Аллаһ бүләк иткән бәйрәм дип кабул итүгә килдем. Шул ике — иҗтимагый һәм шәхси — мәүзугълар ята да инде ошбу язмаларның нигезендә.

Нишләп әле яңа истәлекләр, уйланулар китабын да автор «Замана балалары» дип атарга булган. Башка исемнәр беткәнмени кебек сорау туу да ихтимал. Мин бу хакта күп уйландым, әмма башымны «катырган» саен шул ук атамага килеп төртелдем. Бу исем XX — XXI гасырлар кисешкән чорда җәмгыятебез кичергән өермәле вә болганчык, бер күкләргә күтәрелгән яисә караңгылык чоңгылларына кереп баткан елларда яшәгән кешеләрне сурәтләүдә иң төгәл билгеләмә дип саныйм. Нәкъ шул вакытта милләт балаларының аң-белем, милли мәсьәләрне аңлау дәрәҗәсе, сәяси, рухи өлгергәнлеге сыналды. Адәм сөйләр, язмыш көләр дигәндәй, XXI гасыр башында илне пыран-заран китергән 1917 ел инкыйлабы кебек кискен сәяси үзгәрешләр булмагандай тоелса да, Русия кинлекләрендә урнашкан империячел шовинистик юнәлеш милләтләрне кысуда беришә адымнары белән совет хакимиятеннән дә уздырып җибәргәндәй тоела. Мәскәү басымы астында яңадан кол, буйсынган, кушканны үтәүче (өстән күрсәтелгән кешеләрне сайлауда без иң алда), ихтыярсыз милләт дәрәҗәсенә төшә барабыз. Җилнең татар корабын кая алып чыгасын бер Аллаһ кына белә булыр. Ә тарих һәммәсенә битараф, мәгәр безне сынап, һәммәсен теркәп бара.

## Язмыш сынаулары

Адәм баласы үзенең шәхси иреге, эчке мөстәкыйльлеге, фикри бәйсезлеге турында сафсата корырга яратса да, ата коммунист Ленин бабай әйткәнчә, җәмгыятьтә яшәп, аннан өстен калып булмый. Ул бу сүзләрен халыкны үзләре күзаллаган киләчәк төзелешкә буйсындыру нияте белән әйтсә дә, биредә яшәешнең бер кануны чагыла. Акрынлап язмышыбызның тирәлек, мохит, өстен көчләр кулында икәнлеген, арбаның алды кая барса, арты шул якка борыласын аңларга мәҗбүр булабыз.

Шул ук вакытта һәркемнең бәллүр савыт кебек тиз ватылучан, чит куллар тиде исә уалучан эчке дөньясы, үз кабырчыгы бар. Киләчәккә ышаныч, тычкан утыннан төшкән өмет чаткысы, яктылык аның яшәешенә мәгънә нуры сирпи. Бер карауда артык нисби һәм фәлсәфи күренгән бу төшенчәләргә мин үз язмышым аша килдем.

Унбиш ел дәвамында (декан урынбасары, проректор вазыйфаларын үтәүне санасаң — 20 ел) Алабуга педагогия институтында ректор булып эшләгәндә, яшьлегем белән көне-төне булсын дип хезмәт итеп, сүнеп барган уку йортына яшәү көче вә милли рух биреп, өч факультет янына яңадан алтыны өстәп, 848 урынлы тулай торак, укытучылар өчен йорт, ашханәгә

аерым бина салдырып, өлгереш һәм фәнни күрсәткечләр буенча һәр елны диярлек РСФСРның күчмә кызыл байрагын алып яшәгән, баскыч төбендә өр-яңа кара «Волга» машинасы көтеп торган, милиция, ДАИ әһелләренең кулларын фуражкаларына тидереп сәламләп калуына өйрәнгән кеше Казан педагогия институтының студентлар тулай торагының кечтеки генә бер бүлмәсендә читлеккә куып кертелгән җанвар кебек, үзен кая куярга белмичә, ишекле-түрле уфылдап йөрсен әле!

Бу хәлгә «төшүемдә» берәүнең дә гаебе юк. Тик минем кешеләргә ышанып, уйлап житкермичә, ми урынына бүрек белән кинәшеп карар кабул итүем гаепле. Ул чорда өлкә комитеты әһелләре «добро»сыннан башка бер адым да ясалмый иде. Шул ук вакытта алар бер шәйне дә үз өсләренә алмадылар. Сүзне өченче заттан гына алып бардылар. Мин, беркем кумаса да, Алабугадан күчеп китәргә теләгем тууы турында якташым, аралашкан кешем, әйтергә кирәк, әүвәл Чаллыда Алабуга пединститутының филиалын, аннан соң мөстәкыйль уку йортын ачканда ярдәм иткән Рәис Беляев белән киңәшергә булдым. Ул инде ярты елга якын Казанда обком секретаре. Мәгариф, мәгърифәт, бөтен уку йортлары, мәдәният учаклары аның уч төбендә бии. Бераз уйланып торгандай булды да, минем өчен иң кулай күренгән урынны тәкъдим итте.

— Бу арада Тел, әдәбият, тарих институтына директор кирәк булачак, сине шунда тәкъдим итәрмен.

Мин асыл кош тоткандай, ректорлыктан азат итүне сорап, гаризамны күтәреп Мәскәүгә киттем. Мәгәр министрлыктан әйләнеп кайткан вакытка вәзгыять кискен үзгәргән булып чыкты. Бердән, кемнәндер, каяндыр, ниндидер мине «фаш» иткән исемсез, үзен дә берәү дә күрмәгән, тотып карамаган шикаять хат пәйда булган. Икенчедән, Казан пединститутында ректорның абруена китереп бәргән бер вакыйга булган һәм фәннитикшеренү институтында бушаган урын профессор М.З.Зәкиевкә кирәк булып чыккан. Әлбәттә инде, атаклы Казан пединституты ректорын «авыл» югары уку йорты хуҗасы белән янәшә куеп булмый. Рәис Кыям улы мине янәдән тынычландырды.

— Университетның татар журналистика кафедрасына мөдирлеккә доктор, профессор кирәк. Шунда тәкъдим иттем үзеңне. Мин якташларны ташламыйм.

Мин инде Алабугага кайтып, Казан пединститутыннан җибәрелгән доцент Җәмил Нигъмәтовка кабинетны, мәгълүм мәзәктәге шикелле, Ленин портреты артындагы стаканны тапшырып, чантамны аркама асып, янәдән Казанга әйләнеп кайттым. Әфхәт энекәштә тукталып, киттем ак йорт ягына. Ул көнне Р.Беляев гел җыелышлар уздырып, Чаллыдан килгән аркадашлары белән бикләнеп утырып, берәүне дә кабул итмәде. Икенче көнне житәкчебезне машинасыннан төшкәндә үк, обком янында каршыладым.

Үземне тормышның төрле холыклы кешеләрне шактый күзаллаган, күпне күргән шәхес дип санасам да, партаппарат тәрбиясе алган затларның иң авыр мизгелләрдә дә үз-үзләрен тота белүләренә шаклар катам.

— Рәис Кыямович, мин Алабугадан бөтенләйгә киттем. Журналистика кафедрасы буенча кемгә мөрәҗәгать итәсе булыр икән?

Соравымны бирдем дә җавап көтә башладым. Йөзендә бер үзгәреш сизелмәде. Ул, минем якка карамыйча гына, калын пыялалы күзлеген урынына урнаштыргандай итте дә, карлыкканрак, тамак төбендә оешкан төксе тавыш белән:

— Ректор Коновалов ялда, понимаешь. Анардан башка мәсьәләне берәү дә хәл итми. Эшкә кая урнашу ягын үзең кара инде. Мине артык борчып

йөрмә, — дип кистереп әйтте якташым. Аның бу гамәле көнчелектән (мин доктор, профессор, буем да кәтүк түгел), хөсетлектән булдымы, тәки аңышмый калдым.

Мин бөтен өметләремнең таш кыяга килеп бәрелеп чәлпәрәмә килгән дулкындай, уалып юкка чыгуын аңламыйча, өнсез калып торган арада, иптәш Беляев баскычны үтеп, бина эченә кереп бара иде инде.

Һәр адәм баласы гомерендә бер тапкыр булса да, шундый аяныч хәлгә тара торгандыр. Минем ярык тагарак янында калуымның иң гарьлеге шунда иде: мин житәкчебезгә, якташыма ышанып, үзгә барып сыенып урыным турында бөтенләй кайгыртмаган булып чыктым. Урыс юкка гына: «На бога надейся, сам не оплашай», дип әйтми торгандыр.

Кеше язмышы белән уйнау комсомолдан күтәрелгән сүз осталары, халыкча әйтсәк, тел бистәләре арасында эчкерсез самимилек, сүздә тору абруйга саналмый иде күрәсең. Иң бәхетле яшьлек елларым шунда үткән, элек үзен туган авылым шикелле үк якын иткән Казан да ул көнне миңа шыксыз, мәрхәмәтсез булып күренде.

Аякларым, минем белән «кинәшеп» тә тормыйча, Казан педагогия институты урнашкан Болак урамына юл тотты. Тагын кая бара алам, кемгә кирәк соң мин татар шигърияте белгече?

Сонрак фатир мәсьәләсендә араларыбыз вакытлыча бозылып алса да (юл унаенда искәртим: РСФСР мәгариф министрлыгы квартира бәясен тулысы белән үз өстенә алды), электән үк аралашып, дустанә яшәгән пединститут ректоры Рүзәл Йосыпов мине жылы каршы алды, рус һәм көнбатыш әдәбиятлары тарихы кафедрасына профессор итеп тәкъдим итте, тулай торакта бүлмә бирдертте.

Рәис Кыямовичка үпкәләсәм дә, каргамадым, рәнжешемне күнел түреннән чыгармадым, мәгәр Аллаһ бар һәм ул барысын да күреп, күзәтеп, тигезләп тора икән. Чөнки аның үзенә дә гаделсезлек камчысын шактый татырга туры килде. Мифология каһарманын куәт алып торган туган туфрагыннан аерып кына жиңеп булган шикелле, Р.К. Беляевны үсешенә күп көч куйган Яр Чаллы шәһәре, аның партоешмасы яклавыннан мәхрүм итеп кенә «урынына утыртып» булуны ул чордагы обком хужасы Г.И.Усманов яхшы аңлый. «Обком секретаре булам» дип Рәис Кыям улы очынып Казанга килә. Башкаларны төп башына утыртуны гөнаһка санамаган кеше үзе дә тиз алдана, бушлай сырның капкында гына булганын онытып жибәрә. Кызыл авыз комсомол егете белән нәкъ шулай килеп чыкты да: яна вазыйфаларына чын-чынлап керешкәнче үк, аракы тыелган заманда Мәскәүдә эчү мәжлесе оештырган дип, элек үзе белән санашмаган өчен Г.И.Усманов аңа шелтә белдертте һәм жылылыгын әле татып өлгермәгән кәнәфиеннән «төртеп» тә төшерде. Сонрак Гомәр Исмәгыйль улы үзе дә шул ук жимгә килеп капты. Үзәк комитет секретаре урынына кызыгып, Мәскәүгә күчеп, олы түрә булып, Казанга кайтканда юлларны яптыртып, барабаннар кактырып бер-ике тапкыр гына кәперәеп, һаваланып кала алды. КПСС бетте, Г.И.Усманов ярык тагарак янында калды. Монда ул берәүгә дә кирәк түгел иде.

Р.К Беляевның ярты ел эшсез йөргән дәвердә өй балконында бераз салмыш хәлендә төннәр буе уфылдап йөрүе турында ишетеп, берәүләр аны кызганып, икенчеләре шул кирәк азгын түрәгә дип йөрүчеләре дә аз булмады.

Рәис Кыям улының эшкә, сүзгә сәләтен яхшы белгән, үзе колагыннан тартып үстергән, Татарстанның элеккеге хужасы Ф.А.Табеев турылыклы мөридләрен ташламады. Мәскәүдәге абруеннан файдаланып, аны Казанның мәдәният һәм сәнгать институтының ректоры итеп билгеләтүгә

иреште. Яңа урында да Р.К.Беляев, сөйләүләренә караганда, элеккеге таныплыкларыннан файдаланып, шактый эшләр башкарырга өлгерә, әмма кыйналуга, мондый борчуларга өйрәнмәгән нерв күзәнәкләре чыдамый һәм ул тиз арада фани дөньяны ташлап та китә. Чаллы хәтле шәһәрне төзегән, автогигантны күтәргән кешенең шундый аяныч хәлләргә калу ихтималы ике ятып бер төшенә дә кермәгәндер бахырның.

Безнең шәхси кайгы-хәсрәткә тормышның исе дә китми, алга хәрәкәтен дәвам итә. Укытучы халкын яшьләр белән аралашу, сораулары, тәкъдимнәре илә сине, тарлавыкка юлыккан йомычка кебек, бөтереп алулары коткара, киләчәккә өмет нуры кабыза. Мин һәр көнне диярлек Муса Җәлил урамында урнашкан Казан педагогия институтының филология факультетында бар кайгы-хәсрәтемне, борчуларымны онытып дәресләр уздырам. Татарның бит «аягың тәпелдәмәсә — авызың чәпелдәмәс», дигән мәкале нәкъ шул хакта дип уйлыйм. Татар әдәбияты тарихының белгечләре, филология фәннәре докторлары, декан Фоат Галимуллин, аның урынбасары Әмир Мәхмудов миңа бөтен җайлы шартларны тудырырга тырышалар. Лекцияләремне иң якты аудиториягә, үзем теләгән сәгатьләрдә куялар. Мина ихтирамнары шулай булганмы, эчке халәтемне аңлаганнармы, алар миңа иң якын кешеләренә күрсәткән җылы мөнәсәбәттә булдылар. Кафедра мөдире, рус әдәбияты тарихы белгече Ефим Бушканец, үз милләте вәкилләренә хас булганча, «Алабуга тарафларыннан сезнең турыда төрле бәяләр килеп торса да, мин берсенә дә игътибар итмим, иң мөһиме, сез студентлар белән эшли беләсез. Лекцияләрегездә рус һәм татар әдәбияты бәйләнешләрен ачыклап, уртаклыкны һәм аерманы мисаллар белән раслап барасыз» дип үзенә кирәкле фикерне колакка элгәннән соң, боткага май салып җибәрә белүе таң калдыра иде. Көлке көлә килә, чабудан тарта килә дигәннәре шулдыр инде.

Алабугада эшләү чорында ук еш аралашкан Мөхәммәт Мәһдиев, Фәрваз Миңнуллин, партия өлкә комитетының элеккеге инструкторы Ринат Закиров, энекәш, хәзер медицина профессоры Әфхәт, буйдак тормышымны бизәп, эшкә барганда да, кайтканда да сугылып, хәлне белешеп торалар, бик монсуланган көннәремдә өйләренә чәйгә дә алып киткәлиләр. Һәркайсының үз мәшәкатьләре дә баштан ашкан, гаиләләре дә игътибар сорап, хуҗаларының тизрәк өй бусагасын атлап узуын көтеп яшәүләрен дә онытмыйм.

«Тулай торак дәверемдә», хәлне белүчеләр арасында, элеккеге якын таныш-белешләрдән, даими аралашып яшәгән дуслардан тыш, миңа мәрхәмәтлек мөнәсәбәтен күрсәткән затлардан Җәүдәт Дәрзаманны искә алып үтәсем килә. Ишекне шакырга сәбәбен дә таба. Шагыйрьнең балаларга багышлап язган китабына эчке бәяләмә сырлап биргәнмен икән. Ошатып язганымны хәтерлим. Сәләтле каләм ияләрен канатландыра белгән, ул чорда Татарстан китап нәшриятының баш мөхәррире вазифаларын башкарган Фәрваз, күрәсең, минем язмам белән Җәүдәтне таныштыргандыр. Берише шагыйрьләр иҗатына багышлап җитди мәкалә язсаң да, телефон аша булса да, рәхмәт димим, иң гади мөнәсәбәтләрен җиткерергә дә иренәләр (бәлки, мактау азрак тоела торгандыр). Өстәл артында иркенләп утырырга вакыты булмаган, радионың баш мөхәррире ике битлек бәяләмәгә сылтау итеп, эчемлеген, капкалау әйберләрен кыстырып бүлмәнә килеп керсен әле! Аның янгыравык, көр тавышы, башын артка чөеп авыз тутырып көлә белүе, терекөмеш кебек хәрәкәтчән гәүдәсенә тар бүлмәдә чапкынлап йөрергә урын җитмәү сәбәпле, бер шыгырдавык агач урындыктан икенчесенә күчеп утырудан тәм табып, шулай булса да ташып торган җегәрен «авызлыклавы» һаман күз алдында.

Каләм тибрәтүчеләр, дөресрәге, язучылар арасында Җәүдәт кебек өлгер, хәрәкәтчән һәм милләт гаме белән яшәгән кешеләр сирәк. Әле генә үз бүлмәсендә утырган егетне бер сәгатьтән «Мәдәни Җомга» редакциясендә, бераздан китап кибетендә очрата, иртәнге сәгатьтә телетапшыруда күрә аласың! Берничә Җәүдәт диярсең. Әллә аны чәчкәннәрме, күпләп «чыгарып» таратканнармы дип тә уйлап куясың. «Ут егет» дип әйтәләр андый тумыштан елгыр егетләр турында. Әгәр ул чорда шундый егетнең бер-ике елдан соң авыр чиргә тарып, сыгылып төшеп, ике көпчәкле арбада калуын фаразлаган кешегә, кулына Корьән тотып ант итсә дә ышанмаган булыр идем.

Дәрзаман минем «куышка» килеп кергән мизгелдә Рөстәм Мингалимнең «Юл өстендә тургай» поэмасын тикшереп утырмыш идем.

Әйе, бездә Сәйдәшләр бар,
Бездә Мулланурлар бар.
Аксакаллар булган икән,
Алмаш булырга тиеш.
Без ничек язмыйк ди икән,
Кол Гали булган килеш.

Бу юлларны кунагыма да укып күрсәттем. Җәүдәтнең аналитик журналист мие бер шәйне дә урага кабул итмәгән шикелле, мина камил күренгән юлларда да ышандырып җитмәгән, җөе сүтелеберәк торган урынны тапты.

— Рөстәм абый хисен акылына буйсындыра белгән зур шагыйрь. Сәйдәш янына Мулланурны утыртып куюны мин үзем кабул итә алмыйм. Татар большевигын ижек санын тигезләү өчен генә керткән дисәк, Мингалимне рәнҗетү булмасмы икән?

Мин һәр олы шәхеснең иҗтимагый үсештә үз урыны булуы, безнең әле Вахитовны бәяләп җиткермәвебез, аның буйсынган халыклар мәнфәгатьләрен яклаган өчен үз фикердәшләре үк юкка чыгару ихтималы турында озын-озак нотык тотарга җыенган идем, Дәрзаманнан инде җилләр искән иде. Аның суган кабыгын чәйнәп утырырга вакыты юк. Янәдән ишекне ачып, «Тәлгат абый, теге атналарда шул вакытларда сугылырмын», дип, гаип булды егетем. Әлбәттә, вәгъдәсендә торды.

Ходай Тәгаләбез әле генә мин яратып телгә алган ике дустыма да авыр сынаулар, «инсульт» дигән зәхмәтне җибәрде. Инде күптәннән, элеккеге шикелле, кара-каршы утырып, сулышыбызны тоеп, гәпләшеп утыра алмыйбыз. Ярый әле эшләгән эшләр, кәгазьгә теркәлгән әсәрләр, юаныч табарлык хатирәләр бар икән.

### Тәкъдим

Кешелек язмышы турында борчылып «яшәгән» әдәби образлар дөньясында үземә юаныч табып, буйдак тормыш талгынлыгында хозурланып яткан бер мәлдә, дөресрәге, 1988 елның язында КДУның укыту эшләре буенча проректоры Миркасыйм Госманов әүвәл мине телефоннан эзләп тапты, ике көннән соң машинасын җибәреп, үз янына алдырды. Бу — мине гафләт йокысыннан уятып, бөтен язмышымны үзгәртеп җибәргән вакыйга булды.

Үзең шунда укыган, бер ел булса да мөгаллимлек иткән дәрелфөнүнең белән күрешү ин бәхетле, болытсыз яшьлек елларынны искә төшереп, дулкынландыра, кальбеңне леп-леп китереп сикертеп куя икән. Адәм баласына уйлану, карар кабул итү өчен баш бирелгән. Шунын ярдәменә мөрәҗәгать итсәм дә, ректор урынбасарының ни өчен мине чакыртканын

жиденче тоемым белән сизенгәндәй булсам да, тәгаен күз алдына китерә алмадым. Баш мием дә, үзләрендә укытырга чакырырга уйлый торгандыр дигән фараздан артыгын «әйтә» алмады. Миркасыйм Габделәхәт улы белән очрашкалаган булсак та, якын танышлыгыбыз белән мактана алырлык, бигрәк тә кочаклашып күрешерлек мөхлислегебез юк иде.

Аның артык кырыс, кискен булып кыйланырга, чыгышлары вакытында күп мәгънәле тукталышлар ясап, кул чапканны көтәргә яратканын белә идем. Кыскасы, үзен, сүзен хөрмәт иттерә белә торган шәхес янына җыендым.

Ул мине беренче катта урнашкан бүлмәсеннән, сәркатибе янына ук чыгып, каршы алды. Кулын биргәнче, кулбашын тотып торган сеңерен, үзе белгән хәрәкәтләр ясап йомшарткач кына күрешеп, бүлмәсенә алып керде. Урын тәкъдим итте. Әүвәл гап-гади, таныш сүзләр алыштык.

— Хәлләр ничек?

— Ярыйсы!

— Казанның төтенле һавасына күнегеп буламы?

— Кая барасың инде, язмыш, — дигән булам.

— Ярый, тәк, аргы урамнардан әйләнеп, озаклап ләчтит сатып утырырга вакытым юк, унбердә ректорат. Сина белем биргән татар теле һәм әдәбияты бүлеген факультет дәрәҗәсенә күтәрү хыялыбыз бар. Анда татар теленә, мәдәниятебезгә, динебезгә якынрак башка белгечлекләрне дә ачып җибәрә алырбыз дип торабыз. Яңа юнәлешне оештыру өчен әһелле, фәһемле, булдыклы кешеләр кирәк булачак. Декан сайлаганда синең дә кул астында булуың лазем. Кандидатураң тукталсак, административ эштә тәҗрибәле булуың, житәкче даирәләрне белүең дә исәпкә алыныр. Хәзер озакка сузмыйча, безнең рус әдәбияты кафедрасына күч, мин аларга өстәмә бер профессор урыны бирдем... Синең өчен...

Ачылачак факультетның нинди белгечлекләргә өстенлек бирәчәге, кайсы галимнәргә йөз тотуы, кемнәрне читтән чакыру ихтималы турында сөйләп утырды да, ашыгырга тиешлеге турында исенә төшерепме, үзенең кем икәнлеген ассызыклап үтү өченме, пед. профессоры белән ваклашып, алтынга тиң вакытын сарыф итеп утыруы күңелен тырнап уздымы, кинәт һаваланып, ата күркәдәй кабарынып алды.

Булачак академикка түрәлек килешеп тора. Әйтерсең лә, ул җитәкчелек итү, киңәш бирү, үгет-нәсихәт нурын иңдерү һәм әңгәмәдәше белән ике арадагы аерманы сиздерү өчен туганда ук тамгаланып дөньяга килгән.

— Егетем, тәк, монда сөйләшкәннәрне беркая да ычкындырма, хәтта хатының да белми торсын. Алдан кычкырган күкенең башы авырта дигән мәкальне ишеткәнең бардыр. Син бит иҗат юлыңны фольклорчы буларак башлаган идең. Кыскасы — Алабугада яраган барин замашкаларыңнан арынырга туры килер.

«Замашка» дигәнен, киемгә ябышкан кырмавык кына түгел, аны тиз генә ташлап булмас дип, «этләшергә» исәп бар иде дә, өлгерә алмый калдым, ул ректоратка ашыкты. Кирәксә-кирәкмәсә дә үткәнем белән төрттерүне бер дә кальбем күтәрми шул. Миркасыйм әфәнде артык җитди булырга тырышса да, сүзләрендә әрем әчесен сизмәдем.

Шул көнне үк мине Казан дәүләт университетына күчерүне сорап гаризамны яздым һәм тиз арада рус һәм көнбатыш әдәбиятлары кафедрасында пәйда булдым. Мөдиребез Валерий Коновалов дигән бик ипле, итагатьле, зыялы кеше булып чыкты. Кафедра әгъзалары белән уртак тел тапсам да, минем монда күчүне карьераларына куркыныч тудыруга юрап, миңа кырын карап йөрүчеләр дә табылды. Хикмәт шунда булып чыкты: яңа оешкан рус филологиясе факультетында агымдагы елдан

милли мәктәпләрдә рус телен һәм әдәбиятын укыту (РЯНШ — русский язык в национальной школе) кафедрасы ачыла икән дә, мөдир итеп Т.Н.Галиуллинны куярга җыеналар, дигән әйбәт гайбәт таратылган булып чыкты. Сарафан радиосы аша ингән хәбәр аркасында берничә профессор белән «анлашырга» туры килде. Гаепсездән гаепле дигәннәре шулдыр инде. Бөдрә чәчле, җегәре ташып торган галим мине коридорда туктатып, үзен администрация эшчәнлеген тикшерү өчен оештырылган комитет әгъзасы, җаваплы вәкиле дип тәкъдим итеп, бу урынга кызыкмаска, минә караганда да лаеклыракларның булу ихтималын киртләп куйды, икенче профессор ханым яңа фәнни берәмлектә эшләргә тәгаенләнгән укытучыларның катлаулы, каршылыклы булулары, кафедраның гайбәтчеләр оясына әйләнәчәге турында хисләнеп бәян итте. Икесенең дә (соңрак аларга өченчесе өстәлде) нияте «изге» икәнен аңламыйчарак торганмын мин гидай. Ясаган нәтиҗәләре бер-берсен кабатлаган су тамчылары кебек охшаш булып чыкты.

— Бу хакта сезне ихтирам, галим һәм кеше буларак хөрмәт иткән өчен генә кисәтәбез. Яхшылык теләп кенә.

Аларның изге нияте белән килешкән, рәхмәтле булган хәлдә дә, үзләренең ни өчен шул кырмыска оясына тыгылырга атлыгып торулары гына аңлашылмый калды.

Проректорның КДУга күчерүләренең асылын җиде йозак астында тотарга кирәклеген кисәтүе сәбәпле, тирәнгә кереп тормыйча гына:

— Мин ул кафедрага күчәргә җыенмыйм, андый тәкъдим дә булмады, минә монда да әйбәт, — дип хәлдин килгәнчә, хыялый бәндәләрне, алла колларын тынычландырырга тырыштым. Соңыннан мин аларны кызганып та куйдым, ник дисәгез, җил тегермәне белән сугышып йөргән Дон Кихот кебек, минем белән араларын ачыклап, булышып, көчләрен сарыф итеп йөргән дәгъвачыларның берсе дә «завкаф» була алмады, мөдир итеп, соңрак факультет деканы итеп тә сайлап куелачак Ямиль Сафиуллинны (үзенә һәр шәй килешә торган акыл иясе Индус Таһиров беренче тартык авазга басым ясап, аңа Җәмил дип кенә эндәшә) куйдылар.

Тарих-филология факультетын өчкә бүлү һәм бигрәк тә татар бүлегенең статусын күтәрү буенча шактый катлаулы сөйләшүләр әүвәл ректорат утырышында, икенче көнне үк гыйльми советта каралды.

Ул елларда Казан дәүләт университеты ректоры вазифаларын күренекле химик А.И.Коновалов үти иде, көн тәртибенең мөһимлеген искә алып булса кирәк, утырышны үзе уздырды. Тәкъдим ясау өчен сүзне проректор Миркасыйм Госмановка бирде.

— Җәмгыятебездә барган үзгәртеп кору күренеше, татар теле һәм әдәбияты белгечләренә ихтыяҗ арту тарих-филология факультеты составындагы татар бүлегенең дәрәҗәсен үстерүне таләп итә. Яңа оештырылган берәмлекне «татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләре факультеты» дип атарга тәкъдим итәм. Алабуга педагогия институтының элеккеге ректоры, хәзер университет профессоры Т.Н.Галиуллинны яңа факультетка декан итеп тәгаенләп, бөтен оештыру мәшәкатьләрен аңа тапшырсак, ышанычыбызны аклар дип уйлыйм.

Факультетның белгечлекләре, төзелеше турында бәхәсләр куерып алуы табигый, һәркемнең үз кызыксынуы, күзаллавы, теләге өскә калкып чыкты. Җөмләдән: шул исемдәге факультет була торып, тарих бүлеге ачу кирәкме икән; чит телләрдән кайсыларына өстенлек бирергә, кебек сорауларның калкып чыгуы да аңлашыла. Мең ел дәвамында гарәп әлифбасына таянып иҗат ителгән бөек мирасыбызның эчтәлеген, сәнгати көчен, ислам мифологиясенең йогынтысын өйрәнү ихтыяҗы гарәп, фарсы

һәм төрек телләрен, һич югында терминнарын белүне сорый. Шулар янына Миркасыйм кытай лөгатен кертүне бу илнен зур киләчәге, төрки халыкларының борынгы заманнардан ук алар белән янәшә яшәүләре, анда хәзер дә татарларның шактый булуы белән исбатлады. Бу белгечлекне ачуны тәкъдим итүенен иң тирән катламында проректорнын Кытайда туып, яшьлеге шул тарафларда узган татар кавеменнән икәненә сылтау ясалмаса да, «козырь тузынын» шунда икәнен һәм анын кендек каны тамган жиргә рәхмәте дип аңлап, елмаеп һәм аны хуплап утырдык. Әйтергә кирәк, бу юнәлешне ул алдагы елларда да ярдәменнән ташламады: бер гаиләне Кытайдан чакыртып китереп, аларны урнаштырып, министрлар кабинетына чыгып, кибетләрдә ул чорда булмаган милли ризыклары — бер капчык дөге табып бирүе хәзерге муллык заманында елмаю уятса да, ул чорда чын-чынлап егетлек иде.

Шулай ук яна оешкан тарих факультетының деканы, күренекле тарихчы Индус Таһиров үзләренә көндәш бүлек оештыруны бер кәррә дә хупламады.

— Бездә электән яшәп килгән татар тарихы белгечлеген кинәйтү күздә тотыла, шуна күрә яна факультетта тарих юнәлешен ачу ихтыяжы бармы икән, татфак беренче чиратта татар телен, әдәбиятын, тугандаш телләрне яхшы белгән, милли жанлы, ижади фикерле укытучылар, зыялылар әзерләүгә йөз тотарга тиеш дип саныйм.

Үз ниятен тормышка ашыруда, бәхәстә М.Госманов белән ярыша алырдый кеше сирәк дип беләм. Әле бит проректор кәнәфие дә анын терәге, яклаучысы, хуплаучысы.

— Берише иптәшләр, — дип башлады сүзен Миркасыйм, исемне атамыйча төрттерүдә кытай сәясәтчеләре осталыгына барып тоташкан алымны кулланып, — татфакта тарих бүлеген ачунын тирән мәгънәсен анлап житмичә, тар амбицияләрен алга сөрәләр. Шуларга өстәп — анлатма бирәм. Беренчедән, ошбу бүлеккә татар мәктәпләрен тәмамлаган яшьләрне, күбрәк егетләрне туплап, татар тарихын тирәнтен анлаган белгечләр әзерләү күздә тотыла. Икенчедән, Ш.Мәржани, Х.Фәезханов, Р.Фәхретдин, И.Гаспралы, Г.Гобәйдуллин кебек бөек тарихчыларыбызнын, дин вә мәгърифәт йолдызларыбызнын күпчелек хезмәтләре гарәп-фарсы яисә борынгы төрки-татар телендә, шул халыкларнын чыганакларына таянып язылганнар. Бөек шәхесләребезнең мирасын өйрәнү, фәнни әйләнешкә кертү өчен киң эрудицияле белгечләр әзерләү кирәк. Шунысын да искәртәсе килә: борынгы татар әдәбияты тарихчылар өчен дә әлегәчә тиешенчә бәяләнмәгән һәм әйләнешкә кертелмәгән чыганак. Татар факультетында ачылачак бүлек сезне кабатламаячак.

Ике мөхтәрәм тарихчынын тар басмада очрашкан ике тәкәдәй чәкәләшүенен нигезендә Миркасыймнын проректор вазыйфасы вакытлыча булуын анлап, үзенә чигенү юлын әзерләп куюын без сонрак кына анладык. КДУга яна ректор сайлауда Ю.Г.Коноплев белән бергә бушаган урынга дәгъвада ярты ел ректор вазифаларын башкарган М.Госманов та катнашты. Мәгәр 90нчы еллар башында, татар мәнфәгатьләренә ташламалар ясалгаласа да, төп хужаны сайлап куюда патша заманыннан килеп, совет чорында тагын да көчәйгән шовинистик сөремнән дәрт алган империячел рух көчле иде әле. Мин инде факультет деканы буларак, татар вәкилен, Миркасыйм Госмановны яклап чыгыш та ясадым, әмма тышкы дөнья белән мөнәсәбәтләр проректоры Ю.Г.Коноплев жинеп чыкты. Моннан фажига ясамыйча, Миркасыйм Гәбделәхәт улы үзе ачкан бүлеккә кафедра мөдире булып шыпырт кына күчеп утырды, Татарстан Фәннәр академиясенең президенты кинәшчесе булып раслангач, үз урынына турылыклы шәкерте

Искәндәр Гыйлаҗевны куеп калдырды. Аның өчен иң мөһиме И.Р.Таһиров кулы астына килеп кермәү, аңа баш бирмәү иде.

Татар факультеты язмышына багышланган утырышта яңа кафедра оештыру, аның исемен һәм мөдирен раслау мәсьәләсе дә каралды. Яңа ачкан берәмлек 1917 елдан соңгы әдәбиятны һәм гомумән тел белән әдәбиятны укыту методикасын үзәккә алырга, мәктәпләр белән араны ныгытырга, аларга ярдәмне төп бурычы итеп санарга тиеш иде. Аны «Татар телен һәм әдәбиятын укыту методикасы» кафедрасы дип атарга килештек. Бу гомуми исем аңа башка кафедраларга кермәгән барлык фәннәрне үз эченә алырга мөмкинлек бирде һәм ул, атаклы Казан дәүләт университеты исемен алыштырганчы, совет чорындагыча әйтсәк, үз вазифаларын намус белән үтәп килде.

Мөдир мәсьәләсен Миркасыйм катлауландырып җибәрде.

— Мин яңа кафедра җитәкчесе итеп, элеккеге татар әдәбияты тарихы мөдире булып эшләгән Альберт Яхинны тәкъдим итәм. Бу кафедрага мәктәпләрдә студентларның педагогик практикасын оештыру, аларны укытучылык эшенең нигезләренә төшендерү максатлары йөкләнәчәк. Ә А.Яхин татар әдәбиятын укытуның үрнәк программасын эшләгән шәхес, дәреслекләр авторы. Мөстәкыйль фикерле. Яңа кафедрага мөдирлеккә анардан да кулайрак кеше юктыр дип уйлыйм.

Фикеренең кабул ителүенә үзе дә ышанып бетмәгәнгә дип уйлыйм, озаграк сөйләп ташлавыннан арып, лып итеп урындыкка утырып, терсәкләрен ялтыравык өстәлгә терәп куеп, сынаулы карашын безнең тарафларга юнәлтеп, нәтиҗәне, тәкъдименә мөнәсәбәтне көтә башлады.

Күбебез проректор хыялының асылында методика турында кайгыртудан бигрәк, шәхси мөнәсәбәт ятканны, бакчалары бер төбәктә булып, икесенең дә зәһәр балыкчы булулары ятканны аңладык. Балыкчы кулын балыкчыдан башка кем юсын инде. М.Госманов белән А.Яхинның «һөнәри» дуслыкларыннан хәбәрдар булганнар да, табигый ки, кадрлар өчен җаваплы кешенең тәкъдимен якларга ашыкмаган шикелле, каршы чыгарга да җөрьәт итмәделәр. С.Хәкимнең Муса Җәлил турында аны бөтенләй белмәгән кешеләрнең ярсып-ярсып шигырьләр язуына борчылып әйткән, «белгәннәр тик тора, белмәгәннәр сөйли күбрәк», — дигән юллары искә төште.

Югары уку йортлары системасында күп еллар эшләгән кеше буларак, укыту һәм фәнни эшләрне күз уңында тоту өчен деканның үз кафедрасы булуы бик мөһим икәнлекне тәгаен белә идем.

Әлбәттә, химик-ректор су асты агымнарыннан хәбәрдар түгел иде. Аксыл чәче дулкынланып торган бөдрәлеген югалтмаган, җыйнак гәүдәле ректор, күзлеген төзәтте дә, пырдымсызлануын яшереп торуны кирәк тапмыйча:

— Мәсьәләне сузмыйк. Ягез, нindирәк тәкъдимнәр булыр? Миркасыйм Габделәхәтович кандидатурасына ничегерәк карыйсыз?

Ректорның бимазаланып чакыруына да сикереп төшү булмады. Озакка сузылган тынлыкны мин бозарга тиеш идем. Ләкин ничек? Ни рәвешле? Беткән баш беткән, минем турында теләсә ничек уйласыннар дип, ва-банк барырга булдым.

—Мөмкинме?

Александр Иванович баш кагуы белән генә рөхсәт бирде. Мин җәелеп, тирәнгә кереп, аңлатып тормыйча гына:

— Факультетта үзем җитәкләгән кафедра булмаса, мин деканлыктан баш тартам һәм хәзерге эш урынымда калдыруыгызны сорыйм, — дип урыныма утырдым һәм Миркасыйм кебек үк, фикеремә мөнәсәбәтне көтә башладым.

Проректорның үз кешесен төртеп, «азынуына» кара янып утырган Индус Ризак улы минем карашны гына көткән. Бәлки, мин үзем яна кафедраны оештыруны өстемә алырга теләми торганмындыр. Көчләп өйләндерү килеп чыкмасмы, дип уйлаган икән ул.

— Профессор Галиуллин мәсьәләне дөрес куя, деканның үз кафедрасы булырга тиеш. Нигезсез йорт бик тиз ишелә. Тәлгат Нәбиевич барыннан да элек фән кешесе. Фәндә юнәлеш кафедрада билгеләнә.

Аның артыннан сүз алган Ямиль Сафиуллин, Флорид Әгъзамовлар А.Яхинның кафедра мөдире булып эшләгәндә хезмәттәшләре белән уртак тел таба, табигый мөнәсәбәтләр тудыра алмавын искә төшереп, аның кандидатурасын кире кактылар. Кайсыдыр безнең заманда кафедра мөдире, доктор булырга тиеш, А.Яхинның фәннәр кандидаты гына булуына басым ясады.

Ректоратны алып баручы А.Коноваловның методика кафедрасының мөдире кем булуы теш авыртуы кебек үк борчымаса да, М.Госмановның тәкъдименә сикереп төшмәве сизелеп торды: урынбасарларның чабуыннан тарткалап, кемнең хужа икәнлеген исләренә төшереп тормасаң, азына башлыйлар. Шуңа күрә дип уйлыйм, ул бәхәскә кызып китәргә ирек бирмичә, нокта куйды. Миркасыйм әфәнде дә, ялгызлыкта калуын аңлап, тәкъдимен кабатламады. Болганчык суда балык тотуның азагын аңлады бугай.

— Яңа факультетның деканы һәм кафедра мөдире итеп профессор Галиуллинны тәкъдим итәбез. Иртәгә мәсьәләне зур советка чыгарабыз, — дип, ректор утырышны ябып та куйды.

Гыйльми советка татар бүлегендә эшләгән барлык укытучыларны да чакырганнар иде. Минем кандидатураны советта яшерен тавыш белән сайлау исемлегенә кертүне вазифасы буенча проректор М.Госманов тәкъдим итте. Тарих факультеты деканы И.Р.Таһиров минем биографиямә, фәнни эшчәнлегемә тулы бәя бирде. Башкалар да минем кандидатураны хупладылар. Бал мичкәсенә бер кашык дегет тамызып доцент Хатыйп Миңнегулов арабызга озак елларга кара мәче җибәрде.

— Без Тәлгат Галиуллинны бөтенләй диярлек белмибез. Ул да безнең коллектив белән якыннан таныш түгел. Мин яңа факультетның деканы итеп Азат Әхмәдуллинны тәкъдим итәм. Тәҗрибәле, зур галим. Озак еллар дәвамында тел, әдәбият һәм тарих институтында гыйльми сәркатип, директор урынбасары вазыйфаларын башкарган, университетта эшләү дәверендә үзен гел уңай яктан күрсәтте. Безгә ул кулайрак булыр дип уйлыйм.

Шуннан соң, А.Әхмәдуллин сүз сорап, рәхмәт әйтте, үз кандидатурасын сайлауга чыгармауны үтенде һәм ректорат тәкъдим иткән Т.Н.Галиуллинны яклавын әйтте.

Мин әүвәл Миңнегуловның «Без аны бөтенләй диярлек белмибез» дигәненнән өнсез калып (тормыш юлым белән бик тәфсилләп таныштырдылыр), моны ничегерәк аңларга дип утырган идем, сонрак, Язучылар берлеге чыгарган белешмәдән дустымның биографиясе белән, Таҗикстанны айкап чыгуы, колхозда партоешма секретаре, ел ярым райкомның мәгариф кабинеты мөдире вазифаларын башкаруы белән танышкач, аның шулай инициативалы, әрсез булуының серен аңладым шикелле. Ул яшьлегендә гелән фирка исеменнән сөйли, һәр шәйне шик астына ала торган оешмаларны бизәгән икән. Күпме генә әрләсәк тә, Коммунистлар партиясе үзенә турылыклы, Ленин бабай сызган юлдан тайпылмыйча баручы мөридләрен тәрбияли белде. Телефоннан яисә турыдан-туры сүз алып барганда да, райком сәркатипләре, бүлек мөдирләре,

үз намьнәреннән сөйләшсә, түбәнрәк торганнары гәпне бары тик фирка, аның оешмасы исеменнән алып бардылар.

Миңнегулов Х.Ю. белән мөнәсәбәтләргә килгәндә, зыялы кешеләр буларак, аралашып, телебез, халкыбыз язмышы турында кайгыртып, бер-беребезнең фәнни адымнарын хуплашып яшәсәк тә, алдагы елларда да декан сайлау кебек олы мәсьәләләрне хәл иткәндә, аның миңа каршы килеп, дуга белән печән чапкан очраклары булгалады. Инде гомер кояшыбыз урман артына төшеп барганда үпкәләшеп, рәнҗешеп утыру җитди булмас иде.

Гыйльми советта мин бертавыштан декан итеп сайландым, икенче уку бинасының унберенче катында, кем әйтмешли, җиң сызганып эшкә керештем һәм унбер ел (1989-2000) дәвамында вазифаларымны хәлдин килгәнчә тырышып, яратып башкардым. Чишеләсе мәсьәләләр күп иде, һәм берсе өстенә берсе өелә генә торды.

Элеккеге уртак тарих-филология факультетының берничәгә аерылып чыгуы һәркайсыбызның юрганны үз ягына тартуына алып килде, аудиторияләрне бүлешү шактый четерекле, җитәкчеләрнең шәхси мөнәсәбәтләренә дә кагылышлы булып чыкты.

Кайсы кафедраның нинди бүлмәдә утыруы, укытучыларның яңа оешкан гыйльми берәмлекләрнең кайсына килү-килмәве, деканат эшен тәртипкә салу, урынбасарларны сайлап алу, талибларны тулай торакка урнаштыру, стипендия билгеләү һ.б. шундый тавык чүпләп бетерә алмаслык, вак-төяк күренгән, әмма шулардан башка яшәүне күз алдына да китерә алмаган мәсьәләләр берсе өстенә икенчесе өстәлә барды. Деканатны факультетның йөрәге диләр. Ул туктаусыз эшләп торсын өчен анда тәҗрибәле, студентларны үз балалары, туганнары кебек яраткан, аларның мәнфәгате белән яшәгән кешеләр утырырга тиеш. Деканат факультет тормышы, фәнни юнәлешләре белән җитәкчелек иткән штабны хәтерләтә. Аннан бер мизгелгә дә кеше өзелеп тормый: эш сәгатьләрен белешергә кергән укытучыны стипендиядән төшеп калган яисә икеле алган студент алыштыра, баласын читтән торып уку бүлегеннән көндезгегә күчерүне сорап ата-ана, бәрәңге, чөгендер җыярга фәлән төркемне сорап колхоз рәисе килеп керә һ.б. Деканның абруе унышлы сайлап алынган урынбасарлардан да тора. Уку-укыту эшләре буенча урынбасарлыкка XX гасыр башы әдәбияты белгече Таһир Гыйләҗевны тәкъдим иттем. Аны деканатның баштан ашкан эшләрен яратып башкару өчен генә дөньяда яши диярсең! Гадел кырыслыгы, һәр студентны диярлек танып-белүе, үзенең фәнни эше исәбенә булса да, вакытын кызганмавы Таһирны бөтен университет күләмендә абруйлы администратор итеп танытты. Фән һәм читтән торып укучылар белән эшләүгә кыска вакытка гына, XX гасыр башы хатын-кызлар хәрәкәтен өйрәнүгә тормышын багышлаган Альта Мәхмүтова риза булды. Деканатта үз кешесе — тарихчы булуны проректор М.Г.Госманов бик теләде. Альта Хаҗи кызы бер кеше кубызына да биеми, тәлинкә тотуны түбәнлек саный торган гаҗәп горур ханым булып чыкты. Аны телара сүзлекләр белгече, галимә буларак танылa килгән Әлфия Йосыпова алыштырды, деканатка эшкә алынган яшь кызлар, хәтта күпмедер күләмдә минем урынбасарлар белән «җитәкчелек» итү өчен тәҗрибәле, өлкәнрәк кеше кирәк иде. Андый белгеч тә табылды. Ул — деканатның оештыру үзәге — Нурия Мөхәммәтшина булды. Рус, татар телләрен камил белүе, журналистлык һәм кешеләр белән эшләү тәҗрибәсе аны бәяләп бетергесез кирәкле кешегә әйләндерде. «Казанский университет» (2010, февраль) газетасында басылган «Любовь моя — татфак» мәкаләсендә ул факультетның аякка басу авырлыклары, минем

декан буларак эшчәнлегем турында шактый тәфсилле яза. «Секретари и лаборанты печатали документы на диковинных, тяжёлых как трактор, и таких же шумных пишущих машинках... Однако Талгат Набиевич, благодаря своим организаторским способностям и умению убеждать, находил каких-то спонсоров, и наша жизнь значительно облегчилась. У нас появились более совершенные «Оптима», два компьютера, два принтера, два стационарных копировальных аппарата и много офисной бумаги высокого качества. Помню, соседние факультеты нам очень завидовали».

Шул ук мәкаләсендә Нурия Мәгъсум кызы 1994 елда факультетның юбилеена (татар бүлеге 1944 елда ачыла), башка бик күп бүләкләр өстенә, ике квартира бирелүне искә ала. Аның артыннан күпме чапканымны үзем генә беләм. Министрлар кабинетының кагылмаган, борчымаган, таләп итмәгән бер бүлмәсе калмагандыр. Факультетка эләккән фатирларның ике бүлмәлесен, ике яшь бала атасы, тел галиме, Сөнгатов Гафурга бирдек, бер бүлмәлесе ул чорда әле буйдак доцент Гыйлаҗев Таһирга эләкте. Татар бүлеге һәм факультеты юбилеен бөтен җөмһүриятебез олы милли бәйрәм итеп уздырды.

Факультет мәшәкатьләре белән бер рәттән мин яна оешкан методика кафедрасы алдында торган бурычларны да онытa алмадым. Бу берәмлек алдына телне, әдәбиятны, аларны укыту методикасын яхшы белгән, мәктәптә эшләү тәҗрибәсе булган, үз фәненең абруйлы белгечләрен җәлеп итү бурычы көн тәртибенә куелды. Укыту методикасын элек житди фәнгә санамыйча, кемнең еллык сәгате тулмый — шуңа йөкләгәннәр. Бу предметны теләсә кем укыта ала дигән карашны җиңәргә кирәк иде. Тел методикасын, шивәләрне өйрәнү-өйрәтү ягын күп еллар Алабуга пединститутында чит телләр факультеты деканы, Казанда милли мәктәпләр фәнни институты директоры вазифаларын уңышлы башкарган профессор Фәрит Йосыпов алып китсә, әдәбият канатын лирик шигырьләрне мәктәптә укыту методикасы буенча кандидатлык диссертациясе яклаган, минем шәкертем, хәзер академик Дания Заһидуллина житәкләде.

Үрнәк программа авторы, методист А.Яхин фәнни эзләнүләренең рухы, юнәлеше белән яңа кафедрада үз урынын табып, лаеклы ялга чыкканчы, үзе теләгәнчә дәреслекләр, ярдәмлекләр язу белән шөгыльләнеп, мәктәпләрдә тәҗрибәләр үткәреп яшәде.

Кафедраны белгечләр белән тәэмин итүдә гыйбрәтле, кызыклы хәлләр, хәтта менталитетыбызга килеп орынган аңлашылмаучанлыклар да туа торды. Ул чор хәлләре турында уйланганда (вакыт узгач барыбыз да акыллы), күренекле тел галиме, күңелдә гаҗәеп нурлы, якты булып сакланган Латыйф ага Җәләйнең «синең татарың» дигән яраткан гыйбарәсе искә төште. Университетта укытуының соңгы елларында ул безнең сыйныфка тарихи грамматика белән диалектология курсларын укыды. Ул һәр дәресен «синең татарың» дип башлап китә торгание. Сүз теге яки бу сүзнең, хәрефнең мишәрләрдә болайрак, Минзәлә татарларында тегеләйрәк әйтелеше турында гына барырга мөмкин. Нәтиҗә киңрәк ясала: «синең татарың» үзара уртак тел, уртак әйтелеш таба алмыйча, кирәге булмаганда да интрига ясап, чүптән чүмәлә өеп куярга маһир. Томшык төпләрендә юеше кипмәгән студентлар ул чорда әле профессорның тирән, хәтта сәяси мәгънәгә ия төрттерүен, кинаясен берьяклы гына аңлаганбыз икән.

Яңа оешып килгән методика кафедрасы тирәсендә тудырылган ясалма матавыклар Латыйф аганың «синең татарың» сүз тезмәсен искә төшерде. Хикмәт шунда иде, бериш галимнәр ошбу кафедраны, аның «килмешәк» мөдирен кабул итмәү нәтиҗәсендәме, башка сәбәп беләнме бер-берсен

безгә күчмәскә үгетләү юлына бастылар. Яна фәнни берәмлек тирәсендәге ыгы-зыгыны, үзе дә бәя биреп бетермичәрәк дип уйлыйм, галимә Флера Сафиуллина куертты. Сәер елмаеп, тулы чәлтерләрен ялтыратып, безнең бүлмә кырыннан узып киткәнен күрсәм дә, мин моңа игътибар итмәдем. Кеше кая бармас та, кайларда йөрмәс, шуңа гына булса да аның хокукы бардыр ич! Соңрак билгеле булганча, матур апабызның бу кафедрага, ягъни мәсәлән Галиуллин белән эшләргә күчәргәме, әллә ашыкмаскамы дип икеләнеп, андагы «һава торышын» өйрәнеп йөрүе булган икән. Югары уку йортында кафедра гаять зур әһәмияткә ия, ул чынлыкта кешенең икенче гаиләсе. Фәнни эшләрне тикшерү, нәтиҗә ясау, студентларга бәя бирү, бәйрәмнәрне, туган көннәрне билгеләп үтү һәммәсе дә кафедрада була. Анда урнашкан дусларча мөнәсәбәт унышның яртысын хәл итә. Бер-ике елдан соң үзе дә «чит аудиториядә татар теле» кафедрасы мөдире булачак ханымның үзе генә читтә, битараф ялгызлыкта каласы килми, ул синтаксис һәм стилистика буенча гаҗәеп зур белгеч Сәгадәт абый Ибраһимовны методика кафедрасына күчмәскә үгетли. Бер почмакта булган үзара түбәндәге сөйләшүне «синең татарың» миңа шул көнне үк түкми-чәчми китереп җиткерде.

— Сәгадәт Мөгаллимович, — ди Флера ханым килешле елмаеп, — әйдәгез, Галиуллинга бойкот ясыйбыз, кафедрасына күчмибез. Мин дә баш тартам. Син дә барма, яме. Авылдан күчеп килеп, әлләкем булып, безне мыскыллап йөрмәсен әле. Кафедрасы таркалсын, иеме ( бу аның яраткан сүзе иде).

Сәгадәт абый тыштан күндәм, тынлаучан, басынкы күренсә дә, эчке ышанычына таянып эш итә, мыштым гына, күтәрелеп бәрелмичә, жил унаена кыйбласын үзгәртмичә яши торган шәхес иде. Үзен зурлап мөрәҗәгать иткән ханымның да кәефен бозасы килми.

— Мин сине аңладым, кем Флера, уйлап карарбыз, бәлки күчмәбез дә, — ди, январь кары кебек ап-ак чәчле башын уң як җилкәгә салып. Чиләктән чайкалып түгелгән су кебек җегәре ташып торган ханым канәгать. Адәм баласына күп кирәкме.

Икенче көнне С.Ибраһимов үзен методика кафедрасына доцент итеп алуны сорап гаризасын китерде. Флера ханым бу хакта ишеткәч, «берәүгә дә ышанырга ярамый», дип үрле-кырлы сикергән һәм күчү-күчмәү мәузугын артык күтәрмәгән, диләр. Бер авызын пешкәч, салкын суны да өреп эчәсең шул.

Ник болай булды соң әле, Флера ханым белән тату гына аралашып яши идек дигәнрәк канәгатьсезлек хисе ан төпкелендә пыскып ятса да, мин аңа үпкәләмәдем, яна кафедраны ачканда, мөдир сайлаганда һәрдаим аның тарафдары булдым. Үзгәреш-янарышлар чорында, вакыт узгач бала-чага уены булып күренгән аңлашылмаучылыкларның килеп чыгуы табигый иде. Мәгәр Флера ханымның ни өчендер мишәр кавемен өнәп бетермәве генә барыбыз өчен дә үзе белән алып киткән тирән сер булып калды. Татарның бу төркеменә тискәре карашы университетның ректорын сайлаганда өскә калкып чыкты.

Кичтеки генә тарихи белешмә. А.И.Коноваловның ректорлык вәкаләте чыккач, бу җылы урынга Коноплев Ю.Г. сайланды дигән идем. Ул үз кандидатурасын икенче мөддәткә куйганда аңа көндәш булып профессор, шулай ук физик М.Х.Салахов теркәлде. КДУда эшләүче барлык татарлар, Мәгъзүм Хәлимулла улын яхшы белмәсәк тә, император ачкан уку йортының 200 еллык тарихында бер сайланып куелган төп милләт кешесе булсын дип, җиң сызганып эшкә керештек: кем беләндер сөйләшеп, аңлатып, аның кешелек сыйфатларына басым ясап, кайсыберсен чәйгә-мәйгә чакырып, бөтенесен эшләдек. Безгә бу кәнәфи иң югары түрәләр биләгән урыннан

да әһәмиятле, татарның булдыклылыгын, нәрсәгә лаеклы икәнлеген сынау кебек иде. Яһүдиләрнен күбесе безнен яклы булып чыкты. Күренекле тарихчы, илдәшләр сугышы чорындагы ак һәм кызыл террорлар буенча зур белгеч Алексей Литвин Салахов кандидатурасын яклап матбугатта чыгыш та ясады. Соныннан ул көлә-көлә, «сез татарларны, бер ярты салмыйча анлап булмый», дип бер вакыйганы бәян итте.

— Мине сайлаулар алдыннан профессор Флера Сафиуллина туктатты. Сезгә бер сорау бирергә мөмкинме, ди.

— Рәхим итегез дим. Хет унны.

— Сезгә Салаховны мактап матбугатта чыгыш ясау оят түгелме? — ди чибәр ханым.

— Ни өчен мина оят булсын, ул кешелекле, зыялы шәхес, зур галим, — дим. Ханым минем анлатуымны колак артыннан гына уздырды.

— Аны ректор ясасак зур хата эшлибез, мин ана каршы сайлаячакмын, ул бит — мишәр, — дип, мине аптыраштa калдырып, китеп тә барды.

Татарча белүе дә чыктым аша күпер генә булса да, паспортында безнен милләт кешесе саналган Салаховны уздырмас өчен татарларны күралмаган, женнәре сөймәгән, үзләрен бөек каста санап йөргән бер төркем урыс галимнәре, «тәре походы» оештыргандай, бөтен жирдә ачыктан-ачык шаулап, юри исемен бозып, «никакой Мугъзум-Казмум ректором не будет, это — наш ВУЗ», дип күмәкләшеп шаулашып йөрделәр. Кызганычка каршы, татар факультетын оештыруда, аякка бастыруда ярдәм иткән элеккеге ректорыбыз Коновалов та шовинистлар арасында булып чыкты. Жирле халыкны руслаштыру максаты белән ачылган император университетына татарны куйдыртмау өчен анын Түбән Новгородка президент вәкиленә чаклы барып житүе мәгълүм булды. Безнен белән уйнаганда гына сарык тиресен ябынган арыслан булып чыкты абыебыз. Шулай да без яшерен тавыш бирүдә жинеп чыктык. Бу — олы бер кирмәнне яулап алуга тин шатлык иде. Татар фамилияле ректор үз милләтенә әлләни файда эшли алмаса да, курыктымы, жаен белмәдеме, Ленин укыган Ульян мәктәбе тәрбиясе идеме, кистереп әйтүе дә кыен, бу әхлакый жину, берләшә алунын зур көч булуын исбатлау булды. Эчке бер канәгатьләнү хисен санамаганда, факультет мәсьәләләрен рус фамилияле ректорлар белән хәл иту мина жиңелрәк тә иде. Карышып маташсалар, мин аларны милләтчелектә гаепләүгә, жирле халыкның мәнфәгатьләре белән санашмауда төрттерергә дә күп алмадым, һәртөрле измнар белән «куркытунын» куәсе житмәсә, салпы якларына салам кыстырып, «ике урын биру, бер лаборант өстәү сезнең кебек олы житәкче, акыл иясе өчен пүчтәк нәрсә, кисеп ташлаган тырнагыгыз бәясенә дә тормастай бер гамәл», кебегрәк ачы-төче сүзләр тезеп, ягъни күп нәрсәне телемә салынып хәл итә идем.

Ульян шәһәрендә туып-үскән яна ректорыбызның татарчасы «цытыр-цытыр цапкан цакта цабатамның киндерәсе царт итте дә үзелде» дәрәҗәсендә генә булса да, чуаш кардәшләр әйтмешли, такументынта пезнең милләттән саналган ипдәшне милләтчелектә, «аборигеннарга» кырын карауда гаепләп булмый иде. Берәр танышынның, укытучыларнын балаларын яклый, факультетка жиһазлар янсә штатны арттыруны сорый башласан, ул шунда ук үзенең яраткан Троян атына «атлана».

— Үзләренә кирәк булганда, татар гумердә беренце күргән кешенең якын роднясы булып цыга. Сина да барцацы родня, ницек әле туган.

Ректорның «кәҗәләнәсе» килүен, андый вакытта мәсьәләне мангайга бәреп хәл итеп булмасын жиденче тоемым «хәбәр» иткәч, мин аны читкәрәк алып китү ягын эзлим.

– Ә сез беләсезме, кадерле Мәгъзюм Хәлимуллович, жир шарында яшәүче ике йөз кешенең берсе Чыңгыз ханның туганы булуы ачыкланган. ДНК шуны күрсәткән. Аның бит йөз хатыны, биш йөзләп жариясе булган... балаларының күпмелеген күз алдына китереп карагыз.

Әлбәттә, көчлерәк нәтиҗә турында хыялланып, соңгы саннарны көтмәсәм дә, башка жирдәнме алып үземнән өстәдем.

Ректорның әлегәчә бернинди кызыксыну чаткысы күренмәгән битараф, чәче шикелле үк коңгырт күзләрендә сәер хәрәкәт булып алды.

– Кем атьте?

– Һәр нәрсәдән хәбәрдар император (шулай атау аңа бик ошый иде) университеты ректоры шуны гына белергә тиештер!

–Ни пыцагыма миңа Чыңгызхан роднясы нужен?

Мин дә аның сүзенә юри басым ясап кабатлыйм:

– Соң мин тәкъдим иткән абитуриент может йә минем, может сезнең роднядыр.

– Татарин номер одиннан (ул мине олылапмы, көлепме шулай дип атап йөртә иде) болай гына котылып булмац, давай представлениенне.

Салахов үзе чын фән кешесе буларак, галимнәрне хөрмәт итә иде һәм, аңа хәтле, анардан соң университет хакимиятенә килгән кешеләрдән аермалы буларак, бервакытта да бүлмәсендә бикләнеп вакыт уздырмады, кабул итү сәгате түгел дип, үзебезнең хезмәткәрләрне озак көттереп утыртмады, ягъни ул житәкче булган заманда уку йортыбызга хас демократик рух, зыялылык сакланды.

Элеккеге ректорыбызның янә бер сыйфатын сагынып искә алабыз. Ул университетның бер генә профессорын да туган көне белән котламыйча калдырмады. Иренмичә үзе шылтыратып, изге теләкләрен индерүне абруен төшерү дип санамады. Бу гадәтен ул ректордан китеп, КДУның шәрәфле президенты булып калгач та суга салмады. Туган көн белән тәбрикләүгә бәйле бер мәзәк хәл һаман күз алдымда, шул искә төшкән саен, Тукайның шүрәлесе кытыклагандай, кычкырып көлеп жибәрәм.

2011 елның чилләсе. Туган авылым Кычытканлыдан килеп житәргә тиешле энекәш Әхәтне каршы алырга урамга чыктым. Килешенгән вакыт — нәкъ кичке сәгать алты. Кесә телефоным кыбырсый. Нәкъ шул мизгелдә мине тагын берәр кеше искә алырын башыма да китермичә, энекәшнең шаян холкын белгәнгә, сүзләрен дә үземчә юрыйм.

– Саласызмы инде, — дип сорый теге. Сүзләрне ачык аңларга бирмичә, кайсыбызныңдыр телефоны томау төшкән борын мисле «шыгырдый».

–Юк әле, салмыйбыз, сине көтәбез, кайчан килеп житәсең, — дим.

Теге очтагы тавыш мине бүлдереп: — «Салахов бу», — ди. Мин хатамны аңлап, әүвәл тотлыга-тотлыга «исәнмесез»не үземнән кысып чыгарам һәм, әле генә йокыдан уяна килгән кешедәй, авырлык белән исемен атыйм һәм Сибгат Хәкимнең элеккеге обком секретаре Табеевка яшьләр журналын ачуга рөхсәт сорау урынына, гозерен онытып, «исәнмесез Фикрят Әхмәтжанович», дигән мәзәгендәге шикелле, мин дә, ниһаять, «тыңлыйм сезне Мәгъзюм Хәлимуллович»ны, кирәгеннән катырак кычкырып, телемнән төшерәм.

Аның татарча авыр сукалавы минем файдага булды, ул берни аңламады дип беләм, мине туган көнем белән котлап, исәнлек-саулык теләде, бу юлы, гадәтенчә, үзе үстергән егетләрнең кырын каравыннан да зарланып тормады.

Өч ректор белән төрле дәрәжәдә эш алып бару, дуслык жепләрен ныгытып яшәүгә омтылулар яңа туган «баланы» — татар факультетын үстерү өчен эшләнде.

## Татар факультеты — милли күтәрелеш җимеше

*Зыялылары булмаган көе*
*Татарстан дәүләте яши алмаячак.*
М.Мәһдиев. «Татар зыялысы...
Ул кем?»

Язучы Мөхәммәт Мәһдиев татар зыялыларына шактый таләпчән бәясен биргәннән соң, фикер һәм караш төрлелеген ишетеп, киләчәктә халкыбызның йөзек кашы булырдай укымышлы катламның күтәреләчәгенә шикләнмичә, «Татар зыялысы... Ул кем?» мәкаләсе дөнья күреп, ике ел узуга бакыйлыкка күчте (1995). Үткән гасырның соңгы унъеллыгында телебезне, әдәбиятыбызны яхшы белгән, дөнья мәдәниятеннән хәбәрдар, чит лөгатьләрне үзләштергән, татарны милләт буларак танытып торган горефгадәтләребезне, әдәп-әхлак, гаилә кагыйдәләрен күз карасыдай саклый алырлык айдыннар үсеп чыгасына ышанырлык нигез нык иде. Сәхнәдән ана телебездә нотык тотарлык президентыбыз бар, Дәүләт советы рәисе тырыша-тырмаша татарча өйрәнә, татар-төрек көллиятләре, шәһәрләрдә дә үз телебездә укыткан мәктәпләр эшләп килә, бөтен фәннәрне диярлек татарча алып барган, тарихыбызда беренче югары уку йорты — Гуманитар институт тернәкләнеп килә, тиздән данлыклы Казан дәүләт педагогика униврситетына, яшен яшьнәп алырлык вакытка гына булса да, баш хәреф белән «Татар» сүзе өстәләчәк. Татар теле, әдәбияты, гомумән филологиясе факультетлары, бүлекләре Алабугада, Яр Чаллыда гына түгел, Уфа, Төмән, Тобол, Ижевск шәһәрләрендә югары белемле укытучылар, журналистлар, җәмәгать эшлеклеләре әзерләүгә керешә... Арча, Минзәлә, Тәтеш, Чистай төбәкләрендә эшләп яткан педучилищелар турында әйтеп тә тормыйм.

1989 елга хәтле татар бүлегенә һәр елны нибары егерме биш студент кына кабул ителә иде. Ул татар зыялыларын, язучыларны, укытучыларны, журналистларны әзерләү бурычын үтәп килә алса да, янарыш чорында ирек җилләренә битен куеп үсеп киткән факультет алдына татар лөгатен дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрүне үз кулларына алырлык, милләт гаме белән яшәүче белгечләр әзерләү бурычы куела. 90-нчы еллар башында татар факультеты дәрелфөнүннең иң абруйлы, үз дәрәҗәсен, көчен сиздерә килүче берәмлеге буларак танылa.

Факультетыбызга конкурс иң «кәттәләреннән» булып, бу мәсьәләдә элек-электән күкрәк киереп, сез кем дә, без кем дип, өстән аска карап яшәгән хокук, икътисад белгечлекләре белән «син»гә күчеп сөйләшә алу кимәленә күтәрелдек.

Татар факультетында белем алырга теләүчеләрнең күп булуы халыкның милли хисләре уяну, туган телебезгә, әдәбиятыбызга игътибар үсү, татар теле белгечләренә төрле өлкәләрдә игътибар артыр, ягъни ике дәүләт теле турында игълан ителгән фәрман тормышка ашырылыр, гамәлгә керер дигән ышаныч белән бәйле иде. Казанда, Чаллыда, Түбән Камада һәм башка үзәкләрдә ачылган татар гимназияләренең, яхшы укытучылар белән тәэмин ителгән мәктәпләрнең укучылары безнең факультетка теләп килделәр. Арча, Минзәлә, Чистай көллиятләрен тәмамлаучылар, үзара килешү нигезендә, читтән торып уку бүлегенә имтихансыз алындылар. Берничә ел дәвамында юридик факультетка да иншаны татар әдәбиятыннан язу мөмкинлеге булып алды. Хокук белгечләре арасында татарча аралаша, хәтта чыгыш ясый алучылар бар икән, алар нәкъ шул чорда хокук белгечлегенә безнең аша узган затлар дип беләм. Татар факультетының эчке төзелеше дөрес уйланылу да аның абруе үсүгә тәэсирен ясамый калмады, әлбәттә. Татар теле һәм әдәбияты төп белгечлек булса да, һәр талибның өстәмә бер телне: гарәп, фарсы, кытай, инглиз, алман лөгатьләрен үзләштерергә

мөмкинлеге бар иде. Егетләрне тарих һәм көнчыгыш бүлеге үзенә тартып торды. Һәркайсы дипломның кушымтасына язылды. Гомеремне югары уку йортына багышлаган кеше буларак, шундый психологик халәтне дә исәпкә алырга кирәк дип саныйм. Абитуриентларның зур өлеше соңгы көннәргәчә «кем булырга, укырга кая керергә», дигән сорауга җавапны ачыклый алмыйча, икеләнеп, тегендә сугылып, монда бәрелеп йөри, кайберләренә кая укыса да, кем булса да барыбер, тик армия җәтмәсенә эләкмәсен дә, ахыр чиктә кесәсендә югары белем турындагы таныклыгы булсын. Ул белешмәләр тактасы янында кайсы белгечлеккә ничә урын бирелүен өйрәнә һәм, әлбәттә инде, ун, егерме студент алына торган «мескенкәйгә» караганда, йөз һәм аннан да артыграк урынлы факультетка өстенлек бирә. Чөнки ничек кенә булмасын, соңгысына эләгүнең ихтималы зуррак була.

КДУның татар факультеты җиһанда нибары 20 ел яшәп калды. Олы тарих өчен кыска вакыт тарлыгында да ул халкыбызга, телебезгә турылыклы фидакарь белгечләр, укытучылар, язучылар, журналистлар, XX гасыр башы зыялыларын бәйгегә чакыра алырлык күп телләр белгән айдыннар әзерләп өлгерде. 2011 елда Шаһгали токымы аны эзләп тапты һәм гөрзие белән башына тондырды.

## Канатлы өметләр

Татар факультеты гадәти берәмлек кенә түгел иде. Демократик үзгәреш, янарыш чорында ул халкыбызның киләчәк үсеш, ан-белем дәрәҗәсен күтәрү, яңа буын зыялыларын әзерләү учагы кебек күз алдына китерелде. Студентларда милли рух уяту, җаваплылык хисе тәрбияләү бездән — укытучы-мөгаллимнәрдән тора иде. Төп максатларның берсе буларак халкыбызга гасырлар дәвамында сеңдерелә килгән коллык, куркаклык психологиясен җиңү, яшьләрнең аң кимәлен үстерү торды. Шәхсән мин алып барган «Хәзерге әдәбиятның мөһим мәсьәләләре» курсы студентлар алдында, милләт каршында торган көнүзәк проблемаларны калкытып кую өчен иң кулае иде. Мин әдәбиятның милләт хәтере булуына, аның тарихын, холкын, гасырлардан килгән сагыш-моңнарын нәфис тел ярдәмендә чагылдыруына басым ясадым.

Мин укыган курс турында филология фәннәре кандидаты, доцент Н.Ф.Фәттахов болай дип яза. «Студент чакта ул безгә «Хәзерге әдәбиятның актуаль проблемалары», «Фәнни эшкә өйрәтү» дигән махсус курслар укытты. Ни гаҗәп, аның дәресенә барыбыз да йөрдек, 1112-нче аудиториядә биш төркем бергә, шыплап тутырган шырпы тартмасы кебек утыра идек. Мөгаен, кырыс холыклы, гадел кыяфәтле деканнан шүрләгәнбез инде. Туксан алты битле калын дәфтәргә лектор сөйләгәнен сүзен-сүзгә, тиз-тиз язып бардык. Остазга рәхмәт йөзеннән ул лекцияләр дәфтәрен әле дә кадерләп саклыйм. Миңа калса, Т.Галиуллин кебек әйткән сүзенең тәмен белеп, аңлаткан темасы хакында ләззәтләнеп, 1 сәгать 20 минут дәвамында илһамланып, тоташ бер тын белән укучы галимнәр бик сирәк очрый» (Фәттахов Н.Ф. Язучы-публицист осталыгы серләре, 2011, 56 б.). Бу фәнне миңа чаклы, сиксәненче еллар ахырына кадәр Мөхәммәт Мәһдиев алып барган. Татар әдипләреннән кемнәрне үткәндер, анысын әйтә алмыйм, рус язучыларыннан авыл тормышын гаҗәеп нечкәлекләре һәм сәнгатьчә камил тел белән сурәтләгән И.Бунин, В.Шукшин, В.Солоухин, В.Беловларны әйләнеп үтә алмаганын тәгаен беләм.

Замана уку-укыту каршында яңа максатлар кую белән бәйле рәвештә, әсәрләрне сайлап алу таләпләре дә үзгәрә. Мескен, язмышына буйсынган,

үзен түбәнәйтеп яшәүдән тәм тапкан адәмнәрне сурәтләгән, милләтне инкыйразга алып килүче язмалар төшереп калдырылырга тиеш иде.

Татар халкының ярдәмчел булуы, вакыты белән берни таләп итмичә, соңгы кисәк икмәге белән бүлешергә әзер торуы, корбанчылык идеясе безне башка сугышчан, юлбасар милләтләрдән аерып торган үзенчәлеге дип санау һәр очракта да файдалы күренеш түгел иде. Халык ин авыр шартларда да бөгелеп төшмичә, чыгу юлын таба алганда гына яши ала. Ерак тарих чоңгылларына кереп тормыйча, Урта Иделгә килгән, татар халкына аеруча каты китереп бәргән 1921 елгы ачлыкны натуралистик ваклыклары белән сурәтләгән Г.Ибраһимовның «Адәмнәр» бәянын, М.Гафуриның «Кеше ашаучылар» поэмасын төрлечә бәяләп була. Бер яктан, ачлыктан үз-үзләрен белештермичә, балаларны тураклап, Казанга салып пешерү дәрәжәсенә житкән адәмнәр кызгану уята. Большевиклар «Ленин якташларын ташламаган, һәрдаим ярдәм итеп торган», дип лаф орсалар да, авыл халкы бернинди матди ярдәм алмый. Ачлык башланганчы ук, продразверстка дип аталган кызыл отрядлар крәстианнарның амбарларын, абзарларын «чистартып» чыккан була. Системаны фаш иткән бу әсәрләрне тыю, күп еллар матбугатта чыгармау олы сәясәт белән бәйле иде. Чөнки бу әсәрләр большевикларның «авыр елларда без гел халык белән бергә булдык», дигән ялганнарын фаш итеп, чын йөзләрен ачып бирә. Авыл халкы ачлык белән берүзе көрәшергә мәжбүр була. Шул ук вакытта бу афәт халкыбызның бәла-каза алдында югалып калуын, хәлләрәк күршеләреннән, башка илларда үзен талаган үзәктән ярдәм сорауда, таләп итүдә юашлык күрсәтүенә дә дәлил. Милләтнең Шәкүр карак кебек гаярь, легендар ат караклары кая киткән, ачлыктан кырылып яткан кардәшләренә, бөтен милләтне аларның гына коткарып кала алмаячагын аңлаган хәлдә дә, ник бераз ярдәм итмәгәннәр дип тә ым саласы килә. Халкыбызның фажигасе турында ачыктан-ачык бәян итү аның үзенә каршы эшләгән мәгълүмат дәрәжәсенә төшүе, чын дөреслек турында хәбәрдар булмаган башка милләт вәкилләрендә ялгыш күзаллау тудыруы да мөмкин икән.

Югарыда аталган әсәрләргә бәйле рәвештә, бер вакыйга күңелдә уелып калган. Университетның беренчеме, икенчеме курсында укыганда, безнең бүлмәгә вакытлыча, Ташкенттан килгән үзбәк аспирантын керттеләр. Ана «сов. секретно» бүлегендә эшләргә рөхсәт биргәннәр һәм ул егерменче еллар башындагы ачлыкка багышланган әсәрләр белән танышу мөмкинлеген алган. Кичен, кинаяле елмаеп, бөердән торып әйтеп салмасынмы кунагыбыз.

—Татарлар кеше итен ашыйлар, ашаганнар икән.

Без бертавыштан:

—Дөрес түгел, бу ялган, гайбәт, халыкны пычрату, — дип кычкырдык.

— Мин үзем укыган әсәрләр буенча бәя бирәм, — диде кысык күзле егетебез. Уйлап чыгарган әйберем түгел.

Без ул вакытта әле Г.Ибраһимов, М.Гафури, Һ.Такташ, С.Сөнчәләй кебек авторларның егерме беренче ел фажигасенә багышланган әсәрләре белән таныш түгел идек. Мондый гаепләүгә гарьләнеп, «безгә яла ягасың», дип үзбәк егетен кыйнап ташлау дәрәжәсенә життек. Житмәсә, ул кулына тотып караган әсәрләрнең авторларын да хәтерләми, аның аны тышлыкка чыгарылган «Кеше ашаучылар» тезмәсен генә отып калган. Урта Азия халкы безнең кебек табигатьтән мәрхәмәт көтеп ятмыйча, су каналлары, арыклар уеп, гасырлар дәвамында үз көнен үзе күрергә өйрәнгән. Шунар да халык телендә «Ташкент — город хлебный» дигән гыйбарә яши. Ә без, Тукай язганча, жилнең дә, яңгырның да вакытында сөендерүенә жайлашканбыз, шуны көтеп ятабыз.

1921 елгы корылык татар халкына зур зарар китерә. Аның аянычлы

нәтиҗәләре турында тарихчыларыбыз күп яздылар. Мәгәр хәзергә чаклы ул елларда күпме татарның ачлыктан җан тәслим кылуы, күпмесенен авыр шартларга түзә алмыйча, Урта Азия, Себер якларына, Төркия тарафларына чыгып китүләре турында тулы мәгълүмат туплый алганыбыз юк. Кем аларның исәбен алган да, үлгән, авылдан чыгып киткән кешене кем теркәп барган. Үзе дә бер сынык икмәк, черек бәрәңге, алабута көлчәсе турында хыялланган адәми затта башкалар кайгысымы соң?[1] Ә сүз осталарыбыз шул чорда ук ачлыкның татар, гомумән Урта Идел буе халкына алып килгән зыянын, затлы нәселләрнең дә кырылуын үз вакытында теркәп калдыра алганнар.

Истәлекләргә караганда, нечкә күңелле, хисләнүчән М.Гафурины ул елларның фаҗигасе тетрәндерә. Ачлыкның кешеләргә китергән кайгы-хәсрәтен, дәһшәтен тирән борчылу белән йөрәге аша уздырып тасвирлый.

Кар сырылган озын баганалар
Кәфен сарган үлекләр сыман,
Юлсыз-эзсез калган урамнары
Каберстаннан да шомлырак, –

дип искиткеч кара, өнсез, куркыныч манзараны күз алдына бастыра шагыйрь. Поэмасына төрлечә аңларга урын калдырган исем бирә — «Кеше ашаучылар». Г.Ибраһимовта тере көекләр, кеше дәрәҗәсенә күтәрелә, бөек исемнәрен аклый алмаганнары «Адәмнәр» рәтендә генә кала. Үзбәк аспиранты ул чорда ачлыктан, өметсезлектән бәргәләнгән халык кичергән фаҗиганың асылына игътибар итмичә, акылын җуйган, шашкан, атаклы балта остасының нәни кызы Нәфисәне тураклап Казанга салуына гына игътибар иткән. Моның нигезендә һәр милләт вәкиленең, бигрәк тә айдынының үз халкын башкалардан өстенрәк күрү теләге, үз файдасын гына күздә тотуы, ягъни эгоцентрик эгоизм ята. Ә ни өчен «сов. секретно» бүлегендә эшләүгә рөхсәт алган үзбәк аспиранты Фатих Әмирханның шул ук егерменче еллар башында иҗат ителгән, хакимиятне корал көче һәм ялган шигарләр белән кулларына төшергән большевикларның илне катастрофага, төзәтеп булмаслык фаҗигага алып килү сәясәтен гаҗәеп бер көч һәм ярсулык белән фаш иткән публицистикасына игътибар бирмәгән? Алдан күрүчәнлекләре, ироник юнәлешләре белән русның бөек әдипләре И.Бунинның «Окаянные дни», В.Короленконың «Письма Луначарскому» кебек әсәрләре югарылыгында торган Ф.Әмирхан язмаларында үзбәк егете күңеленә хуш килерлек «кайнар пәрәмәчләр» тапмаган.

Житлеккән әдәби әсәр бер күзәнәкле матдә түгел, ул катлаулы төзелешле берәмлек, үзенең янгырашын, сәнгатьчә көчен шунда ук ачып салмаска да мөмкин. Камил иҗат җимешенең икенче, өченче һәм әллә ничәнче катламы, су асты агымнары була. Һәр чор үткәннән казанышларыннан рухына якынын җиз иләк аша үткәреп, аның әлегәчә игътибар ителмәгән кыйммәтләрен табып ала. Әдәби әсәрне укый, аңлый һәм аңлата белү зәвыкны, әзерлекне таләп итә. Әйтик, совет чорында Г.Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романында коммунист образының ни дәрәҗәдә тулы һәм ышандырырлык итеп сурәтләнүен игътибар божрасына алырга тиеш идек. Әсәр социалистик реализмның казанышы буларак бәяләнә килде. Хәзерге әдәбият белемендә ул татар халкының имән агачы кебек тирән тамырлары,

[1] Язмамның ошбу өлешен тәмамлап килгәндә, «Казан утлары»ның 2013 елның беренче санында басылган Тәэминә Биктимированың «Ачлык фаҗигасе» исемле мәкаләсенә тап булдым. Анда мин куйган сорауларның күбесенә җавап бирелгән.

илаһи көче турында уйлануларны, фәлсәфи хөкемнәрне эченә алган гасыр романы буларак бәяләнә. Жанр ягыннан ул детектив әсәрнен классик үрнәге, «Фәхрине үтереп ташладылар», дигән беренче җөмләнен эчтәлеген ачу юнәлешендә, бөркет кебек, канатларын һавада җәйгән роман.

Фәлсәфи эчтәлекләрен, язучының уен, зиһен катламын вакыт узган саен яначарак ача барган «серле» әсәрләр бар. Үзем укыган курста шундый бәяләр төрлелегенен үрнәкләре итеп, М.Горькийның «На дне» һәм А.Гыйләҗевнең «Җомга көн кич белән» әсәрләрен тикшердем. Әйе, М.Горькийның бу пьесасы үткән гасыр башында ук язылган. Бер караганда, патша Русиясендәге хәерчелекне, кешене сытуны, рәнҗетүне фаш итүгә багышланган әсәрнең тематикасы да әлләни яна түгел. XIX гасыр ахырында, XX йөз башында бу мәүзугъны үзәккә алган язмаларның хисабы юк. Горький драмасында үзәк образ буларак уйланылмаса да вакыт узган, илдәге сәяси вәзгыять үзгәргән саен, сәхнәнең йә бер почмагында, йә түрендә урын алган Лука образы үзенчәлекле. Ул пьесада кешеләрне юатучы, төрле вәгъдәләре белән тынычландыручы, күнелләрен күтәрүче — «утешитель» буларак уйланылган. Башка персонажлар шикелле үк, түбәнлектә яшәргә мәҗбүр булса да, ул беркайчан төшенкелеккә бирелми генә түгел, төн үткәрү өчен каралган вакытлы торакта кунучыларга да унай йогынты ясарга тырыша. Аракыга бәйлелектән интеккән Сатинга Себердә бушлай дәвалау үзәге ачканнар, тиздән сине шунда җибәрербез дип вәгъдә бирә, ә инде югары мәхәббәт, сөю-сөелү турында шашып-шашып хыялланган Настяны олы хис турында уйлыйсын икән, ул синен йә бар, йә булыр, азга гына түз, дип тынычландыра. Совет идеологиясе тантана иткән чорда Лука тормышка ашмас вәгъдәләре белән кешене көрәштән читләштерә, аның ялган гуманизмы сыйныфларны тигезли, дингә ышанырга үгетли, дип аны тискәре персонаж итеп кенә бәяләделәр. Безнең чорда аңа мөнәсәбәт яхшы якка үзгәрде.

А.Гыйләҗевнең «Җомга көн кич белән» бәянының төп персонажы — Бибинур карчык — һаман әдәби-фәлсәфи бәхәсләр үзәгендә тора дисәм дә хата булмастыр. Гомерен чит-ят балаларны тәрбияләүгә, аякка бастыруга багышлап та, алардан мәрхәмәт түгел, рәхмәт тә ишетмәсә дә күнелендә рәнҗү сакламаган Бибинур карчыкка бәяләр төрлечә булды. Берәүләр аны фәрештә, изге җан дәрәҗәсенә күтәреп, соклансалар, икенчеләре аны бөтенләе белән кабул итмәде, корбанчылык идеясенен буыннар арасындагы якынлыкны югалтуга алып килүенә басым ясадылар. Бибинурның кешеләргә бары тик яхшылык теләве, рәнҗи белмәве, Җиһангиргә яшертен-орынтын мәхәббәтендә җавап хисләренә дәгъва итмәве бөеклек үрнәге, шәфкатьле, миһербанлы, рәхимле гуманизм чагылышы түгелме? Инсаниятне кешелеклелек нурында коендыру, бар кешене бәхетле итү турында хыялланган Лука, Бибинурлар күн тужурка киеп, кулларына алтатарлар тотып, кан агызудан тәм тапкан кызыл комиссарларга караганда җәмгыятьтә рухи бөтенлекне ныгытуга күбрәк файда китергәндер дип уйлыйм. Җан тынычлыгы, таяныч ноктасы булганда адәм баласы күп изгелек эшли, үз сулышы белән, җил тегермәненең канатларын әйләндерә ала. «Таяну ноктасы бирсәгез, җир шарын күтәрә алам», дигәнме әле Архимед бабабыз.

Югарыда аталган образлар белән соклануым турында яздым да, уйга калдым. Татар әдәбияты әдәп-әхлак кагыйдәләрен буыннарга җиткерүче, гореф-гадәтләребезне саклаучы буларак өлкән буынны, әби-бабайларны, ак әбиләрне, сихерче карчыкларны сурәтләү белән артык мавыкмыймы? Гомерләрен кеше балаларын тәрбияләүгә багышлаган, алардан ни Аллага, ни муллага, ни милләткә, ни үзенә берни таләп итмәгән әбиләр корбанчылыгы

гына халкыбызны инкыйраздан коткарырмы? Милли мәнфәгатьләр өчен көрәшү турында онытып, кул кушырып, күктән мәрхәмәт көтеп утырып кына телебезне, менталитетыбызны саклап кала алырбызмы?

Моннан кырык елдан элек яшь шагыйрь Равил Фәйзуллин «Көрәшчеләр кирәк» дип күтәрелгән, Мансур Вәлиев китабына «Каһарманнар кирәк» дип исем биргән иде. Күренекле галим-библиограф, академик Әбрар Кәримуллин милләттәшенә бәясендә берүк сүзне югары бәя буларак, ә анын капма-каршысын тисәре мәгънәдә кулланды: «ул — көрәшче, йә ул — көрәшче түгел». Бу сүзенә ачыкламыш кертүне, аңлатма бирүне артык санады. Чөнки ул барлык башка төсләрнең ак белән кара кушылмасыннан торуын тәгаен белә иде.

Татар факультеты оешуның беренче көненнән, үпкәсен тутырып соңгы сулышын алганчы, хәзер керәге табылмаган бу әдәби курста, татар сүз сәнгатеннән халкыбыздагы рухи сәләтне, дәртне, эчке җегәрне арттыра, горурлык хисе тәрбияли торган, шул ук вакытта өстен көчләрнең аны гасырлар буена сыта, изә килүен фаш иткән әсәрләрне үзәктә тотарга тырыштым. Субъективизм, шәхси аңлау да булгандыр. Әмма примитив, бөек татар әдәбияты дәрәҗәсеннән түбән торган әсәрләрне алмадым.

Шәхес культын фаш итү И.Сәлаховның «Колыма хикәяләре», А.Гыйләҗевнең «Йәгез, бер дога», Г.Тавлинның «Афәт» кебек әсәрләре мисалында каралса, «Батырша» (Ж.Рәхимов), «Ишелеп төшкән бәхет» (Ф.Латыйфи), «Ялгызак» (Р.Сибат), «Татар ир-егетләре» (З.Зәйнуллин), «Ком сәгате» (К.Кәримов) һ.б. роман-повестьларда милли сыйфатларыбызның табигый чагылышын өйрәнсәк, татар тарихын инләүдә Н.Фәттах, М.Хәбибуллин, Р.Батулла, В.Имамов, Ф.Бәйрамова, Ф.Латыйфи, Р.Зәйдулла иҗатлары таяныч булды. Әдәбиятыбызның көнбатыш һәм рус сүз сәнгатендә барган яңача эзләнүләрдән, халыкча әйтсәк, мөгез чыгарулардан да «куркып» тормаганын күрсәтү нияте белән Ф.Бәйрәмова, Н.Гыйматдинова, Г.Гыйльманов, З.Хәким һ.б. эзләнүләренә дә тукталдык. Шагыйрьләребездән милли рухлы, яңача фикерләү сәләтенә ия Р.Фәйзуллин, Р.Харис, Р.Мингалим, Г.Рәхим, А.Хәлим, М.Әгъләм, Зөлфәт, З.Мансуров, Г.Морат, Л.Шагыйрьҗан, Н.Сафина, Р.Рахман, К.Булатова һ.б. иҗаты тикшерү, өйрәнү божрасына алынды. Драматургиябезнең иң гүзәл үрнәкләре дә читкә тибәрелмәде, якынча булса да, әдәбиятыбызны инләгәч, аңа татар кешесен көрәшче итеп сурәтләү җитешми дигән нәтиҗәне күңелемнән чыгара алмадым. Гасырлар буена изелеп, сытылып килгән халыкка Робин Гудларын үстерүе кыен шул. Роман-трилогиямнең каһарманы Сәет Сакмановны шул юнәлештә күтәрү турында хыялланып каләмгә тотынган идем. Барып чыкмады. Хәзерге тормышыбызның мантыйгы намуслы кешегә урын калдырмый икән. Ә инде җинаятьчеләрне, юлбасарларны сурәтләү кирәк булса, сыналган, тикшерелгән алымнары җитәрлек, рәхим ит!

Башка милләт сүз сәнгате осталарыннан Чыңгыз Айтматов, Василь Быков, Виктор Некрасов, Валентин Распутин, Виктор Астафьев һ.б. авторларның реалистик әсәрләре һәм аеруча тыелган, авторлары исән чакта матбугатта басылмаган, большевиклар системасының кеше ирекен бууга корылган сәясәтен фаш иткән Борис Пастернакның «Доктор Живаго», Василий Гроссманның Ватан сугышы нәтиҗәләре турында дөреслекне күрсәткән, командирларның булдыксызлыгы, куркаклыгы аркасында миллионлаган сугышчыларның туп итенә әверелүен ачып салган «Жизнь и судьба» әсәрләренә тукталдым. Соңгы роман-эпопеяның Казан һәм аның кешеләренә (галимнәр Мадьяров, Кәримов образлары үзенчәлекле) багышланган өлешләрендә авторның милли азатлык, шәхес ирекe турында

уйлануларын илебездә соңгы чорда туган вәзгыять белән чагыштырып шәрехләргә тырыштым.

Булсын әдәбият, булсын тел гыйлеме, булсын тарих дәресләрендә факультетның барлык мөгаллимнәре студентларыбызны мөстәкыйль фикерләүгә, үз халкының үткәне һәм хәзергесе белән горурланып яшәүгә, үзләрен югалтмаска, киләчәктә милләтебезнең патриотлары булып калуларына өмет баглавыбызны күңелләренә сеңдерергә тырыштык.

Теләсә кайсы халыкның әдәби-мәдәни мирасыннан тарихының авыр, аянычлы мизгелләрен үзәккә алган, мескенлеген сурәтләгән әсәрләр табып була. Шундый язмаларга карап кына (үзбәк аспиранты кебек) милләт характерына, яшәешенә бәя бирү ялгыш нәтиҗәләргә алып килергә мөмкин. Шунар да С.Рәмиевнең үтә кыю, күкләргә, абруйларга кизәнгән нисби каһарманы белән сокланса к та, үзебезнең Морат мулла, Батырша, Бәхтияр Канкаев кебек халык азатлыгы өчен җаннарын фида кылган, көрәшеп һәлак булган бабаларыбыздан 90-нчы елларда халкыбызны гафләт йокысыннан уяткан Марат Мөлеков, Зәки Зәйнуллин, Фәүзия Бәйрәмова, бертуган Рәшит һәм Илдус Әхмәтҗановлар, аларга килеп кушылган Айдар Хәлим, Шамил һәм Ренат Закировлар, Туфан Миңнуллин, Разил Вәлиев һ.б. шәхесләребездән үрнәк алып, рухларына, көрәшләренә турылыклы калыгыз, дигәнрәк фикерне җае чыккан саен кыстырып куярга онытмадым.

Татар факультеты укытучыларының, гамәли хезмәткәрләренең тырышлыгы өстенә илдә хөкем сөргән азатлык рухы, халыкның әледән-әле мәйданнарга шашып чыгуы тәэсирендәме барыбыз, бигрәк тә студентлар, ниндидер яктылык нурында коендык, илаһи бер халәт кичердек, Казанны янәдән берәүгә дә баш бирмәс, үзебезнең бәйсез башкалабыз итеп күрдек. Юк дәрәҗәсендә хезмәт хакы алып эшләгән сәркатипларның, лаборантларның ягымлылыгын, арабыздан киткән В.Хаков, Д.Тумашева, М.Госманов кебек профессорларның, канат куйгандай очынып йөрүләрен, шатлыклы йөзләрен күрү үзе бер бәхет һәм илһам чыганагы иде. Гайбәтләр, көнчелек, монафикълык кебек гадәтләр бөтенләй булмагандай тоелды.

Дәрелфөнүнебез ректорының нинди милләт кешесе булуына карамастан, көндәлек аралашуда Татфак дип йөртелгән үсмеребез, әкияттәгечә, төн үсәсен көнгә ялгап, милләтенең җылы карашын, ара-тирә матди ярдәмен дә тоеп, уку йортыбызның иң эре вә абруйлы факультетларының берсе дәрәҗәсенә күтәрелде диган идек. Әлбәттә, иң зур күрсәткеч студентлар сафының елдан-ел ишәя баруы иде.

Җөмләдән, 1992 елда бюджетлы урынга 100 талиб-талибә кабул иттек, читтән торып укучыларның санын гомумән чикләмәделәр, 150 кешедән артыграк алган бәхетле еллар безнең тарихыбыз сәхифәсе. Алда аталган елда факультет студенты булуга дәгъва итү өчен кирәкле балны җыйган, ягъни конкурс җәтмәсен узган 20 балага урын җитмәде, ректорат өстәмә урыннар бирә алмады, авыллардан килгән абитуриентларның түләп укырлык мөмкинлекләре юк. Татар теле, әдәбияты буенча белем алу турында хыялланып йөргән балаларны өйләренә кайтарып җибәрү гафу ителмәслек бер гамәл булыр иде. Факультетның кабул итү комиссиясе рәисе Флера Ганиева белән киңәш һәм ярдәм сорап үзебезнең Мәгариф министрлыгына, аерым алганда министрның урынбасары Флера Илдархановага «без сезнең өчен укытучылар, тәрбиячеләр әзерлибез, сынауларны узган әзерлекле яшьләребезнең егермесе урамда калды, ярдәм сорыйбыз», дип мөрәҗәгать иттек. Бергәләп төрле мөмкинлекләрне эзләп

Казан, Алабуга, Чаллы югары уку йортларына тәкъдим ясап карадык, аларның да буш урыннары калмаган булып чыкты. Бу «авыр» халәтне мин татар халкы ирешкән, татар теленең абруе иң кайнар ноктасына күтәрелгән бәхетле еллар дип беләм.

Шулай бергәләп киңәш-табыш иткәннән соң (ул чорда министр вазыйфаларын милли җанлы, төгәл фәннәр белгече булса да, татарчаны су кебек эчкән соңгы могиканнарның берсе, Васил Гайфуллин үти иде). Министрлык безгә мондый җавап бирде.

– Студентларга стипендия, укытучыларга сәгатьләп хезмәт хакын түләүне үз өстебезгә алабыз. Сездән аудиторияләр һәм педагоглар белән тәэмин итү сорала.

Кыскасы, авырлык белән булса да, әзерлекле, укырга теләге булган, милләтебезнең киләчәге өчен ифрат кирәкле яшьләрне саклап калу әмәлен таптык. Уку-укыту яшертен-орынтын рәвештә диярлек факультет оялаган 2-нче уку бинасының 11-12 катларында кичләрен оештырылды. КДУ ректораты, администрациясе бу хакта белгәндер дип уйлыйм, тавыш күтәрмәде, шелтә белдермәде. Икенче елны Идел-Пресстан бер тукталыш арырак урнашкан балалар бакчасын бушатып, ремонтлап, безгә бирделәр. Бер-ике ел ул педагогик көллият дип йөртелде, студентлар саны җиткәч, аңа Гуманитар институт дигән югары исем бирелде һәм ул Татарстан мәгариф министрлыгы карамагындагы, рус теле һәм әдәбиятыннан башка, барлык фәннәрне татарча укыта торган югары белем бирүче гыйлем йорты буларак дөрләп, һәммә милли җанлы кешеләрне сөендереп, үсеп китте. Ректор итеп тарих фәннәре докторы, татар өчен җан атып йөргән, милләтпәрвар, ифрат намуслы ир-егет Илдус Заһидуллин расланды, уку-укыту, фән буенча проректор вазыйфаларын үтәү, бу уку йортын оештыруның беренче адымнарыннан ук башында торган Флера Ганиевага йөкләнде. Ул студентларның таләпчән укытучылары, кайгы-хәсрәтләрен уртаклашкан әниләре дә булды. Үзешчән сәнгатьтә, спортта, олимпиадаларда, газеталар чыгарудагы уңышлар — барысы да аның ярдәме белән башкарылды. Яңа уку йортында укыту эшенә татфактан башка университетның тарих, филология факультетларыннан, методика, педагогика, математика, чит телләр буенча белгечләр Казан педагогия институтыннан җәлеп ителде. Аның яшәеш үзәнен, асылын татар мәктәпләре өчен укытучылар, тәрбиячеләр әзерләү тәшкил итте. Чит телләр, бигрәк тә инглиз, немец лөгатьләре буенча бу фәннәрдән бөтенләй хәбәре булмаган балалар биш елда менә дигән «шприхчеләр» булып китте. Иң мөһиме: институтта югары мәгънәсендә милли рух яшәде, гел шунда эшләүче укытучылар коллективы оешты. Мин үзем дә анда «Хәзерге әдәбиятның мөһим мәсьәләләре» исемле курсны укуга ашкынып, бик теләп йөрдем. Андагы җылылык, студентлар белән аңлашып яшәү, таләпчәнлекне киметмичә һәркемнең хәленә керү, бер уку йортында да юк һәм була да алмас кебек. Фәнни җегәре, укыту эшенең тиешле дәрәҗәдә куелуы, милләткә турылыклы белгечләр әзерләве буенча Гуманитар институтның атаклы Галия мәдрәсәсе яисә хыялда гына калган татар милли университеты дәрәҗәсенә күтәрелергә бөтен мөмкинлеге бар иде. Яңа бина, тулай торак төзү өчен дә шул тирәдә үк урын табылды. Тиешле документлары да әзерләнә башланды. Ун елдан аз гына артык гомере дәвамында Гуманитар институт берничә мең белгеч әзерләп калырга өлгерде. Аның мәдәни тормышыбызга йогынтысы һәр өлкәдә сизелә башлады. Үз күзәтүләрем буенча гына берничә мисал китерәм. 2007 елда мине М.Горький музеена очрашуга чакырдылар. Кичәне бик сөйкемле бер кыз алып барды. Соңыннан ул яныма килеп, «сезнең

лекцияләрне мин Гуманитар институтта укыганда байтак тынладым, диплом алгач, методист итеп монда чакырдылар», — дип аңлатма бирде. Җәен Норлат районында урнашкан туган авылым Кычыткanлыга кайттым һәм, гадәтемчә, мәктәпкә кердем. Укучылар җәйге каникулга таралышкан булсалар да директор урынында иде. Икенче ел инде директор вазифаларын беренче татар режиссеры Габдулла Кариевны, Г.Исхакыйның дусты — гаярь журналист, мөһаҗир, Төркиядә беренче халык китапханәсен ачкан Фоат Туктаровны биргән бай тарихлы, күрше Күлбай Мораса авылы егете башкара икән. Ул да Гуманитар институтны тәмамлаган булып чыкты.

### Фетнә

Кешелек тарихы төрлечә аталган хакимият белән аңа буйсынган кешеләр арасында барган астыртын яисә ачыктан-ачык көрәшнең төрле чорларын хәтерли. Әлбәттә, күп очракта кулларында хәрби көч тупланган беренчеләре җиңеп чыккан. Канга батырылып, асып-кисеп буйсындырылсалар да фетнәләр чыгып торган. Артык зурга: коралга, сәнәккә, балтага тотынырлык хәлгә җитмәсә дә, шуңа нисби ишарә иткән вакыйга факультетыбызда да булып алды. Ул заман студентларының кыюлыгына, үзләрен яклый алуларына мисал булырдай бер фетнә бүгенгедәй һаман күз алдымда. 90-нчы елларның беренче яртысындагы шикелле әзерлекле, милли рухлы, кыю һәм тәвәккәл татар студентлары булмагандыр һәм киләчәктә андый шәкертләрне тудырырлык вәзгыятьнең янәдән кайтасына үзенне ышандыруы да кыен. Факультетның иң тәвәккәл студентларының берсе — Рамай Юлдашевны Азатлык мәйданында, Ленин бабай һәйкәле тирәсендә тулы мөстәкыйльлек турында «коткы» таратып йөргән өчен кулга алып, зинданга ябып куялар. Ошбу хәбәр яшен тизлеге белән факультетка килеп җитә. Егетнең аркадашлары, сыйныфташлары бүлмәдән-бүлмәгә йөреп, укучыларны шул ук мәйданга митингка чакыралар, берсе дә куркып качып калмасын дип күзәтеп торалар. Мин вакыйгалар куерган мәлдә ректорат утырышында, төп бинада идем, икенче уку бинасының унберенче катына күтәрелсәм, умарта күче кебек гөжләп торган коридорда үлем тынлыгына тап булдым. Аптыраганнан аудиторияләрне ачып-ачып карыйм, шул ук бушлык. Деканатта ике яшь кыз һәм уйга талып, дәресләрен уздырырга килгән берничә мөгаллим утыра.

—Студентлар кая? — дип сорыйм сәркатипләрдән.

— Митингка, Ирек мәйданына киттеләр, Рамай исемле егетебезне кулга алганнар.

— Алар анда чыгып нишли ала инде? — дигән булам, декан икәнемне искә төшереп. — Әүвәл минем белән киңәшергә, уйлашырга иде.

— Иптәшебезне азат итмичә, факультетка кире кайтмыйбыз, — дип чыгып киттеләр.

Дөрес, мин митингка ярсулы, ачулы сүзләр белән чыгыш ясаган бер талибыбызны саклау оешмасының кулга алуы турында ишеткән һәм хәзер нәкъ шул мәсьәлә белән шөгыльләнергә исәпләп кайткан идем. Студентлар миннән өлгерерәк булып чыктылар. Бөтен факультетның бердәм күтәрелүенә шатланырга да, ахыры нәрсә белән бетәсен чамалаганга, кайгырырга да белмичә башымны тотып утырам. Үз хокукларын яклый белүгә, кыюлыкка үзебез үк өйрәтергә тырыштык, шул ниятләр тормышка аша башлагач, куркытылган буын вәкилләре, югалып ук калдык. Бу хәлләр хәзерге үзәкләштерелгән хакимият

заманында булса уйланып утырырга, мәйданда озак басып торырга ирек бирмәсләр, оештыручыларны кулга алып, башкаларын куып таратырлар иде. Әнә бит 2011 елда Казан дәүләт университетының шундый авырлык белән ачылган татар факультетын саклауны таләп итеп бер төркем студентларны урамга алып чыккан декан урынбасары, яшь галим, доцент Радик Сабировтан чын диссидент ясап, олы сәясәтне анламауда, корткычлыкта гаепләп, урынбасарлыктан азат итәләр. Яңа урындагы житәкчелек тә, кыюлыгы өчен хуплау урынына, аңа кырын күз белән карый, ышанычсызлар рәтендә йөртә. Ә ул студентлар белән уртак тел тапкан, тулай торакта төрле очрашулар оештырып, концертлар, спорт бәйгеләрендә факультетны мактаулы урыннарга чыгарган ифрат булдыклы егетләребезнең берсе. Житмәсә, деканатның икенче бер житәкчесе, өеннән килеп, студентларны әрләп, ачуланып, университеттан куып чыгару белән куркытып, бинага алып кереп киткән.

Мина деканатта озаклап оеп утырырга туры килмәде. Бүлмәгә шакып та тормыйча (бәлки, уйга талып ишетмәгәнмендер), төз атлап милиция әһеле килеп керде. Погоннарын білгән өч зур йолдыз буенча мин аның полковник дәрәжәсендәге кеше икәнен шәйләдем. Өстәл янына килә-килешкә:

— Мөмкинме, исәнмесез, — дигән ике сүзне кысып чыгарып, кулын козырегына тидереп алган арада, хәрбиләрдә кабул ителгәнчә, отып, аңлап алмаслык кимәлдә, тиз-тиз генә «полковник фәләнов» дип өстәде. Шакировмы, Низамовмы кебегрәк хәтердә калды. Татар мәктәбендә укыганлыгы сөйләменнән сизелеп тора. Очратсам, хәзер дә таныр идем. Уң як битендә күз төбеннән авызы янына хәтле дип әйтерлек, инде төзәлгән булса да, ярасы эчкә батып торган пычак эзе беленеп тора. Бәлки Чечня истәлегедер. Үзеннән сорап булмый. Уртачадан калкурак буйлы, тулы гәүдәле (минем арык полковникны очратканым булмады) ир уртасы кеше. Ул инде күптән лаеклы пенсиясен санап өендә яисә берәр шәхси саклау оешмасында утыра торгандыр.

— Сезнең факультет студентлары Ленин памятнигы каршында басып торалар. Шуны беләсезме? Өстән күргәннәр, «корреспондентлар фотога төшереп алганчы, немедленно таратыгыз», дигән әмер килде.

— Соң, таратыгыз, мин каршы түгел, — дим, башны җүләргә салып, монда минем ни катнашым бар дигәнне аңлатырлык чырай «ясап». Детектив фильмнарда җинаять кылган кешеләр кыланышын кабатлап:

— Мине кулга алырга килгән булсагыз, рәхим итеп, ордерыгызны күрсәтегез!

Ул, минем чытыклануыма исе китмичә, үз сүзен дәвам итте.

—Студентларга карата көч кулланмаска кушылды. Зурга китәр диделәр.

— Сез аларның таләпләрен үтәсәгез, ягъни иптәшләрен азат итсәгез, үзләре дә кайтып китәрләр.

— Әлегә тикшерү бара. Анысы миннән генә тормый. Сәгать икеләрдән соң аны җибәрерләр дип уйлыйм.

Погонлы кешенең гасабилануы тавышының дулкын өстеннән барган көймә шикелле калтырануыннан сизелә.

—Миннән нәрсә сорала?

— Аңламаганга салышып утырмагыз инде, бергә барып, студентларны таралышырга күндерик.

Лифтка утырып, аска төштек. Икенче уку бинасының баскычы янында ук чем-кара, өр яңа «Волга» машинасы көтеп тора икән абзагызны.

Абруйлы урынны иң кадерле кунагына биргәндәй, полковник җәһәт

кенә алгы ишекне ачып, мине утыртканнан соң, үзе арткы утыргычка кереп сыенуга йөртүчесенә металл тавыш белән:

—Ирек мәйданына, опера театры янына иттек. Тиз селкен! — диде.

Яшь шаян язучылар Мәһдиевнең алга утырып, һаваның нинди булуына карамастан, терсәген ачык тәрәзәдән чыгарып баруыннан көләргә яратсалар, минем шул мизгелдә Шәүкәт абый Галиевнең, «р»ны «г»га алыштырып сөйләшүе искә төшеп, елмаеп куйдым: «Кагале, бу халык агасында да рәтлеләге баг икән», дияр иде кебек ул.

Тиешле урынга бик тиз килеп җиттек. Студентларым опера һәм балет театры бинасы ягына карап, өчәр рәт булып (ул елларда армия хезмәтен үткән егетләр шактый иде), хәрбиләрне көнләштерерлек итеп, атакага әзер колонна кебек, басып торлар. Сөйләшү дә, көлешү дә ишетелми. Сәер тынлык. Факультетыбызның зур, күп санлы икәнен белсәм дә, электр йә телефон чыбыгына оялаган кошлар кебек бер рәткә төзеп, бастырып караганым юк иде. Теләсән дә моны эшләп булмый: урыны да, форсаты да табылмас иде. Менә алар чын милләт балалары, халкыбызның йөзек кашлары, хакыйки байлыгы дип уйлап куйдым.

Тәвәккәлләр, кыюлар. Милли мәнфәгатьләрне яклап күтәрелгән студентларга, аларга белем бирүчеләргә сукыр бер тиене дә тәтемәгән кара алтыны, каучугы, синтез-минтезлары безнеке түгел. Аларның рәхәтен тар даирә генә күрә. Ә бу балалар безнең киләчәгебез, таянычыбыз! Мәдәнияткә, мәгърифәткә, тыйбка тиешле мөлкәтебезне имеп ятучы хоккей, футбол командалары кемнәр өчендер шөһрәт, мал чыганагы гына.

Мәгәр полковник мине Ирек мәйданына сентиментка бирелеп, балавыз сыгып, студентларым белән соклану, тәэсирләнеп хискә бирелү өчен алгы рәткә утыртып алып килмәгән иде. Урынбасарым Таһир Гыйләҗев студентлар кырында икән. Ул вакыты белән кабыгы ватылмаган чикләвек төше кебек иде. Бу очракта да аның студентларны факультетка кайтырга өндиме, әллә инде таләпләрен үтәмичә, урыннарыннан селкенмәскә үгетләп йөриме, анысын аңламый калдым. Стипендияләр, тулай торакка урыннар бүлүче кеше студентларның иң зур дусты да, үзенә иганәсе эләкмәгәненең «дошманы» да иде.

Студентларның миңгә якын күз карашы алдында (ул чорда 500 дән артык талибыбыз бар иде) бер мизгелгә үзем дә каушап калдым һәм әүвәл, араны киеренкеләндермәс өчен, сүзне сәламлаудан башларга булдым.

—Бүген әле безнең күрешкәнебез юк. Исәнмесез, студентлар.

—Исәнмесез!

— Иптәшегезне яклап чыгуыгыз дөрестер, бәлки. Әүвәл декан белән киңәшергә кирәк иде. Мин ректоратка, тиешле оешмаларга чыккан булыр идем. Минем янда басып торган иптәш полковник егетебезне сәгать икедә азат итәбез, формаль кәгазьләр тутыру гына калды, ди.

Мине монда алып килгән кешене үз фикеремә бәйләп кую өчен аның ягына борылып, «шулай дидегез бит, иптәш полковник», дип, сүземне тәгәлләдем. Аның башын селкеп, килешүдән башка хуты калмаган иде.

Студент халкы вәгъдәләргә ышанырга ашыкмый. Ана жылырак сүз әйтү лазем иде.

— Кадерле укучыларым, сезнең төп бурычыгыз уку, үзегезне факультетта мөхтәрәм профессорлар көтеп утыра. Әйдәгез, акрынлап белем оябызга кайтыйк. Кулга алынган студентны азат итүне үз өстемә алам, — дигән фикеремне, таралышырга чакыруны Таһир да кабатлагач, яшьләр ышанырышанмас кына университет ягына кузгалдылар. «Бергә кайтырбыз, мине машина көтә», дип урынбасарымны да чакырып, вәкарь генә атлап, кара

«Волга»ны калдырган җиргә барсак, үз вазифасын намус белән үтәгән полковниктан да, машинадан да җилләр искән иде. Мин шунда Наполеонга Алжирда француз гаскәренең җиңү хәбәрен алып килгән мавврның кирәкмәгән кешегә әйләнгән хәлен аңладым. Иң кыска юлны сайлаган студентлар артыннан тәпи-тәпи «өйгә таба» (Г.Исхакый) атладык. Без гидайларны төп башына утырткан, агач атка атландырып калдырган кара полковникны артык очратмадым. Күрәсең башка кирәгем чыкмагандыр. Алар бит эш кешеләре.

Шул көнне үк хибестән чыгарылган, мәгәр егетлеген югалтмаган, сынмас-сыгылмас рухлы Рамай диплом алгач, Казанның бер гимназиясендә укыта башлады, иҗтимагый тормышта, татар мәнфәгатьләрен яклауда эшчәнлеген дәвам итте. Ул хәзер Марий Эл башкаласы Йошкар-Олада яши, эшли, татар иҗтимагый хәрәкәтенең узаманнарының берсе икән. Мари кызы белән кушылып, гаилә корып җибәргән, хәзер хатыны белән баласын татар теленә өйрәтеп ятмыш, чын татар байлары кебек (аның тәхәллүсе бездә «Чапай» булса, хәзер аны «хан» дип йөртәләр, ди) хәләл җефетен эшләтми икән дигән әйбәт гайбәт тә безнең колакларга килеп инде.

Карсак гәүдәсе, саргылт чәче, зәңгәрсу күзләре, тамак төбендә оешкан тавышы буенча егетне татарлашкан мари дип бәяләргә мөмкин. Аның күңелендәге өздереп әйтә белүе, гыйсъян рухы, кыюлыгы сокландыра да, кемдер әйткәнчә, ана карынында ук куркытылган өлкән буынны өркетеп тә куя. Ул Мари башкаласына килеп чыккан театр коллективларын, артистларны каршы алып, кадер-хөрмәт күрсәтеп озатып кала, диләр. Рамай һәр елны үзенең укучыларын, татар яшьләрен Тукай көннәренә — шигырь бәйрәменә алып килә. Сүзе гел милләт язмышы турында.

— Татар рухы Йошкар-Олада Казанга караганда көчлерәк сизелә. Мин анда күбрәк файдалы эшләр башкарам, — ди ул үзен юатып, әйтерсең лә, аңа табу салган кешеләр кулыннан идарә дилбегәсе киткән дә, Рамайны бик сагынып-саргаеп кире чакырып торалар. Милләтнең киләчәге өчен көрәшеп яшәгән, көчле рухлы затларны бер урында гына котәләр шул.

Мин юри аны ирештереп:

— Син анда яшәгән һәм татар иҗтимагый үзәге белән җитәкчелек иткән өчен саклана торгандыр ул рух?

Ул минем кинаяле төрттерүемне колагына да элмичә, җитди фикер дип кабул итмичә, үзенекен туглый:

—Татарстанның суверенитетыннан ни-нәрсә калды соң?

Мин ыкы-мыкы килеп, ниндидер үзенчәлекне табарга тырышам.

—Ә мин беләм.

—Йә, әйтеп кара әле!

— Туксанынчы елларда ирешелгән ярым-йорты бәйсезлектән Шәймиев бабай гына калды.

Беренче президентыбызның Гуманитар институтны, Казан санаториен, татар факультетларын бетерүгә, Тукай йортын җимерүгә юл куюын хупламасам да, аны «мари егете»ннән хурлатасы килми.

— Сәяси киңәшче буларак та ул зур эшләр башкара. Болгар чоры мөселман истәлекләрен торгыза... Рамайның Казанны алу терәге булган утрауны яратмавын белә торып, юри «Свияжскийны рәткә кертә», — дип ычкындырам.

— Болгар торгызылыр ди. Ул кемгә кирәк булыр, анда бит яшәүчеләр юк, ә хурлыклы Свияжскины торгызу бик кирәкле эш дип саныйсызмы?

— Без, өлкән буын, Минтимер Шәриповичның чордашлары, аның

һаман да ялга чыкмыйча, үзенә шөгыль табып, борчылып яшәвен хуплыйбыз.

Йошкар-Ола егетенең беренче президентыбызга катырак бәрелүен Казанда булган хәлләр өчен үпкәсе дип кенә кабул итсәм дә, заманында Рамай кебек милләтпәрвар, үз сүзен өздереп әйтүдән курыкмаган кыю егетләрне әзерләп кала алган милли күтәрелеш җимеше — татар факультетының үткәне белән горурлану хисе күңелемне җылытты.

## Хастаханә мәктүпләре
## Беренче хат. Обком бульнисе

Коммунистлар фиркасенең өлкә комитеты дигән дәһшәтле оешмасы күптәннән гаип булып, исеме дә олы буын хәтерендә генә сакланса да, биналары шул чорда төзелеп, хастаханә буларак аякка бастырылып, халык аңына һәм теленә «обком бульнисе» буларак сеңеп калган, мәркәзебезнең урта бер җиренә, төгәлрәк әйткәндә, Чехов базары янына оялаган дәвалау үзәгенең рәсми исемен үзгәртсәләр дә, аны күпчелек элеккеге исеме буенча белә. Керү ишеге янындагы тактага республиканың икенче клиник хастаханәсе дип язылса да, бик сирәк кеше аны яңа исеме белән атый. «Ирен яисә хатының кайда ята», дигән сорауга горурлык белән диярлек, «обком бульнисендә» дигән җавапны ишетергә мөмкин. Кыскасы, анда үзе дәваланган, таныш-белеше яткан, шунда урнаша алмаган көнчеләр өчен дә ул сүнгән фирка хастаханәсе булып кала бирә. Озын телләр житкергәнчә, ошбу дәвалау үзәген үткән гасыр урталарында, максатчан рәвештә, югары даирә мәэмүрләрен (чиновникларын, укы: обком түрәләрен) дәвалау, махмырдан тизрәк арындыру, ахыр чиктә кешечә ял иттерү өчен төзелгән диләр. Бу фаразга мәрмәр баскычлы мәһабәт бина эчендәге җиһазлар, җайлы бүлмәләр, ашау-эчүнең башка хастаханәләр белән чагыштырганда әгъләдән булуы һәм хозурланып йөрү, буш вакытны уздыру, төрле дәрәҗәдәге сөйләшүләр алып бару өчен ифрат уңайлы, Сочиның атаклы диндрариендә үскән барлык агачлар диярлек утыртылган бакчасы дәлил була ала. Шунысы да хак: анда эшләүче табибларны мөккибән китеп, авыз суларын корытып мактаган чирлене очратканым булмады. Беренче мәлдә анда эшләү өчен табибларны җиз иләк аша уздырып, өстән иңгән күрсәтмә буенча, ата-анасының билгән кәнәфиен искә алып кына кабул иткәннәр, диләр. Мондый катгый «селекция» дәвалау сыйфатына ни дәрәҗәдә ярдәм иткәндер, гөнаһысын өстемә алмыйм. Совет хакимлеге чорында бездәй язу-сызу, укыту эше белән мәшгуль мәхлукларны бу йортка якын да китермиләр иде. Демократия җилләре сызгырып, обкомнар исемнәрен алыштыргач, ошбу хастаханәнең яшәү рәвеше дә үзгәреш кичерде. Кысынкырак бүлмәләрдә утырып, чәен үзе ясап эчәргә мәҗбүр булган урынбасарларга, бүлек мөдирләренә, профессор, исемле язучы, каләмен кая юнәлтергә икәнен тәгаен чамалаган журналист, милли мәүзугъ белән артык мавыкмаган рәссам кебек әһелләргә, хастаханәнең бусагасыннан үтеп керергә рөхсәт ителә башлады. Анда дәвалануга рөхсәт алу өчен хөкүмәт кешесенең имзасына лаек булу лазем. Хастаханәнең эшчәнлегендә бер үзгәреш ачык сизелә: табиблар, шәфкать туташлары арасында дипломнарын үз хәләл көчләре белән алган, эшләренә ихластан бирелгән сәләтле шәхесләр дә пәйда була башлады. Мәгәр баш табиб, аның урынбасарлары, бүлек мөдирләре кебек төшемле урыннарда үткән гасырның соңгы елларында совет чоры «чыныгуын» узган, арка терәге нык булган инсаннар утыра. Алдарак киная ителгәнчә, анда дәваланып, ятып чыккан кешеләрдән «обком бульнисеннән» терелеп, чиремне калдырып

кайттым (бәлки ул мөмкин дә түгелдер) дигән раслауны ишетергә туры килмәде. «Ярый инде шунда, система алдым, дөнья мәшәкатьләреннән арынып, хатынның мырлавын ишетми тордым, элеккеге дус-иш, танышбелеш илә аралаштым» диючеләрне күбрәк очраттым. «Дөрес диагноз куя алмаулары нәтиҗәсендә «обком бүльнисеннән» үземне начаррак хис итеп чыктым», дип зарланучылары күбрәк тә булгандыр. Исән саналган кеше тиешенчә тикшерелмәгән өчен генә сәламәтләр рәтендә йөри диләр түгелме соң?

Бу фикерем буш сүз, бигрәк тә яла ягу дип кабул ителмәсен дип иң «сбежий» мисалны китерәм. 2011 елның август аенда аяк шәрифләре хуҗаларын тыңлаудан баш тарткач, Г.Камал театрының әйдәп баручы, өлкән артистларының берсе — Ирек Баһмановны обком бульнисенең неврология бүлегенә салдылар. Дөресе, мәшһүр артистыбызны ике көпчәкле арбада алып керделәр. Мин аны шунда ук таныдым. Тавышы язучыларыбызның, аерым алганда, М.Мәһдиев әсәрләрен укыгандагы шикелле ягымлы да, буйсындыручан усал да. Сәхнәдә ул һәрвакыт бәясен белеп, үзен һавалырак тоткандай тоела иде. Биредә ул яклаучысыз калган сабый бала шикелле. Үз өендә, ике бүлмә арасына куела торган тактага абынып, иңен имгәтеп, шуны дәвалап йөргән мәлдә, аяклары хуҗаларын кешегә «санамый» башлаганнар. Хәрәкәтсез калулары гына җитмәгән, чәлтерләре гел кайнар суда тоткандай сызлыйлар икән. Палатада без икәү. Күршемдә Маликов Михаил Степанович — Ключище кирпеч заводының баш механигы. Нәкъ Тукаебыз шикелле, әтисен хәтерләми, аңа өч ай вакытта татар әттәсе вафат була. Әнисе рус кешесенә, әтисенең дустына кияүгә чыга, (бәлки малайны шулай тынычландыргандыр). Аны улы итеп таныган яңа папасы Мәхмүтне Михаилга әйләндереп, Степанович дип яздырса да, егетнең үз фамилиясен калдыра. Ул үги әтисенә шуның өчен бик рәхмәтле. Михаил татар кияве белән горурлана, аның һәр эшкә кулы ятып торуын сөйләп туймый. Ирек абый белән танышканда ул үзен Михаил-Мәхмүт дип тәкъдим итте. Тик сөекле сәхнәчебезнең үз хәле-хәл, аяклары хуҗаларын диварга сикерерлек дәрәҗәгә җиткерә. Авыртуын онытырга тырышып Ирек абый мәзәкләр, булган хәлләрне, үз тормышыннан төрле күренешләрне сөйли. Ул да, Шәүкәт Биктимирев кебек, хатыны вафат булганнан соң өйләнмәгән, кызы, оныгы белән тора икән. Әмма аякларының сызлавы бик онытылырга бирми. Бик көчле дару керткәннән соң гына берәр сәгать йокымсырап ала да, төннәр буена ыңгырашып ятагында утырып чыга. Без аның сөйләкләрен дөньябызны онытып тыңласак та, сызлау артистның бәрхет тавышына да безнең кебек мөккибән китми, олы шәхесебезне рәхимсез кимсетүен белә.

Хастаханәләрдә диагнозын ачыклый алмаган авыруларны «бу безнең бүлеккә карамый», дип, башка белгечләргә күчерү ягын каералар. Бер атнадан соң, шул ук ике көпчәкле арба белән Ирек абыйны хирургиягә күчерделәр. Гаҗизлектән сабыйланып киткән күзләрендә өмет чаткылары, яшәүгә ышаныч, дәрт күреп аның өчен сөенеп озатып калдык. Янына менеп берничә тапкыр хәлен белештем. Җавап шул ук: «унай якка үзгәреш сизелми, ыңгырашып чыгам төннәремне, инде монда да миннән туйдылар, табиблар бүлмәгә кермәскә тырышалар». Хастаханәдә гадәттә ике атнадан артык тотмыйлар, сәхнә остасын тиздән өенә чыгардылар.

Берничә көннән соң мин аның өенә шылтыраттым. «Туган йортында хәлләрен ничек, абзыкай», дип сорагач, ул болайрак аңлатма бирде.

— Өемә кайтып чәйләп алгач, хирургия бүлеге биреп чыгарган кәгазьне укып карарга булдым. Анда язылганнарны кат-кат күземнән кичердем, күзлегемне алыштырып та карадым. Анда акка кара белән «выписан в связи

с выздоровлением», — дип язып куелган. Исем-акылым китте. Мондый галәмәтне сиксән яшемә житеп күргәнем юк иде.

—Хәзер хәлегез ничек?

—Ашыкмыйча гына рәтләнеп киләм кебек.

—Өй һавасы килештеме?

— Мине сәламәтләндерү шөгылен театрыбызның директоры Шамил Зиннурович үз кулына алды.

— Соң ул төп белгечлеге буенча химик бугай, табиблык белеме дә бармы әллә ? — дигән булам.

— Шамил энекәш бөтен мәсьәләдә безнең төп таянычыбыз. Минем өйгә кайтуымны белүгә таныш табибы белән килеп тә житте. Сораштыргач, тикшергәч, зур фанера такта китертеп, абзанны шунда жәеп салдылар. Хәзер инде икенче атна, гырда өстендә яткандай, катыда яшим. Шунысы гына житмәгән, беренче көннән үк ике яктан тотып, кычкыруыма, бакыруыма исләре дә китмичә, бүлмә буйлап йөртә башладылар. Бездә тәртип шундый. Шамил аякка бастыра, Фәрит Бикчәнтәй эш куша. Соңгысы миннән «сез фәлән спектакльдә күренергә тиешсез», дип бик үтенеп сорады инде. Болай булгач, малай, яшибез әле, Алла боерса, 80 яшьлекне аякта каршы алабыз.

Кызганычка каршы, мәрхәмәтле, изге җан Шамил Закиров көтмәгәндә, уйламаганда безне ташлап китте. Татар академия театры аның игелекле традицияләрен саклый алырмы, һәрдаим ярдәмгә мохтаж «баһманнарны» шулай аякка бастырырлык кеше табылырмы?

Хәзер Ирек абый кызы бүләк иткән «мен тәнкәлек» матур таягына «ярдәм» итеп урамда да йөри, сәхнәгә дә күтәрелә. Мине якын итеп, күптәнге дусты, фикердәше кебек исәнләшә, шаярта, үрти.

Күрәсең, кешеләрне уртак язмыш, кайгы-хәсрәт тәсбих төймәләредәй бер жепкә тезә. Адәм балаларын иң якынлаштырган, гомерлек дуслар ясаган яисә дошманлаштырган урын төрмә, диләр. Гаяз Исхакыйның Архангельск зинданында Польшаның булачак Президенты Ю.Пильсудский белән утыруы мөһажирлектәге тормышын жиңеләйтүгә, татарча журнал-газеталар чыгаруга матди мөмкинлек бирә. Ярдәм итә алмаса да, маршал К.Ворошилов та Исхакыйга уңай карап, яшисе килсә, Советлар илендә күренмәве хәерлерәк дигән киңәшен житкерә.

Кешеләрне якынлаштырган икенче урын — ул хастаханә. Ихласи дусларны шунда гына табып була дигән ышаныч көннән-көн күңелемдә тирәнрәк тамыр жибәрә. Гомеремне югары уку йортлары системасында үткәргән кеше буларак, мисалларны да шуннан китерәм. Кадерлесең укырга керү нияте белән килгән ата кеше бер алдыңа, бер артыңа төшә, мактау сүзләренең энже-мәржәннәрен тезә, гомерлеккә турылыклы дус булып калырга вәгъдәләр бирә. Мәсьәлә хәл ителгәч, хисләр ялкыны сүрелсә дә, беренче сессия узганчы, элемтә өзелми. Бердәнбере яхшы гына укып китсә, синең кирәгең калмый. Соңыннан бөтенләй онытыласың.

Хастаханәдә тапкан аркадашларың бөтенләй башка икән. Бирелә якынлыкны уртак язмыш тудырган рухи жепләр бәйләп тота. Өч-дүрт ел элек кышкы каникуллар вакытында 12 нче шәһәр хастаханәсенең баш табибы, күп еллар дәүләт Советы депутаты булып торган, милли жанлы Тәүфикъ Сафин дәваланып чыгарга дәште, ике ятаклы бүлмәгә берүземне урнаштырды. Берничә көннән соң төнге сәгать унберләрдә «вакытлыча кертеп торабыз», дип илле яшьләрдәге бер ирне буш ятакка кертеп салдылар. Акны-караны күрми, бик авырлык белән, ыңгырашып кына сулый. Өендә үзен бик начар сизә башлагач, ашыгыч ярдәм машинасын чакыртып, хастаханәгә китергәннәр.

Кизү табиб чирлененң йөрәген тынлаган, караган булды да, уколлар кадатып чыгып та китте. Хатынын да өенә кайтарып җибәрделәр. Бүлмәдә икәү генә калдык. Бераздан күршем күзен яртылаш ачып, су сорады. Татар кешесе икән. Бәхеткә, алма согы, чишмә суы, ясалган чәем дә бар иде. Башын күтәребрәк эчердем, ярылган иреннәре арасыннан рәхмәт сүзен кысып чыгарып, егетем йоклап та китте. Табиблар кергәнче, хатыны килеп җиткәнче, мин аны янә су белән кат-кат «сыйладым», ә көндез ул урынына торып утырып, кичен йөри үк башлады, кризисы үтеп тә китте.

— Тәлгат абый, сез кичен биргән сок мине терелтте, — дип минем күнелне күрерлек дәрәҗәгә дә җитте.

Күршем — төзелеш фирмасы хуҗасы Хөсәенов Равил Миргазиз улы ике көннән түләүле, затлырак бүлмәгә күчкәч тә мине ташламады.

— Күркә ите салып пешерелгән коймак китергән иде хатын, җылы чакта ашап алыйк әле, — дип килеп керә, йә коридорга сөйләшеп утырырга чакыра. Равил китап ярата торган кеше булып чыкты. Заманында Чиләбе шәһәрендә китап сәүдәсе белән шөгыльләнеп алган икән.

Хастаханәдән чыккач та, ул мине онытмады. Аена бер булса да, телефоннан хәлне белешеп тора, нервларын тынычландыру өчен табиблар умартачылык белән шөгыльләнергә кушканнар икән, беренче балыннан да авыз иттерде. Хатыным Фәүзиягә туган авылы Олы Солтаннан бакча кишәрлеге бүлеп биреп, шунда өй салырга уйлагач, иң беренче кинәшчебез, ярдәмчебез Равил булып чыкты. Ә кирпечне каян алдыгыз, сездә укып чыккан берәр шәкертегез, туганнарыгыз, күптәнге дусларыгыз ярдәм иткәндер дип уйлыйсыз инде сез һәм бик нык ялгышасыз. Хастаханәдә табылган дустым Маликов М.С. мәрхәмәтеннән ташламады. Чын дуслык адәм баласына авырлык килгәндә сынала икән шул.

## Икенче хат.
## Чирне сорап алмыйлар...

Күренекле артист Ирек Баһманов обком бульнисенә авыр чиреннән котылу нияте белән, ике көпчәкле «такси»да килеп инсә, мин бу оешмага үз аягым белән йөгереп килеп кереп, авыр чирне шунда эзләп табып, аннан маймыл кебек үрмәләп диярлек чыктым.

Хикмәт шунда иде: 1999 елнын көзендә сул як тезем сызлавына бирешеп, дөресрәге, Г.Камал театрында алтмыш еллыгымны уздыру мәшәкатьләреннән котылып ял итәрмен дип кенә кергән идем, обком бульнисендә үземне инсульт дигән иң зәхмәт авыру эзләп тапты һәм инде менә унике ел шунын шаукымын татып сул аягымны артык күтәрергә «яхшысынмыйча», кан басымын «тәртипкә чакырып», гомер сөрәм.

Чит ил фильмнарындагы шикелле «бу урында тәфсилләбрәк» — дигән сорауны бердерәсе килә укучымнан. Кара-каршы утырсак, иманым камил, ул бу хакта сөйләвемне үтенер иде.

Чир ишекне шакып, рөхсәт-мазар сорап тормыйча, каядыр посып торган ерткыч шикелле, кинәт өстенә ташланып сугып ега икән. Моны кемнәндер ишетеп кенә түгел, ә үз ачы тәҗрибәм буенча беләм. Ошбу вакыйганы онытасы, телгә аласы килмәсә дә, ул үзе турында, теш сызлавы мисле, гел искә төшереп тора. Ходай Тәгалә мина, ышануымча, авыруның иң әшәкесен һәм гыйбрәтлесен — инсульт, халык телендәгечә, паралич дигәнен җибәрде. Мен дә бер төрле чирләр арасында максатчан уйлап чыгарылган, бәла-казадан котылу чарасы буларак кулланылганнарын санамаганда, фани дөньяда үзең ялынып, сорап алган яхшы авыру юктыр. Күз буяу, алдалау, хәрәмләү нияте белән хастага «сабышкан каһарманнар»

әдәбиятыбызда күптәннән кояш яктысына чыгарылып килә. Үткен каләмле, күзәтүчән Г.Камал әле буржуаз мөнәсәбәтләр урнаша гына килгән XX йөз башында, шул ук гасыр ахырында гадәти, типик булып китәчәк хәл-әхвәлне «Банкрот» комедиясендә, әҗәтен түлисе килмичә, акылы алышынган, җүләрләнгән кешедәй кыланган Сиражетдин образында бу вәзгыятьне гаять зур осталык белән гәүдәләндерә. Безнең чорда кредит алып качу, ширкәтенең, үзенең юкка чыгуы, исем-фамилиясен алыштыру, һич югында хастаханәгә кереп яшеренү гадәти хәл, заманыбызның бер үзенчәлеге булып бара.

Тормыш шартларын яхшырту нияте белән соңгы тиененә чаклы тәмле телле узгынчыларга илтеп биргән, мыегы гына чыланып калган алданучыларны зәңгәр экран һәр көнне күрсәтеп тора. Жинел яшәү алымнарына өйрәткән телесериалларның да чуты юк. Эзәрлекләнүдән качып котылуның иң кулай юлы — сары йортка — психбольницага килеп сылану икәнлекне Зөлфәт Хәким каләменнән төшкән «Җүләрләр йорты» драмасының геройлары яхшы белә. Бер булдыксызы кыскартудан, икенчесе бурычын түләүдән качып, «бәхетләрен» шул серле клиникада табалар.

Әлбәттә, иң зур күпчелек чирне үзе теләп, сорап алмый. Кешене үрмәкүч дәрәҗәсенә төшергән авыруны күренекле шагыйребез Рөстәм Мингалим яисә терекөмеш кебек хәрәкәтчән, элгер, гаярь журналист, язучы Җәүдәт Дәрзаман бу афәтне үзләре эзләп таптылармы? Ничәмә ничә еллар дәвамында ятакта аунап яту яисә, читлектәге кош кебек, дүрт дивар эчендә яшәү тормышка мәхәббәт уята аламы?

Йөрәк, бавыр, умыртка, ашказаны, диабет ( халыкча бирән авыруы), аяк-кул сызлау кебек чирләрнең берсе дә, кичен әйбәт кенә сыйланганнан соң, иртәнге сөтле чәй кебек ләззәт бирмәсәләр дә, бу хасталарга тарган кешеләр матур итеп, фасонын китереп, аксап-туксап йөреп көлдермичә, арабызда кешеләрчә яшиләр. Ә инсульт, син кем дә мин кем дигәндәй, кешенең тышкы кыяфәтен танымаслык хәлгә китерә. Йә уң, йә сул якның кулы, аягы чөйдә эленеп торган аркан хәленә килә, күзләр акая, иреннәр чалшая, җилкәнең бер ягы өскә менә, икенчесе аскарак төшә, умыртка баганасы турылыгын югалта... Беренче мәлне читтән ярдәм өметләнеп, кашыкны, кәсәне исәнрәк кулыңа тоттырганны көтеп, бүрәнә кебек аунап ятасың... Бу авыру кешенең хисләрен өскә чыгара, иреннәр көчкә эленеп торган көзге яфраклар кебек дерелди, күзләр тозлы су белән тула, ягъни ул кешенең ихтыярын, яшәүгә дәртен сындыра, сихерче кебек, селкенмичә, тын гына, урында ятарга котыртып, бөтен «шартларын» тудыра. Табиблар вакытында ярдәмен күрсәтеп, ихтыяр көчең житеп, аякка басып, сау-сәламәт күренсән дә, аяк-кулларга элеккеге куәт кайтмый, бу зәхмәт сине эзләп янадан кабатланмасын дисәң, кан басымын даими үлчәп, даруханә сәдәпләрен йотkалап торырга тиеш буласың. Кем әйтмешли, тәрмәнең дә мөддәте була, ә бу чирнең галәмәтләре гомерлек юлдашың булып кала, бик бәхетлеләр генә аның авыр нәтиҗәсеннән арына...

Сүземне юкка гына «обком бульнисе»н искә алудан башламаган идем. Хастаханәдән чыгарга ике-өч көн кала деканатка тиздән эшкә киләсемне житкердем. Ул елны алма бик котырып уңган иде. Җиләк-җимеш, алма алып керим дип Чехов базарына килеп керүем булды, каршымда урынбасарым, XX йөз башы әдәбияты белгече, ифрат тәртипле Таһир Гыйләҗев пәйда булды. Ул да шул ук шөгыль белән йөри икән. Бер-беребезгә карашып кызарыштык та (сәбәбе: ул эш сәгатендә алма сайлап йөрсә, мин хастаханә тәртибен санга сукмыйм), берничә көннән деканатта очрашырга килешеп аерылыштык. Ни хәл итмәк, минем бу фаразым фәрештәләрнең амин

торткан мизгеленә туры килмәгән булып чыкты. Нәкъ шул кичне, соңгы хәбәрләрне тыңлап утырганда, бөтен тәнемдә таныш булмаган сангырау калтырану һәм ниндидер эчке борчылу тойдым. Соңрак ачыкланганча, ул инсультның тәүге хәбәре, ашыкмастан чаралар күрәсе, дип кымтырыклавы булган икән. Мин яткан терапия бүлеге мөдире хастаханә буенча кизү икән, аны табып, хәлемне ачыкларга тырышып карадым. Озын, төз буйлы, ясалма күперткән аксыл чәчле, зәңгәрсу күзле Татьяна Федоровна минем хәвефләнүемне, профессорның иркәләнүе дип кенә санап, җитди кабул итмәде. Кырыс кына киңәшен бирде.

– Сез сау-сәламәт күренәсез. Төнгә аспирин белән йокы даруы эчеп ятыгыз. Барысы да узар.

Яшьрәк чакта, чирләренә үзең табиб булып җитешкәнче, хастаханә хезмәткәрләренә ышанып, аларның киңәшен тотып яшисең. Мин дә табиб кушканча эшләдем, әйбәт кенә йокладым шикелле. Икенче көнне иртән үземне яхшырак хис итеп, кырынып-юынып, соңрак хәтта залга төшеп, җинелчә физик күнегүләр ясап алдым. Бакчага да сәлам биреп кердем. Караңгы төшә башлагач, кичәге халәтем әйләнеп кайткандай булды. Коридорда йөргәндә үземне авыр йөк күтәреп тауга менәргә маташкан кешедәй хис итә башладым. Янәдән дәвалаучы табибымны эзләп киттем. Татьяна Федоровна бинадан чыгып китәргә өлгермәгән иде, аңа тәнем кызыша, аңлашылмый торган дискомфортка тардым дип, булдыра алганча үземдә зур үзгәреш тоюны аңлатып бирергә тырыштым. Җавап кичәгене кабатлаудан узмады.

– Сестрага әйтеп калдырырмын. Сезгә соңрак аспирин белән йокы даруын бирер. Барысы да узар.

Йөрәкне тыңлап карау, кан басымын үлчәү кебек түбәнлекләргә төшмичә, докторым кайтып та китте.

Өченче көнне иртән бик авырлык белән генә урыннан торып, юынгандай иттем дә, янәдән караватыма барып егылдым. Шәфкать туташы аша табибны чакыртып карадым, ул бераздан гадәти җавап белән килде: «хәзергә эшем күп, үз вакытым белән килермен». Вәссәлам. Синең хәлең начарланып китүдә берәүнең дә эше юк. Ятагымнан күтәрелеп, үзем тотынып булса да, врач янына барыйм дип, узып барышлый кием шкафына кадакланган көзгегә күзем төште. Билләһи дим, үземне танымадым. Өске иреннең сул ягы авызны, җим көткән кош баласыдай ачыграк калдырып, күз тарафларына ук менеп киткән. Бер күз кысылган, бит очлары пешкән алманы хәтерләтеп торалар. Чарли Чаплин сүзсез фильмнарында яратмаган кешеләрен шулай мыскыллый иде. Күрше караватта яткан иптәшемә, «карале, минем авыз нишләп чалшаеп киткән икән», дип сүз катмакчы булам, мәгәр тел буйсынмый, кыска гына җөмләне дә оештырып чыгара алмый, авызга бозлы бияләй тыкканнар диярсең. Минем нәрсәдер әйтергә теләп, мыгырдануыма игътибар итеп, ул йөземә, гәүдәмә күтәрелеп карауга, табибны эзләп чыгып китте. Хәлемнең мөшкеллеген чамалап, кичтән хатыным Галиягә шылтыратып, үземне начар хис итүемне әйтеп калган идем. Ул үзе дә табиб, күзе белән күрмәсә дә, минем юк-барга борчымаганымнан чыгып, эчке тоемы белән сиземләп, хәлемне аңлаган һәм ярдәм итәргә кирәк булыр дип, авылдашым, гаҗәеп игелекле, ярдәмчел шәхес Илдар Камаловны да алып килгән (бик кызганыч, алар инде икесе дә гүр ияләре). Эшнең нәрсәдә булырга мөмкинлеген сиземләгән бүлек мөдире, тулы җаваплылыкны үз өстенә алмас өчен, Есин фамилияле невропатологны да ияртеп килгән. Шул мизгелдә минем кыяфәт буенча хәлемне, дөресрәге, чиремне билгеләү өчен табиб булу кирәкмәсә дә, диагноз куюның Әбугалисина заманыннан ук килгән, күбебезгә мәгълүм

«процедурный» башкатыргычларын кулландылар. Алар: ике кулын белән табибның бармакларын кысып карауны, кечкенә ялтыравык чүкеч артыннан күз алмаларын уннан-сулга, аска-өскә йөртүне, тез асларына, беләкләргә суккалауны, күзне бер йомып, бер ачып, борын очын табуны эченә ала. Шуларны үтәгәннән соң, ишекле-түрле йөреп карарга тәкъдим итеЛә. Чапаевның академиягә укырга керү имтиханнарын тапшыруыннан көлгән мәзәктәге шикелле, беренче җинел сынауларны якынча булса да ерып чыктым, әмма идәнне үлчәп йөреп карарлык хәл тапмадым, җирнен тарту көченә карыша алмыйча, сыгылып төштем.

– «Инсульт» булырга тиеш дип, бик зур «ачыш» ясап, нервылар белгече эре генә чыгып та китте. Галия белән Илдар мине хастаханә киемнәренә төреп, ике тәгәрмәчле арбага утыртып, җиденче катка, реанимация дигән бүлеккә күтәрделәр. Нәкъ унбер көн, ташландык бүрәнә шикелле, шунда аунап, дәваланып яттым.

Мин соңгы өч көн дәвамында инсульт белән яшәгәнмен икән. Үземне начар сизә башлаган беренче көнне үк урында ятып, тиешле даруларын капкаласам, авыру бу хәтле котырынып, минем сул якны бөтенләй хәрәкәтсез хәлгә китерә алмаган булыр иде. Өйдә булсам, тәнемдә үзгәрешләрне сизүгә ашыгыч ярдәм чакыртып, диагнозны тизрәк куйган булырлар иде дип тә уйлыйм. Бәлки, мондый аяныч хәлгә төшмәгән дә булыр идем. Нишләмәк кирәк: язмыштан узмыш юк, син күрәсен башка берәү дә күрми, диләрме әле.

А.Ситель «Гимнастика для сосудов» (М., 2009) исемле китабында болай дип яза: «Инсульт кичергән кешегә вакытында ярдәм күрсәтелмәсә, һәр минуты баш миенең 1,9 миллион күзәнәген (клеткасын) югалтуга тора». Минем бу чирне үземдә йөрткән ике көн ярымны дәкыйкалар белән санасаң, күпме күзәнәкнең үлүен хисаплау өчен безгә таныш саннар гына җитмәскә мөмкин. Исән калган күзәнәкләре дә, үз кадерен белгән чибәр кыз шикелле, гаять «кәпризле», гел үзенә игътибар таләп итеп торалар.

«Теге дөньядан кайтару», ягъни реанимация бүлеге үзе бер дөнья икән. Анда беркемне, иң якын кешеңне дә кертмиләр, ризык-мазар да кабул итмиләр. Печән аланы хәтле бүлмәдә, казармадагы яисә хибестәге[1] шикелле, идәннән бер сөям генә биегрәк, (егылып төшә калса) тигез рәткә тезелгән, йөрү өчен араларында урын калдырылган караватларда ап-ак җәймәләргә төрелгән төрле язмышлы ун-уникe кеше тәгәрәп ята. Чирлеләрнең барысы да ир-ат затыннан, һәммәбезгә туктаусыз сыек дару агызып торалар. Алдында, диварда эленеп торган экранда кан басымың, йөрәк тибешен, пульсың күренеп тора. Каршыдагы диварга уелган кечкенә тәрәзәләр аша сине дөньяви фәрештәләр — шәфкать туташлары күзәтеп утыралар.

Беренче көннәрдә бүлмәдә ятучылар белән кызыксынырлык хәлем юк иде: йә йокладым, йә югалган аңымны эзләп, күземне йомып яттым. Уң ягымдагы ятакта минем шикелле үк бер диванасы паралич белән аунап ята икән, сул ягымдагысына һава җитми, тончыга, ыңгыраша, уң якта бер карават аша яткан адәм баласы торып утырырга маташа, чыгу ишеге янында урнашканының тавышы-тыны ишетелмәү буенча фараз итсәң, суына башлаган гәүдәсен санитарлар күтәреп алып чыгып баралар. Көннәр буена ап-ак акшарга буялган түшәмгә багып ятканда, монда бит кешелек яшәешенең кыскартылган мизгеле уза, моннан исән-сау чыга алсам, тормышның кадерен белебрәк яшәр идем дигән уй күңелдә ныклап урнаша.

Күзеңне йомсаң, төрле төсләр, бердәй киенгән кешеләр, биегән

[1] хибес – төрмә

бүрәнәләр уза. Күңел үзеңә якын затларның рәсемен ясый. Реаль тормыш чынбарлыгы ясалма, хыялый дөнья сурәтләре белән тулыландырыла. Баш миенең бик күп җаваплы күзәнәкләренең үлүе сәбәпле, күргән төшләреңнән берсен дә хәтерләмисең. Төшеңне бөтен ваклыклары белән сөйләп бирә алу үзенә күрә баш миенең сәламәтлек билгесе икән. Йоклаганда күргәннәремне иртән күз алдыма китерә алмый башласам, хастаханәгә кереп, системалар алырга вакыт җиткән дигән карарга киләм. Күп еллык тормыш тәҗрибәм кеше организмының, баш миенең шул үзенчәлегенә игътибар иттерде.

Берничә көннән соң намусым «уянып» киткәндәй булды. «Мин бит ике-өч көннән эшкә чыгам, дип вәгъдә биргән идем, сүземдә тора алмадым, ничектер хәбәр бирергә кирәк». Ручка белән кәгазь сорап алып, «мине тиз генә көтмәгез, чирләбрәк киттем», дип, «эшкә тотынган» идем (кем аша, ничек, ни рәвешчә җибәрәм, ул хакта фикер йөртерлек зиһен юк), кеше укырлык язу урынына безнең беренче әлифбабызны хәтерләткән рун язуы хәрефләре — таяклар гына килеп чыкты.

Сөйләшкән көнне деканатта минем нурлы йөзем пәйда булмагач, «абзый белән бер-бер хәл тугандыр, чирләп киткәндер» дигән хәбәрнең яшен тизлеге белән барып житүе турында хөкем итәрлек җаваплы ми күзәнәге «ялга чыккан» булган күрәсең.

Чынлыкта бит нәкъ шушы көннәрдә, сәгатьләрдә минем аякка басу-басмау яисә калган гомеремдә җан көеге булып ятак белән ике көпчәкле коляскада калу-калмаулар, домокл кылычы мисле, баш очымда эленеп торган чак булган. Иртәнге чыкта яланаяк көтүдән кайтмаган сыерны эзләп йөрүләр, язгы ташу, көзге пычрак, кышкы бураннарда 5-6 чакрым ераклыкта урнашкан күрше Әлмәткә тәпиләп барып кайтулар, җырдагыча, учакта «тәгәрәткән бәрәңге ашап, тәгәрәп үсүләр», соңрак печән чабу, урман кисү, юкә төшерү чорларында табигатьтән чыныгу алган тән, җан, вакытында чара күрмәгән өчен «үпкәләсә» дә, мине сырхау сазлыгыннан сөйрәп чыгару өчен бөтенесен эшләгән булып чыкты.

Бишме, алтымы көн «бүрәнәлек» чорын кичергәннән соң, күзләр яхшырак күрә, колаклар ишетә башлауны «тышкы дөнья» барлыгын аңлауга, кабул итүгә теләк уяну буенча чамаладым.

Без яткан бүлмә белән каршыдагысы арасында диварга дүрт кырлы тәрәзә уеп куелган. Андагы өстәлнең ике башындагы утыргычларда һәрдаим безне күзәтеп, ак халатлы шәфкать туташлары кизүдә тора дигән идем. Дозор — тәрәзә нәкъ минем вакытлы өем — караватым каршысында булып чыкты. Язучылык кызыксынуы уяна башладымы, педагог төпченүе үзен сиздердеме, мин як-ягымдагы уфтану-ыңгырашуларны ишетмәскә тырышып, дикъкатемне тәрәзәнең аргы ягындагы дөнья бизәкләренә юнәлтергә булдым. Чөнки анда яшьлек, матурлык, чын хакыйки тормыш. Үзләрен күрү генә житмәгән, колак шәрифләрен сагайтыбрак тыңласаң, ачык форточка аша тавышларын ишетеп, сүзләрен дә аңлап була икән. Киләчәктә кирәге чыкмаса да, мәсәлән, мин помидор, кыяр, борыч тозлауның серләренә төшендем, безнең хастаханә янындагы Чехов базарында бәяләрнең башка шундый сәүдә үзәкләре белән чагыштырганда кыйммәтлерәк булуны зиһенемә салдым. «Гаепле» затларны да беләм: бәяне шул тирәдә урнашкан затлы йортларда яшәүче түрәләр, депутатлар, яна урыс һәм «иске» татар байлары, ягъни алар әйткәнчә, «толстосумнар» күтәрәләр икән (бу очракта мин шәфкать туташлары ягында икәнемне сиздем). Ниһаять, кайсы табибның «фашист кебек» явыз, кайсысының яхшы күңелле, зыялы, шәфкать туташларын гына түгел, җыештыручыларны да кешегә санавын колакка элдем. Көннәр-

төннәр буена кизүдә утырганда шәхси мәүзугъны читләтеп үтеп булмавы да дәүләт сере түгел. Бер көнне гаилә тормышыннан канәгать ханымның мактанганын, үземнен дә шул бәхеткә өлеш керткән кешедәй, рәхәтләнеп тынлап ятсам, ешрак шәфкать туташларының хезмәт хакының түбән булуыннан зарланганын, берсен юри гел төнге кизүгә куеп, житмәсә йокларга бирмәүләрен ишетеп, чыннан да авыр тормыштан күз төпләре каралган, янаклары эчкә баткан ханымга хисси теләктәшлек күрсәттем. Тулышкан шомырттай кара күзле, чем-кара чәчле, айны хәтерләткән түгәрәк йөзле Ләйләнең өч ел бергә торып та балалары булмау сәбәпле, иренең азгын үгез кебек, ужымга чыккалавын, кичә хәтта кунарга ук кайтмавын, аксыл чәчле, кылыч борынлы, зәңгәр күзле Оксананы йөргән егетенең ташлавын авыр кабул иттем. Шундый чибәр, шәфкатьле хатын-кызны рәнжеткән ирләрне эт итеп әрләп яттым. Шәхси фажигаларын бер-берсенә (һәм мина) күз яшьләрен ак тастымалга сөртә-сөртә сөйләгән ханымнарга берничек тә ярдәм итә алмавым өчен кыенсыну халәте кичердем.

Хәзер аңлыйм: кеше язмышы хәл ителгән оешмада шундый таләпчән, кырыс табиблар да булырга тиеш. Шулай да Ләйлә белән Оксанага, янымa килгәндә, юату сүзе әйтмәкче булып кыймылдыйм да, аларның үзара гына бүлешкән эч серләрен тыңларга ярамаганны исемә төшереп, сул якка салыныбрак төшкән авызымны исән кулым белән капларга ашыгам.

Хастаханәдән чыгуыма жиде-сигез ел узганнан соң, мине иң авыр көннәремдә дәвалаган кызларга кучтәнәч кертеп, хәлләрен белеп чыгыйм дип сугылган, шул бүлектә эшләгән табибтан кызлар турында сорашкан идем, ул аларның (фамилияләрен белми идем, «авылга, бабайга» кебегрәк килеп чыккандыр инде) берсен дә хәтерләми булып чыкты. Ә ул чибәркәйләр һаман да минем өчен гел яшь, моңсу, хыялый гүзәлләр... Бәхетсезлекләрендә дә бәхетле шәфкать туташлары.

Реанимация дигән бүлектән аскарак төшергәч тә әле мин аякка баса, үз ихтыяжларымны канәгатьләндерә торган хәлдә түгел идем. Сул якны (кул, аяк) гәүдәгә жилем белән ябыштырып куйгандай, аерып алып булмый. Авыртуны да, чеметүне дә тоймыйлар. Өстәге катта чирлеләрне кашыктан ашатсалар, биредә ризыкны янындагы тумбочкага китереп куялар да, чыгып китәләр (бер син генә түгел). Шунда инде үзенә бер сынау башлана. Ятакның иң кырыена килеп, сузылып кашыкны алып, башны мендәргә терәтеп күтәребрәк куеп, тәлинкәдәге азыкны алып, авыз шәрифләренә китерергә тиешсең. Берәр әйбер, кашык, су, алма алырга сузылганда, үле сул як сине аска, идәнгә үк «төртеп» төшерә. Бу хәл гажәеп зур космик тизлек белән башкарыла ки, шап итеп идәнгә килеп төшкәнеңне сизми дә каласың. Бернәрсә дә болай гына эшләнми, караваттан егылып төшүнең дә жае бар, дигән гыйбарәне ишеткәнием. Чыннан да шулай икән. Тик минә ятакка кире менүе, Гарәфәт тавына күтәрелүдән дә кыенрак булып чыкты. Күршем Наил Жамалиев дигән элемтәче егет аягында йөреп, оекбашларын үзе кия алса да (минем иң көнләшкән шөгылем), аның сул ягы аз-маз хәрәкәтләнсә дә, күтәрү кебек житди гамәлләр башкарырлык хәлдә түгел иде әле. Үзе генә мине күтәреп салырлык куәте булмагач, ул ярдәмгә кизү туташларны, жыештыручы апаларны алып килергә мәжбүр була. Бер ай элек кенә болан мисле йөгереп йөргән, ыржыктай кешегә хатын-кыздан күтәртү гарьлек тә, оят та бит әле. Үзләрен таза беләкләрдә йөртүне артыграк күргән чибәркәйләрдән аяк-кулларыннан тотып өскә менгертүнең хурлыклы булуын әйтеп тә тормыйм. Нихәл итмәк, сыкранып булса да түзәсең. Һәр табышмакның чишелү әмәле табыла дигәндәй, мин дә

шомара башладым. Күршемне идәнгә егылып төшү белән («шантаж» диләр аны) куркыту юлына бастым.

– Егетем, (ул миннән егерме елга соңрак туган, инсульт белән инфаркт «яшәрә» диләр ич), мине идәннән күтәреп интегәсең килмәсә, кашыгымны уң кулыма тоттыр, боткамны мондарак күчер, су агызып бир..., дип, кушып кына ята башладым.

Иптәш Җамалиевнын һәр «кәприземне» тырышып үтәвенә караганда, шул арада уналты килога ябыккан булсам да, кашык алып бирү, мине идәннән күтәрүгә караганда җинелрәктер дип фаразладым.

Ирләре алдаган, егетләре ташлаган шәфкать туташларын кызганып «картаюым» гына җитмәгән иде, күршем дә бу тарафтан үрмәкүч пәрәвезе җәтмәсенә эләккән чебен хәлендә булып чыкты (Ул хакта сүз алдарак булыр).

Неврология бүлегендә унбиш көн бүрәнәдәй сузылып ятканнан соң, Илшат улым коридорга алып чыкты. Минем алдымда бөтенләй башка, яңа дөнья җәйрәп яткандай булды. Якты, озын коридор, диварларга һәммәсе сәламәтлекне саклау, ныгыту юнәлешендә җылы тәкъдимнәрен керткән язмалар эленгән. Берсеннән-берсе чибәр шәфкать туташлары тыз-быз килеп йөриләр. «Мин үз аягым белән басып дөньяга чыктым, ник берегез дә игътибар итмисез», дип, шыр ярып кычкырасым килә. Ап-ак чырайлы абзыйның сул аягын сөйрәп булса да йөрергә маташуы үзеннән башка кемгә кирәк соң? Ошбу җиһанда адәм баласы ялгыз шул: берүзе туа, берүзе үлә. Тормышынның урта бер җирендә мондый халәтне бер кичереп аласың икән. Олы галәм һәм син. Бу очракта минем өчен җиһан чиксезлеге хастаханә коридоры иде.

Сырхауханә коридорын үлчәп йөргәндә үземнең дөньяга карашым, табигатькә, кешеләргә, суга, утка, айга, йолдызларга мөнәсәбәтем үзгәрүен аңлап, мифологияне яңача, тормышчанрак кабул итәм. Җиһаным стеналар белән чикләнгән булса да, мин яктылык, җиңеллек, иркенлек тойдым. Офыкларым кинәйде, хисләрем кайнарланды. Ак болытларга утырып яшьлек үтеп китә, мәхәббәтен эзләгән җан кебек, кошлар гыйшык җырын җырлый.

– Кешене вакыт үзгәртми. Кеше үзе үзгәрә икән дим, үз-үземне нәрсәгәдер инандырырга тырышкандай.

Алдарак әйтелгәнчә, инсульт — ялкаулар вә ихтыярсызлар чире, чөнки ул синең колагыңа, назлы саба җиле кебек, пышылдап тора: «нигә шулай интегәсең, болай да күп эшләдең, дөнья кудың, аны куып тотып булмасына инандың, башынны йомшак мендәренә куй да, ап-ак юрганынны өстеңә тартып, үз кадереңне үзең белеп, ят та ят, берәүнең дә сине борчырга хакы юк. Ни пычагыма кирәк интегүләрең, аяк-кулларың барыбер төзәлеп бетмәячәк, тырышма». Үзең дә бу халәтеңә разый булып ятасың, артык хәрәкәтләр ясыйсың, селкенәсең килми. Бу әшәке чирнең «иркәләүләрен» җиңү өчен хәттин ашкан үҗәтлек, яшәүгә дәрт, беркадәр купшы сүз булып күренсә дә, җаваплылык хисенең булуы лазем. Өлешчә булса да терелү өчен үзеңне, адәм баласына хас ялкаулыкны җиңү икәнлекне ятакта бераз селкенә алу мөмкинлеге тууга аңладым.

Безнең бүлмәгә инструктор кыз йөри башлады. Исеме Сөембикә. Рәсемнәре буенча күзалланган чем-кара күзле, түгәрәк йөзле Казан ханбикәсенә бөтенләй охшамаган саргылт чәчле, яшькелт соры күзле, әмма ифрат сөйкемле иде җанлы Сөембикә. Иртүк килеп керә дә төрле хәрәкәтләр ясата, сул якны уа, сөялмичә утырып торырга мәҗбүр итә, идәнгә бастырып йөртеп карый. Үзе белән алып килгән кечкенә баскычка үрләткәндә, аяк табаннары утлы күмер өстендә йөргәндәй авырта. Минем сызланудан

чырайларымны күрән капкандай сытуга исе дә китми кызыйның. Шул вакытка туры килсәләр якыннарым да, ачу китереп, «ялкауланма, сул кулынны хәрәкәтләндер», дип өстәп торалар.

Мине аякка бастыруга зур өлеш керткән Сөембикә хәзер кайларда икән? Чөнки мин янәдән хастаханәдә пәйда булганда, ул анда түгел иде инде. Абруе көчле вакытта «обком бульнисе»ндә эшләүчеләрнең башкалардан бер өстенлеге яшәде: алар бу хастаханәдә ятучы төрле дәрәҗәдәге түрәләр, хакимият башлыклары, депутатлар белән иркен аралаша, сорау-үтенечләр белән мөрәҗәгать итә алдылар. Ә чирле кешенең күнеле йомшак була, икенчедән, ышанычлы хезмәткәрләр кая да кирәк.

Ни өчен Сөембикәне искә төшерден әле дип сорасалар, «иң әүвәл исеме матур булган өчен» дияр идем, һәм, сонрак анлавымча, «ул мине кызганмыйча дер селкеткән көннәрдә минем киләчәгем хәл ителеп яткан икән», дип җавап тотар идем. Ягъни мәсәлән, мин аякларыма басаммы, әллә урында ятып, ике көпчәкле арбада йөрүче булып каламмы? Сонгысын күз алдына китерү өстәмә көч биргәндәй була. Кеше кулына калмыйча, мин авыруны җинеп, укытучылык, язучылык хезмәтемә кайтырга, мона ихтыяр көчем, тормышка мәхәббәтем ярдәм итәргә тиеш дип, үзем генә калганда кычкырып, берәрсе янымда булганда эчтән тәкрарлап тордым.

Үзенең эчке һәм тышкы халәте турында язу кешегә кызык икән. Теләк белән көч туры килмәү психологияне үзгәртә. Үзәген нык булганда гына чир белән көрәшә аласын. Туктаусыз рухи көрәш кешенең характерын ныгыта, яшәвенә көч бирә. Шул хакта башкачарак Фәнис Яруллин да язып калдырган икән. «Әгәр дә күнелендә нәрсәгә дә булса омтылыш юк икән, син нинди таза кеше булсаң да, барыбер әкренләп-әкренләп, ауган агач кебек череп бетәсең... үз-үзеңне раслар өчен ихтыяр көче табарга кирәк» («К.У.», 2013, № 2, 171-172 б.).

Кем булуына, чиреннең, терелүеннең дәрәҗәсенә карамастан, хастаханәдә артыгын тотмыйлар. Минем дә «дембел» көнем якынлашты. Берәр якыныма, таякка таянып йөри башлагач, мина өемә кайтырга, дәвалануны ял йортларында дәвам итәргә бик акыллы «кинәшләрен» биреп, кулыма «выписан в связи с выздоровлением», дигән кәгазь тоттырып, чыгарып җибәрделәр. Берәүнен дә күзенә чалынасы, берәүне дә күрәсе килмәгән вакытта иң яхшы танышың авызын ерып каршына килә дә чыга. Бу юлы да нәкъ шул хәл килеп туды. Хәзер инде гүр иясе, мин ифрат ихтирам иткән шәхес, олуг язучыбыз Гариф Ахунов, улым белән хатыным ике яктан култыклап, аягымны көчкә сөйрәп атлап «обком бульнисе»ннән титаклап килүемнең шаһиты булды. Каләм иясеннән сер саклау көтмә, ул белгәне белән уртаклашырга ашыга. Ахун да кемгәдер, һәрхәлдә мина китереп житкерердәй кешегә:

—Галиуллинны хатыны өенә үләргә алып кайтып китте, — дигән ым сала.

Шул ук вакытта аның тавышында бернинди сөенү, шатлану галәмәте сизелмәде, киресенчә, фикерен көрсенеп, кызганып, үкенеч белдереп әйтте, — диде «сер ташучы». Минем үз аягымда йөри башлавымны, терелеп килүемне күргәч, «элеккеге бюрократ Галиуллинга охшый башлагансын», дип, иң сөенгән кешеләрнен берсе дә шул ук Гариф абый булды.

Дөрес, иң кешелекле, киң күнелле, ярдәмчел, һәерхаклы һөнәр ияләре — язучылар арасында да, нәкъ котүдәге шикелле, бер азгыны, эчкерлесе, үчлесе була икән. «Идел» журналында исемен куярга оныткан берсе Марсель Галиевкә сылтама ясап (янәсе, ул әйтте), фәлән язучы бер

аягы белән гүрдә торса да, икенчесе белән романнар язуын дәвам итә дигән «табышы» белән уртаклаша. Минеме (киная угы шул тарафларга юнәлгәндәй тоелды), башка берәүнеме күздә тоткан, көнчелектән төкерегенә буылган бәндә белән бәхәсләшеп тормастан, үзе дөньяга мәңгелеккә килгәндәй, шаяртуына азык таба алмый интеккән каләмдәшем колагына, «яшьлегең белән масайма, безнең баштан үткән хәл, тазалыгың белән мактанма, безнең баштан кичкән хәл, синнән дә күп сорамас», дигән халык акылы җимешен генә искә төшерәсе килә. Раббыбыз мине, сине, аны кеше итеп яраткан икән, бу бөек исемне кош-кортлар, бөҗәк-ерткычлар дәрәҗәсенә төшермичә, бер-беребезне максатчан рәнҗетмичә, кимсетмичә, фани дөньядагы үз вазифабызны намус белән үтәп, һәр очракта да миһербанлы булып калсак иде. «Мәрхәмәт ул кешегә ярдәмгә ашкыну, үзеңнең вакытыңнымы яки бик кирәк нәрсәңне корбан итү бәрабәренә башкаларга яхшылык эшләү... Ә мәрхәмәт, талант кебек, сирәк кешеләргә бирелә, күрәсең». Бу фәлсәфи нәтиҗәне, ташка кадак каккандай, бөек шәхесебез Фәнис Яруллин әйтеп, язып калдырган. *(«К. У.», 2013, № 2, 75 б.).*

Кыскасы, бер айдан соң инсультны шунда эзләп тапкан «обком бульнисе»ннән чыгарып җибәрсәләр дә, мин әле эшкә яраклы хәлдә түгел идем, ике айга якын Боровое Матюшино дип аталган табигатьнең ямьле бер җиренә урнашкан дәвалау үзәгендә булдым. Инсульт кичергән кеше өчен иң кыены — өскә кием кию һәм сәдәфләрне төймәләү. Кул бармаклары хуҗаларын тыңламый, бернәрсәне дә тота алмый. Өскә кием кию, бигрәк тә күлмәкнең вак төймәләре ояларын таба алмыйча шабыр тиргә батыра. Ул заманда киң, иркен, җиңел, үзләре ифрат җылы Кытай пуховиклары киң таралышта иде. Урамга чыкканда шуны кию дә үзе бер газап. Ихтыяҗ булганда әмәле табыла икән. Әүвәл киемне креслога җәеп салам да, өстенә утырып, уңы белән җиңгә сул кулны тыгам, аннан уң кулны урнаштырып, ике терсәккә (берсе шартлы) таянып, пуховик белән бергә өскә күтәреләм. Дустыбыз, Әфхәт энекәшнең укучысы, баш табиб Рөстәм Халитовның затлы бүлмәсендә, икенче катта гына яшәсәм дә, аяк баскыч дигән төшенчәне гомумән кабул итми. Аска лифт белән төшеп, таякка таянып, урман буйлап сәфәргә чыгып китәм. Ходайның һәр бирмеш көнендә үзем өчен яна дөнья ачып, салкын көнне карда алтын бөртекләре кебек күзне камаштырган ялтыравыкларга күз кысып йөрим дә йөрим.

Аз гына сөртенсәң дә, җиргә хөрмәт күрсәтеп, шап итеп шунда барып төшәсең. Беренче елларны егылу гадәти хәл булды, уйланып, хыялланып китеп, күктән йолдыз чүпләсәң яисә кешеләр турында начар уйласаң, хатын белән бәхәсләшә башласаң — барасың да төшәсең. Негатив уйларны «куа» белергә кирәк икән.

Бераз хәл кереп, үземнең киләчәгем турында кайгырта башлагач, мондый карарга килдем. Минем өчен иң мөһиме — исәнлек. Шуңа күрә ректор исеменә гариза язып, декан вазифаларыннан азат итүен сорадым. Берәүләр «без әле хәзергә чаклы шундый абруйлы эштән үзе теләп киткән очракны белмибез» дисәләр, минем урынбасарларым — Таһир Гыйлаҗев белән Әлфия Йосыпова, деканат кызлары «зинһар калыгыз, бар эшне үзебез эшлибез, безгә сезнең кинәшләр һәм авторитет кына кирәк», дип үгетләделәр. Бәлки, ашыгып китү факультетның киләчәгенә зыян да китергәндер, мәгәр ул вакытта — сәламәтлегем турында гына уйладым. Мин декан вазифаларын үтәргә заманында бу эшне башкарган, милли мәктәпләр институты филиалы директоры булып эшләгән тәҗрибәле профессор Фәрит Йосыповны тәкъдим иттем. Әмма факультет хуҗасы булып, тарихчы, яшь галим Искәндәр

Гыйләжев бер артык тавыш белән узды: (Карфагенны алган кешеләрдәй, минем тавыш хәл итте, дип күкрәк киереп йөрүчеләр шактый булды). Мин тәкъдим иткән кешене уздырмас өчен Хатыйп Миңнегулов бик тырышты. Икенче срокка сайлаганда Искәндәр гаризасын язганчы ук, ул кафедрасының карарын чыгарып куйды. Сайлауның нәтиҗәләренә үзен ифрат зур галим итеп күрсәтү һәм ышандыру сәләтенә ия академик Миркасыйм Госмановның үз янына мине өнәп бетермәгән кешеләрне туплый алуы һәм минем кандидатураны яклаучыларның оешып бетә алмавы хәл итте. Искәндәрнең күренекле язучы Аяз Гыйләжев малае булуы да (филологларга якын) иң соңгы кылны уйнамады кебек. Үзен күтәргән, яклаган кешеләрне онытмады деканыбыз. Аерым алганда, Х.Миңнегуловның бөтен борнай теләк-омтылышларын үти килде. Нәтиҗә шул: И.Гыйләжев факультет шәхсән үзенә бирә алган мөмкинлекләрне кулдан ычкындырмыйча, ун ел декан кабинетын бизәп, килештереп утырды да, 2011 елда бик матур гына яңа оешкан тарих институтына кафедра мөдире булып күчеп китте.

Деканаттан киткәннән соңгы хәл-әхвәлем турында берничә сүз. Дәвалану барышында кая гына бармадым, кем белән генә аралашмадым. Хатыным Мәскәүгә, Петербургка, инсульт белән шөгыльләнүче оешмаларга, «Ми» институтына хатлар язып, дарулар, тәкъдимнәр соратып алды. Туганнарымнан берсе генә дә минем язмышка битараф булмады дисәм, ялгыш булмастыр. Мине аякка бастыруда аеруча уртанчы сеңелем Лилиянең тормыш иптәше Тәлгат вакытын да, көчен дә кызганмады. Өйдә дәвалаучы табиблар табып, шәһәрнең бер башыннан икенчесенә һәр көнне шунда йөртте. Табиб мине кәбестә диетасына һәм скипидарлы ваннага «утыртты». Уналты көн дәвамында шул тәкъдимнәрне үтәп яшәдем. Кыскасы, кыланмаган гамәл, эчмәгән дару калмады. Шулай да инсульт дигән зәхмәтнең нәтиҗәләреннән, язучы Р.Зәйдулла әйтмешли, башны ташка бәрсәң дә ахыргача котылып булмый икән. Һәрдаим кан басымын үлчәп, дару сәдәпләрен йота тору мәҗбүри. Нәтиҗә ясабрак әйткәндә, зур котылгысыз ихтыяҗ булмаганда, хастаханәдә эшләүчеләргә исәнлек теләп, бу оешманы әйләнебрәк үтәргә тырышырга кирәк. Ә мин, кызганычка каршы, хәзер дә елына бер булса да, «обком бульнисе»нә кереп ятып, тикшертеп, тиешле сыекчаларны канга кушып чыгарга мәҗбүр булам. Һәр елның август ае җиттеме, аяклар шул якка тарта. Кем булса да, «ни өчен август ае» дип сораса, җавабым әзер. Бердән — укытучының ял ае. Төрле уку йортларыннан педагоглар шунда очрашабыз. Икенчедән, һәм иң мөһиме: көз, кыш айларында хастаханәгә эләгүе кыенрак. Сугыш, тыл ветераннары, элек югары урыннар биләгән, таныш-белеше күп өлкән буын бакча эшләрен бетереп, суларын агызып, ишек-капкаларга йозак элгәннән соң, ял турында уйлана башлый. Ә аның өчен иң кулай урын — «обком бульнисе». Бүлмәләр җылы, ашау-эчү, дәвалану бушлай, аралашу, яшьлек хатирәләренә кереп чуму өчен менә дигән бакча. Пенсиянең янга калуы турында әйтеп тә торасы юк.

Хастаханә ул үзенә күрә тормыш мәктәбен узуның дәвамы. Мин анда, мәсәлән, бик күп яңа кешеләр, язмышлар, бигрәк тә төрле һөнәр ияләре, мәсәлән, театр әһелләре белән очраштым, беришесе илә дуслашып ук киттем. Үзеңне бик начар сизә башлап хастаханәгә кергәч, фани дөньяның бер көнлеген искә төшерәсең. Язучы халкының күбесенә танылу гөнаһлы дөньяны ташлап киткәннән соң гына килә. Анда да әле мирасын барлап, артыннан төрткәләп йөрүче Нәкыясе булса яисә иҗатын кабул итмәүчеләре вә битарафлары өч аршин җиргә күчкәч кенә яктылык иңәргә мөмкин. Ә артист, җырчы язмышы башкачарак: табигать һәм ата-

анасы сәләт галиҗәнапләрен биреп тудырса, шуның өстенә фортуна да елмайса, аңа танылу исән чагында килә, сәхнә тотканда ул алкышларга, чәчәккә күмелә, житәкчелекнең күз уңына (төп бер кешенен) эләксә, затлы фатиры да, сый-хөрмәте дә килә. Сәхнәдән төшүгә, язма-басма сүз ярдәмгә килмәсә, йә кайгыртучысы булмаса, күбесенең исеме иске афишаларда гына кала.

Мин бу язмаларымда шуларның берничәсен булса да, кәгазьдә калдырып, үземнең олы ихтирамымны белдереп үтәсем килде.

## Өченче хат. Артистлар даирәсендә... (Ш.Биктимеров, И.Әхмәтҗанов һ.б.)

Күренекле сәхнә остабыз Шәүкәт Биктимеров турында кечтеки генә булса да истәлек язарга хакым бармы икән, иҗатында, холкын-менәзендә аз беләм дип уйланып йөргәндә, Саба районында, 2012 елнын иң соңгы көннәрендә, зәңгәр экраннан анын барельефы белән искә алу тактасы куелуны карагач, илһамланып китеп, бер гомумирәк фикерем белән уртаклашырга һәм театр тарихына үлмәс Әлмәндәр карт һәм башка образлары белән кереп калган шәхес турында уйлануларымны тәкъдим итәргә булдым.

Теләсә кайсы, булсын әдәбият, булсын театр, булсын рәсем сәнгате өлкәсендәге мәшһүр шәхесләрнең язмышлары варисларынын мәненә, буыннар арасындагы бәйләнешләр тирәнлегенә бәйле дигән идек. Жөмләдән, утызынчы елларның җырчысы Мохтар Мутинны «татар Шаляпины» дип йөртәләр. Фёдор дәдәй чит илгә чыгып котылса, андый мөмкинлеге булмаган татар артисты Себергә сөрелә һәм шунда һәлак була. Репрессия корбаны, атаклы җырчыбыз Мохтар Мутин турында Ибраһим Салахов «Колыма хикәяләре» исемле романында җылы һәм күңелдә калырлык ваклыклары белән язып калдырмаса, яңа гасыр башында яшәүче театр белгечләрен санамаганда, гади укучы, тыңлаучы, горурлыгыбыз булып күтәрелергә тиешле җырчыбыз турында каян мәгълүмат алыр һәм нәрсә белер иде. Фәнни язмаларны күбебез укымасак та, И.Салаховның студентларның стипендия тиеннәрен, ашау-эчүдән кысып булса да, Мутин спектакльләре өчен саклаулары, теге яки бу сәхнә әсәрен караудан бигрәк, Мохтар абыйны тыңлау өчен театрга йөрүләре турында һәм лагерьда урманнан баракларны җылыту өчен чыбык-чабык күтәреп кайтканда, чирле артистның керү капкасы янында егылып калуы, этләрдән талатылуы һәм шунын нәтиҗәсендә «агач бушлат» киюе хакындагы юлларны сыкранмыйча уку мөмкин түгел.

Казанда Качалов, Шаляпин, Нуриев фестивальләре гөрләп уза, ә Мохтар Мутинны зур театр залында узган искә алу кичәсен дә хәтерләмим. Якташы Рифат Фәттахов тырышып йөрмәсә, Рәшит Ваһапов фестивале мондый уңышка ирешә, талантларны үзенә җыя-җыя дөнья буйлап сәяхәт итә алыр идеме? Беренче елларда кемнәрнендер эчләре пошып, «ни өчен Рәшит Ваһапов, безнең башка олы җырчыларыбыз юкмыни», дип сөйләнеп йөрүчеләре дә булмады түгел. Тик бу бәйгене оештыручы сынмады-сыгылмады, эзләнүен, татар җырын, монын җиһанга сибүен дәвам итте.

Кыскасы, җырчы, артист, башка өлкәнең талант иясе язучы, журналист игътибарына, каләм очына эләксә, әдәби образ буларак та күңелләрдә яшәячәк. Олы талант турында язу өчен анын белән гомер буена аралашу кирәк тә түгел икән. Кайсы вакыт бер утырып сөйләшү дә олы әсәр өчен зәмин бирергә мөмкин. Озын-озак еллар татар академия сәхнәсен киеренкелектә тоткан, сүнмәс йолдыздай образлары белән рухи дөньябызны

баеткан Шәүкәт Биктимеров белән мина шул ук «обком бульнисе»ндә күрешергә, бераз аралашырга насыйп булды.

Гомеренең соңгы елларында, бигрәк тә, хәләл җефете мәңгелеккә күчкәннән соң, ул чирләп тә, ялгызлыктан качу максаты белән дә булса кирәк, хастаханәдә дәваланып ятуларын ешайтты. Аның «обком бульнисе»ндә пәйда булуы, күктән йолдыз төшкәндәй, һәрвакыт үзенә күрә бер вакыйгага дәрәҗәсен ала иде. Татарлар гына түгел, шунда хезмәт итүче башка милләт вәкилләре дә аны яхшы белә, таный. Аның шөһрәте искитмәле. Табиблар, бигрәк тә яшь шәфкать туташлары Шәүкәт абыйның һәр капризен үтәргә әзер булып, янында умарта күче шикелле выжылдап, биеп йөриләр. Ул кайберәүләр кебек, үзенә игътибарны таләп итми, тегене бирегез, моны китерегез дип тенкәләренә тими. Ә инде Шәүкәт абый сырлы матур таягын тотып, вәкарь генә атлап бакчага чыкса, аны балга җыелган чебен көтүе төсле сырып алалар. Ир-ат заты оялыбракмы, чирле кешегә бәйләнергә яхшы түгелрәкме дип, читтәнрәк күзәтеп, үз чиратын көтебрәк торса, хатын-кыз аны мәрмәр баскычтан җиргә басуга ук сырып ала. Шуннан китә бушлай тамаша, режиссёрын да, алып баручын да... берсе дә кирәк түгел. Төрле яшьтәге апалар, сеңелләр, авызларын яулык чите белән каплаган әбиләр, туачак баласын сакларга яткан, йортка чыкканда да бизәнергә онытмаган киленнәр аны сырып алып, берсен-берсе бүлдерә-бүлдерә сәхнә остасы уйнавында караган спектакльләр турында сөйләшүләр, мактаулар, уфтанулар, истәлекләр китә... Аның киеменә, үзенә орынып алу зур бәхет санала. Озак еллар дәвамында халык белән аралашып яшәргә өйрәнгән артист канәгать, ихтирам-хөрмәт нурларында коена. Хатын-кыз чыркылдашып туйгач, ир-ат заты килеп исәнләшә башлый.

Шәүкәт абыйның олыгайган саен затлы мәрмәр төсенә керә барган бит тиресе эчке, илаһи матурлыгына тәңгәл. Ул тыйнаклыгы, шул ук вакытта үз бәясен белгән вәкарьлеге белән кеше кулы тимәгән табигатьне хәтерләтеп куя. Аңа кагылырга ярамый, бары тик читтән торып, сокланырга гына рөхсәт ителә. Шул ук вакытта бөекләрнең юлдашы — ялгызлык. Халык мәхәббәте ничаклы гына җылы, хәтта кайнар булмасын, ул ялгызлык хисен, эчке әрнүне баса алмый икән. Эч серләренне бер кеше белән генә бүлешеп була. Ә ул юк. «Әлмәндәр бабай» дип янында биеп йөрүчеләр аның җанында ниләр көйрәгәненнән хәбәрдар түгелләр.

Артистлар бик ихласи халык, мәкаль-әйтем андыйлар турында «эчендәге тышында», ди. Берничә көн бакчада йөреп, аралашуыбыз вакытында Шәүкәт абый үз шәхси тормышы, сәхнәдә яратып һәм мәҗбүри уйнаган рольләре турында шактый гыйбрәтле хәлләр сөйләп өлгерде. Бөтен бер олы залны үзенә буйсындырып, тетрәндереп, сокландырып тору сәләтенә ия бөек шәхесне абзагыз берүзе тынлап йөри. С.Хәким: «Бер горурлык хисе яши миндә», дип мондый мизгелләрне, билләһи дим, шигырь юлларына күчерми калмас иде. Бөек шәхесләрнең тормыш юллары да, киләчәкләре дә гадәти була алмый икән. Аның мәхәббәт вә гаилә тарихы үзе бер кыйссага торырлык. Театр көллиятендә бергә укыган кыз — булачак хатыны белән яратышып, киләчәк бәхетле гаилә тормышы турында хыял дәрьясында йөзгәндә, көймәләре комга терәлә, егеткә армиягә алынырга дигән кәгазь килеп төшә. Яшьләр икенче көнне үк язылышу үзәгенә барып, аңлатып, инәлеп, хәрби комиссариат кәгазен күрсәтеп, мөнәсәбәтләрен рәсмиләштерәләр. Әти-әниләренә, туганнарына ләм-мим бер сүз әйтмиләр. Кочаклашу, үбешүдән узмыйча, аерылышалар. Ул чорда әле хезмәт итү мөддәте шактый була. Шәүкәт шул чыгып китүдән дүрт ел ил чикләрен саклый, икесенең дә юанычлары — кайнар яшьләре тамган хатлары гына була. Армия хезмәтен тутырып кайткач, ике яшь йөрәк гаилә корып

җибәрә, гөрләтеп туй уздыралар, балалар үстерәләр, карьера ясыйлар. Баш-аягы белән эшкә чумган Шәүкәт югары белем, диплом турында да уйламый, бәхетле көннәрен сәхнә белән гаилә арасында йөреп уздыра. Бөек шәхес, таягына таянып, иплә генә агачлар арасыннан атлаган көйгә үткән көннәренең татлы мизгелләрен исенә төшереп, кичә генә булган хәлләрдәй хисләнеп, хәләл җефетенең үзеннән иртәрәк вафат булуына үкенеч белдереп, үзен анлап тыңлаучы булганга куанып сөйли дә сөйли. Тавышы ягымлы, иркә, ялыктырмый...

— Тормыш иптәшегез бакыйлыкка күчкәч, балаларыгыз үз гаиләләре белән аерым яшәгәч, бик күңелсез түгелме? Яңадан өйләнеп, үзегезгә таяныч булдырырга уйламадыгызмы, Шәүкәт абый, — дип сорау бирергә җөрьәт итәм.

Мондый соальне ул инде күпләрдән ишеткән күрәсең, әүвәл, чыраен, җыерчыклар чыгармыйча гына сытып, болай дип җавап бирде.

— Юк, янәдән өйләнергә дигән уй башыма да килмәде. Без, Ирек Баһманов белән, аның да хатыны вафат, яңа гаилә кормаска дип сүз куештык. Дөрес, мине яхшы белгән, дөньяда яшәвем турында бөтенләй хәбәрдар булмаган ханымнардан тәкъдимнәр шактый булды. Тик берсе дә үлгән хатынымны йөрәктән кысрыклап чыгара алмады.

— Бәлки, берәрсен алып кайтып, торып карарга кирәк булгандыр? Ялгыз яшәү бик кыендыр бит? — дип, үз язмышым, шулай ук хатыным үлгәннән соң, өйләнеп, бик матур гына яшәп китүебез турында бәян итәм. Бу мәсьәләгә аның үз фәлсәфи карашы бар.

— Халык «өйләнү, түгел сөйләнү», диме әле. Минем белән чәчләрен бәйләргә теләгән ханымнарның ниятләрен күзләреннән укыдым. Берсе мине бик бай дип уйласа, икенчесен минем сәхнә шөһрәтем кызыктырса, күбесенә минем Шәймиев биргән затлы фатирым кирәк иде. Берсе дә миңа теге вакыттагы гап-гади Биктимеров булганым өчен генә кияүгә чыгарга ашкынып тормады. Менә шулай китек көзге хәлендә калдым. Театрдан да киттем.

Вәкаләтем булмаса да:

— Менә анысын юкка эшләгәнсез, Г.Камал исемен йөртүче театрны сездән башка күз алдына китерә алмый тамашачы. Һәм мин дә, — дип өстәдем.

— Миңа берәү дә урынны бушат дип әйтмәде. Үз теләгем белән эшемне ташладым.

—Барыбер ашыккансыз, — дигән булам.

— Тәлгат, театрга яңа, яшь буын килде. Актер хезмәтенә, иҗатның асылына мөнәсәбәт башка, кыйммәтләр үзгә, мин аларны ишетмим, алар мине күрми. Чукраклар белән сукырлар шикелле аралашабыз. Ә нәтиҗә юк...

Ул чорда мин, бәлки, бөеклекнең иң югары үренә күтәрелгән сәхнә остасы арттыра торгандыр, өлкәннәр тиз үпкәләүчән була дип уйласам, хәзер үзебезнең уку йортында үзгәрешләр, кыскартулар башлангач, буыннар арасындагы мөнәсәбәтләрнең киеренкеләнә барачагын күзаллап яшим.

— Үзегезгә генә яшәү бик күңелсез түгелме соң, дип янә шул соравымны кабатлыйм.

— Кеше гомеренең һәр чоры — яшьлеге бер төрле, картлыгы башкача — үз кызыгын һәм сызыгын алып килә икән.

—Сез үзегез уйнаган каһарманнар дөньясында яшисездер инде?

— Анысы да булгалый, кем Тәлгат. Авыл болыны чаклы фатирымда берүзем көн күрәм. Көнозын идәннән бөртекләп чүп җыеп йөрим. Келәм өстендә берәр мамык йоны, йомычка-мазар күрсәм, балаларча шатланып, бөгелеп алам, аны чүп чиләгенә салганчы, әүвәл «хәлен» белеп сөйләшәм,

кинәшәм... Дөньясыннан туя башласам, монда хастаханәгә юл тотам. Биредә күбрәк өлкәннәр ята, мине таныйлар, сөйләшәләр, кайгы-хәсрәтне тараталар, бүлешәләр.

Шәүкәт абый белән аралашуы рәхәт, ул туйдырмый, артык сораулар бирми, күбрәк үзе сөйли. Менләгән кешенең күңелен эреткән, жылыткан, елаткан тавыш хозурында берүзең йөзүең горурлык түгелме? Шул ук вакытта күңелдә кем булуына карамастан, кеше гомеренең кыскалыгы, өлкәннәрнең әйләнеп торган язмыш көпчәгеннән төшеп калуы үкенечле дә, моңсу да.

Соңгы күрешүебездән соң күп тә үтми мин Шәүкәт абыйның инсульт белән егылганын ишеттем. Ул зәхмәт илә якыннан «таныш» кеше буларак, чирнең олы шәхесебезне ычкындырмаячагын аңладым. Табиблар, балалары, аеруча подполковник улы яныннан китмичә, тырышып караганнар, әмма коткара алмаганнар дигән аяныгчлы хәбәр килде.

2010 елның август аенда мина шулай ук күренекле шәхесләребезнең берсе, Г.Камал исемендәге театр артисты, Тукай әсәрләрен һәм аңа багышланган шигырьләрне укып дан казанган Илдус Әхмәтҗанов белән «обком бульнисе»ндә бергә дәваланырга туры килде. Ул мина караганда хастаханәгә берничә көнгә иртәрәк кереп, 25нче палатага урнашып та куйган иде. Чираттагы ботканы көтеп утырганда күрешеп, Илдус әфәнде мине үз янындагы буш караватка чакырды һәм бик ихтирам белән каршы алып, көннәр бик эссе тору сәбәпле, тәрәзә янындагы җиләсрәк урынны да мина тәкъдим итте. Аңа мөнәсәбәтем беренче мәлдә милли рухлы шагыйрьләребезнең берсе, «Ачлык мәйданы» шигъри гөләндәме авторы Рәшит Әхмәтҗановның энесе булуы белән билгеләнсә, соңрак мин аны мөстәкыйль фикерле, һәр шәйгә үз бәясе булган шәхес итеп таныдым. Әлбәттә, аны сәхнәдән укыган һәр әсәренең мәгънәви эчтәлегеннән бигрәк, сәнгати назиклыгын ачып бирә алганы өчен хөрмәт итә идем. Шулай да артист халкы турында башкалар язганны уку өчен әлләни акыл кирәкми дигәнрәк стереотип фикернең яшәвен дә әйтми китә алмыйм. Алар еш кына әсәрне тавыш агышына җайлап яңгыраталар һәм мәгънәви офыгына артык игътибар бирмиләр дигәнрәк бәянең дә аң төпкелендә яшәвен искәртми булмый.

Үзем дә шулайрак уйлаучылар арасында идем. Артист дигән һөнәр ияләре әдәбият, сәнгать үсеше, сәясәт белән артык кызыксынмыйча, төнлә уйнап, көнозын йоклап, зур акчалар алып, үз җайларына яшәп ята диючеләр дә юк түгел. Ун көннән артык Илдус, шул чорда ук иркәләнеп йөргән тикшертергә кергән, Г.Камал театрының баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәев белән аралашу, диндрарий бакчасында тормыш, дөнья хәлләре, әдәби барышыбыз, сәхнәбез репертуары турында сөйләшеп утыруларыбыздан соң, үзләренә әйтергә базмасам да, аларга хас тирән белемлелектән хәйран вә вәйран калып, вакыты белән оялыбрак та куйгаладым. Тирәнлеген белмичә, суга кермә, диләр. Кайбер мәсьәләләрдә үземнең алардан саерак йөзүемне, мәгълүматымның азрак булуын да аңладым.

Аерым алганда, татар әдәбиятында детектив жанрының үсеше, «Меннәр, яки гүзәл кыз Хәдичә», «Гөнаһе кәбаир» романнарының авторы Заһир Бигиевнең (1870 — 1902) шулай яшьли үлеме, ә энесе Муса Бигиевнең (1875 — 1949) совет төрмәләрендә утырып, көч-хәл белән чит илгә чыгып китеп, Финляндия, Һиндстан, Мисыр кебек мәмләкәтләрдә яшәп, төрлесен күрсә дә, озак яшәве, абыйсы озын гомерле булса әллә нинди әсәрләр яза алган булыр иде, дигән үкенеч белдергәч, бик төгәл аңлатма алдым.

—Соң, Заһир Бигиевны көнче хатыны чәнчеп үтергән ич, — диде Илдус.

Совет чорында аның фаҗигале вафаты турында имеш-мимешне

ишетсәм дә, Тукайның «Мәрхүм Мөхәммәтзаһир әфәндегә» (1908) шигыре каһарманының ничек, ни рәвешле үлемен тәгаен белми идем.

Мин тынсыз калып, аптырап утырдым, күз алдымнан соңга калып кайткан ыспай ир, җәнҗал, мондый вәхшилекне көтмәгән, канга баткан яшь Заһир хәзрәтләре язмышы узды. Минем үкенечемне, балавыз сыгуымны тынлап та тормыйча, сәхнә әһелләре әдәбият тарихыннан мисаллары, мәгълүматлары белән мине кызганмыйча «дөмбәсләүне» дәвам иттеләр.

— Татар, башкорт, казах халыкларының уртак мәгърифәтче шагыйре Мифтахетдин Акмулланың ни өчен, ни рәвешле үлгәнен беләсезме?

Мин җилкәләремне күтәребрәк куеп, тавышыма җинүче төсмере биреп, совет чоры китапларында укыганымны ярып салдым.

— Аны байларны, муллаларны фаш иткән ачы телле сатирасы, чичәнлеге өчен ялланган куштаннар куып җитеп, үтереп, елгага ташлаганнар.

— Китапча дөрес, — диде Илдус, кешелекле, гафу итүчән елмаеп. — Әмма аны ир-ат азгынлыгы, казах баеның бичәсе белән буталганы өчен үтергәннәр шул. Язучыларыбызны бөек итеп күрәсебез килә. Барыбыз да җан белән тәннән торган адәм балалары шул, — дип өстәде Илдус көрсенеп, үз шәхси уйларын күңеленнән уздырып.

Мин шунда һәр көнне аралашып, бер-берсенә ишеткән хәбәрләрен сөйләп, мәгълүматлары белән бүлешеп яшәгән театр коллективларының, аркасын катырып бүлмәсендә берүзе утырган язучыдан өстен яклары да бар икәнлекне аңладым.

Заһир Бигиев, Акмулла... тагын әллә кемнәрнең язмышлары. Олы шәхесләребезнең иң гадәти тормыш-көнкүреш низаглары өчен вафат булуларын күңел авыр кабул итсә дә, дәлилләре нык, ир-ат холкын яхшы ук белгәч, ышанырга туры килде. Әйтик, сатирик шигырь нинди генә көчле, усал, кешеләрнең иң начар сыйфатларын кояш яктысына тартып чыгарып хур итмәсен, хан, патша, генсек, президентның атасы кушкан исеме чыгарылмаса, хәтта әйтелсә дә, шуның өчен генә берәүнен дә гомерен өзмәгәннәр. Үзен мыскыл итеп язылган шигырь ГУЛАГ тоткыннары, яшьләр арасында телдән-телгә күчеп, кәгазьгә басылып таратылгач кына, Сталин шагыйрь Осип Мандельштамны аттыра, ягъни шагыйрьгә грузин мыегы белән «уйнау» кыйммәткә төшә. Гомуми көлгән өчен җәзаласалар, күпме тел шомартучының башы таш идәнгә тәгәрәп төшәр иде.

Миңа артистлар аз укыйлар, үзләренә кирәкле өзекне генә ятлыйлар дигән фикеремнән дә баш тартырга туры килде. Берәр язучының минем «Мәкер» (2008) исемле соңгы проза китабымны башыннан ахырына чаклы укып чыгуында ышанычым юк. Мин аны, кызыксынуында шигем булса да, Ф.Бикчәнтәевкә бүләк итәргә булдым. Үземдә берничә данә генә калу сәбәпле, Илдуска алып килә алмадым. Ул аны «хуҗасына» тапшырганчы, ике көндә тулысынча укып, кызык тоелган метафораларын кат-кат кабатлап укып чыкты, бәясен дә бирде.

Алтмышын ваклаган, «капчыгы» белән даруларын күтәреп, төрле төсле «төймәләрне» даими капкалап йөрсә дә, Илдус Әхмәтҗанов әле көчендә, иҗади хыяллар белән яши, буш вакытында Коръән сүрәләрен ятлый.

Минем артист халкына бәйләнерлек соңгы «өметем» калып бара шикелле. Һәр очрашуда, мәҗлестә ясаган чыгышы өчен акча «каерган» сәхнә әһелләре басылып чыккан китабы өчен алган тиеннәргә яшәгән язучы халкыннан күп тапкырлар баерак яшиләр дигән фикер иде ул. Әнә бит Мәскәүнең Басков, Галкин, Пугачева, Газманов, Киркоров кебек сәхнә йолдызлары акчалары, әллә ничә катлы зиннәтле сарайлары белән мактанып туя алмыйлар. Мәгәр башкалада яшәүче берәр язучының шул ук кимәлдәге байлыкка ия булуын ишетеп, күңләшүдән төкереккә буылырлык коттеджын күргәнем юк.

Яшерен-батырын түгел, совет чорында Лебедев-Кумач, С.Михалков, Г.Марков, А.Чаковский, Ю.Бондарев, К.Федин, милли республикалардан совет сәясәтен хуплап яшәгән берничә кеше һәрдаим игътибар үзәгендә булдылар, орден-медальләрен вакытында алып, типтереп яшәделәр, хәтта диссидент битлеген үзләренә ярата, шуннан файда күрә белгән Р.Рождественский, А.Вознесенский, Б.Ахмадуллина, Е.Евтушенко, Б.Окуджава кебек яшь «гыйсъянчыларга» да, бармак белән янаганнан сон, төрле ташламалар ясадылар. Аерым алганда, Мәскәү астында, Переделкино ял йорты янында яхшы өйләр салып, һәркайсына зур урман кишәрлеге бүлеп бирделәр. Шунда рәхәтләнеп йөре, иҗат ит, дусларың белән аралаш, тик дулый торган ат кебек, тәртәгә генә типмә.

Күпмилләтле совет әдәбиятының иң күренекле вәкилләре исемлегендә йөртелгән, баллы сүзләргә, матур чагыштыруларга ихластан ышанган, әнисе ягыннан татар, кыргыз язучысы Чыңгыз Айтматовның Мәскәү язучысы булып, «алар кебек» яшисе килүе табигый иде.

Ул шундый зур бәхеткә ирешә үк язды. Фортуна аңа елмаеп куйгандай булды. Табадан төшкән майлы коймак, Гоголь әкиятләрендәге шикелле, авызына үзе килеп керде диярсең. «Доктор Живаго» романы Нобель премиясенә лаек булгач, аның авторы Борис Пастернакны бүләктән баш тарттырып, Швед академиясенә телеграмма сугарга мәҗбүр иттеләр. Нечкә хисле лирик шагыйрьнең йөрәге үзенә каршы алып барылган хурлау, рәнҗетү компаниясенә түзә алмыйча, тибүдән туктый. Язучының хатыны белән кызлары Лондонда яши, Переделкинодагы дачасы хуҗасыз кала. Үзенең югары абруена шикләнмәгән Чыңгыз Айтматов Мәскәү астында яшәп, иҗат итү турында хыяллана. Әдип Борис Пастернак йортын үзенә бирүне сорап, СССР Язучылар берлегенә үтенеч белән мөрәҗәгать итә. Аның нияте изге: мәрмәр залларда яһүди сүз осталары белән җыелышларда, киңәшмәләрдә утырганнан сон, үз шәхси өенә кайтып ял итү. Идарәдә мәсьәлә аның файдасына хәл ителгәч, ул Кыргызстаннан мәрмәр ташлар, башка кыйммәтле төзелеш кирәк-яраклары китертеп, Мәскәү осталарын, рәссамнарын акча кызганмыйча яллап, Пастернак дачасын нигездән янарта, мансарда, француз камины ясата, тәрәзә рамаларын, ишекләрне алыштыра, йортка яна асфальт җәйдерә. Чыңгыз абый үзе төзелеш белән җитәкчелек итеп, илһамланып, эчке ләззәт кичереп, бер якыннан, бер ераккарак китеп карап, кулын кулга ышкып, сабыйларча шатланып йөргән, диләр. Инде төзелеш һәм җыештыру шөгыльләре тәмамланып, йортта яши башларга мөмкин дигән нәтиҗәгә килгәч, Чыңгыз Айтматовны янәдән Язучылар берлегенә чакыртып алалар. Аның белән ул чордагы союз рәисе Георгий Марков сөйләшкән, диләр озын телләр. Ул чорда «аңлашу» болай гына була иде.

— Кадерле Чингиз Терегулович, мина, әлбәттә, бик кызганыч, әмма язучылар һәм халык ул йортта Пастернак музеен ачуны сорыйлар. Партия Үзәк Комитеты да шул ук фикердә тора. Сез коммунист, алдынгы язучы, мине дөрес аңларсыз дип уйлыйм. Азат Советлар илендә халык теләге барыбыз өчен закон. Кирәк санасагыз, сатып алган әйберләрегезгә кәгазьләрегез булса, түләрбез, гариза язсагыз, матди ярдәм күрсәтербез!

«Бер көн — бер гомер» авторы ризалыгын да белдермичә, карышып маташудан да файда булмаячагын һәм үзенә мөнәсәбәтне аңлап, авызын, борынын салындыра да, Переделкино тарафларына юл тота. Бик күп акча, көч түгеп, бер кич тә куна алмаган йорт янында моңаеп басып торып, Мәскәү куйган сакчыга ачкычларын тапшыра да, ниһаять, үзенең ни дәрәҗәдә

күпмилләтле илнең бөек язучысы икәнен аңлап, Ала-Тоо якларына кайтып китә. Балаларын чит илләргә урнаштырып, үзе Брюссельдә Кыргыстаннан илче вазифаларын үтәүгә керешә. Шуннан ул битенә төкергән Мәскәүгә аяк басмаган диләр, ә нигезләре турында уйлап, Казанга, дусты Шәймиев янына килүен ешайтуы олы хөкүмәт сере түгел дип уйлыйм. Ихласи дусларын, кардәшләрен үлеме алдыннан гына тапты шул.

Янәдән гафу, гафу... Бозга эләгеп, тайпылып киттем. Сүзем бит артистлар, аларның «умыртып» акча алулары турында иде. «Обком бульнисе»ндә ятканда бу гайбәткә дә ышана яздым. Бүлмәбездә ваемсыз гына, чәен-мәен капкалап, ләчтит сатып утырганда, кесә телефоны Илдус Хәнифи улын искә төшерде. Тавышның ерактан килгәнлеген аңлап, чын зыялы кыяфәтен китереп, коридорга ук чыгып киттем. Кеше тыңлый дип курыкмыйча, рәхәтләнеп сүз дәрьясында йөзсен, бахыр.

Палатага кире кергәндә, мин Илдусны зур, иске маркалы телефонын ике кулы белән тоткан килеш, ишекле-түрле йөргән хәлендә таптым.

«Әллә инде үзенә берәр күнелсез хәбәр әйткәннәр», — дип борчылып куйган идем, адәм баласы шатлыктан да шулай дулкынланырга мөмкин икән. Минем соравымны көтмичә, үзе аңлатып китте.

— Звонок Мәскәүдән иде. Билайн телефон фирмасыннан. Аларга татарча реклама кирәк икән, мине шунда катнашырга чакыралар. 140 мең түлиячәкбез, диде ханым.

—Исем, фамилиясен, кем булып эшләвен сорадыңмы соң?

— Өлгермәдемме, башка килмәдеме шунда... Белешә алмый калдым. Иртәгә шалтыратырмын, җавап бирерсез диде.

Агач ятагына барып утырып, минем белән дә сөйләшкәндәй, дөресрәге, үз-үзе илә киңәшеп, «тере Тукаебыз» аңлатмалар бирүен дәвам иттерде.

— Бер чыгыш өчен шулай түләсәләр, иллә́м зур гонорар була бит инде ул. Мондый акчаны тотып караган да юк. Тапканыбыз бердәнбер улыбызның фатирына түләүгә, көндәлек кирәк-яракка керә дә бетә. Олыгайгач, даруга да акча күп китә икән.

— Әүвәл, Илдус, тынычлан. Коръәнне укы, мин тыңлап утырыйм. Сезгә бит, артист затына, тәртипле тамашачы кирәк.

Юк шул, «Тукаем» тынгысызлана, үзенә урын таба алмый. Зур керем нервыларны какшата, гасабиландыра, тәкатьне корыта икән шул. Күктән төшкән байлык бигрәк тә. Миллиардерлар ничек түзә икән... мескенкәйләрем...

— Хатынга әйтергәме, юкмы? Әллә бераз соңрак, акчасын алгач хәбәр итәрменме? Суммасын атасаң, ул аны туздыруга план кора башлый. Тегендә түлибез, моны алабыз, калганын банкка салып торырбыз дия башлый...

Ирләргә бит хатыннары акчаны юк-барга, бүгенгесе көнне мәҗбүри булмаган әйберләр сатып алуга сарыф итәләр кебек тоела. Ошбу бәйлелектән азат ир-ат заты юктыр, бу җеннең җиле бөек артистларны да әйләнеп үтми имди.

— Әлегә хатыныңны татлы йокысыннан мәхрүм итү иртәрәк дип саныйм. Күп нәрсә ачыкланып җитмәгән. Янәдән шылтыратып, тәкъдимен кабатласын, теге ханым.

Икенче көнебез Мәскәүдән хәбәр көтү белән узды. Үземә дә өлеш чыгар кешедәй, мин дә уенга чын-чынлап тартылганымны сизми дә калдым. Илдус дару кадатырга кергәндә дә, кесә телефонын үзеннән калдырмый. Мин дә үземә күрә алдан уйлап куям: «чирдәшем» акчаны бульнистә алса, Чехов базарына алып чыгып, казылык белән кызыл балык, Бразилия чикләвеге алдырам. Акчасын кочаклап утырмасын. Йорт күршем, дустым, Татарстанның халык артисты Нуретдин Нәҗмиев холкыннан беләм, сәхнә

кешеләре саран түгел, аларда карнавал заманнарыннан калган галахлык (ыштансызлык ди аны «синен татарын») саклана. Акчасы гына кулына килеп керсен.

Икенче көнебез көчле махмыр халәтендә, звонок көтеп, әлже-мөлже хәлдә узды. Мәскәү әшәкесен, әйтик, салкын җилләрен, кар буранын безнең тарафларга тиз җибәрсә дә, байлыклары белән бүлешергә ашыкмый.

Ханым шылтыраткан көнне мин туры килмәдем. Мәгәр Хәниф абзый угълынын мыеклы йөзен күрүгә сөйләшүдән айга кизәнерлек көч-куәт алмаганын сиземләдем.

—Йә, ничегрәк булды аралашу?

— Гәпләштек. Мин риза дидем. Шулай дип әйтүем булды, теге «без әле клипка тагын берничә кеше белән сөйләшү алып барабыз, ин яхшысын кәмиссия сайлап алачак», дип өстәде.

—Шуннан? — дим мин, кигәвен тешләгән ат кебек пырдымсызланып.

— Утырган да шуган. Гомуми сумма йөз кырык меннән йөзгә генә калдырылган. Кәмиссия дигәннәренең башында документалист режиссер Илдар Ягофаров тора, кемгә күпме түлисен, җинүчене дә шул билгели икән.

— Синең тавыш урман күгәрчене шикелле, гөрелдәп чыга. Җинеп чыгачагында шигем юк.

— Бәйгедә Равил Шәрәфи, Ринат Тажетдинов, Ирек Баһманов, Наил Дунаев һәм тагын берничә бөегебез катнашачак, ди. Мин алар белән ярышка чыга алмыйм. Намусым кушмый.

Мин Әхмәтҗановнын аек карашын, тыйнаклыгын хупласам да, «Шәрәфи белән Баһман отканнан минa ни файда, аларны Чехов базарына алып чыгып булмый» дип, үземнекен туглыйм.

— Син ул карт-корыны җинеп чыгачаксын, — дигән булам, Тукай әйтмешли, лампам эчендә маем кими, «җинүгә» ышанычым сүнә барганны сизсәм дә.

Берничә көннән соң Ягофаров чакыруы буенча, Илдус каядыр барып, язылып, клипка төшеп кайтты. Тик ул рекламаны беркая да янгыратмадылар бугай. Мәскәү вәгъдә иткән йөз кырык мең һавадагы торна, капкындагы сыр булып чыкты.

Соңыннан уйланып йөрдем: Казанга килеп, бер чыгыш ясаганнары өчен Собчак, Лолита, Макаревич кебек Мәскәү йолдызлары бер чыгышлары өчен зур суммаларны (140 мең белән пычранып та тормыйлар) каерып алалар. Әгәренки, шул акчаны үзебезнекеләргә түләсәләр, кимен куярлар идемени?

Илдус Әхмәтҗанов бер чыгышы өчен 140 мең алса да, әлләни зур акча түгел иде, тик анысы да әкият ахырындагы шикелле мыеклар буйлап акты, ә авызга эләкмәде. Аның белән бер палатада ике атна яшәү шуңа инандырды: артистлар матди тарафлардан язучы халкыннан бай яшәмиләр, ә белем, рухи дөньялары тирәнлеге ягыннан кайбер борылышларда, бездәй борын күтәреп йөрүчеләргә дә, мат куя алалар икән.

Шәүкәт Биктимеров сырлы матур таякчыгын тотып, дусты Ирек Баһманов мисле «минем таяк мең тәнкәлек», дип миләрне черетмичә, арабызда исән-имин йөргән чорда ук, Казан дәүләт дәрелфөнүне студентларыннан шундый артистны беләсезме дип сорадым. Өченче курс талиб-талибәләре, үзәктән килгән тикшерүче өчен алдан әзерләнеп торгандай, берсен-берсе бүлдерә-бүлдерә:

— Әлмәндәр картнымы? Аны кем белми инде. Мин анын туган авылында да булдым. Әлдермештә ул салган йорт тора микән әле?

Шундыйрак рухтагы сөйләшүләр, сораулар, фаразлар, гөманнар шактый

озак дәвам итте. Әлмәндәр бабайны шулай эзәрлекләп йөргән өчен Равил Шәрәфигә дә «эләкте». Артист, язучы, рәссам тарихка, халык күңеленә бер образы, әсәре белән мәңгелеккә кереп калырга мөмкин икән.

—Илдус Әхмәтҗанов турында ишеткәнегез бармы?

Әле генә күз алдыннан узган шартлау, шапырыну булмады. Тынлыкны беренче рәттә утыручы күзлекле кыз өзде.

—Тукай шигырьләрен укучы абыймы?

—Дөрес. Аның тагын нинди һөнәрләре бар?

Соравымның бик үк ипле куелмаганын аңлап, бит алмаларыма кызыллык та йөгертеп алдым бугай. Татарың егет кешегә житмеш төрле һөнәр дә аз, ди. Адәм баласының нинди мавыгуы булмас. Мин тиз генә сүз вә фикер агышына башка юнәлеш бирергә тырышып:

— Ул тышкы кыяфәте белән без рәсемнәр буенча белгән Тукайга охшаганмы һәм кайсы театр артисты?

Исләренә төшерделәр тәки. Илдус Әхмәтҗанов гәүдәгә Тукайдан калкурак, тулырак булса да, битенең төзелеше, маңгаенын текә кинлеге, күз карашының үткенлеге белән бөек шагыйребезне хәтерләтә икән. Тик аның Г.Камал исемен йөртүче театрда нинди рольләр башкаруын гына әйтә алмадылар. Ә инде И.Әхмәтҗановның үткән гасырның туксанынчы еллары башында абыйсы, иң милли шагыйрьләребезнең берсе, атаклы «Ачлык мәйданы» шигъри бәйләме авторы Рәшит белән унөч көн азатлык өчен көрәшеп ач торуын бер студент та белми икән.

Ә инде минем икесе белән дә яхшы таныш булуым, «обком больнисе»ндә бер чорда ятуым турында бәйнә-бәйнә мактанып сөйлисем килсә дә, берәүнең дә кызыксынганы күренмәү сәбәпле, кәгазьгә «төшереп» калдырырга булдым. Бигайбә.

## Дүртенче хат. Элемтәче мәхәббәте

Элеккеге хатларымда сүз күбебез таныган, хөрмәт иткән олуг шәхесләр турында барса, «жиргә төшәргә», иң кыен мизгелләрдә кулыма кашык тоттырган, суымны алып биргән кеше турында язарга да вакыт житте. Ләйлә белән Оксаналар «карамагыннан» аска, неврология бүлегенә төшереп, ике кешелек палатага урнаштырдылар. Күршем белгечлеге буенча элемтәче, шулай ук инсульт кичергән, үзен мина караганда яхшырак хис иткән Наил Жамалиев булып чыкты. Таныштык. Ипле генә яши башладык шикелле. Берничә көннән соң, күршем янына 14-15 яшьләрдәге малаен һәм аннан берничә яшькә кечерәк кызын ияртеп хатыны килде. Мин аның өчен шатланып ук куйдым, димәк кешенең тулы гаиләсе, кайгыртырдай якыннары бар. Әмма кара тут йөзле, уртача буйлы, тыйнак кына киенгән ханым ни сәбәптәндер, бурычка әйбер сорарга кергән теләнче кебек, тартынып, һәр адымын санагандай, иренә акрын гына якынлашты. Өчесе дә, бер-берсенә юл бирергә теләгәндәй, бүлмә ишеге янында тукталып-төртелеп калдылар. Чирле әтиләрен бимазалаудан читенсенәләр диебрәк уйлап, үз өстемә чикләнгән җаваплылыкны алып, «түргәрәк узыгыз, нишләп ят кешеләрдәй бусага янында торасыз», дип сүз каттым, дивар ягына борылып яткан элемтәчем кунакларны күрмидер яисә йокыга киткәндер дип уйлап:

—Наил тор, балаларын килгән, — дип өстәдем.

Минем эндәшүдән соң, ятагы кырыена торып утырган әтиләре янына балалары якынрак килеп, җиңелчә генә сыеныштылар да, әниләренә урынны бушаткандай, читкәрәк китеп бастылар. Ханым кулындагы төргәген

урындыкка куеп, песи шикелле атлап, бик акрын гына ире янына килеп туктады.

— Хәлләрен ничек, Наил. Терелеп киләсенме? Без бик борчылдык. Реанимациягә дә килгән идек, кертмәделәр.

Иркенләп көрешсеннәр, кочаклашсыннар, кирәк булса, пәп итешсеннәр дип читкәрәк борылган идем, колакларыма теләсә кемне егып салырлык сүзләр килеп бәялде.

—Мин бит сина килеп, борчып йөрмәгез дип кат-кат әйттем.

— Балалар әтине күрәсебез килә дип тенкәмә тигәч, алып килдем инде, — диде ханым, әллә каян ерактан килгәндәй төксе, гаепле тавыш белән. — Мин үзем сине борчып йөрмәгән дә булыр идем. Кызын сине бик сагына, елый, төшемдә әтием башымнан сыйпады, чәчләремне рәтләп куйды, саташып беттем, — ди.

— Мин бит сина башка хатын янына китәм дип, кат-кат әйттем. Килде-китте төшләр сөйләп, нервымда уйнап йөрмәгез!

Ханым башка бер сүз әйтмичә, урындыктагы төргәген кулына алып, кая куярга белмичә уйланып, икеләнеп торганнан соң, минем якка борылып, «абый, мин пылау пешереп алып килгән идем, сезгә калдырыйм әле», диюгә мин күз карашым белән генә тумбочкам өстенә күрсәттем. Бу адымымны хәзергәчә аңлата алмыйм. Ни өчен шулай, боламык кебек җебеп төшеп, чит ханымның төргәген алып калуымның сәбәбен тапмыйм. Чөнки ул «төерле» пылау булып чыкты. Иренен турсаеп ятып, ризыктан баш тартуын хупламасам да, арадашчы булырга ни хакым бар? Аң төпкелемә ашамлыкка ана сөте белән кергән ихтирам шуңа этәрдеме, әллә хатыны, балалары чыгып киткәч, Наил белән бергә утырып ашарбыз дип уйладыммы, билләһи дим, бу «сентиментальлегемне» һич кенә дә тәртәгә сыйдыра алмыйм.

Кинәт ашыгыч эше исенә төшкәндәй, тиз-тиз атлап әүвәл ханым, аның артыннан ирлек горурлыгы уяна башлаганы сизелеп торган малае чыгып киттеләр. Кызы ишек янында туктап, ятагына җәелеп ятарга өлгергән әтисе ягына карлыгандай кара күзләре белән, мәңгегә саубуллашкандай, гаҗизләнеп, томырылып карап алды. Аларда рәнҗү, өмет, ярату, гарьләнү, сагыш, үкенү... барысы бергә укмашкан иде. Инсультның бер үзенчәлеге — күңел йомшару, күз төбендә тулышып, һәрдаим тышка бәреп чыгарга әзер булып көтеп кенә торган тозлы су.

Кыз ишеккә янә бер адым ясап, такта бусаганы атлап чыгарга да өлгермәде, бүлмәбезгә өермәдәй атылып, яшь, чибәр бер хатын-кыз заты килеп керде. Ул уяткан җилдән кыз бала егылып китә язгандай тоелды. Артыннан ишекне ябып вакланмыйча, кerә-керешкә затлы җиңел күн пальтосын Наил караваты янындагы урындыкка ташлады да, «привет милый», сүзләре авызыннан чыгып җиткәнче үк, ятагыннан күтәрелергә азапланган элемтәчене урынына төртеп яткырды, битеннән, күзләреннән, иреннәреннән шаша-шаша үбәргә тотынды. Күзебезгә акыл хуҗа дип ышандырырга тырышсак та, кызыксыну (бәлки, нәфестер) хисе һәрнәрсәнә җиңә икән. Минем якка арты белән торып ярым бөгелеп Наилне иркәләгән хатынның озын төз аякларын, йомры арт санын иңләүдән күрер күзләремне — оятсыз явызларымны тыя алмадым. Хәтта бер мизгелгә югары әхлаклы педагог абзагыз теге нарасый турында да онытып җибәрә язды. Ишекне кайсыдыр ныклап ябып куйган икән. Ә монда бушлай тамаша дәвам итте. Авызлар бушаган мизгелләрдә: «ты зачем так долго не звонил? Я потеряла всякое терпение, ведь я очень соскучилась по тебе, мой зайчик», кебек җөмләләр һавага эленә торды. «Я здесь больше оставаться не намерена, как ты обещал, мы срочно переезжаем в Москву. Ты еще до болезни говорил,

что тебе подыскали работу, квартиру пока снимем». Бу сүз тезмәләре артык примитив күренсәләр дә, аларның нигезендә мәхәббәт төтене — «фәлсәфи фикер» — элемтәчене тирәлегеннән, гаиләсеннән аерып алып китү нияте ятканы мөгез кебек алга чыгып тора иде.

Озакка сузылган үбешүдән, русчадан «бурычка» алынган җөмләләрдән соң, «шулай бит матурым, китәбез дигәч, китәбез», — кебек татарча тәгъбирләргә дә урын табылды. Бүрәнә астында калган кешене хәтерләткән элемтәче, ясалма икәнлекләре артык төчелекләреннән аңкып торган аңлашуларны, бәйләнешсез җөмләләрне, ихласи, чын күңелдән дип кабул итә иде бугай.

Ниһаять, чакырылмаган кунагыбыз, үз бәясен белеп, Наил өстеннән акрын гына күтәрелде дә, монда тагын бер бөҗәк бар икән мәгънәдә минем якка күз салды. Ханым рәсемнән төшкән тере сын кебек чибәр иде. Озын буй, нечкә бил, төз аяклар, затлы иннек-кершәнне мул кабул иткән ияккә тараеп төшкән бит дисеңме, җилкәсенә таратып салынган куе коңгырт чәчкә дәһшәти көч биреп, очкын чәчеп торган күзләр һәм бөтен гәүдәсенә, басып торышына иңгән серле эрелекне әйтәсеңме, һәммәсе урынында. Мондый һавалы тәкәбберлек еракта килгән затлы нәсел дәвамчыларында яисә арка тирәге нык, ышанычлы кешеләрдә генә була. Бу түтинең таянычы паралич авыруы кичергән элемтәче Җамалиев кына булмавында бер кәррә дә шигем калмаган иде.

Димәк, бу чибәркәйнең башка, кайсыдыр югарылыкта йөнтәс кулы бар. Үзләрен артык югары бәяләгән бәндәләр еш кына тәҗрибәсез, беркатлы, артык ышанучан булалар һәм тормышның кырыс чынбарлыгына барып төрәлгәч, уалып төшәләр, югалып калалар, дип тә уйлап куйдым.

— Исәнмесез, — дип өстән — минем караватт дәрәҗәсенә төшкән сүз, мине чынбарлыкка кайтарып, айнытып җибәрде. Ханым бу сәламләүне үзеннән кысып чыгарып, түгәрәк йомры тезләрен минем игътибарга калдырып, караватт кырыена утырып, янәдән урысча-татарча шул ук сүзләрен кабатлый-кабатлый, яраткан шөгылен — элемтәчене ялавын дәвам иттерде. Мин әле аякка басмаган, бүлмәдән чыгып та китә алмыйм, икенче якка борылып кына ята беләм. Бичарадан ничара дигәндәй, берәүләрнең фаҗигасенә, икенченең сөенеченә шаһит булып, тик бушлай тамаша карап ятам.

Үбешеп туйганнан соң, олы бурычын үтәгән кешедәй, ханым «чао, милый»га кул изәвен кушып, истәлеккә кыйммәтле хушбуй исен калдырып, чыгып та китте. Рәнҗетелгән, кимсетелгән никахлы хатыныннан аермалы буларак, кунак кызының кулында төргәк-мазар юк, нәрсәдер күтәреп йөрү дәрәҗәсенә төшмәгән иде ул.

Ханым чыгып киткәч, андый очракларда булырга тиешле тынлыктан соң, мин «сүз алдым».

— Минем тумбочка өстендә хатының сиңа күчтәнәч калдырды. Пылау диде бугай. Ашап куябызмы? Минем тамагым тук булса да, тәмләп карый алам.

— Юк, мин ачка үлсәм дә, аны ашамыйм. Алып калгансыз икән, үзегез сыйланыгыз, — дигән тез астына китереп бәргән җавапны ишеткәч, ялган демократлыгым белән үземне нинди авыр хәлгә куйганымны бөтен гаҗизлеге белән тойдым. «Ризыктан өстен булырга ярамый» дигән ислам тәгълиматына хуҗаның исе дә китми, хатыны, балалары күтәреп килгән пылауга кагылырга да теләми. Мин дә башка кеше өчен пешерелгән тәгамны авыз тутырып ашап утыра алмыйм ич инде. Бүлмәгә хуш ис таратып утырган пылауны капкалап та куйган булыр идем дә, гүр иясе хатыным Галия, авыр туфрагы җиңел булсын, һәр көнне иртәнге тугызга кайнар өй

ризыгы алып килеп, мендәргә терәтеп утыртып, ашатып, савытларымны түгеп, чистартып китә торганые.

— Сон, егетем, синен өчен махсус пешерелгән пылауны берүзем уртлап (никтер шунда башкорт сүзе телгә килде) утыра алмыйм ич инде. Хатыным алып килгән пилмәнне күптән түгел көчкә ашап бетердем.

Инде дустым булмаса да, яхшы ук танышым — элемтәчем мина тагын да катырак бәрелде.

— Алып калган вакытта нәрсә уйлагансыздыр, анысы мина билгесез. Хатынымны ошаткансыз икән, ул хәзер ирекле, рәхим итегез!

Мондый авыр гаепләүне ишеткәч, минем дә жен ачуларым чыкты, авырудан ныгып житмәгән һөжүмчән психлыгым уянды, нәрсә әйткәнемә жавап бирмәс дәрәжәдә туарылдым.

— Мин, егетем, яшем, жәмгыятьтәге урыным белән дә синнән өлкәнрәк. Ни сөйләгәннәренне чамалап әйт! Мин бу төргәкне хатынынның хезмәтен, балаларынны, аеруча куян баласы кебек ягымлы кызынны кызганып алып калдым. Чибәр гайшәне кулга төшердем, дөресрәге, анын жәтмәсенә эләктем дип кенә гаиләнә шулай миһербансыз булырга ярамый. Хатынын да тыйнаклыгы белән мина ошады. Ошау белән женси азгынлыкны бутама.

Дөнья куляса, берәү дә кем кулында сонгы сулышын аласын белми. Әнә бит бөтен ил дөньясын онытып, ябырылып, телевизорнын эченә керерлек булып караган «Язнын 17 мизгеле» фильмынын сценарий авторы Юлиан Семеновны паралич суккач, Германия дә, Израиль дә аякка бастыра алмагач, бай, исән вакытында типтереп яшәгән хатыннарына-сөяркәләренә килеп алырга тәкъдим иткәннәр. Барысы да баш тарткан. Синен шикелле ташлап киткән беренче хатыны риза булып, карап, гомерен дә азмы-күпме озайтып, кадерләп сонгы юлга озаткан.

Элемтәченен мине чыгырымнан чыгаруы шул чаклы көчле булды ахырысы, караватта яткан килеш мондый озын нотыкны гомеремдә тотканым юк иде. Хәтта Наил иптәш тә мине беренче кат күргәндәй, хөкүмәт мендәреннән башын күтәреп, гажәпләнеп, сәерсенеп тынлады. Ә мин татарга акыл, нәкъ мәкальдәгечә, төштән сон керә икән дип, үземне кызган табада «сикертә», тәрбияли башладым.

«Вәт шыр тиле, ахмак. Ни пычагыма кирәк иде сина ул үзбәк ризыгы, элемтәче төрттергәнчә, эчендә ач бүреләр улыймы, әллә ризыкнын тәмле исе борынынны кытыклап, нәфесенне тыя алмадынмы? Кемгәдер яхшатлы булып, кемсәнендер жәберсетелгән, ташланган хатынын жәлләгән имеш, Саламторхан, буш демократ (дермократы турырак та килер иде). Ирләрен янында тота алмаган мәхлукъ хатыннар буа буарлык. Хәләл жефете башкага күз салган икән, димәк ки, гаеп үзендә дә бар. Әлеге түти кебек урынына төртеп егып, шашып-шашып убә, мәхәббәте турында сафсата сата, иркәли белмәгәндер. Сина нәрсә житмәгән? Үз хәсрәтен генә азмыни? Әле үзен дә аягына баса, яраткан эшенә кайта алырсынмы? Ярым мәет булып хөкүмәт караватында аунап ятып, жимерелгән гаиләләр кайгысы белән чәбәләнергә булдынмы? Афәрин, иптәш Галиуллин». Шул рухтарак үземне шактый тәрбияләдем, уттан алып салкын суга ташладым.

Шактый вакыт борын шәрифләрен (ана бераз салкын тигән иде) шыгырдатып ятканнан сон, элемтәчем мина тикмәгә шулай каты бәрелгәнен анлады бугай.

— Гафу итегез инде, Тәлгат абый. Минем чыннан да ашыйсым килми. Элек пылауны бик ярата идем. Хәзер ул ризыктан биздем.

Шактый озак тоелган тын алыштан сон өстәп куйды:

—Бер житди сәбәбе бар. Ул хакта соңрак...

Икебезне дә бизәмәгән әңгәмә алып барган мәлдә бүлмәгә даруларын, инәләрен күтәреп, шәфкать туташыбыз килеп керде. Күк капусы ачылгандай булды, ми шәрифләрем: «менә бит бер гаепсезгә кимсетелгән пылауга хуҗа», дип пышылдады. Ходай яраткан колына — чыгарып куяр юлына дигәннәре шулдыр инде.

– Гөлназ, тастымал белән төрелгән пыяла банкада бик тәмле (ашап караган кеше кебек) пылау. Шуны алып чыгып, кызлар белән безнең исәнлеккә тәмләп куегыз әле!

—Үзегез ник ашамыйсыз?

—Без тукландык инде. Зинһар алыгыз, юкса бозыла башлар.

Шәфкать туташы, ялындырып тормыйча, дустан дошманга әйләнә башлаган төргәкне алып чыгып киткәч, өстемнән тау төшкәндәй булды.

Форсаттан файдаланып, шуны да искәртәсе килә: хастаханәләрдә эшләүче шәфкать туташларының иң зур күпчелеге Казан, Чистай, Минзәлә, Алабуга медицина көллиятләрендә укып чыккан итагатьле, ягымлы, чын татар гаиләсе тәрбиясе алган кызлар. Хәтта башка милләт балалары да алар йогынтысына бирелә. Халат кесәләренә «авыз тәмләтеп алырсыз», дип алма, апельсин, шоколад, груша ише вак-төякне салсаң да, мәгънәле елмаеп кабул итәләр. Бу үзенә күрә чирлене ихтирам итү, ә безнең яктан кылган игелекләре өчен рәхмәт әйтү кебек санала.

Ә элемтәченең мәхәббәт маҗарасы һәр көнне берүк сценарий буенча дәвам итә: кичектермәс эшен башкарырга килгән кеше кебек, ашыга-кабалана бүлмәгә килеп керү, өске киемне урындык артына ташлауга Наилне ятагына төртеп яткырып үбә, иркәли башлау. Тулышкан яскынуны бастырганнан соң гына, бүлмәдә янә бер мәхлугы аунап ятуны искә төшереп, минем якка әллә кимсетүле, әллә кызганулы караш һәм нечкә иреннәрдән кысып чыгарылган «исәнмесез». Каршы яктагы караватта сүз икесенең дә булган акчаларын җыеп, машиналарын сатып Мәскәүдә торак юнәтү турында. Башлам кәлимә шул ук: «ты обещал, ты мужчина, должен сдержать свое слово». Ходай Тәгаләнең телевизор карый, концертларга йөри алмаган өчен миңа бушлай тамаша җибәрүе булгандыр дисәң, кемнәр өчендер (әйтик, элемтәченең хатыны, балалары) биредә чын фаҗига төенләнеп ята.

Ханымның табигый һәм ясалма матурлыгын таныйрга мәҗбүр булган хәлдә дә, мин Наилне әгъвәләүчедән житешсезлекләр, килешеп бетмәгән яклар эзли башладым. Борыныннан аска таба очлаеп киткән йөзе ниндидер кошнымы, җәнлекнеме хәтерләтеп тора. Үбешүдән туктый, туя белмәгән бәндәләр ягына тәнкыйди караш ташлагач, элемтәчем миңа козгынга җим дәрәҗәсенә төшкән яралы аккош булып күренде. Бу «табышым», ач карынга көчле хәмер эчкәндәй, бөтен барлыгымны җылытып җибәрде. Каян килеп керде соң әле бу козгын сурәте? Баш миенең исән калган сул ягы хуҗасына ярдәмгә килде. XX йөз башы татар шигъриятенең күренекле сүз остасы Дәрдемәнднең «Козгын» исемле эчтәлеге, мәгънәви тирәнлеге белән һәр чорда заманча яңгыраган шигыре бар ич. Тиешле бәясен алмаган бу әсәр шагыйрь мирасында аерым урын тота. Хикмәт шунда: вакыйгалы сюжетны өнәмәгән, фикерен, хисен лирик кичереш аша чагылдыруга өстенлек биргән философ шагыйрь «Козгын»да әйтергә теләгән фикерен укучысына драма алымы — ике ерткыч җәнлекне «сөйләштерү» аша житкерә. Тамагы ач козгынның ярдәм сорап мөрәҗәгать итүенә икенчесе: «Мин җим табамын», ди һәм аны «Яшел тугайда... Алдап үтерелгән батыр» янына алып килә. Баксаң, анда бик күп козгыннарга житәрлек азык ята икән. Кем ул егет, нинди язмыш аны шундый аяныч хәлгә төшергән?

Шагыйрь, детектив әсәрләргә хас төенләнеш үрнәгендә, үтерелүнең сәбәбен жәһәт кенә ачып салмый, киресенчә. «Кемдер егетне үтергән, Алган йөгерек атыны» дип, ярдәмче сәбәпне алга чыгарып серне тирәнгәрәк яшерә. Хәзергечә әйтсәк, ялланган киллер яхшы атына хужа булу өчен генә батыр егетнең жанын алмагандыр. Алдагы юлларда фажиганың сәбәбе тирәндәрәк ятуы, яхшы уйланылган мәкергә барып тоташуы, иң якын булырга, киресенчә, егетне сакларга тиешле кешенең хыянәте нәтиҗәсендә тууы ачыла. Тирән мәгънәле, фәлсәфи-әхлакый уйлануларга нигез булырлык чишелеш ике юлга сыя: «Белде бизәнеп утырган өендә яшь хатыны».

Мондый вәхшилекне оештырган ханымның, берни булмагандай, иннек-кершән ягып күзгә каршында утыруы, аны үле гәүдәгә ташланган козгыннардан да усал, мәрхәмәтсез — явызлык символы буларак күз алдына китереп бастыра.

Нибары унике юлдан торган шигырь образлар бәйләменнән, сүз-сурәт байлыгыннан бигрәк адәми затның табигатьтәге иң миһербансыз ерткычлардан да явызрак була алуын искә төшерә.

Шигырь тәэсирендә мин, чит язмышларга бәя бирергә хакым юклыгы турында онытыбрак жибәреп, элемтәчегә кинәшләремне индереп маташтым.

— Бар мал-мөлкәтеңне үз исеменә яздырганнан соң, «жимешең» (бу сүзгә көчле басым ясадым) «мин яшь, мин чибәр» дип, синнән йөз чөереп, урамга куып чыгарса яисә «Козгын»дагы ханым кебек, заманча әйтсәк, киллер яллап, үзеннән котылу юлын сайласа, нихәл итәрсең? Гаиләңне ташлап, ашыкмыйсыңмы, егетем.

Әлбәттә, мин көтелгән саллы жавап та алдым.

— Абзый, сез тормыштан, заманча яшәүдән артта калып барасыз. Кешеләрне берьяклы, китапча бәялисез. Без бер-беребезне үлеп яратабыз. Регинамның вак-төяк мавыгулары булгаласа да, ул миңа чаклы берәүне дә яратмаган. Мин аны очратканчы, үземне никчемный кешегә санап йөри идем, хәзер ачылып киткәндәй булдым. Чиремне тиз жиңүемдә (минем тарафка мыскыллы карашын уйнатып алды) мәхәббәтем төп таяныч булды. Сез «әгәр ташласа, нишләрсең», дип сорыйсыз. Андый хәлләргә төшкәнче, мин аның рәхәтен татып, сихри бишектә тибрәлеп калам әле. Андый сылу гәүдәне яратмыйча буламы соң?

— Бераз тыйнаграк кыйланса да, зарар итмәс иде, — дип мыгырдануым янган учакка коры утын өстәү генә булды.

— Ә ни өчен матурлыкны яшереп торырга. Кәкре йә артык нечкә аяклы хатын-кыз гына житешсезлеген кара ирләр чалбарына яшерә. Минем жимешем рәхәтләнеп тар итәк, төрле төсле колготкилар киеп, битенә, күз төпләренә кыйммәтле майлар сөртеп, үзен һәм дөньяны бизәп яши белә.

Көнбатыш илләре ни өчен шулай алга киткән? Алар им-томга, гайбәткә, катып калган әхлак кануннарына ябышып ятмый, үзләре теләгәнчә яши.

Минем «ну-ну» дип, исән кулым белән тимер карават артына тотынып, дивар ягына борылып ятудан башка хутым калмаган иде. «Моралист абзый» белән төнге бәхәсне дәвам итүнең мәгънәсе юклыкны икебез дә аңладык.

Таякка һәм диварга таянып, бүлмәдән чыгып йөри башлагач, чибәр ханым килеп керүгә, коридорга юл ала торган булдым. Анда да дөньяви мәшәкатьләрдән котылып булмый икән. Коридорның безгә якын башында утыручы апаныңмы, сеңелнеңме тавышын тыярга тырышып уфтануы, ыңгырашуы колагыма чалынды. Ханым миңа таныш тоелды. Бәрәч, бу элемтәче Наил балаларының анасы түгелме соң? Ул жыйнак гәүдәсе,

тыйнаклыгы, бигрәк тә бохар мәчесенеке кебек куе күгелҗем күзләре белән хәтеремә кереп калган иде. Иренең кырыс мөнәсәбәте, көндәше белән очрашасы килмәве аркасындамы ул шулай ишек төбендә йөренеп торырга мәҗбүр икән. Башка берәү булсамы, «мин аның законлы хатыны» дип, Наилнең җимешен бүлмәдән пыркылдатып куып чыгарыр, чәчләрен йолкып бетерер иде. Чын татар хатыны шул... Иң гадәти әхлак кагыйдәсе буенча тынлыкны мин бозарга тиеш идем.

—Исәнмесез! Хәлләрегез ничек, балаларыгыз сау-сәламәтме?

– Аллага шөкер! Барыбыз да исән-имин. Менә авыл тавыгы белән бәрәнге кыздырып алып килгән идем. Кызым җылый-җылый, «әнием, бик тәмле булган, әтигә дә илтеп кайт, син бармасаң, үзем чыгып китәм дип тәмам тенкәмә тиде. Аптыраганнан арты белән суга чумган үрдәк кебек риза булдым да, хәзер бүлмәгезгә керергә базмый йөрим. Шул зәхмәте алдында түбәнсенәсем килми. Теге көнне иремнең гаиләсен чит-ят кешеләрдәй кабул итүе йөрәккә тиде, рәнҗетте... Сау булыгыз дип тә әйтмәде. Ярый, мине якын итми, мәхәббәте узды, ди, ә балалары, балалары... Аларның ни гөнаһлары бар? Шулайдыр бит, — дип, ханым мине дә «почмакка» китереп кысты.

Иренә алып килгән ризыкны янәдән минем аша тапшыру теләге тууны сөрмә күзләреннән «укып», сүзне башкага күчермәк булып кына сорау бирдем.

– Наилең бу ханымның кармагына күптәннән каптымы соң? Балаларына да әтинең иң кирәк вакыты, — дип беренче соравымның урынсызрак яңгырашын аз булса да шомарту нияте белән, акыл сатып алу юлына төштем. — Минем аңлавымча, аеруча кызы әтисен бик ярата. Улың үзен ирләрчә тота, мескенләнми, ялынмый.

Ханым балаларына бәямне читтә калдырып, җавап боҗрасына беренче соравымны алды.

– Өйдән киткәненә өч ай. Теге нәмәстәкәйнең фатирына күчте дә, үзенә инсульт булды. Паспорты буенча, ул бездә торганга санала, табигый ки, больницадан өйгә шалтыраттылар. Шуңа гына килгән идек ул көнне. Явыз чиргә таргач, күңеле йомшарыр дип уйлаган идем. Зәхмәте моңа тешетырнагы белән ябышкан. Байлыгын алып бетергәч, үзен чыгарып ташлар әле. Соныннан барыбер балалары кулына калачак, ул шуны аңламый. Минем күңелем катты. Үзен яратсам да, гафу итә алмам шикелле. Сукыр мәхәббәтемнең күзе ачылгандай булды, — диде дә ханым, өерелеп килгән хисен тыя алмыйча, елап ук җибәрде. Аның фикерләү рәвеше, татарча матур итеп сөйләве мине гаҗәпләндерде. Шул хакта соравыма ул «мин әүвәл татарча педучилище тәмамладым, аннан соң химия-технология институтында белем алдым», дип җавап бирде яшьләрен сабыйлар шикелле йодрыгы белән сөртә-сөртә.

Язучы һәм әле генә дөнья мәшәкатьләре белән кызыксына башлаган кеше буларак, Наилнең бу гайшәне каян, ничек табуы, мөнәсәбәтләренең ни дәрәҗәдә житдилеге, тирәнлеге турында беләсем килү эчтән кымтырыклап торса да, шул мәүзугъка килеп чыгачагыбызны җиденче тоемым белән сиземләп, үземне тыеп кала алдым. Кеше дигән бөек затның кем беләндер серен уртаклашасы, минем кебек тыңлаучы булганда, эчен бушатасы килүне аңлау өчен дипломлы психолог булуның кирәге юк иде. Ханымның рухи халәте шундыйрак, бугазыннан буып алган хәсрәтен чыгарып ташлыйсы килүе, кинәт битенә бәреп чыккан кызгылт тимгелләр буенча сизелеп тора иде. Бераз икеләнеп алгандай булды да, яныма ук утырып, тормыш йомгагын, ачы тәҗрибәсен сүтүне дәвам иттерде. Су буаны бер тишеп чыкса, аны тиз генә туктату турында хыялланма.

– Шәһәр элемтә бүлегендә яхшы гына эшләгән Наилне Казанның бай ширкәтенә белгечлеге буенча эшкә чакырдылар. Элемтәчеләр бит болай да нефтьчеләр, газовиклар, электр белән эш итүчеләрдән һәм түрәләрдән кала иң югары хезмәт хакы алучылар. Өйгә яна җиһазлар кайтардык, чын күн тышлы диван, креслолар алдык, барыбызга да затлы киемнәр юнәттек. Царицино бистәсендә күптәннән төзи башлаган коттеджның очына чыктык. Кыскасы, тормышыбыз тәмам рәтләнеп, кешечә яши башлагач кына, беркөнне эштән кайтсам, фатирыбызга угры кергәндәй, һәрнәрсәнең астыөскә килгән. Шактый аптырап, аңымны югалткандай утыргач, өнемә килеп, Наилгә шалтыратыйм дип, телефон янына барганда, өстәл өстендә кош теле хәтле генә язу күрдем, кат-кат укыгач кына хатның эчтәлегенә төшендем. «Рәмзия! Мин башка хатынны яраттым, аның янына күчеп китәм. Фатир сезгә кала, теге йорт үземә. Син акыллы хатын, аңларсың, тавыш күтәреп кеше көлдереп йөрмәссең дип ышанам. Наил».

Яшь балаларыбыз хакына, горурлыгымны җиңеп, иремнең кесә телефонына шалтыратып, «нәрсә булды, җинаятьче кебек чыгып качкансың, кешечә аңлашып аерылышып булмый идеме», дип, сөйләшеп алмакчы идем, җавап бирмәде, телефонын сүндереп куйган идеме, башка номерга алыштырганмы, ул хәтлесен аңларга башым җитмәде. Сулкылдауларын басарга тырышып, чигәләремне ике яклап кулларым белән тотып, уйга чумдым. Шундый хәтәр мизгелләрдә ми үзенең йоклап яткан мөмкинлекләрен эшкә җигә икән. Шулай ярым миңгерәп утырганда, Наилнең күлмәген юарга салганда, күкрәк кесәсеннән чыккан, ул вакытта бик гадәти күренгән бер хат кисәге искә төште. «Наиль сегодня тебя не смогла увидеть, с работы не отпустили, вечерком брякни домой. Регина», — дип язылган иде анда. Эше буенча берәр танышы яисә Самарада институтта бергә укыган сабакташы дип уйлап, игътибар итмәгән идем бу язмага. Шунда миңа эчке тоемым Регина атлы ханымны эзләп табарга дигән «киңәшен» бирде. Бу көнчелек булдымы, әллә мине кемгә алыштырган икән дип кызыксыну гына идеме, киттем ирем эшләгән ширкәткә. Анда керүе дә, кеше турында нинди дер мәгълүмат алу сират күперен кичкәннән дә хәтәррәк булып чыкты. Баласы бик каты чирләп китте, әтиләрен эзләп килдем, телефонын алмый дип, паспорттагы тамгаларны тикшергәч кенә, эчкә үткәрделәр. Өлкәнрәк яшьтәге каравылчыдан «минем әле монда Регина исемле туганнан туган сеңелем эшли, аны да күреп чыгармын дигән идем», кебек шомартуым тиз генә нәтиҗә бирмәде. «Монда меңләгән хатын-кыз арасында Регинадар бик күп, татар бит шундый, бер исемгә ябышса, бертөсле кычкырган дивана күке кебек, башка матур исемнәрне оныта», дип, акыл сатырга ярата торган, күп сүзле абзый булып чыкты. Башка мөмкинлек күрмәү сәбәпле, җыйнак кына кечкенә сакаллы каравылчыга үзем күзаллаганча, юнәлеш бирергә тырыштым. Наилнең гади эшче, ашханә хезмәткәре белән бәйләнмәячәген чамалап, «сеңелем бик чибәр, каядыр контора, кадрлар бүлеге, бухгалтерия тирәсендә хезмәт итәргә тиеш, бүген аны туган көнемә чакырмакчы идем», дип, үзем ышанырлык итеп ялганларга керештем.

– Иң югары түрәләрнең секретаремы, тагын кемедер булып эшләүчесеме бер Регина бар. Тик ул озын буйлы, сиңа бөтенләй охшамаган, — диде, буемны үлчәп карагандай, кечкенә күзләре белән мине үтәли сөзеп карап. Мин икенче кат мәкергә, алдашуга барырга җөрьәт иттем.

– Без аның белән бөтенләй бер-беребезгә охшамаганбыз. Чөнки без кодачалар, — дип тагын нәрсәдер өстәмәкче идем, бәйләнчек кигәвенне кугандай, абзыем өч катлы зиннәтле йортка төртеп күрсәтте дә, икенче якка ук борылып китте. Каравылчы күрсәткән бинаның беренче катында шул ук сораулар белән җыештыручы апага мөрәҗәгать иттем. Белгәнен кем

беләндер уртаклашасы килгәнен яшермәгән татар апасы сөйләгәннәрне тынлап, иремнең мине кемгә алыштырганын белгәч, гарьлектән күз алларым караңгыланып китте, аның артыннан үзем дә пычрак базга тәгәрәп төшкәндәй булдым. Шул ук апаиның аңлатуынча, Регина Хәйруллина дигән чибәр ханым ширкәтнең башында торучы егетләрнең берсенең сәркатибе саналып, чынлыкта аларга ашарга әзерләп, башка барлык ихтыяжларын канәгатьләндереп торырга тиеш булган, бу җәһәттән аның вазифалары чикләнмәгән икән. Кызый күпне белә, таләп итә башлагач, аңардан ипле генә котылу әмәлен эзли башлыйлар һәм аны бу мәсьәләдә тәҗрибәсез, талымсыз, боламык Наил белән таныштыралар. Элек мондый давыллы, оста ханымны күрмәгән өй тавыгы тәмам изрәп, чын-чынлап гашыйк була.

Әлбәттә инде минем иремнән сөйрәлчекләренең ни, нәрсә белән шөгыльләнгәнен яшерәләр, кәгазь эшләрен белә, гаять таләпчән сәркатип дип күкләргә чөеп мактыйлар, үзебезнең аны читкә җибәрәсебез килмәсә дә, ул гашыйк булдым, гаилә корып җибәрер, балалар үстерер вакытым житте, мине тоткарламагыз дип, безне ышандырды. Кешенең бәхетенә аяк чалырга хакыбыз юк дигәннәр, имеш. Шул ук апаның курка-курка, мәгәр гаепләп, әрнеп сөйләвенә караганда, бу бай егетләр «сәркатиплеккә» конкурс белән яшь, ышанучан кызларны сайлап алып, зур эш хакы түләп, фатирлар биреп, берничә елдан соң, үзләрен туйдыргач, аны шул рәвешле, борынгы алпавытлар кебек, кияүгә бирәләр. Гаҗәеп, тирән уйланылган мәкер, сарык та почти исән, бүре дә тук.

Үзен чир бәреп екканчы ук, Наил коттеджын, машинасын сатып җибәргән бугай. Мәскәүдә фатир юнәтеп, шунда күчеп китмәкчеләр.

—Башкалада нәрсә белән шөгыльләнмәкче була икән ул?

— Ширкәт егетләре әлеге чәердән коткарган өчен рәхмәт йөзеннән, Мәскәүгә чыгып, белгечлеге буенча эш тапканнар, дип ишеттем.

Ханым сөйләгән мажаралы вакыйга-хәлләргә ышаныргамы, юкмы, көнчелек хисенә бирелеп, үзе генә уйлап чыгарма ганмы дип икеләнеп, шул ук вакытта авырткан башка тимер тарак кебек килеп төшкән бу мәгълүматлар миңа ни пычагыма кирәк инде дип үземне битәрләп торган мәлдә ханымның теге көндәге шикелле, алып килгән ризыгын миңа тапшырып китәргә җыенуын сиздем.

— Сез моны алыгыз әле? Рәхәтләнеп бергә ашарсыз, кызым хаклы, чыннан да кетердәп, авызда эреп тора.

Бу юлы абзагыз, селәгәен агызып, жебеп төшмәде: ризык тәменә дә, борын тишекләреннән үтеп, ихтыярын кипкән камыш кебек сындырырга ирек куймады.

— Юк инде, ханым, үзегез кертеп бирегез. Бер кулым начар тота, йә төшереп җибәрермен. Үз хатыным китергән мантыйны да ашап бетерә алганым юк. Теге юлы сезнең пылауны кызларга бирдем.

Соңгы җөмләмә ханым батып баручы саламга ябышкандай тотынды.

— Карагыз әле, бу бит шәп идея. Мин дә сестраларга калдырам да, кызым сораса, «әтиең ашады», диярмен. Алдый алсам, сабыемны.

Әйләнеп торган көпчәккә эләккән тиен кебек бәргәләнгән хатынны шунда калдырып, бүлмәмә кереп китү ягын карадым. Ятып торасым да килә башлаган иде.

Ашыкмыйча гына булса да, көн артыннан көн уза торды, акрынлап «пылау фетнәсе» тудырган киеренкелектән арынып, бераз тынычлангач, элемтәче күршем белән кешеләрчә аралаша башладык. Олы мәхәббәтемне таптым дип әтәчләнсә дә, аңа да жинел түгелдер, нинди генә таш йөрәкле кеше дә, психик яктан кагыйдәгә сыешлы акылы, хисе булса, балаларын ташламый. Вакыт күп, дәрескә соңга калам дип кабаланасы юк, Наил белән

тормыш, адәм баласының язмышы, бездән берәр нәрсә torгандай, татар халкының киләчәге турында сөйләшүләребез шактый булды. Яна хатыны белән ничек танышуы, аның кем булуы турында җәелеп китеп, мәхәббәт көймәсен селкетәсе килми егетнең. Минем дә белгәнемне ачып салырга хакым юклык аңлашыла булыр.

– Дустым, синең беренче хатының сабыр, итагатьле, акыллы күренә, үзен яратмасаң, балаларың өчен булса да түзәргә, ә жимешенне (ул аны шулай гына атый) болай гына «чеметкәләп» йөрергә идең. Гашыйк булган саен хатын алыштырган намуслы ирләр сирәк. Андыйларны рәсемдә генә сакланган диназаврлар шикелле кабул итәләр безнең заманда. Үткән гасырның бөек артистларыннан берсе — Габдулла Шамуков нәрсә ди: «Касыбыз гына катыннар белән йөрмәгән дә, касыбыз гына аны катып катынына сүләгән инде».

– Юк абзый, мин алай булдыра алмыйм. Дөресе, болай гына очрашып-ратышып йөрүгә ул риза булмады, өйләнү, бергә тору шартын куйды. Мин өйләнергә вәгъдәләр биреп ташладым. Регина эшкә чумган, берәү белән дә буталмаган, мин аны беренче күрүдә ук, унжиде яшьлек егет кебек, втюрился.

Артыгын ычкындырып ташлаганын аңлап, элемтәчем шып туктап калды, мин дә телем бәйдән ычкынып китмәсен, дип, аны аркылыга тешләп, сүз елгасын башкарак агымга күчердем. Гамлетның бөтен дөньяны кубызында биеткән «tu be or not tu be» кәлимәсе кебек, безнен дә очына чыгып житмәгән «пылау мәсьәләсе» бар иде бит әле.

– Теге көнне пылауны ашаудан баш тартуынны тәки аңламый калдым. Синең борын чөюең аркасында мин дә ризыкны авыз итмичә калдым.

–Алдыгызда торды. Ашарга идегез!

–Һм...

–Минем аңа кагылмавымның житди сәбәбе бар.

–Барыбер үзенне аштан өстен куярга ярамый.

Ул бу абзыйга ачылыргамы, әллә кабык эчендә калыргамы дигән төсле янәдән икеләнеп торганнан соң, мина шактый көлке тоелган серен уйдырып салды.

– Плов пешерүченең, ягъни минем хатынның им-том белән шөгыльләнүче таныш чуаш карчыгы бар. Регинаны ташлатып, кире янына кайтарыр өчен өшкертеп китергән булу ихтималы бар иде. Рәмзия барысын да булдыра. Пловны бик яратсам да, үземне тыеп кала алдым.

Мин үзем андый хорафатларга, им-томнарга, сихерче карчыкларга ышанмый торган кеше буларак, Наилнең мондый юрамасын шик астына алдым.

– Син шул әкияти юк-барга ышанасыңмы, замана баласы? — дип белдерүемә ул:

– Шуның аша узган кеше буларак, үземне сакларга тырышам. Биш-алты ел элек башка хатын янына китәргә җыенгач, «кичке ашны соңгы тапкыр бергә утырып ашыйк та, аннары дүрт ягың кыйбла», дип алдады. Йөз грамм салып, жылынып киткәч, кунарга өйдә калдым. Иртәгесен шашынып, дөньямны онытып яратып йөргән теге чибәр ханым миңа мунча пәрие булып күренә башлады, — дигән аңлатмасын тәкъдим итте элемтәчем.

Беренче хатыны Рәмзия аны боламык, өй тавыгы, ди, ә ул шактый «эзләнүчән», тынгысыз, Көнбатыш әхлагы беләнрәк яши торган кеше икән. Егетнең интеллекты тирән түгеллеген чамалап, мишәрең әйтмешли, берцәк акыл сатырга булдым.

– Син үзең тиктормас кеше икәнсең. Гомер буе мәхәббәт нурында коенып кына яшәп булмый. Минем туган авылым Кычытканлының

философы Әбелгаяз абый «хатын беренче айда гына чәчәк, гомернең калган өлешендә тигәнәк», ди торган иде. Без бит бал корты кебек чәчәктән чәчәккә сикереп йөри алмыйбыз. Тигәнәкне дә үзенә җайлаштырырга, аның файдалы ягын таба белергә кирәк.

Ачылып киткән Наилнең кемгәдер эч серләрен сөйлисе килүен сизеп, сорау бирмәдем.

— Беренче ялгышуымда Рәмзия үзе гаепле. Дәртем уянганда, үзенә җибәрми интектерде. Йә арыдым, йә теләгем юк, йә синен өчен бала алдырырга йөрисем калмаган дип үзеннән биздерде. Бер дустыма синең хатының да шулай интектерәме дип зарланган идем. Мин андый хатынны акылга утыртуның әмәлен беләм, димәсенме бу.

—Мине дә өйрәтмәссеңме дип сорагач, — ул шунда ук:

—Бүген кичкә мин кунакка чакырулы. Бергә барабыз, — диде.

—Нинди мәҗелес ул. Ире нәрсә әйтер?

—Хуҗабикә тол ханым. Аерылган.

Шампан шәрабы, чәчәк, конфет коробкалары күтәреп кергән кунакларны җылы каршы алдылар.

— Берсенең дә ире юк. Икебезгә җиде хатын. Әүвәл мәҗлес оештырган җаваплы кешене котладык. Үзләрен ташлап киткән ирләрен гаепләп, хурлап туйгач, җырлый, бии башладылар. Авылларда иң өлгер әтәчләр кычкыра башлаган вакытта гына таралыштык. Хуҗабикә «өстәлләрне урыннарына куясы бар» дип, мине җибәрмәде. Кунакларны озатып, ханым куенына килеп кергәч, эш турында оныттык.

Агач җимешеннән, адәм кыланышыннан беленә, ди халкыбыз. Элемтәчем шул хәлләре турында сөйләгәч, мин хәтта Наилнең «җимеше» — Регинаны да кызганыр дәрәҗәгә җиттем. Хәер, иш ишен табар, дигән әйтем дә бар бит әле мәгърур телебездә.

Икенче көнне элемтәчемнең кулына «выписан с выздоровлением» дигән кәгазь тоттырып, хастаханәдән чыгарып җибәрделәр. Тәрәзәмнән чыгу капкасы күренмәсә дә, аны каршы алырга балалары белән никахлы хатыны да, затлы машинада Регинасы да килгәнлеккә шигем юк иде. Наилнең кемгә ияреп киткәнен сизенсәм дә, җаваплылыкны һәм гөнаһын өстемә аласым килми...

Шул көннән соң ошбу мәктүбемдә бәян иткән каһарманнарымның берсен дә очратмадым. Инде Җамалиевнын улы да, кызы да үсеп җитеп, үз гаиләләрен корып җибәргәннәрдер. «Элемтәче мәхәббәте» исемле язмамның, хикәя яисә новелладагы шикелле, чишелеше дә, бетеме дә юк. Ул — ирексездән шаһит булган бер вакыйга, кем өчендер фаҗига, кемгәдер күңелле вакыт уздыру турындагы гадәти язма гына. Нәтиҗә ясауны да укучының үзенә калдырам.

*Ахыры киләсе санда*

**Редакциядән**

*Шушы айда язучы, галим, журналыбызның даими авторы Тәлгат Галиуллинга 75 яшь тула. Каләмдәшебезне юбилее белән котлыйбыз, саулык, яңа иҗат уңышлары телибез!*



Луиза
Янсуар

# ДӨНЬЯЛЫКТАН САРКЫЛАМЫ САГЫШ...

## Кичә генә...

**Безне кисеп исә юха җилләр,
Сыенырга ышык юк илдә.
Бусагалар арты бусагалар.
Һәм тик безгә насыйп йөк — иңдә.**

**Безне көтеп тора күпме үрләр,
Безне сынап бага ничә күз.
Битлек арты битлек — салдырасың...
Кичә генә башка идек без.**

**Кичә генә бер хәвефсез иде,
Канлы эзсез иде туар таң.
Күзләренә багып үткәннәрнең,
Гыйбрәт алыр төсле иде җан.**

**Һәм хакыйкать... бардыр сыман иде,
Табылыр күк иде. Һичшиксез.
Кыйблалары куптарылган илнең
Тупсалары сыкрый — ишексез.**

**Тустаганнар арты тустаганнар —
Тостлар бар ла — булсын тик сәбәп.
Дошман белән бүлешсәк тә, барыбер
Безне көткән икән бу сәгать.**

**Безне көткән икән бу сынау да,
Бу сыкрау да, —
Сынатмыйча түз!
Ялган битлек кигән чынбарлыкка
Кичә әле ятлар идек без.**

---

Луиза ЯНСУАР — *шагыйрә; «Күзен ача умырзая», «Мин Күкләргә кайтам», «Болан кызы» һ.б. китаплар авторы. «Татнефть» һәм Татарстан Язучылар берлегенең С.Сөләйманова исемендәге әдәби премиясе иясе. Казанда яши.*

**Кичә әле изге иде сүзләр,**
**Ак өрфия иде болытлар...**
**Кояшы да сөрем бу урданы**
**Каның белән бүген юып ал...**

**Ә җаныңны киптер, элеп бауга —**
**Кылыч булып кискән җилләрдә.**
**Табылыр да, бәлки, чын хакыйкать,**
**Табылуга... безне җиңәр дә.**

***

**Бу шәһәрдә тайгак юллар гына.**
**Юллар.**
**Юллар.**
**Берни — шуннан кала.**
**Кемнәр белән генә бүлешмәдең —**
**Бер шартламас микән**
**Бу башкала?**

**Ханнар чорын хәтерләтә никтер**
**Хыянәтең.**
**Кан укмаша җөйгә.**
**Син салмаган яралар да хәтта**
**Кубарылып сызлый —**
**Иске көйгә.**

**Бу шәһәрдә тайгак юллар гына.**
**Юллар.**
**Юллар.**
**Берни — шуннан кала.**
**Һичкем белән бүлешәсем килми.**
**Калдырам. Һәм китәм.**
**Бул башкага.**

***

**Мин көчлерәк хәзер үз-үземнән.**
**Олпатрак. Зирәк. Чыдамлы.**
**Чәчтәге чал белән үлчәнми**
**һәм**
**чикләнми бу гомер чырагы.**

**Һәм китүләр саны белән генә**
**төгәлләнми безнең янулар.**
**Син... рәнҗемә.**
**миңа**
**һәм**
**Аңарга.**
**Җанда һәрчак хәтәр агу бар.**

**Сәбәбе шул бары. Башка берни.**
**Башка беркем.**
**Үлем — тантана.**
**— Әле күпме юллар көтә мине...**
**Күрәчәгең бүген аклана.**

**Бу мизгелдә. Түгел иртәгә дә.**
**Һәм кичә дә.**

Шушы
кышында.
Алдагы көн белән исәпләнми
гамәлләрең.
Бүген.
Шушында.

Син көчлерәк хәзер һәммәбездән.
Кирәк түгел инде бер терәк...
Без синсез дә алырбыз күк яши.
Бары дөнья булыр
керлерәк.

## Гомер

Ташландык бер йортта
чөйгә элеп куйган
иске бишмәт гүя.
Телгәләнеп беткән
шул бишмәтне чөйдән
Көн дә алып киям.

Төн дә әләм кабат
урынына. Инде
күгәргән ул чөй дә.
тигәнәкләр белән
күмелгән тар сукмак, —
җил дә үтми өйгә.

Ватык тәрәзләрдә —
телем-телем шәфәкъ,
чәрдәк-чәрдәк дөнья.
Күпме карасам да,
күзләремә ап-ак
бушлык кына коя.

Ташландык бер йортта
Чөйгә эленгән дә...
Калган гүя катып.
Ә кешеләр йортка
Кырын карап уза:
— Сүтәргә, — дип, — вакыт...

***

*Һ-га*

Безгә бер яз гомер җитмәс, бәлки.
Гомер нәрсә?!
Бары уен кыры.
Карашыңа сыйган диңгез бүген
Тозлы тамчы сыман... тыенкымы?

Килеп яусын! яусын! тәрәземә, —
Җилләр кайта аннан ничә тәүлек?
Минем җанга йөгәннәр юк хәзер,
Юк богаулар, җепләр — син сүтәрлек...

Безгә бер яз гомер җитмәс, бәлки.
Кирәкми дә!
Дөнья — яу мәйданы.
...Карашыма тулган Казан күге
Сагынуың сыман — зар-каймалы...

***

Юк, бер җәйдән ары тоткарламам,
Бушатырмын көзгә бу урынны —
Тын ярларын ялан күңелеңнең.
Син кысарсың кулым:
— Хуш, җылындым...

Юк, бер кыштан ары ютәлләмәм,
Савыгырмын. Табылыр им–дәва.
Бу шәһәрдә — хисабы юк узгын —
Миннән сиңа булмас битәр, дәгъва.

Булмас кинә... Очрашканда — ялгыш —
Кыңгыраудай күзләреңә багып
Пышылдармын:
— Син киләсе җәйгә
Урыныма... куй берәрсен табып...

## Ратканга...

Кәгазьләрнең ап–ак тузанында
Безнең яшьлек калды — пыскып, янып.
Инде керәм тып–тын яңа йортның
Ишекләрен тыйнак кына ябып.

Мәйданнарның алкыш, каргышлары
Бәрелсә дә кәрниз, тәрәзләргә,
Алгысытмас ымсындыргыч шаукым,
Ышандырмас кайнар вәгазьләр дә.

Инандырмас иске дөреслеккә.
Үлчәмнәргә — таныш, кысаларга.
Солтанлыктан олтанлыкка күчкәч,
Хыяллар бер барыбер усаллана.

Инкарь түгел, түгел тибәрү дә,
Юл алу бу яңа тарафларга:
Корбан киткән яшьлек хакыйкатен
Үзеңнән дә артык ратканга.

***

Дөньялыктан саркыламы сагыш,
Ләхеттәнме әллә күтәрелә?
Шелтәлисең: зар чәчәсең, диеп,
Орлык төшкән саен түтәлемә.

Шаулап торган сөенечкә, диеп,
Ачылырмы беркөн ишекләрең.
Чөйгә элгән урагымны алып,
Чыгам кырга.
Гүя ишетмәдем:

Сине түгел, узгыннарның сүзен.
Һәркем белә, белә тик үз хәлен.
...Тук башаклар коя учларыма
Фанилыкның миңа насыйп гамен.

Марат Әмирханов

# ИР–МАМАЙ

ТАРИХИ БӘЯН

***

Тәүге шикне Толымбикә беллерде. Ана жаны тынгысыз бит инде ул, һаман бала дип, ут йотып яши.

– Мамуч, Литвадагы хәлләр балабызга зыян салыр шикелле тоела, нигәдер йөрәгем әрни, – диде иртәнге тәгам вакытында, – синең исеңдә дә юк, ахры, ләм-мим.

– Синең ул балаң, ханәкә, утызны тутырып килә, – дип көлде бәк, – Литваның абруйлы кенәзе, күз карашы җитмәс биләмәләр хуҗасы, үзен-үзе сакларлык ир-егет.

– Шәхси дошманлык дәрәҗәләрне дә таптап уза ул.

Мамай кулына алган чынаягын кире куйды.

– Нинди дошманлык уйлап чыгардың тагын, Мысык?

– Улың кенәз Ягеллоның күз атып йөргән кызын тартып алды лабаса, әллә онытныңмы?

– Әлләниләр чокып чыгарасың син, ханәкә, егетләр арасында борын канатулар була инде ул, аны бераү дә дошманлыкка санамый, – дип, Мамай чынаягын каплап ук куйды, – әгәр хәтерләсәң, теге вакытта мин дә сине Себер ханзадәсеннән тартып алдым бит, аңа карап ташлашмадык.

Толымбикә ире янынарак шуышып утырды.

– Барыбер күнелем урынында түгел, Мамуч...

– Ягелло дигәннәренең башы ике булса гына инде, – Алтын Урда белән мөнәсәбәтләрне катлауландыру һич тә аның файдасына түгел. Дөрес, Литва белән кылыч чәкештергән чаклар да булгалады, яу да чапкалаштык. Тик бервакытта да чама хисен югалтмадык, эшне тирәнгә җибәрмәдек. Хәзер дә чарасын күрермен.

Толымбикәнең күнеле дөрес сизенгән икән. Көннәрдән бер көнне Мансурны төн уртасында йокысыннан уяттылар.

– Кенәз, утар читендә бер хәрби төркем пәйда булды, посып кына киләләр, ни боерасың? – диде сакбаш.

– Тоткавыл яугирларны күтәр, минем атны иярләгез! – дип күрсәтмә бирде Мансур.

Атылып юлга чыктылар. Ләкин кылычлар чәкешкәнче каршы яктан тавыш яңгырады.

– Кенәз, сабыр, мин синең янга кенәз Витаутас кушуы буенча килдем.

*Ахыры. Башы 5 санда*

– Әүвәл кем икәнлегенне әйт, – диде Мансур.

– Мин инкогнито, кенәз, йөземне дә күрсәтә алмыйм, исем-атымны да ача алмыйм. Шуна күрә төн пәрдәсендә килдем дә.

– Йомышың ни?

– Кенәз Витаутас үзен Литва тәхетенең хак варисы дип саный...

– Ул тәхеттә Ягелло утыра ич инде, – дип бүлде Мансур төн кунагын, – белүемчә, Витаутас үзе дә Пруссиядә яши.

– Ягеллоны бәреп төшерергә, Литвада гаделлек урнаштырырга кирәк, кенәз. Кенәз Витаутасның беләсе килә: син бу көрәштә аның яклы булачаксыңмы?

Кешеләрне сискәндереп, кинәт кенә яланда утлап йөргүче көтүнең айгыры кешнәп җибәрде. Кешнәүгә дөп-дөп дөпелдәгән тояк тавышы өстәлде. Аннан соң колакларны ачы чыелдау ярып керде.

– Чи-чи-чи...

– Бүре дөнья белән хушлашты, – диде яугир.

– Тамак тәмугка кертә.

– Җавап көтәм, – дип, янә инкогнито зат аваз салды.

– Мин дустым Витаутаска ярдәм итәргә һәрвакыт әзер, – диде Мансур, – ләкин бу качып-посып кына сөйләшә торган сүз түгел, җитди мәсьәлә. Сиңа ышанычым юк, башка монда эзең булмасын.

Төн мизгел эчендә ят төркемне үзенә йотты.

Ә иртә белән тәхет тотучы Ягеллодан чапкын килде.

– Өйләдән соң олуг кенәз катында бул, – диде ул эре генә, – соңласаң, үзеңә үпкәлә.

Мансур юри кичегеп барды. Башы керсә, койрыгы кермәгән, күр, йомышчысына кадәр тавышын бөердән чыгарып кына сөйләшкән була, дип уйлады, таяк ике очлы ул.

Ягеллоның чырае сытык иде.

– Көттерүеңне минем дәүләт башлыгы статусымны инкарь итү дип аңларга боерасыңмы? – дип үпкәсен дә белдерде.

– Хак, олуг кенәз, мөхтәрәм бәк үзен сыендырган мәмләкәтнең кануннарын санга сукмый, – дип җөпләде Ягеллоны озынча шома йөзле, кылыч борынлы воевода, – илдән качкан фетнәче Витаутаска ярдәм кулы сузарга да әзер.

– Дусты бит, – диде Ягелло.

– Белүемчә, кенәз, Витаутас белән сезнең ике арага да кыл сыймый иде.

– Бәк, бу узган заман.

– Аңлашылды, кенәз, мине дә шымчылар җибәреп сынамак иттең инде, алайса, шулаймы? Оят! Рыцарь өчен моннан да хурлыклы, моннан да түбәнчелекле гамәлнең булуы мөмкин түгел.

Мансур сөрлекмә авазлы тавыш иясенең төнге кунак икәнен танып алган иде инде.

Ягелло аның сүзләрен күз очлары белән көлемсерәп кенә уткәреп җибәрде.

– Әгәр, бәк, мине ошатмыйсың икән, тотмыйм, дүрт ягың кыйбла.

– Мин Бөек Литва дәүләте кенәзе, һәм бу җирдән беркая да китәргә җыенмыйм, – диде Мансур кистереп, – кайбер поляклардан үзгә буларак, Литва өчен мин күп кан койдым.

Ягелло үзен-үзе белешмичә кылычына ябышты.

– Кызма, кенәз, иң элек тәрәзәңә күз төшер, – диде Мансур тыныч кына, – минем угланнарның талканы коры, алар вәгъдәсезлекне кабул итми.

– Кырым чирүеннән ким түгел, – диде воевода, – эләгергә язмасын.

Бу сүзләрне Мансур ишетмәде, ул бүлмәдән чыгып киткән иде инде.

***

Низаг тирәнгә кермәде. Анын утын Урдадан килгән илче басты. Мөхәммәд Бүләк хан исеменнән ярлык алып килгән иде. Хан ярлыгынын көч-абруе зур. Атама ярлык хакимнен канунилыгын тану дигән сүз ул. Бу исә Ягеллога сулаган һава кебек зарур иде.

Ярлыкка үзара ярдәмләшү турында Килешү язуы да теркәлгән иде. Ягелло аңа аерым канәгатьләнү белән имза салды. Чөнки бер яктан Пруссия яный, икенче яктан Мәскәү кул уйната. Олуг кенәз Альгирдас улларынын хыянәте дә күп авырлыклар китерде, алга таба алар тагын да артачак.

Мансур бу алышларда терәк кенә. Ә ул артык хискә бирелеп китте, төзәтә алмастай хата эшләп ташлый язды.

— Кенәз, кичер, башым эшләп житмәде, — дип хатасын таныды Ягелло.

— Зыян юк, — диде Мансур, — яу барысын да юа ул, ә яу чабарга туры килер әле.

***

Мөхәммәд Бүләк хан да ата булу бәхетенә иреште. Мул һәм кояшлы көз башында сагындырып кына улы туды. Аны өч ел көттеләр. Баласызлыкны бигрәк тә Хәдичә ханбикә авыр кичерде. Вариссыз хан тамыры корыган алмагач кебек ул, гомерсез вә жимешсез. Варисны исә хатын табып бирә. Бу анын иң төп вазифасы. Булдыра алмый икән, алыштыралар гына, кысыр хатынга хан ыруында урын юк.

Хан үзе дә гафиллек чигендә иде. Аны башта өйләндерә алмыйча йөдәделәр. Аяк терәп каршы торды: әле вакыт житмәгән, әле кәләшне ошатмый... сәбәпләре бихисап иде.

Варис мәсьәләсе көн тәртибенә басып, икенче хатын турында сүз кузгалгач, төкерек чәчеп, Хәдичәсен яклады, яна никахка ризалашмады.

Хәдичә жон бүксәдәй тупыллап торган малай алып кайтты.

Урда менә айга якын инде шушы күренекле вакыйга эчендә кайный: табын, тамаша, бүләк...

Мамай бер көтү орыш аты бүләк итте.

—Мөхәммәд бине Асылбәк ханның тупланы Чынгыз бабабыз ыруы үрнәгендә жиһаннын һәр тарафында үз тояк эзен калдырсын, күп халыкларны баш идерсен, — дип теләк теләде.

Бүген шул атларны тамаша кылу өчен даирә яланга чыкты. Тугарылып кәеф-сафа коруга житди сәбәп иде бу.

Көтүне олы кунакларга әүвәл өергә жыеп күрсәттеләр. Атлар шәп иде. Көрләр, ялык-йолык. Бер басасыга биш басып, биешеп кенә торалар.

— Сөбханалла, күз тимәсен!

Ханнын да авызы ерылды.

— Асылбәк ханзадәгә асыл бүләк!

Гаскәриләр кебек тезелешеп киткән эреле-ваклы бакыр казаннар тирәсендә ашчылар мәш килә, кулларында агач калаклар ишкәктәй уйнаклый. Тамакны котыртып, тирә-якка озын казыкларга эленгән куй түшкәләреннән учакка шып-шып килеп тамган май исе тарала. Аякчылар да баш күтәрми. Алар эчемлек белән мәшгуль.

Әледән-әле кубыз, чалгы тавышлары ишетелә — болары музыкантлар. Жыручылар да шунда гына. Мәжлес шаңлы буласы.

— Аш-суга рәхим итегез, — диде Табын-би, — ризык әзер!

Талчыкканнар иде, күрәсен, ә дигәнче утырышып та беттеләр.

— Асылбәк ханзадәнен күнеле мәрхәмәтле, бәгыре таш, кулы каты булсын! — диде Мамай, тустыганын учына кысып, — юлына ту-байрак!

Тышаулар чишелде, инде авыз вә куллар эшкә тотынды. Ләкин табын кызып кына барганда, Карачы-би Мамайга сәер хәбәр житкерде.

– Бәк, Мәскәү ягыннан бер качкын килде, шушы көннәрдә олуг кенәз Урдага яу чапмакчы, имеш.

Мамай башта аңышмый торды. Аннан соң эчен тотып, шырык-шырык көләргә тотынды.

– Ха-ха-ха...

Табындагылар күшәүдән туктады.

– Хан, кенәз Дмитрий Московский Урдага яу чапмакчы икән ләбаса, ә без мәжлес корып утырабыз, ха-ха-ха, – дип көлүен дәвам итте бәк.

Әмма бу көтелмәгән хәбәр акыл киштәсеннән хәмер дуамаллыгын бик тиз кысрыклап чыгарды. Качкынны үз чатырына алып керергә кушты.

Ул аны бер күз сирпеп карауга танып алды. Танымаслыкмыни, теге вакытта Абдуллаһ ханны Сарай тәхетеннән мәхрүм иткән хыянәтче Туктар углан ич. Яшәрлеген калдырмыйча сөяген-сөяккә чәрдәкләп калдырган жиреннән ниндидер могжиза белән чыгып качкан гыйсьянчы. Үләксәгә чүтлыйлар иде аны. Юк, үлмәгән, ничек исән калган – Алла белсен?

Чокынудан файда юк, буласы булган, өстенә үлән үскән. Хәзергесе мөһим. Мамай текәлеп бакты да:

– Син бу турыда каян беләсең? – дип сорады.

– Дмитрий гаскәренә монахлар килеп тулды, мин Александр Пересвет белән Радион Ослябя дигәннәрне төркемендә идем.

– Әллә монахларга да корал тоттыралармы?

– Корал алучылары да бар, шулай да монахларның вазифасы рухи вазифа, гаскәрне батырлыкка өндәү, ә басурманнарның гомерен өзү Ходай алдында изге гамәл, – диде углан.

– Мин сиңа ышанмыйм, – диде Мамай.

– Ихтыярың, – диде углан, – мин бервакытта да ялган сөйләмим, Сарай мәрәкәсе уңаеннан да, исеңдәдер, турысын ярган идем. Ә ышану-ышанмау синең эш.

Ул биштәрен рәтләгәндәй итте дә, ишек ягына атлады.

– Шулай жиңел генә минем кулдан ычкынмак буласыңмы әллә? – дип иреннәрен кыйшайтты Мамай.

– Мин бурычымны үтәдем, – диде Туктар, башын гына борып, – көчләп тәкә урынына печтергән агаем Туганча әмир үлем түшәгендә ята икән, шуның янына ашыгам, ярлыкарга хәл иттем, бакыйга олы гөнаһ белән китмәсен инде. Аннан соң, мырза, бу дөньяда мине тоткарлардай көч юк. Хуш!

Туктар углан ишек япмасын иңе белән генә читкә этәрде дә, чатырдан чыгып китте.

Аның артыннан ук Олег Рязанскийдан язулы хәбәр ирештерделәр. Рәзән кенәзе, гадәттәгечә, барысын да бәйдән-бәйгә тәфсилләгән иде. Дмитрий дөрестән дә яу чабарга әзерләнә икән. Ныклап әзерләнә ди. Чиркәү ярдәмендә кенәзләрне Мәскәүгә жыйган. Гаскәр көне-төне өйрәнү уза, имеш. «Мин Мәскәүгә буйсынмыйм, бу орышта синең яктан торып сугышачакмын» – дип вәгъдә бирә кенәз. Тверь, Смоленск, Новгород һәм Суздаль кенәзләре дә битарафлык саклый, имеш.

– Туктар угланга тимәсеннәр, – дип күрсәтмә бирде Мамай, – үз юлында булсын.

– Ни булсын ул жеңгә, – диде Кәмал углан.

– Яу хакында ни уйлыйсың? – дип ярдәмчесенә күз тегеп бакты Мамай.

– Елыйсы килгән бала атасының сакалы белән уйнар ди, Дмитрийны әйтәм, мыкый баш икән, – диде Кәмал углан.

— Сүзең хак, бу чынында да сакал белән уйнау белән бер, — диде Мамай, — салым тәртибе үзгәреп тора инде ул, аны яу белән түгел, сөйләшү-аңлашу ярдәмендә хәл итү фарыз. Әгәр салым сылтау гына икән, монсы инде коткы.

— Һөҗүмчеләргә нинди көчне каршы куярга боерасың? — дип углан әңгәмәне төп юнәлешкә борып җибәрде.

— Ялланган гаскәрне сынап карарга дыр, мөгаен, — диде Мамай маңгаен сырлатып, — әйдә, кыпчаклар, генуялылар, нугайлар, черкаслар, осетиннар, әрмәннәр, бәҗанаклар, урыслар барысы бергә укмашып яу чапсыннар.

— Бәк, ялланганнарны Гарәпшаһ углан түбәне белән көчәйтүгә ничек карыйсың?

— Гарәпшаһ угланны Казанга тәгаенләп торам, анда елга юлбасарлары тузына икән. Аның урынына Чәлуби мырзаны кузгатырбыз. Ягелло белән Мансурга да хәбәр салырбыз. Үзара ызгышып ятканчы, тузаннарын яу кырында кагып алсыннар.

— Ә хан?

— Ханга да җилләнү зыян итмәс.

***

Кремльнең барлык капкаларын да ачып куйдылар. Гаскәриләр тезмәсе алдына зур-зур тәреләрен үрә бастырып, руханилар килеп сыенды. Могҗиза сәләтенә ия иконалар да шунда.

Сергей атакай догалык китабын бер кулы белән бала кочкандай күкрәгенә кысып тоткан. Икенчесендә — кечкенә алтын тәре. Укына-укына шул тәрене әйләндергәли.

— С богом!

Олуг кенәз инде ат өстендә. Кузгалырга әмер бирергә дип торганда гына кенәз Олег Рязанскийдан юллама китереп тоттырдылар.

«Олуг кенәз, Мамай бөтен дөньясы белән Рәзән җиренә, миңа һәм дә сиңа каршы килә», — дип кисәткән иде ул.

— Хыянәтче, соң инде, — дип, Дмитрий юлламаны ерткалап, җилгә очырды.

Гаскәрне бөтен Мәскәү озатып калды. Озатучылар арасында бөек княгиня Евдокия дә бар иде. Гап-гади киемнән, башкалардан бернинди аермасы юк.

Дмитрий атыннан төшеп, хәләле белән кочаклашып саубуллашты.

— Үзеңне сакла, — дип пышылдады Евдокия, — син миңа исән-сау килеш кирәк.

— Барысы да Ходай кулында, княгиня, догада бул.

Коломнада мәскәүлеләрне дружиналарын тезеп, мәрхүм Альгирдасның уллары Андрей белән Дмитрий көтеп тора иде инде.

Төпле, акыллы, орыш корының бөтен нечкәлекләрен үзләштергән кыю вә тәвәккәл воеводалар иде Литва кенәзләре. Аларның әзерлеклеге яу алды киңәшмәсендә дә ачык күренде.

Татарларга Дон аръягында һөҗүм итәргәме, әллә елганы кичүләрен көтәргәме — төп бәхәс шушы мөһим мәсьәлә тирәсендә куерды. Мәскәүлеләр елгага кермәү ягында иде.

— Сез татарлардан куркасыз, качарга унай ысул сайлыйсыз, — дип турысын бәреп әйтте Андрей.

— Аръякта, билгеле, орыш бермә-бер катлауланачак, — дип агасын хуплады Дмитрий, — чөнки качкан-чигенгән очракта Мамай безне елга эчендә тураклау мөмкинлеге алачак. Ә безгә үләргә түгел, җиңәргә кирәк.

– Тарихтан мәгълүм ләбаса, шушы алым белән Ярослав Мудрый кенәз вә гаделсез Святополк Окаянныйны; Александр Невский шведларны тар-мар итә, – дип өстәде кенәз Андрей.

– Бу очракта Мамай белән безнең кан дошманыбыз Ягелло гаскәрләренең кушылу мөмкинлеге дә азая, – диде үз чиратында төпчек кенәз.

Олуг кенәз бер өстәмә белән Альгирдасларның тәкъдимен хуплавын белдерде. Орыш Дон аръягында үтәчәк. Өстәмә дигәне – кенәз Владимир карамагындагы яртысын татар сугышчылары хасил иткән дружинаны засадага кую турында иде.

Бер мең дә өч йөз сиксәненче елның сигезенче сентябрь иртәсе сөткә манчылгандай ап-ак иде. Җиһанны калын томан йоткан, күз егәре ике-өч адымнан да узмый. Кешеләрне тавышларыннан гына абайлап була.

Кичтән үк Дон тамагыннан өстәрәк, Непрядва елгасы ташлыгы турында атлылар өчен кичү урыны билгеләделәр. Җәяүлеләргә – вакытлы күпер.

– Ходай догаларыбызны кабул итә, күрегез, дошман белән ике арага нинди томан пәрдәсе элеп куйды, – дип чукынып алды Дмитрий.

– Митяй атакай йортында әтәч кояш баегач кычкырган, – диде арадан берәү, – аяз көнгә бу.

Дөрестән дә, сәгать иртәнге сигезләр тирәсендә томан болыты өстендә кояш шәйләнеп алды. Шуннан соң күп тә тормый, күктән рәт-рәт якты нурлар сузылды. Җил исеп китте. Җил белән бергә томан да таралды.

Бу вакытта төп көчләр кичүне тәгәлләгәннәр иде инде.

Биек үр өстенә корылган чатырыннан олуг кенәзгә Куликово кыры уч төбендәгедәй күренә иде. Көмештәй балкыган Непрядва һәм Дон елгалары колач житмәс киң болынлыкны үз кочакларына алган. Уң түрдә көз кылкаләме белән алтынсу-саргылт төскә буяган кечерәк кенә урман кишәрлеге күренә. Бу – засада урыны. Кенәз Владимир дружинасы инде шунда булырга тиеш...

Дмитрийның карашы офык читендәге карга көтүедәй чуп-чуар яу төркеменә төртелеп калды, уйлый башлаган уйлары шушы урында капылт кына киселде.

– Мамай, – дип пышылдады иреннәре.

Ул бәкнең ачулы вакыттагы пычактай үткен мыскыллы вә үтергеч карашын бөтен эчәк-бавырлары белән тойгандай булды, калтыранып китте.

– Мамай...

Ин элек, йоласына туры китереп, яу алдыннан вәкаләтле вәкилләр очрашты. Алар сөнге сузымы арасындагы ераклыкта торып, орыш тәртибен килештеләр. Ике як та баһадирлар алышына ризалык бирде.

– Бездән Чәлүби мырза көч сынаячак, – диде Мамай вәкиле.

– Бездән – бояр Пересвет, – диде Дмитрий вәкиле.

Күп тә үтми, баһадурлар мәйданга атылып чыкты. Чәлүби ак атта, Пересвет көрән атта. Бояр гәүдәгә калкурак, юан беләкле, киң җилкәле. Баштан-аяк тимер киемгә төренгән, йөзе генә ачык.

Чәлүби атына имән төбедәй береккән. Шуңа күрә буй-сынга көндәшеннән кайтыш күренә, очлы бүреге дә ярдәм итми. Өстендә тимер боҗралардан үрелгән сугыш күлмәге, Коръән аятьләре язылган корыч очлык, бизәкле терсәкчә. Бер кулында – калкан. Аңа Коръән аятьләренә өстәп, адәм йөзле кояш сурәте, кош, җанвар сурәтләре төшерелгән. Икенче кулында – озын саплы сөнге.

– Син үз-үзеңә Алла, фәкать үзеңә генә ышан, – дип озатып калды аны Мамай имам.

Атлар күз иярмәс тизлек белән бер-берсенә таба чабып килделәр дә, инде

мангайга-мангай чәкешәбез дигәндә генә читкә тайпылдылар. Монысы әле танышу ритуалы гына иде. Орыш икенче әйләнештә башланды.

Тәүге ыргымны Пересвет ясады.

— Басурманга — басурманнарча үлем!

Чәлүби көч-хәл белән генә гәүдәсен читкә авыштырып өлгерде, югыйсә атыннан мәтәлеп төшә иде.

Мәскәүлеләр ягында бүрекләр һавага очты.

— Ур-р-ра!

Мырза тезгенен бушатып, атына типке бирде дә, боярның уң кырыена ятты: кулы сулагайга да, уңагайга да бердәй уйный иде.

— Ал кирәгеңне, мырык!

Сөңге Пересветның тәнкәле тимер күлмәген ертып эчкә керә алмады, чакма ташыдай чынлап, очкын гына чәчте.

Инде Мамай ягында бүрекләр очты.

— Мәгальурра!

Бояр дулкынлануын басар өчен берничә әйләнеш ясап алды.

Орыш бер якның үлеме яки җинелүен тануы белән генә тәмамланачак. Чәлүби дә, Пересвет та бары җиңү вариантын гына сайлады. Әлегә икесе дә сакланып кына эш итә, алны-артны карамыйча һөҗүмгә ташланмый.

Бу көтүле ялкау алымны күзәтүчеләр ошатмады, ике яктан да ризасызлык авазлары ишетелә башлады.

— Коли, не спи!

— Эчен актар, эчен!

Тора-бара кычкыру-бакырулар ике арада мыскыллы сүз көрәшенә, сүгенүгә әверелде.

— Урыс, каткан крис!

— Татарва, косоглазый...

Көтмәгәндә Чәлүбинең аты ниндидер түмгәккә сөртенеп китте дә мырза үзеннән-үзе ян-якка янтайды. Һәм Перевсетның сөңгесе яшен ташыдай дошманының күкрәген өттереп алды.

— Получай, гад!

Көбә эченнән кып-кызыл кан саркып чыкты. Бәхетенә, сөңге тирән кермәде, тимер боҗралар саклап калды.

Чәлүбинең үч, ачу, гарьлек хисләре бер йомгакка йомарланды. Авырту артка чигенде. Аргамагы да гаебен төзәтергә ашыкты, чонтык койрыгын тырпайтып, һөҗүмгә ыргылды.

— Бирахмәтикә, йәәә...

Сөңге Пересветның эчен айкады. Чәлүби аның әҗәл тырнагындагы чалшайган йөзен генә күреп калырга өлгерде. Чөнки урыс алышчысының үлем ачысы белән очырган сөңгесе үзенең дә муенына килеп кадалды...

Ике гәүдә берьюлы җиргә тәгәрәде.

Орышчының мәетен алып кайткан арада, Дмитрий шәхси корал йөртүчесе Мишка Бренокны чатырына чакыртып алды.

— Ни боерасың, олуг кенәз?

Михаил саф-пакь зәңгәр күзләре белән падишаһына бакты. Бу керсез вә гөнаһсыз караштa бетмәс-төкәнмәс ихтирам һәм ярату, олы хөрмәт, чын күңелдән бирелгәнлек, эчкерсез табыну, тагын да исемнәре билгесез илаһи хисләр барысы бергә укмашкан иде.

— Минем хәрби киемнәремне ки, — диде Дмитрий пышылдап кына, — ләкин берәүгә дә белгертмә.

— Галиҗәнап, бу Ходай каршында зур гөнаһ һәм синең кебек олуг затны кимсетү булыр иде, — диде Михаил еларга житешеп, — юк... батырчылык итә алмыйм... мин гади бер бояр...

— Бу олуг кенәзнең боерыгы, бояр, ә боерыкны шиккә алмыйлар, боерыкны үтиләр!

— Ә үзең, галиҗәнап?

— Бояр Бренок киемендә.

Чатырдан алар бергә чыктылар. Алда — олуг кенәз булып киенгән Михаил, артта — бояр рәвешендәге Дмитрий.

— Боже! Государебызга җиңү бүләк ит!

Дмитрий шәхси хакимлек символы — кара әләме каршына тезләнеп, аны берничә мәртәбә үбеп алды.

Гаскәр кыюсыз гына дошман тарафына кузгалды. Сәгать угы нәкъ 12 саны турысына килеп җиткән иде.

Мамай орышның үз файдасына тәмамлануында бөртек тә шикләнми иде. Шуңа күрә артык уйланып тормыйча егерме менлек түмәнен өч төркемгә бүлде дә, урыс гаскәрләренә маңгайга-маңгай җибәрде. Уң кул төркемгә йөзбашы Кәмал угланның сыналган татар тупламын өстәде. Аларга, көтелмәгән хәл туа-нитә калса, дошманны искәрмәстән арка яктан камап алу бурычы йөкләнгән иде.

Урданың янә дә бер өстенлеге — Генуя җәяүлеләреннән кала, яу тулысынча шаһсуарлардан гыйбарәт. Мәскәү гаскәрен исә, Владимир воевода һәм Альгирдаслар дружиналарын исәпкә алмаганда, нигездә пехота тәшкил итә. Тиздән Ягелло белән Мансур килеп җитәчәк.

Менә шундый нисбәт.

— Дмитрий үкенәчәк әле, аякка ятып гафу үтенәчәк, — диде Мамай ханга, — бу юлы мин аны сиңа җибәрермен, үзең хәл ит, бәлки, вакытлыча олуг кенәз вазифасын башкага тәгаенләргәдер? Безнең Олег Рязанскиебез дә бар ич әле. Янә дә Тверь, Суздаль, Новгород кенәзләре...

— Мин бу орышта турыдан-туры үзем катнашырга телим, — диде Мөхәммәд Булак, — яңа булат кылычымны сынап карыйсым килә.

Мамай бәхәскә кереп тормады.

Маңлай башы яугирларының кылычлары канга буялды инде. Үгез үкерүе белән үкергән торба-быргы тавышларына яралылар ыңгырашуы, сөңгеләр чыңы, ат кешнәүләре, тояклар дөпелдәве килеп кушылды.

Әле кичә генә моңсу көзге табигать кочагында хозурланып утырган Куликово кыры төче кан исе, тир сасысы белән тулды.

Кояш бу мәхшәрне күтәрә алмады, болыт арасына кереп китте. Тик сәләмә болыт аны барыбер хәвефле манзарадан яшерә алмады, үзе дә зәһәрләнеп янып, парга әйләнде.

Кояш күктә, аңа бернәрсә дә янамый. Җирдәге җан ияләренең хәле менә күпкә мөшкелрәк. Әнә, баядан бирле аяк астында ике куян баласы өтәләнә. Кая барып борын төртергә белми мескеннәр. Унга тайпылсаң — ат тоягына эләгәсең, сулга каерылсаң — орышчы олтаны астына килеп керәсең. Ерткычлар күзеннән саклаган, ризык биргән баялыч, давыл чәчкәсе, кәрәшкә үләннәре инде тапталып бетте, болын катканак тарлауга әйләнде.

Куянкайларның бигрәк тә кара колаклысы арлы-бирле өтәләнә. Куркуыннандыр, мөгаен. Тик бу пырдымсыз чәбәләнү аны коткармады: бер ыргымында тояк астына эләкте дә, кош йомыркасыдай сытылды, тузанда юеш эзе генә калды.

Шул вакыт, каяндыр бот араларыннан, нажагадай елтырап, ана куян килеп чыкты. Килеп тә чыкты, исән баласын авызына кабып күздән дә югалды.

Балаларын имезеп тә азапланмыйча, кем әйтмешли, үлемгә дучар иткән куянның да, күрәсең, бу хафалы мизгелдә ана хисләре уянган иде.

Орышчылар, киресенчә, ерткыч рәвешенә керде. Күнелләрендә бер генә теләк, бер генә омтылыш – дошманыңның жанын кыю.. Тәүге кан курку хисен дә юып ташлады. Һәр киселгән баш, һәр яра бетмәс-төкәнмәс ләззәт вә канәгатьлек китерә иде.

Урдалылар беренче ыргымда ук өстенлекне үз кулларына алды. Хан да кылычын гади яугирлар белән беррәттән уйнатты. Исәбендә берничә корбан да бар. Шуңа күнеле күтәренке. Әле дә шактый зур гәүдәле бер сугышчыны эзәрлекләве. Көчле, каһәр, һәр селтәнүгә калканын куеп өлгерә. Хәрәкәтләре төгәл, ник бер хата адым ясасын. Сөңгесе дә уйнаклап кына тора.

– Получай, басурман!

Бу һөҗүме искәрмәстән һәм көтелмәгәндә булды, сөңгесе, кайнар дулкынын өрдереп, колак төбеннән генә очып узды. Мөхәммәд азга гына югалып калды. Урыс моны сизде, әлбәттә. Һәм сөңгесе үтергеч ыргымга күтәрелде. Ләкин сөңгесе генә түгел, башы да жиргә тәгәрәде. Тоткавыл яугир арт яктан муенын чабып өзгән иде.

– Үзем дә дөмектерә идем, – дип мыгырданды хан, – моннан ары юкка-барга кысылма.

– Бу минем бурычым, галиҗәнап.

– Орыш кырында галиҗәнап юк, орыш кырында яугир гына бар.

Ине-буе ун чакрым чамасы жир биләгән мәйданга кырык меңнән артык орышчы кереп укмашты. Чиләктәге балыктай чәбәләнәләр: үзеннекеләр кайда, дошман кайда – кайвакыт аера да алмыйсың.

Бигрәк тә мәскәүлеләрнең хәле авыр. Җәяүлеләре әлеге куян балалары мисалында иде. Кыркын яунын таяк башы бөтенләе белән диярлек шул гажиз жаннарга төште, чебен урынына кырылдылар.

«Бу болганчык казанда кайнамасын, төп бурычын үтәргә вакыт», дигән фәрман белән Мамай Кәмал мырзага чапкын жибәрде.

Фәрманны үтәү йөзеннән, углан тупланын Дон елгасы ягыннан, урысларның төп көчләрен уратып, арка тарафына төшерде. Моннан Дмитрий чатырына да кул гына сузмалы иде.

– Олуг кенәзнең кара әләмен эләктерегез, воеводаларын әсир итегез, – дип, Кәмал бер төркем яугирларын шунда жибәрде.

Владимир кенәз баядан бирле үз-үзенә урын таба алмый, әле кылычын кынысыннан тартып чыгара, әле атының муенына килеп сарыла.

– Минем түзәрлегем калмады, анда безнекеләрне изәләр, ә без засадада посып ятабыз. Кузгалырга вакыт.

Бу сүзләр мәртәбәле һәм тәҗрибәле воевода Дмитрий Михайлович Волынскийга төбәлеп әйтелде. Ләкин кенәз битараф. Ул ниндидер эчке сиземләү белән һөҗүмнең хәлиткеч мизгелен тотып ала белә иде.

Таш-кыялар өстенә кунаклаган биниһая калын боз катламын кузгатып жибәрергә бер йомарлам кар житкән кебек, кайвакыт орышның язмышын бер кечкенә генә алым да үзгәртеп куя. Бу күп тапкырлар сыналган хакыйкать.

– Кенәз, артыбызга төшәләр ич, кенәз...

– Менә хәзер вакыт!

Владимир атына очып кына кунды. «Кылыч астына кермә, сак бул!» – дип кисәтте Волынский. Ләкин кенәз бу сүзләрне колагына элмәде. Болай да аяклары жиргә тияр-тимәс жилдерткән атына камчы арты камчы өсти. Мамайныкылар, әнә, ярдәмче полкның аркасына төшеп килә, ставкага да куркыныч яный.

Владимир күз кырые белән генә гаскәрен барлады. Атларынын еш-еш мышнавы гына ишетелә, шактый артка калып баралар, Шулай да, тезгенен кыскартмады, кылычын гына болгады.

— Алга, безне Урданың алтын-көмешләре көтә!

Дружина ярдәмче полк белән Кәмал углан йөзлеге аралыгында юктан гына бар булды, әйтерсең лә күк ярыгыннан гына коелып төштеләр.

Кәмал тәкәббер халәттә иде, борын чөюле. Шулай булмыйча, орышның язмышы аның кулында лабаса. Һәм ул ашыкмый-кабаланмый, үз өстенлегенең дәрәҗәсен белеп кенә бәкләрбәгенең күрсәтмәсен жиренә житкереп башкарып чыгачак. Бу жиңү аның югарыга үрмәләвенә ышанычлы баскыч булыр.

— Москальләр! — дип кычкырып жибәрде кемдер.

Кәмал углан татлы уйларыннан арынып китте. Урыс явы болыт булып килә иде. Вәзгыять күз йомган арада дошман файдасына үзгәрде дә куйды. Өермә тизлеге белән ябырылып килгән гаскәрне тыю аның кулыннан килми иде инде.

— Дон аръягына!

Яр буе да урыслар кулында иде. Кара камалышта калдылар.

— Сез бу төркемнең хәлен хәл итегез, әсир алмагыз, кырып бетерегез, — диде Владимир Альгирдасларга.

Альгирдаслар, литуяйларга хас салкын канлылык һәм төгәллек белән, татарларны елгага куып кертеп, ит турагандай турадылар.

Кәмал мырза тупланыннан берәү дә исән калмады.

Владимир орышның үзәгенә ерып керде. Нәкъ монголларча, бара тора, ега тора, туктап сугышмый.

Ул мәскәүлеләрнең иң булдыклы, иң тәвәккәл, иң күркәм воеводасы. Урта буйлы, кин җилкәле, ыспай сынлы. Ат өстендә уенчыктай бөтерелә. Ходай көч-куәтне дә өеп биргән. Даганы кулы белән икегә аера да куя. Аны бигрәк тә вәгъдәле, турылыклы, гадел булганы өчен ихтирам итәләр.

Мәскәүне Мәскәү иткән мәшһүр Иван Калитаның оныгы тәхеткә дә дәгъва итә алыр иде. Юк, ул чынлап торып ызгыш юлына басмады, туганнан туганы Дмитрийның хакимиятен таныды, аңа турылыклы булырга ант эчте.

Владимирның, Альгирдасларның таушалмаган әзерлекле дружиналары кайнарлыгы сүрелә барган орыш учагына коры кура өстәде. Яу яңа көч белән кабынып китте.

Әнә, зур борынлы урдалы әрмәнне ничек кысрыклаганнар. Бирешергә уйламый үзе, айбалтасын селтәргә ирек бирмәгәч, сузылып, кулы белән бакырдай кызгылт мыеклы яшь тартышчының шлемын бәреп төшерде.

— Вай-вай.

Әрмән йодрыгын төйнәгән халәттә сыгылып төште.

— Менә шулай, — дип канәгать елмаю белән елмайды өлкән сугышчы һәм яшь кулдашы бакыр мыекның шлемын башына кидермәк итте...

Житешә генә алмады, үзенең дә күкрәгенә сөңге килеп кадалды.

Шунда ук чүлмәктәй зур гәүдәле ике алып әүмәкләшә иде. Хәлләре, күренә, төкәнгән, канга батып беткәннәр, хәтта сүгенергә дә чамалары беткән, ахры, ыңгырашу авазлары гына ишетелә.

Әле берсе өскә чыга, әле икенчесе. Ә кулдагы хәнҗәрне батырырлык куәт юк. Шулай көрмәкләштеләр-көрмәкләштеләр дә, башларын-башка терәшеп тынып калдылар. Учларында таштай береккән хәнҗәрләре генә тырпаеп калды.

Мөхәммәд Буләк хан да шушы котычкыч зилзилә эчендә. Ярасына карамый, кизәнә дә кизәнә.

Алда мәскәүлеләрнең зур кара әләме пәйда булуга, ул шул якка каерылды. Тик бу кадәр кылыч-сөңгене ерып бару жинелләрдән түгел шул.

— Хан! Орыш сугым базарына әверелде, кире борылыйк! — диде соткавыл яугир ялынып-ялварып, — Аллам сакласын, болай да канын чыкты, галиҗәнап...

— Орышта галиҗәнап юк!

Тоткавыл тагын нидер әйтмәкче иде дә, колак очыннан гына очып узган сөңге җилен тоеп, янга янтайды.

— Дөп!

Башын борса, җә, Ходай, хан җиргә чалкан төшкән. Күкрәгендә — әлеге сөңге. Әҗәлен сизмәгән дә, күрәсең, йөзендәге ризасызлык билгеләре әле сүнеп тә житмәгән. Калын иреннәре ярым ачык, әйтерсең лә, янә: «Орышта галиҗәнап юк», — дип әйтергә тели иде.

Тоткавыл үзен-үзе белешмичә оран салды:

— Ханны үтерделәр!

Тоткавылның тавышы орыш авызында йотылып калды. Ә ул бернәрсәгә карамый, кычкырды да кычкырды:

— Ханны үтерделәр! Ханны үтерделәр!

Бу оранны, ниһаять, тагын кемдер күтәреп алды.

— Ханны үтерделәр!

Бераздан аңа башкалар кушылды.

— Ханны үтерделәр!

Хан — ту-байрак!

Хан — җиңү хәбәрчесе!

Хан юк икән, җиңү дә юк!

Ханның үлеме урдалыларга әлеге таш-кыялар өстендәге боз катламын кузгатып җибәргән бер йомарлам кар вазифасын үтәде. Кенәз Волынскийның элгәрана сиземләве рас килде. Урданың ялланган җыелма төмәне эчендә паника купты. Паника дигән афәт исә үләт чире белән бер, аны үлем дә туктата алмый.

***

Әүвәл Мамай алдына Кәмал угланның чапкыны килеп ауды. Хәлдән тайган, сүзен дә сөйли алмый.

— Ни булды, нигә бу кадәр кабыктың? — дип сорады бәкләрбәге тешен кысып.

— Елгага кысалар, углан ярдәм сорый...

— Орышчыга берләнбер ярдәм — ул үзе. Әллә мине житәкләп йөртер идегезме? Ычкын моннан — синең урының яу кырында.

Бу вакытта Кәмал угланга берниндә ярдәм дә кирәкми иде инде, елга өстендә кара түмәрдәй үле гәүдәсе генә чайкала иде.

Мамай ярсуын баса алмыйча әрле-бирле йөренгәндә, чатырга Мөхәммәд Буләк ханның җәсәден алып керделәр. Ул сүзсез генә хан алдына килеп тезләнде.

Мөхәммәд Буләкнең җәрәхәт-ярасын каплаганнар, үзенә әле мәет төсе кермәгән иде, тере кеше кебек, гүя ял итеп кенә ята.

Мамай ханның күз кабакларын учы белән каплап, аска шудырды да, фатихасын житкерде:

— Мин, Мамай имам, Күкләр илчесе, мәртәбәле илаһиун[1], мәшһүр Үзбәк хан кыйпылчыгы Мөхәммәд Буләк солтанны ярлыкадым һәм дә хидәят табучылар янында дәрәҗәсен һәрдаим күтәрергә сүз бирәм.

Каберең киң һәм нурлы булыр, хөрмәтле зат!

— Кайда җирлибез? — дип сорады тоткавыл яугир.

— Урдада, ә хәзер алып китегез.

[1] Илаһиун – дини тәгълиматчы.

Чатырга көне-тыны бетеп, күзәтүче углан атылып керде.

— Бәк, мәскәүлеләргә яна көч өстәлде, безнекеләр кача! — дип сөрән салды.

Мамай чатырдан чыгып, орыш кырына карап бакты.

Ул хәтсездән кулына корал тотып, дошман белән турыдан-туры күзгә-күз очрашмый. Бу — яшьләр вазифасы. Әмма орышның шундый бер гаҗәеп мавыктыргыч габиданә[2] вакыты була, алыш әле төгәлләнер-төгәлләнмәс, шулай да күнелгә ямь биреп, шатлыклы мәгальура вә билбанзай авазлары инде ишетелеп-ишетелеп киткәли.

Күк төбендә ризык муллыгына күзләре кызган козгыннар куаныша.

Тиздән аларны да мул бәйрәм көтә.

Бу — жину!

Мамай өчен орышның бу мизгеле һични белән чагыштыргысыз ләззәт чыганагы. Аны алыштырыр башка хис юк. Татлы чибәркәйләр кочагы да, далада иң көчле ерткычлардан саналган арыслан киекне буйсындыру да, дәүләти казанышлар да әлеге хис белән чагыша алмый.

Менә шунда ул толпарын иярли дә, орыш мәйданына ашыга. Тирә-якта кылычлар чыңлый, сөңгеләр выжылдый, атлар кешни, кешеләр кычкырыша — болар аның күнеленә иң аһәнле моң булып ята.

Рухланып китеп, кылычын да кынысыннан тартып чыгара. Орыш кырының канлы исен дә, үлем тулы шау-шуын да, ачыттыргыч кайнар һавасын да тоймый. Йөрәктә — ашкыну, кальбендә — канәгатьлек, тәнендә — җан рәхәте.

Җиһангир бәхете менә шушы инде ул. Димәк, угланнарын, яугирларын орышка җиренә җиткереп әзерләгән, күнелләренә җину оеткысы сала белгән, гаскәрен орыш мәйданында дөрес урнаштырган.

Бу үзе бер ашкынулы җыр, ярсулы шигъри дәрт.

Арсаеп[3] атка менәрмен,
Карчыга булып очармын,
Куып барып басармын –
Башын алып канҗагама[4] асармын.
Казнасын алып илгә.
Мин дигәнне кылармын,
Әгәр дигәнемне кылмасам,
Атамның хәрам улы булырмын.

Бүген дә кылыч чыңнары яңгырый, бүген дә күк түрендә җепкә тезелгәндәй ач козгыннар эленеп тора... Инде, әнә, быргылар тавыш бирә башлады. Тик бу мәскәүлеләр быргысы...

— Бәк, шәхси йөзлегенне орышка кертүгә ничек карыйсың, бәлки, хәлне үзгәртеп булыр, — дип мөрәҗәгать итте ярдәмче углан.

— Москальгә әсир төшерәсең киләме әллә мине? — диде Мамай ачусыз гына.

Шулай да шәрехләүне кирәк тапты, ахры, өстәде: «Бәхет кошыбызны кулыбыздан ычкындырдык инде, углан, хәзер безгә шәхси йөзлек тә ярдәм итмәячәк».

— Ә Ягелло?

— Ягелло да соңарды, акылы булса, бу зилзиләгә баш тыкмас.

Яннарыннан кычкырыша-бакырыша башта итальяннар төркеме йөгереп узды, аларга ияреп, калганнар теркелдәде.

[2] Габиданә – гыйбадәти.
[3] Арсаеп – ирәеп.
[4] Канҗага – күн кап.

— Күр инде, хурлык ич бу, бәк, каршы төшик...

— Куй, углан, китсеннәр, мина куркаклар кирәкми. Бу юлы Күкләр Дмитрий ягында булды. Гаеп үземдә. Мин ул ялгышымны төзәтәчәкмен, татар төмәне туплап, тиздән урап киләчәкмен. Мәскәү салымны мин билгеләгән күләмдә, мин куйган вакытта түлиячәк!

— Амин, бәк!

***

— Кенәз, кенәз... Дмитрий Михайлович... Мамай качты... качты!

Владимир бик дулкынланган халәттә иде. Йөзе, күзләре, иреннәре, тешләре... сакал-мыегына кадәр нур бөрки. Мәхәббәт җиле кагылган үсмердәй үзенә урын таба алмый, кылычын үбә-үбә сикергәләпме-сикергәли.

Гадәти тормышта искиткеч тотанаклы, сабыр һәм әдәп иясе кенәзнең чыгырыннан чыкканын күрү сәеррәк иде. Шулаен шулай, ә вакыйгасы нинди бит! Җиңү хакына боларның барысы да аклана. Урдадан өстен күтәрелү — бу сиңа шведларны җиңү генә түгел.

Воевода Волынский шлемен салып кулына тотты да:

— Владимир Андреевич, син хәзерге заман рус хәрби сәнгатенең якты йолдызы, — диде чал кергән башын иеп, — ихластан әйтәм, сөенечебезнең чиге юк, без, ниһаять, аягүрә торып бастык, бүгенге көннән хөр Русия башлана.

— Бу синең дә казаныш, Дмитрий Михайлович, һәм дә, — кенәз сал бүрәнәләредәй мәет белән түшәлгән яу кырына күз төшереп алды, — һәм дә башларын салган меңнәрчә сугышчыларыбыз казанышы.

— Боярин Иоанн Радионович Квашня, кенәзләребез Иоанн Васильевич Смоленский, Андрей Федорович Ростовский, Василий Васильевич Ярославский, Симеон Константинович Оболенский, Роман Михайлович Брянский...

— Бик дөрес, Дмитрий Михайлович, ошбу воеводаларның батырлыгы...

Владимир җөмләсен өзеп, зур хата кылган кешедәй хафалы сискәнү белән сискәнеп китте дә:

— Без монда мактанышабыз, торбалар өрдерәбез, ә кая соң данлы җиңүебезнең тәүбашы, оештыручысы, минем турылыклы туганым Дмитрий? — дип җыелучыларга мөрәҗәгать итте.

— Олуг кенәз!

Олуг кенәзне озак эзләмәделәр. Җыен урыныннан ун-унбиш сажень читтә үк, Владимирны дәшеп алдылыр.

— Кенәз, беда!

— О, Боже, нинди зур кайгы!

Олуг кенәз йөзтүбән җәйрәп төшкән, җиргә беркеп бетеп ята. Күрәсең, әҗәл угы эчен айкаган. Һәм ул аны искәрмәстән еккан булырга охшый.

— Падишаһыбыз Дмитрий Иоанновичны әйләндереп яткырыгыз, — диде Владимир, яшьләрен тыя алмыйча, — торбалар, халыкны матәмгә чакырыгыз!

Мәет янына руханилар килеп басты.

— Дмитрий сын Иоанна, раб Божьи...

Баш очындагы монах мәетнең йөзенә үк төшкән шлемын салдырмак итте. Ләкин шлем яньчелгән иде, кузгата алмый азапланды.

— Иплә, атакай, башын авырттырма, — диде Владимир. Ул әле һаман йоммый түгә иде.

Икәүләп тотынгач, шлемны салдырдылар тәки.

– О, Боже, кенәз!
– Ни булды?
– Үзен ныклабрак кара әле!
Күзләр мәеткә төбәлде.
– Царство ему небесное, бу сон боярин Михаил Бренок лабаса! – диде монах куркынып.
– Нишләп сон ул олуг кенәз киемендә?
Владимир гәпкә куерырга ирек бирмәде, яралгысында ук өзде.
– Сүз әйләндермибез, Русия үз падишаһын исән-сау килеш күрергә тиеш!
Олуг кенәзнең орышта гади сугышчы сыйфатында катнашуы мәгълүм булды. Бу исә эзләү эшләрен бик нык катлауландырды. Чөнки аны меңләгән мәет арасыннан табу кибәннән төймә эзләү белән бер.
Инде көн төгәлләнеп килә иде. Офык читенә кунган алсу төс Дон елгасының җәрәхәткә манчылган кызыллыгы белән бербөтен булып кушылды да, җир вә күкне тоташтырды. Җиһан кан түсенә керде. Читтән караганда эзләүчеләр кан дәрьясында йөзгән кебек күренә иде.
Бу кыска гына вакыт эчендә бөтен яу кырын энә күзеннән үткәрү мөмкин түгел иде, әлбәттә. Әмма орыш үзәген тәшкил иткән Дон тамагы төбәген бик җентекләп тикшерделәр. Тик нәтиҗәсез. Олуг кенәз үлеләр арасында да, яралылар арасында да юк иде.
– Иманлеккә дә сугылып карарга кирәк, – дип киңәш бирде Волынский, – бәлки...
– Засада урыны ич ул Иманлек, анда орыш булмады, – диде Владимир.
– Дөнья хәлен белеп булмый, кенәз.
Кенәз воеводаның тел төбен аңлады. Хак, сугыш ул батырлардан гына тормый. Анда куркаклар да, хыянәтчеләр дә, мал кортлары да, очраклы бәндәләр дә, ачык авызлар да җитәрлек була. Иманлек исә теге яки бу сәбәп белән яуны ташлап китүчеләр өчен менә дигән аулак урын.
Монда ни рәвешле килеп чыккандыр, олуг кенәзгә нәкъ менә шунда тап булдылар да инде. Бер ауган усак агачы астында ята иде. Аңсыз. Ә үзе тере, сулышыннан сизелеп тора. Җәрәхәте-ярасы күренми. Исәнгерәгәнгә охшый. Сугып һушын алганнармы, үзе сугылып-бәрелгәнме, бәлкем йоклагандыр, – монысын ачыклыйсы бар.
– Тезләрегезгә чүгегез!
Владимирның кискен вә көчле әмере олуг кенәзне дә уятып җибәрде. Ул күзләрен ачты.
Кенәз инде аңа мөрәҗәгать итте:
– Государь! Син дошманнарыңны җиңдең!
Бу шатлыклы җөмлә хуплау авазларына, алкышларга төренде.
– Дан! Дан! Дан!
Олуг кенәзгә торып басарга булыштылар, баш очына кара төстәге шәхси әләмен күтәрделәр. Ни гаҗәп, ул яшь баладай җитез, ашкынулы һәм күнелчәк иде. Чыраенда бары бер генә хис – канәгатьлек! Әйтерсең лә, көнозын сузылган канлы бәрелештә дә, сансыз бихисап корбаннарда да, биниһая күп югалтуларда да аның катнашы юк.
Таҗын кигезүгә, Владимирның сөенечле хәбәренә мөнәсәбәтен дә белдерде.
– Минем бу бөек җиңүем Вож җиңүенең дәвамы һәм ул татарларның безнең өстән торуына кире кайтмаслык итеп чик куйды, – диде, – моннан ары Мамай Мәскәүгә указ түгел.
– Ур-р-а!!!

Табигый ки, сугашчыларнын күнел хөҗрәләре мөлдерәмә тулы. Җиңү шатлыгы җир астыннын тибеп чыккан кайнар чишмәдәй ургыла иде. Бу чамасыз вә йөгәнсез олы хис – олуг кенәзгә кагылышлы мәдхияләрендә, омтылышларында, гамәлләрендә...

– Син икенче Ярослав Великий, яна Александар Невский, мәңге яшә! – дип оран салды берсе.

Икенчесе мактаулы исем такты.

– Моннан ары син – Дмитрий Донской! Ур-р-а!

– Донской? Бу мина ошый, – диде олуг кенәз, – Дмитрий Донской! Искиткеч ятышлы. Дмитрий Донской!

Берара хор белән олуг кенәзнен яна исемен кабатладылар.

– Дмитрий Донской! Дмитрий Донской!

– Ә Владимирга нинди кушамат бирәбез? – дип сорады Дмитрий.

– Храбрый! Владимир Храбрый!

– Бик хуш, котлыйм Владимир Храбрый!

Дмитрий туганын кочаклап күкрәгенә кысты да әйтте:

– Мина һәм туганым Владимирга яу кырында турылыклы иптәш булыгыз!

– Баш өсте, государь!

– Олуг кенәз, бу данлыклы көнне «Дмитрий шимбәсе» дип атау һәм аны Русия өчен мәнгелек бәйрәм буларак игълан итү турында тәкъдим кертәм, – диде воевода Волынский шау-шу тынган арада, – ничек карыйсың?

– Мәрхәбә, кенәз, мин ике куллап риза, шәрәфле күрсәтмәм бүген үк бирелер.

Ут тергезеп җибәрделәр. Чатыр-чотыр килеп янган учак тавышы белән күнелләргә илаһи тынычлык, сүз ярдәмендә генә анлатып булмый торган садә ваемсызлык инде. Бу урысларның барысына да мәгълүм халәт: димәк, кәеф-сафа корыр чак җиткән!

Олуг кенәз мут карашын уйнатып алды да, хәйләле соравын юллады:

– Хәтеремнән чыккан, Русиядә христиан диненә юл ачканда мәшһүр кенәзебез Владимир-Красное Солнышко ни дигән әле?

Мондый вакытта Волынскийга тиңнәр эзләмә, җавабы да әзер.

– Хәмер урыслар өчен күнел ачу ул, без ансыз тора алмыйбыз, дигән кенәз Владимир.

– Афәрин. Алайса, ни көтәбез соң, тәгәрәтегез мичкәләрне!

Михаил Бренокны гына искә алучы табылмады, күнел ачу башланды.

1380 елның 8 сентябрь кояшын болытлар да, томан да бу даулы көннен фаҗигале галәмәтләреннән саклап-яшереп кала алмады. Инде, ниһаять, батар чагы җитте. Һәм ул яу кырында егерме мен татар-урыс орышчыларының мәетен козгыннарга калдырып, таулар арасына кереп югалды.

***

Мамай Куликово кырындагы хурлыклы җиңелүдән соң тернәкләнеп килә иде инде. Генуя акча капчыклары, шөкер, бу юлы да үтенечен кире какмады, кирәгенчә тамыздылар. Шартлары үзгәрмәде: Мәскәү икътисадында тамыр җибәрүгә булышу, шул нигездә тышкы алыш-биреше тулысынча кулга алу.

Кыска гына вакыт эчендә ул шактый әзерлекле татар гаскәре туплады. Язга кадәр ул әле тагын да камилләшер. Күкләр фатихасы белән май аенда, урыс җирендә җир-су кипшенүгә, үч явына кузгалачак, Дмитрийны тезләндерәчәк.

Менә шушы үч катыш татлы уйлар белән куанып йөргәндә, көтелмәгән хәбәр килеп ирешге. Имеш, Күк Урда әмире Токтамыш Сарай тәхетенә

утырган. Дөресен әйткәндә, бу хәбәргә аның әллә ни исе китмәде. Ник дисән, Сарайда кәтәнә ханнар бияләй урынына алышынып тора. Аларның Алтын Урда дәүләтенә йогынтысы юк диярлек. Шуңа күрә Мамай андагы хәлләргә инде күптәннән кул селтәгән иде. Әйдә, үтерешсеннәр сон, иртәмесонмы, кала барыбер янә аның аягына килеп авачак.

Монысы исә бөтенләй башка яктан китереп сукты. Көннәрдән бер көнне, гомер булмаганны, Сарайдан Акхужа атлы илче килеп төште.

Тартма йөзле унсигез яшьләрдәге шаһзадә. Уң күз төбендә вак-вак тишекле кызгылт-карасу миң кабарып тора. Караш иң элек шул күңел кайтаргыч миңгә барып төртелә.

— Минем туганым Токтамыш солтан үзен Алтын Урда дәүләтенең ханы дип игълан итте, — диде ул вәкарь белән генә, — Алтын Урда җирбиләмәләре, барча кешеләре һәм мал-мөлкәте белән, тулысынча аның карамагына күчә, бүгеннән Токтамыш ханга бил бөгеш.

— Мин үземне Рим императоры дип тә игълан итә алам, — диде Мамай илчене үртәп, — тик ана карап, мине кем император дип таныр икән?

— Токтамыш хан мине монда шул җәһәттән җибәрде дә инде, бәк, — диде илче углан тыныч вә җитди кыяфәткә кереп, — аның сине үзенең теләктәше итеп күрәсе килә. Токтамыш ханны тәхет иясе сыйфатында берсүзсез тануыңны белдереп, әмирләргә, солтаннарга, вә дә күрше мәмләкәт башлыкларына рәсми ярлык белән мөрәҗәгать итүеңне тели, үзенә Сарайда бәкләрбәге вазифасын тәгаенли.

— Миңа? Бәкләрбәге? Ха!

Мамай йодрыгын төйнәп, илче каршысына килеп басты да:

— Урыныңнан торып бас, син Мамай гурген катында! — дип тамак ярды, — Алтын Урда минем дәүләт, ханнарны мин үзем куям! Ә ул ялган ханыңа әйт, исән чакта табанын ялтыратсын!

Вәкил һич тә дерелдәп төшмәде. Басуын-басты, әмма дерелдәп төшмәде. Алай гынамы, тапкыр телмәр икәнен дә исбатлады.

— Бәк, — диде борынын чөярәк төшеп, — кояшның кызуы сүрелә баруын син үзең дә сизенәсең булыр, мөгаен. Әле генә мәскәүлеләрнең тәпәләп кайтаруы бу сүрелүнең җитди бер чагылышы. Үз таягың үзенә төште. Чөнки син урысларны үзең аздырдың, һәрдаим иркәләп боздың. Хәзер әнә өстенә ябыштылар. Аларны йөгәнләү синең кулдан килә торган эш түгел. Бары Токтамыш хан гына бу узынуга чик куярга сәләтле.

— Күземнән югал!

Мамай котырган бүредәй утка керер хәлгә житте. Толымбикә дә ирен тынычландырырга ашыкмады, киресенчә, бәхәскә керде.

— Илченең сүзләрендә хаклык бар, — диде, — без урысларны үзебез үсендердек, син аеруча йомшаклык күрсәттең, күп ташламалар ясадың.

— Ясадым, һәм белеп ясадым, — диде Мамай үҗәтләнеп, — чөнки дә мөхтәрәм ханбикә, Урыс җирләренең Алтын Урда биләмәләре булуын онытып җибәрмә. Үзбәк хан, халык санын алдырганнан соң, ул җирләрне вакытлыча файдалану хокукы белән генә Рюрикларга багышлаган. Шуның өчен алар салым түли.

— Ә нигә яу чабасыз?

— Яу аерым гакур[5]* кенәзләрне акылга утырту ысулы гына, дәүләтнең турыдан-туры катнашы юк монда. Алай гынамы, урыс дәүләте ни кадәр тотрыклы булса, Алтын Урда өчен шул кадәр файдалы.

— Төшендердең, рәхмәт, — диде Толымбикә, — хәзер, миңа калса, синең төп бурычың, урыслардан битәр, Мөхәммәд Бүләк урынына хан табу. Буш тәхет — гауга чыганагы.

[5] Гакур – зәһәр, явыз.

— Дөрес, ханәкә, тик аңа кадәр бу Токтамыш дигәннәре белән араны өзәргә кирәк, буталмасын аяк астында.

— Мәрхәбә, хуплыйм.

***

Мамай Токтамышны Азак каласыннан аз гына өстәрәк бормаланып аккан кечкенә ташлы елга янында сагалап торды.

Орыш өчен Калка исемен йөртүче әлеге елганы сайлавы очраклы түгел иде.

1223 елның май башында монда Сүбәдәй һәм Жәбә жиһангирлар урысларның жыелма гаскәрен һәм дә аларның аркадаш Көтән хан кыпчаклары төмәнен пычакка-пычак тар-мар итеп ташлаганнар иде.

Сүбәдәй чигенгән атлы булып дошманнарын ялган «капчыкка» алдап кертте дә, канга батырып турады. Исән калган кыпчакларны исә Днепр бусагасында куып суктылар. Шуннан соң Кыпчак мөстәкыйльлеген жуйды.

Урыслар тәүгесендә Монгол көчен шушында, Калка ярында татыды.

Жинүчеләр Калкадан Идел Болгарстанына юл тотты.

Менә шундый истәлекле урын бу.

— Токтамышны башка бу якка күз салмаслык итеп кыйнап жибәрергә кирәк, — диде Мамай, — минем белән тәрәшергә башы яшь әле.

— Яу эчендә аңа тиңнәр юк диләр, канатына карчыгадай кан тигерми икән, — диде Гарәпшаһ.

— Батырга да батыр бар, шуны онытма!

— Күренми әле, — диде Гарәпшаһ офык артына чекерәйгән хәлдә, — санга сукмавымы?

— Яңшак[6] булдың тәки, житәр сиңа.

Эләгешергә генә тора, бер дә харап.

Мамай дөрестән дә үзен куз өстендә басып торгандай хис итә иде. Күнеле тынычсызлана. Гомер булмаганны төнне дә керфеген керфеккә какмыйча уткәрде. Югыйсә Мамай кем дә Токтамыш кем?

Шул селәгәйгә дә баш имәс ич инде. Дистә елдан артык бөртекләп жыйган, жаны кебек күргән дәүләтен әллә нинди әмир кисәге кулына бирсә, тавык көләр.

Шулаен-шулай, әмма ул аның Мәскәүгә яу чабу планнарын челпәрәмә китереп ташлады бит. Хәзер әнә бөтенләй көтелмәгән хәлгә тарыды.

Кешеләр икенде намазы хәстәрен күреп йөриләр иде. Нәкъ шул мизгелдә калкулык канатында давыл дулкыныдай тоташ өер булып, атлы чиру калкып чыкты. Алдан сөттән дә ак толпар өстендә Токтамыш элдертә. Гүя кыя очына кунган бөркет — мәһабәт, горур, ыспай. Ул ыру атасы Чыңгызханны хәтерләтә иде. Жиһангир да Сэтэр атлы ак атына менеп, гаскәрне үзе житәкләгән бит, яу эчендә кайнаган.

Илче Мамайга: «Токтамышның сансыз татар урдасы бар», дип шапырынган иде. Хак икән. Ыжгырып килүләрен генә күр, очып кунарлар иде, валлаһи...

Мамайның моннан да хәтәррәк яу өерләрен күргәне бар иде, билгеле, бу юлы ничектер хәвефләнебрәк калды. Ник дисәң, гадәттә, каршы яклар алдан килешенеп, орышның тәртибен тәгаенлиләр. Дөрес, бу Аурупадан кергән йола. Ләкин күнегеп баралар иде инде. Чыңгызхан исә күргән, килгән, жиңгән. Токтамыш та шул гадәтне куа, күрәсең.

— Гарәпшаһ углан, бу мокыт килә-килешкә кылычка тотынмакчы, ахры, — диде Мамай, көр күренергә тырышып, — бар, каршы ал якташыңны, жә үпкәләр.

[6] Яңшак – такылдык.

Өер якынлашканнан-якынлаша, пәри әвәрәседәй тәгәри генә. Беренче карашка, бу яу зилзиләсен йөгәнләр чама юк кебек. Ләкин беренче карашка гына, теләсә-нинди орышны үз файдаңа борып була, шөкер, тәҗрибәсе бар, кибәккә алдана торганнардан түгел. Мондый чакта дошманыңнан усалрак, кыюрак, кансызрак булу зарур.

— Тәвәккәлләдек, углан!

Гарәпшаһ атына типке бирде. Чирү алга ябырылды.

— Һер-р-р... Һер-р-р...

Мамайның йөрәгенә җылы йөгерде. Хәерлегә!

— Күп тә үтми, күзәтүче угланның йөзе катты, бөтен дәрәҗә кагыйдәләрен онытып, кычкырып җибәрде.

— Бәк! Бәла!

Инде Мамай күмердәй кара киселде.

— Хыянәт!

Гарәпшаһ барган шәпкә кылыч очын түбәнгә каратып, калканын җиргә бәрде.

Гарәпшаһ Күк Урдага сәяхәте вакытында Токтамыш белән очрашып сөйләшкән иде. Ә бәкләрбәгенә күрә алмадым дип алдашты.

Токтамышны ул ошатты. Җае чыгуга, яңа ханга ант эчәчәген күңеленә беркетеп куйды.

Һәм менә җае чыкты...

Иң ышанычлы, иң якын угланының үз күз алдында Токтамыш ягына чыгуы Мамайны башта гаҗәпләндерде, аннан тетрәндерде.

Беравык һушсыз калып торды. Нидер эшләргә кирәк, ниндидер чара күрергә кирәк — ә ул аңгыра бәрән хәлендә, күзләрен челт-челт йомгалап, тик басып тора.

Аны яугирларының чираттагы гамәле айнытып җибәрде. Гарәпшаһ углан үрнәгендә тагын берничә туплан калканын орды.

— Токтамыш ханга ант эчәбез!

Бу өндәмәне кыюлыгы белән дан тоткан Хафиз углан яңгыратты. Аны теләктәшләре дәррәү күтәреп алды:

— Ант! Ант! Ант!

Мамай ханнарны үзе тәхеткә күтәрде, ошатмаса, үзе үк алып та ташлады. Тик нинди генә гали вә көчле зат булмасын, ул бервакытта да ханнарны алыштыра алмады. Һәм бу мөмкин дә түгел иде. Хан — ул хан! Дәүләт символы, мәмләкәтнең терәге. Хан умартаны оя итеп укмаштырып тотучы корт анасы кебек, халыкны дәүләткә берләштерә. Ана кортсыз умарта оясы булмаган кебек, хансыз да дәүләт була алмый.

Мөхәммәд Бүләк орыш кырында һәлак булганнан соң, Алтын Урда хансыз калды. Ә Токтамыш нәкъ вакытында түрәсез калган киң йорт тәхетенә менде. Лаеклы ыруг вәкиле, кануни хаким. Аны кем куюы фәкать Мамай өчен, аның теләктәшләре өчен генә мөһим иде. Халыкка барыбер. Җүләрме ул, акыл иясеме, булдыклымы-булдыксызмы, яшьме-картмы — монысы башка чут. Хан гына булсын.

Бәс, әгәр шулай икән, Гарәпшаһ угланның Токтамышны тануы да гайре табигый хәл түгел.

Бу күпчелекнең фикере иде булса кирәк. Орышның язмышын, ахыр чиктә Мамайның да язмышын шушы хакыйкать хәл итте инде.

Бер-бер артлы ике зур җинелү. Куликово кырында бәкләрбәген ялланган төмән ташлап качкан булса, Калка явында үз татарлары, үзе сайлап җыйган иң һиммәтле угланнары йөзенә төкерде.

Токтамышның албаш яугирлары чөй сыман төркем эченә ерып керде. Максат, билгеле, арка якка узып, төмәнне тулысы белән боҗрага алу.

Аннан соң утардагы сарык көтүенә ябырылган бүре өередәй дошманыңны рәхәтләнеп канга батырганчы тәпәлә. Бу кыркын орыш. Анда исән калу икеле.

— Бәк, өмет бетте, — диде йөзбашы Муса углан, — ни боерасың?

Мамай орыш кырын күзеннән кичерде дә, кулларын җәеп, башын күккә чөйде.

— Әй, вәгъдәсез вә вафасыз Күк иясе! Син мине алдадың. Сиңа кушылганнан бирле бәла-каза, җиңелү ачысы эчендә мин. Адым саен абыну-сөртенү, егылу, таю. Инде сазлыкка ук кереп баттым.

Син минем акылымны томаладың, зиһенемне чуалттың, кыйбламны боздың, кальбемне зәгыйфьләндердең, әһле тәкъвәи асылымны үзгәрттең. Кан белән бирелгән данлыклы Кыят ыруына гына хас сыйфатларны Иблис булышлыгында сыгып чыгардың. Кабыгым гына Мамай минем хәзер, үзем — затсыз мәхлук...

Тирә-якта кылычлар кисешә, сөңгеләр оча, кешеләр кычкырыша, атлар кешни. Һава уттай кызган, тын кысыла, йөрәк кага.

Мамай исә тәүбәгә оеган. Ул бу котырык зилзиләне күрми дә, ишетми дә.

— Син күрәләтә бидгати гамәлләр[7] учагына коры кура өстисең. Бу үзгәрешләр...

— Бәк, хәл мөшкел. Камалышта калабыз, кузгалыйк, — дип ялварды Муса углан, — зинһар өчен, Толымбикә ханәкә хакына, бәк...

Мамай орыш шау-шуын басардай булып кычкырды:

— Күк иясе! Мин синнән ваз кичәм! Ишетәсеңме, ваз кичәм!

— Бәк, алда әле сине зур җиңүләр көтә, — диде Муса, атларын иярләгәч, — бу гадәти орыш кына, борчылулар урынсыз.

— Юк, углан, бу җиңелү — Мамай Алтын Урдасының җиңелүе. Ошбу җиңелү белән Бату хан дәүләтенең дә кояшы баеды. Бирдебәк ханнан соң җиһангирның тәхеткә дәгъва итәрдәй токымы калмады. Мин теләгемә ирешә алмадым. Алтын Урда читләр кулына күчә.

***

Токтамыш хан җиң сызганып, Алтын Урданың коргаксый башлаган тәгәрмәчләрен сугару эшенә керешә.

— Мин Алтын Урда дәүләтен элекке халәтенә кайтарачакмын, — диде ул Алтын Ташта үткәргән тәүге җыенда, — Мамай чоры үтте, әмма бугазда ул йотып җибәрә алмаган Куликово кылчыгы кадалып калды. Бу кылчыкны мин яңадан Мәскәүнең олуг кенәзе Дмитрий бугазына кадаячакмын.

— Без әүвәл максатыбызга илчелек, сүз вә тел ярдәмендә ирешеп караячакбыз, — диде Акхуҗа шаһзадә, — аннан соң...

— Аннан соң рәхимсез яу, — дип элеп алды Токтамыш, — атларыбыз һәрвакыт иярле!

Акхуҗа шул атна азагында ук җиде йөз кылычлы шәхси туплан белән Рәсәй тарафына юл алды. Аның төп бурычы урыс кенәзләренә асылын югалта башлаган ярлык системасының тулысынча кайтарылуын хәбәр итүдән гыйбарәт иде. Элеккечә тәхеткә фатиханы Алтын Урда ханы бирәчәк. Моның өчен кенәз урынына дәгъва итүче кыйммәтле бүләкләрен төяп, Сарайга килеп баш орырга тиеш.

Русия Куликово җиңүе дулкынында әле һаман ләззәт кичерә иде: бәйрәм арты бәйрәм, мәҗлес арты мәҗлес, хәмер елга булып ага. Шуңа күрә нииндидер билгесез яшь ханның фәрманын күнелмән тиленең җүләр сатуы дип кенә кабул иттеләр.

[7] Бидгати гамәл – яңалык гамәле ( дингә үзгәреш кертү нисбәтендә).

Тәүге очрашу олуг кенәзнең каенатасы Дмитрий Нижегородский белән булды. Ул исә илче белән өстән торып кына сөйләште.

– Дон елгасы буендагы данлы җиңүдән соң бу хакта сүз кузгату үзе бер мәгънәсезлек булыр иде, – диде масаюлы елмаю аша, – без хәзер Сарайга йөрмибез, үз хакимнәребезне үзебез куябыз.

Акхуҗаның төерле битенә алсу төс йөгерде, шулай да ачуына бәреп чыгарга ирек бирмәде, кенәзне сүзе белән утыртты.

– Кенәз, беләсенме, Токтамыш ханның арысланы эт иснәгән суга тел тигерми бит, – диде тыныч кына.

Нижегородский аптырап калды.

– Арысланның ни катышы бар монда?

– Тискәрелегегез өстен чыкса, иншаллаһ, ханның арысланын да күрү насыйп булыр, – диде илче, – аның янында сезнең урынсыз шатлануларыгызның алшарты булган Вож, Куликово орышлары коры куыкка гына әйләнер.

Шаһзадә иленә кайтып, күргән-белгәннәрен түкми-чәчми ханга җиткерде. Токтамыш илче сөйләгәннәрне мыегына урап куйды.

Шуннан соң бер ел вакыт үтеп китте. Токтамыш ләм-мим. Мәскәү тәмам тынычланды. Шулай булмыйча, Урданың хәзер Русиягә теше үтәме соң? Мамай булып Мамайны кыйнап ташлаганны, ул борын асты кипмәгән яшь хан кәмәшеннән куркыргамы? Хәер, ул үзе дә яу чабарга кыймас, башы ике түгелдер.

Ләкин бу гөманлаулар акланмады. 1382 елның июнь аенда Кремльгә Токтамыш ханның Казан Болгары янында Иделне кичеп, Мәскәүгә килүе турында хәбәр килеп ирешә. Ар-чирмеш урманнарын үткән икән инде, Русия җиренә аяк баскан.

Токтамыш белән Мәскәү арасы кимеп, чакрымнар ашала барган саен, Кремльдәге шапырынулы бөеклек гыйбарәләре дә үзгәрә-үзгәрә шом кабыгына төренә барды. Чөнки хатирәләр әле җуелмаган, яралар бөтәймәгән. Үчле татар – зәһәр татар. Аның белән юлларыңның кисешмәве хәерлерәк.

***

Олуг кенәзнең көндәлек тормышында табигать, хайваннар дөньясы аерым бер садә урын биләп тора иде. Сәламәтлеккә туймас барлык кешеләр кебек үк, ул да урман-кырларга, ялан-болыннарга, саф һавага тартыла иде. Аның алдында кемдер үсеп утырган чәчәкне өзсә:

– Чәчкәне өзеп алу кул-аягыңны чабып ташлау белән бер ул, – ди ачынып, – чәчкә дә тереклек, Ходай аны да җан өреп яраткан.

Дмитрий урманга барган саен, болан уты үләнен эзләп тапмыйча калмый. Утрау-утрау булып үсүче бу ал-кызыл чәчәкле, талсыман яфраклы, күкрәккә җитешле озын үләнне бик ошата ул. Күпләр болан утын киптереп, чәй ясый. Аңлашыла, болар инде аның дошманы.

Тәгәрәй үләнгә бигрәк тә балалары мөкиббән. Аталары җил чыксынга сызгыра, ә алар тәгәрәтә-тәгәрәтә уйныйлар.

> Көзләр җитәр, җил чыгар,
> Пәри арбасы юл чыгар,
> Җил белән куча йөрер,
> Орлыгын чәчә йөрер.

Яз кунагы – эргәзембайны барысы бергә саклап торып, чәчәк аттыралар. Бу мизгелне күреп калу зур бәхеткә санала, күк капусы ачылу белән бер.

Чөнки тажларын чыгара бара, коела бара. Әлвадиян, баялыч үләннәре дә махсус исәптә. Әлвадиян авыру песиләргә дәва, ә баялыч изге үлән, ата-бабаларыбыз тәүге утны шунын ярдәмендә тапкан.

Олуг кенәз ауга йөрергә яратмый, чит мәмләкәт илчеләренең күңелен күрергә кирәк булган чакларда гына катнашкалый.

Бервакыт Константинопольдән килгән олы кунак белән бүре авына барганнар иде.

Ауны шулай оештырдылар ки, олуг кенәз дә, кунак та куып китерелгән бер җанвар белән бермә-бер очрашырга тиеш иде. Бу затлы аучыларнын вазифасы — чукмар тондыру.

Дмитрий да тондырды, күзләре генә йомык иде. Шуна күрәме, бүрене имгәтте генә. Булышчысы ярдәмгә ашыкты.

— Не сметь! — дип кычкырды олуг кенәз, — не сметь!

Ул яралы ерткычнын башыннан сыйпамак итте. Тегесе мәрхәмәтле аучынын эчкерсез омтылышына хак бәясен генә бирмәде, ырылдап камзул итәген умырып алды. Бүренен үләргә егылганда да бер куйлык көче кала ди. Бүе җитсә, аучынын җитдиерәк әгъзасын да кабат өзгән булыр иде, мөгаен.

— Тимәгез, минем читлеккә ябыгыз!

Бүрегә «Ырылдык» дип исем бирделәр. Ул әле дә исән, патша тәрбиясендә яши.

Гомер өзү кенәзнең табигатенә чит-ят иде. Ләкин теләсә-нинди дәүләтнең яшәешен сугыш-орыш билгеләгән бу кынгыр заманда Дмитрий ызгышлардан читтә кала алмый иде, билгеле. Шул ук вакытта, ниндидер сәбәп чыгарып, читләшү җаен да таба иде.

Ул Токтамыш явына да битараф калырга карар итте. Вәзгыять шуна этәрде. Вәзгыять исә чамадан тыш каршылыклы иде. Ул, әйтик, Олег Рязанскийнын койрык болгавына күнгән иде инде. Бу юлы да кенәз үз кыйбласына турылыклы калган. Яшь ханны зур бүләкләр белән чик буенда үзе каршы алган, юл күрсәтүчеләр биргән.

Каенатасы Нижегородскийнын ялагайлыгын менә бик авыр кичерде. Кенәз ике улын да хан янына җибәреп, гамәлләрен тулысынча хуплавын белдергән. Бу соң башка сыймаслык хәл ләбаса!

1382 елнын август уртасында олуг кенәз Дмитрий Донской-Московский гаиләсе белән башкаланы ташлап китте. Аларга Костромада урын хәзерләгәннәр иде. Максаты изге — гаскәр туплау. Ләкин бу сәбәп күпчелекне ышандырмады. Бигрәк тә мәскәүлеләрне. Митрополит Киприон да олуг кенәз үрнәгенә ияргәч, өмет-ышанычлар гомумән тәкәнде.

— Хыянәт!

Халык тузынган корт күчедәй кая барып бәрелергә белми. Талаш-ызгыш, кычкырыш-бакырыш, вату-җимерү...

Фетнә эчендә калган шәһәр тилеләр йортын хәтерләтә иде. Карлыккан авазларда фәкать бер сүз:

— Хыянәт!

Токтамыш атларынын тояк тавышы инде Мәскәү диварларында кайтаваз булып янгырый иде.

— Дөп-дөп, дөп-дөп!

Куркыныч җисми рәвешкә керде. Нишләргә?

Шөкер, дөньяда халык хакын хаклап йөрүче мәрхәмәт ияләре дә бар әле. Көннәрдән бер көнне, таудан төшеп килгән Гайсә пәйгамбәрдәй, халык алдында изге Коткаручы пәйда булды.

— Мин сезгә ярдәм кулымны сузарга карар иттем, — диде ул, вакыт тар, шуна күрә гәп куертмыйбыз. Кемнәр ополчениегә язылырга риза, ун якка басыгыз...

Озын буйлы, киң җилкәле, зәңгәр күзле, аксыл-саргылт чәчле бу яшь углан Альгирдасның оныгы Литва кенәзе Остей иде.

Халык Коткаручысын бер күз сирпеп караудa үз итте. Ике-өч көн дә үтмәде, берничә полк тәгаенләнгән иде инде. Һөнәрчеләр, сәүдәгәрләр, якын-тирә авыллардан килгән керәстиәннәр, руханилар, талиблар, йомышлы хезмәткәрләр кулларына беренче мәртәбә корал алды. Араларында сыгылып кына калган аз санлы хәрбиләр дә бар иде.

Бәхеткәме-бәхетсезлеккәме, кылыч чәкештерергә туры килмәде. Дөрес, татарларның маңлай баш яугирлары кирмән ныгытмалары аша ук аткаладылар-аткалавын. Ләкин бу, без монда дип, үзләрен белгертү генә иде булса кирәк. Чынлыкта Түбән Новгородның яшь кенәзләре, олуг кенәзнең каенишләре Василий белән Симеон Токтамыш ханнан каланы кан коймыйча гына буйсындыруын үтенгәннәр иде.

Хан ризалашты. Ул да Мамай кебек мәскәүлеләрне Алтын Урда дәүләте кешеләре дип саный иде. Дошман бер генә – ул олуг кенәз Дмитрий.

– Шәрәфле вә бөек солтани хакимлегемне танып, җиңүчегә лаек кадер-хөрмәт күрсәтсәләр, кылычым кынымнан чыкмас, угым садагында калыр, – диде, – әгәр ошбу килешүне бозалар икән – үзләренә үпкәләсеннәр.

Тәкъдимне кенәз Остей да хуп күрде.

Августның егерме алтынчы көнендә барча капкаларны да киереп ачтылар. Кремльгә даирәсе белән Токтамыш хан аяк басты. Остей кенәз аны зурлап каршы алды.

– Хан, Мәскәү сиңа баш ия, рәхим ит.

Мәскәүлеләр тезгә чүкте.

Атыннан төшүгә, Токтамышка Акхуҗа илче телгә алган арысланын китерделәр.

Арыслан ефәктәй бизәкле шома гәүдәсен киереп бер сузылып алды да, тирә-якны дер селкетеп, авазын салды. Ул гүя, хәзер монда без хуҗа, дип белдерә иде.

– Ыр-р-р-р, ыр-р-р-р!

Кремль этләре иярләренең чабу астына кереп посты.

Күзләр – арысланда. Кәләш яшенә житкән чибәр кызлардай горур иде ул. Аякларын гына күр, куш йодрыктай җәлпәк табаннарын җаена китереп кенә ничек кәс-кәс атлый. Үз кадерен белә, каһәр.

Ерткыч Харәзем якларында Идегәй мырза бүләк иткән арыслан токымыннан иде. Шуннан бирле Токтамыш үзе белән арыслан йөртә. Арыслан аңа һәрвакыт җиңү китерә.

– Баһадур!

Хуҗасын бер сүзеннән аңлады җанвар, янә диварлар дерелтәде:

– Ыр-р-р-р, ыр-р-р-р!

Арысланның тавышы ук сызгыруын үзенә йотты. Шул сәбәпле, Үмәр угланның сыгылып төшүен абайламыйча калдылар. Баксаң, күкрәгендә – ук. Сызлана-сызлана җан бирә.

Токтамыш муенчагын ярдәмчесенә ыргытты да, иярenә очып кунды. Шул менүдән өч көн атыннан төшмәде. Кала дәһшәтле зилзилә буранына чумды. Иң беренче кенәз Остейның башы тәгәрәде. Урамнар мәет белән түшәлде, йортлар янгынга төренде, җир кан белән сугарылды. Мәскәүнең шәһәр дигән исеме генә калды. Бу хәрабәләр уртасында ниндидер могҗиза белән Кремльнең манаралары гына кукраеп утыра иде.

Шушы кубудан татарлар Владимир, Переяславль, Юрьев, Можайск, Дмитров, Коломно калаларын да пыран-заран китереп ташлады.

Токтамыш Русия җиренә атылган йолдыздай килеп керде дә, атылган йолдыздай чыгып та китте.

Дмитрий үле калага кайтты.

Ханнын артыннан ук кыйммәтле бүләкләр төяп, ярлык артыннан Сарайга урыс кенәзләре теркелдәде. Дмитрий Донской да читтә калмады. Токтамыш аны кичерде, Мамай бәк биргән олуг кенәз вазифасында калдырды.

Барысы да элекке эзенә төште. Куликово орышы гадәти бер вакыйгага гына әйләнеп калды, арбаның бишенче тәгәрмәчедәй әһәмиятен югалтты.

Мәскәү аннан соң да йөз ел буе Урдага салым түләп торды.

***

Мөйтән тарлавыкка аяк басканда, көн туып кына килә иде әле. Үлән яфраклары өстендәге чык бөртекләренең дә йомык чагы. Аның урынына, эреле-ваклы матурдан-матур бөҗәкләр инде ризык хәстәрен күрә, тыз-быз чабышалар.

Һава ахак ташыдай саф. Кояш шушы иртәнге манзарага сокланып, әкрен генә офык чаршавыннан күккә үрмәли.

Алтын икән бу дөнья, көмеш икән бу дөнья, кадерен белеп яшәгәндә, сәхрә икән бу дөнья!

Тик дөньяның гына үз көе: берәве үсә тора, берәве пешә тора, тервәве төшә тора.

Мөйтәннең дә тервәве төшкән якын кардәше янына килеше. Ул аның мәңгелек йортынерактан ук абайлап алды. Җыйнак кына түгәрәк калкулык түбәсендә тирә-якка ямь биреп, нурланып утыра. Ыруына, тоткан урынына тиң итеп җирләгәннәр икән.

Әүвәл гомерен өзгәннәр, аннан олылып-хөрмәтләп ләхеткә индергәннәр. Яшь хан бәкләрбәген дошман күрсә дә, ихтирамы зур булган икән.

Мосафир юл таягын адымнары уңаена еш-еш торткали башлаган иде дә, бераздан тукталып калды. Төрбә ягыннан шыңшуга тартым ниндидер елак тавыш ишетелеп-ишетелеп ала иде. Салмак садә җил бу шыңшулы тавышны әле якынайта, әле каядыр очыртып алып китә.

Берәр адашкан көчек-фәләндер, дип нәтиҗә чыгарды ул, котырык була күрмәсен.

Мөйтән тавышны янә колагына салды.

Мамай әкә, яшь чагыннан белә идек без сине,
Онытырлар дип уйлама, онытмабыз без сине...

Төрбәнең кыйбла тарафында тоташ кара сын күренде. Кабер ташыдай турыга каткан. Шуңа күрә егълавы күктән төшә сыман тоела иде.

Алма бирдем – алмадың, тәңкә бирдем – сайладың,
Фани диген бу дөньяда ник гомергә калмадың?

Бу мәнзумга[8] салынган җөмләләр иясенең наихә[9] хатын икәне аңлашыла иде инде.

Мөйтән үзе дә наихәгә кушылып китте.

Мамай диген ир әйтер:
Ятыр идем бер бостанда[10],

[8] Мәнзум – тезмә.
[9] Наихә – ялланып елаучы.
[10] Бостан – бакча.

Бостаны терәкнең төбендә
Тигәнәйне[11] түшәнеп,
Алтынияр ястынып,
Әзраил дигән Ауан Бый
Инеп килде сайра өстемегә,
Алмас кылычын таянып.
Атаен дип атмадым,
Чабаен дип чапмадым.
Алганым Толымбикә сылуның
Уң иңенә таянып,
Күкрәгендә азиз җаным аянып.

Хатын үзенекен егълады:

— Әй, минем сөекле хәләлем! Мин дә синең яныңа барыймчы, икәүләп бергә торыйкчы. Ни өчен соң безне аердылар?

— Сине кем яллады, наихә? — дип белеште Мөйтән.

— Бу сер, — диде теге егълавын өзеп, — аны ачарга хакым юк.

— Мин Аллаһы хозурындагы тәкъвә затмын, әүлияләр иҗазәтенә[12] ия суфи, мина ачылу мәрхүмнең рухы өчен дә, синең үзең өчен дә Бөек Затка якынаюга, илаһи силсилә җебен ныгытуга гына булышачак.

— Мине яллаган шәрәф иясе әйтте: «Мамай бәк Күкләрдән үзе ваз кичте, Җирдәгеләр аның үзеннән баш тартты», — диде.

— Анладым, сине Толымбикә ханбикә яллаган, — диде Мөйтән, — ә үзенең табаны монда эз калдырмаганга охшый.

— Ул ир хатыны!

— Ничек?

— Токтамыш хан ярәште ханәкәне.

Мамайны Токтамыш хан үтертте диюләре хак икән, дип нәтиҗә ясады Мөйтән, зур гөнаһка кергән икән хан. Дөрес, бәкләрбәгенә Генуяның акча капчыклары кул салган икән дигән гайбәт сүз дә йөри. Яңа ханга ярарга тырышулары, имеш. Тик дәрәҗәле адәмнәр бу ихтималлыкны нахакка саный. Бәкләрбәге генуялылар хисабына баштан-аяк бурычка баткан иде. Ә бурычлы кешене үтермиләр. Димәк, ошбу хәбәр дөреслеккә туры килми.

Наихә хатын, гәүдәсен элеккечә каккан баганадай туры тоткан хәлдә, бөркәүле башын әнгәмәдәше ягына борды.

— Син, мосафир, дала коланы, фанидагы хәлләргә игътибарың җитми булыр, — диде, — тел төбеннән анлашылганча, Токтамыш солтанның үзеннән өлкән тол хатынга өйләнүен шик астына куясың. Әйе, аерма шактый, Толымбикә ханәкә ханнан ундүрт яшькә өлкәнрәк. Ләкин бу һич тә никахка киртә була алмый. Бәгъзе тәхет дәгъвачеләре куеннарына йөз яшьлек кортканы да кертергә әзер, дип беләм. Толымбикә ханәкә ничә яшьтә дә үтемле кәләш. Аның ыру-нәселе — теләсә-кайсы ханга олы терәк.

— Ошбу тәфсилләүләр минем өчен хаҗәтсез, наихә хатын, — диде Мөйтән суфи, — мине монда Мамай рухы китерде. Ә Мамай Байду ханның мирасын җаны урынына җыеп тотучы даһи дәүләт агасы иде, барча татарларның шөһрәтле вә дәрәҗәле яклаучысы (Ходай Токтамыш ханга да шушы сыйфатларны насыйп итсен!), толпары Дөлдөл, кылычы зөлфәкар Гали батырга тиң олуг зат. Кемгәдер җәллад та, кемгәдер дошман да...

— Синең үзеңә, мосафир?

— Әүвәл, Аллаһының баш бирмәс адашкан колы. Ә минем алыштыргысыз әкәм иде Ир-Мамай.

[11] Тигәнәй – бизәкле киез.
[12] Иҗазәт – рөхсәт.

## Ахыр кыйсса

– А-а-а-а...

Патшабикә Еленаның әһле тулгагы башлану хөрмәтенә чаң кагу өчен җан-фәрман манарага менеп баручы раһибны өермә җиле бөтереп алды да түбәнгә тәгәрәтте.

Мәскәүнең мондый да казалы, мондый да хафалы зилзиләне күргәне юк иде әле. Котырык җил гомерлеккә исәпләп төзелгән өй түбәләренә кадәр умырып ташлый, такта-токталарны исә йомычка урынына очыртып йөри, хәтта йөзьяшәр тирәкләр дә кипкән курадай шартлап кына сына. Мизгел эчендә урамнар хәрабә өеменә әверелде.

1530 елгы бу Мәскәү зилзиләсе дуамаллыгы, аяусызлыгы белән моннан нәкъ ике йөз ел элек Мамай мырзаның тууы турындагы хәбәрне дөньяга тараткан дала зилзиләсенә ике тамчы судай охшаш иде. Шулай да, сәмумнан үзгә буларак, бу гарасат янгыр алып килде. Болыты-болыты белән генә ишелә. Яшен биниһая зур чакма ташыдай чәчрәп, берөзлексез каланы өтә, чалт та чалт, әйтерсең лә кыямәт түе.

Иртәнге якта барысы да күркәм иде: көләч матур көн, патшабикәнең күңеле дә күтәренке, гүя арпа эчендәге бодай бөртеге, тулгак айхаенда да юк. Ире Василий белешкәч тә: «Ашыктырма, үссен әле, – дип шаярткан гына иде.

Олуг кенәз хәләл җефетен өрмәгән урынга утыртмый да, уч төбендә генә йөртә.

Тәүге җәмәгате Соломония белән дә, ике җан бер булып, егерме ел гомер сөргәннәр иде. Тирә-якка соклангач бер гаилә иде. Княгиня чибәрнең чибәре, мөлаем, тәмле телле. Иренә олтан булырга да әзер зат. Үзе искиткеч дәртле, камыш ничек судан туймаса, ул да кайнар кочактан һич ялыкмас иде. Ни кызганыч, кысыр булды, агачы җимеш бирмәде.

Баласызлык Рюриклар ыруының киләчәген дә билгесезлек ярына, низагларга этәрә иде. Шуңа күрә Василий никахын янарту мөмкинлеләре хакында уйланырга мәҗбүр булды. Ниятен якыннарына җиткерде. Алар исә хәстәренә дә кереште.

Яңа никах өчен патшаның тол булуы шарт. Аерылышуны исә дини кануннар тыя. Соломония үз ирке белән бакыйга күчсә, мәсьәлә үзеннән-үзе хәл ителер иде дә бит, кая ул, тәкъдимне тыңлап бетергәнче үк кире какты. Бердәнбер юл калды – монастырь. Ләкин бу да Василийның кул-аягын никах богавыннан ычкындырмый иде. Православиедә җәмәгате ризалыгы буенча башына кара яулык япкан хатынның ире үзе дә дөньяви тормыш белән яши алмый.

Әлеге вәзгыятьтә бөтен җаваплылык митрополит өстенә төшә. Ә ул, дәүләти мәнфәгатьләр хакына дип, никахка рөхсәт бирде.

Ике айдан Василий яшь кәләш куенына керде. Җәмгыять аннан соң да шактый вакыт тынычлана алмады әле. Әүвәлге ризасызлыкка тагын бер мөһим сәбәп өстәлде. Ул кәләшнең чыгышына кагыла иде.

Мәскәүдә Глинскийлар ыруын вакыт-вакыт Рәсәйне Литвага, Литваны Рәсәйгә алыштырганы өчен өнәп бетермиләр иде. Хәлбуки, Глинскийлар бөтен Аурупада зыялы, укымышлы булулары, байлыклары белән дан тоталар. Андый дан Мәскәү боярларының төшенә дә керми.

Василий бу көнчелекле гайбәтләрне ияк кагу белән генә уздырып җибәрде. Чөнки Елена Глинскаяга үлеп гашыйк булды. Яшь мәгъшукага ярау өчен хәтта ки, сакал-мыегын да кырдырып ташлады.

Кадими даирә янә борын җыерды. Ничек инде хатыным нәзакәтле алман тәрбиясе алган дип, үз гореф-гадәтләреннән читләшмәк кирәк? Олуг кенәзнең бу «гөнаһ»ын да митрополит Даниил йолып калды. Имеш, патшаның ошбу гамәле чиркәү уставына каршы килми.

Елена гына өметне һаман аклый алмый бичаракай, орлыкны йота, ә чәчәге йомарланмый. Көтә-көтә өч җәй, өч кыш узып китте.

Күпләр бу хәлнең сәбәбен гайре кануни никахта күрәләр иде. Янәсе, Ходай Василийга рухи әхлаксызлыгы өчен җәза бирә.

Елена гүзәлкәйне дә Соломония язмышы көтәме әллә?

Юк, яшь кәләшнең һич тә көндәше хәленә каласы килми иде. Ходайның рәхмәте киң, иншаллаһ, мәрхәмәтеннән аермас. Гыйбадәт кылу, чиркәүгә йөрү, хәер-сәдака өләшү, хәйрия гамәлләре аның көндәлек ихтыяҗына әверелде. Тора-бара гап-гади тәкъвә зат сыйфатында изге урыннарга сәяхәткә чыгып йөри башлады. Башыннан төрле хәлләр үтте, бик күп мохтаҗлык вә кыенлыклар кичерде. Ул аларны искиткеч зур түземлек һәм сабырлык белән үткәрә дә белде.

Бервакыт үзе шикелле мосафир түтә белән Әүлияләр зиратында төне буе догага оеп утырдылар. Таң алдыннан мул булып чык төште. Манма чыланып, өшеп беттеләр.

— Догаларыбызны Ходай ишеткәндер, шәт, сизәсеңме, рухыбыз ничек пакъләнеп калды, — диде түтә, — инде кояшта бераз кибешеп алсак та зыян итмәстер, мөгаен.

Табигать тәмам уянган иде инде. Яшь усак ябалдашлары эчендә, ботактан-ботакка сикерешеп, сары түшле йомгактай нәфис кошлар сайраша, үлән өсләрендә төрледән-төрле бөҗәкләр кайнаша, чәчәк араларында бал кортлары безелдәшә...

— Күр, Ходай нинди күркәм дөнья яраткан, — диде Елена, — шушы игелекле җирдә балаларыңны җитәкләп йөрсәң иде.

— Борчылма, туганым тутакай, Ходай сиңа бик тә тәүфыйклы нарасыйлар насыйп итәр, — дип юатты аны мосафир түтә.

Елена утырмак булып, аягы белән үлән көлтәсен аудармак иткән иде дә, ярты юлда кычкырып җибәрде:

— Аһ!

Шунда ук үлән төбеннән елдырымдай ялтыр гына шуышып үткән елан шәүләсе шәйләнеп китте.

— Туганым тутакай, хәзер яраңа бака үләне каплыйбыз, бик тиз агуын суырыр, — дип юлдашы кабалана-кабалана эзләнергә дә тотынды.

— Түтә туганым, берүк кирәкми, Ходай ул еланны сынау өчен җибәргән, шифасы фәкать дога гына, — дип Елена үз фаразын куәтләде.

Бераздан аягы гөбедәй шешеп чыкты, тәне кызыша башлады. Кичкә таба хәле бөтенләй төкәнде, саташуга сабышты. Догаларын дәвам итте. Файдасы тиде, күрәсең, Елена иртәнгә тернәкләнеп, аякка басты.

Ялгызы гына Ак күл гыйбадәтханәсенә сәяхәте вакытында булган гыйбрәтле вакыйга да күңелендә тирән уелып калды.

Көн инде кичкә авышып килә иде. Кояш нурлары сүрәнләнгәннән-сүрәнләнә, ара-тирә салкынча җил дә искәләп куйгалый. Хәер, ул боларны сизми, чөнки җаны-тәне дога белән тулышкан, күңеле Күкләр мөнбәрендә.

Шулай да берзаман Еленаның күңеленә шом катыш хәвеф инде. Кемдер күзәтә, сагалый сыман тоелды. Артына борылып караса, аны, дөрестән дә, ашыгып-кабаланып ниндидер бер адәм куып килә иде. Эче жу итеп китте. Яман туар юл буар, ди, бер-бер кара йөрәк булмасын?

Елена адымнарын ешайтты, ләкин әллә ни алдыра алмады, озын итәкләренә уралып, мәтәлеп үк төште.

Адәм аны күтәреп торгызды да, муен хачы сузды.

— Әһ-әһ...

Бу Еленаның үз хачы иде. Күрәсең, абынгалаганда җебе өзелеп төшкән. Әпә мосафир шуны табып алган икән. Ә ул әллә нинди нахак уйлар

уйлап бетерде. Курыкканга куш, койрыгы белән биш, дип бик дөрес әйткәннәр.

Шул ук көнне ак җәймәле төш керде. Таш-тау арасында адашып йөри, имеш. Әле бер якка, әле икенче якка кайрылмак була, тик шундук сукмак ябыла, каршында сөңгедәй очлы кыялар калкып чыга.

– Тәнрем, юлыңны ач, мин синең ин турылыклы колың, Тәнрем...

Елена кулларын сузып күккә баккан иде, җир убылып та китте һәм ул атылган таш кебек упкынга тәгәрәде.

– Ah!..

Курку авазы авызыннан чыгарга өлгергәнче янәшәсендә ак җәймә пәйда булган иде инде. Ике башында ике аккош, канатларында бала кошлар. Аны тирбәтеп кенә кояш яктысына алып чыктылар.

– Синең өчен бик шатмын, туганым тутакай, Ходай догаларыңны кабул иткән, көт, көмәненә кадәм төшәр, – дип, гыйбадәтханә хуҗабикәсе әлеге төшне балага юрады.

...Еленаны янә тулгак әләктереп алды. Авыртудан ул казналары сытылып чыкканчы тешләрен кысты, хәтта тырнаклары уч итенә сытылып керде.

– Патшабикә, берүк түзмә, ярылганчы кычкыр, – дип өйрәтеп торды боярыня Ксения Федоровна, – мин биш баламны да оран салып таптым, алай җиңелрәккә килә, тизрәк котылырсың.

– Бала – билнең куәте, – диде кизү княгиня, – көч биллдә.

– Оялам, – диде Елена, – күрше бүлмә тулы кеше бит...

– Йоладан узмыш юк, – диде боярыня, – бөтен Рәсәйнең күзе синдә.

– Минем үземнең дә халыкны сөендерәсем килә, – диде Елена тулгагына буылган хәлдә, – Ходай ни язгандыр бит...

– Күрерсең, патшабикә, барысы да олуг кенәз теләгәнчә булыр.

Нәфеснең башы ачык ди. Василий да, Елена да әүвәл бала булуын гына теләделәр, малаймы-кызмы, анысы мөһим саналмады. Һәрхәлдә, бу хакта ачылып гәп кормадылар. Патшабикәнең авырга узуы тәгаенләнгәч исә хәл тамырыннан үзгәрде. Бөтен Рәсәй уптым-илаһи купты, әйтерсең лә, өсләреннән гафләт тунын салдырып ташладылар, телләре ачылды. Хәзер инде Кыят бәк заманындагыча, фәкать варис турында гына сүз бара иде.

Елена ике такта арасында калды. Бер яктан, олы куаныч, икенче яктан – үпкә-бавырларга кадәр төшкән яшерен борчылу. Их, белергә иде, көмәнендә кем ята икән?

Аңа туташы боярыня Ксения Федоровна ярдәмгә килде:

– Сина, патшабикә, Домитиан янына барып кайтырга кирәк, – дип киңәш итте.

– Кем соң ул Домитиан?

– Күрәзәче дивана, грек нәселеннән, көенә килгәндә, юраганы бик тә юш була.

Домитиан дивана кадимилеге белән даны чыккан бер аулак монастырьда яши иде. Барды анда Елена. Гыйбадәт вакытында шыпырт кына янәшәсенә килеп утырды. Гыйбадәт иртә таңнан кояш баеганчы дәвам итте. Корсагын борынына житкән килеш догада оеп утыру ифрат авыр иде, ләкин ул догасын өзмәде. Домитианга бу охшады булса кирәк, күз очлары белән генә көлемсерәп, карап-карап алгалый башлады. Гыйбадәттән соң аягына басарга булышты. Шул арада колагына пышылдарга да өлгерде:

– Син, тутакай, җиһанга икенче Тит Флавины[13] бүләк итәчәксең, – диде.

– Минем улым Римның күренекле Веспасиан ыруы императоры кебек олы акыл иясе булачак алайса?!

[13] Тит Флавий – мәшһүр Рим императоры.

Атакай авызы колагына житкәнче елмайды гына, фикерен шәрехләп тормады.

...Күк гөмбәзен икегә ярып, тагын күк күкрәде. Монысы шул кадәр көчле иде ки, идәнгә шыбыр-шыбыр тәрәзә пыялалары коелып төште.

Шуны гына көткәндәй, патшабикә катыннан кенәз Оболенский килеп чыкты. Йөзе кояштай балкый, авызын жыя да алмый.

– Жә, ничек анда? – дип белеште Василий түземсезләнеп, – көттермә!

– Галижәнап, Рәсәй варислы булды, котлыйм!

Бүлмәдә тыштагы гарасаттан да битәррәк авыш-тәвеш башланды: кочаклашалар, кычкырышалар, котлашалар...

– Славься! Славься! Славься!

Ун көннән соң, ниһаять, бәйрәм табыныннан арынып, Василий улын Троицкий монастырена алып барды. Анда булачак тәхет иясен игумен Иоасаф, йөз яшьлек рухани Кассиан һәм урыс чиркәвенең башка күренекле әһелләре тантаналы шартларда бик жентекләп чукындырдылар. Исеме дә тәгаенләнде, ерак бабасы, мәшһүр кенәз Иоанн патша атына лаек табылды.

Урам тулы халык иде. Өзлексез рәвештә: «Василий Иванович, без синең белән бер үк дәрәжәдә бәхетле!» дигән сүзләр яңгырый.

Берәү бәхетеннән таш эри, берәү бәхетеннән май туна, ди. Василийның бәхете исә жир астыннан таш-кыяларны ерып чыккан янартау сулышына тиң иде. Урамнарга һәр иртә таңнан мичкә-мичкә хәмер тәгәрәтәләр, өстәлләр тәгамнән сыгылып тора. Бүләк мул, һәммәсенә өлеш чыга. Аеруча чиркәү-монастырьларның бүресе улады, алтын-көмеш, асылташлар елга булып ага. Әүлияләр дә онытылмады. Митрополит Петр атакайның кабырчыгын алтынга, Алексей атакайныкын көмешкә төрделәр. Василийның чама хисе шул кадәр төкәнгән иде ки, бер ай эчендә дәүләт казнасы тотып селкер дәрәжәгә житте.

Варис исә үз тормышы белән яши, көннәре тынычлыкта, хозурлыкта үтә. Анасы аны үзе имезә, үзе карый, янына чит кешеләрне якын да китерми, хәтта әткәсе Василийдан да шикләнә. Зарыга-зарыга көтеп алынган бала бит, бәгыреннән өзелеп төшкән йөрәк пәрәсе.

Бәләкәч килеш тә Иоанн үзенең кем икәнлеген бик яхшы аңлый иде күрәсең, әнә, ничек тәкәббер генә галибәнә бер гафиллек белән тирә-якны күзәтеп ята. Мыгырданып та куйгалый, елмайгандай да итенә. Малай малай шул инде, артык иркәләү-төчеләнүләрне өнәми, ахрысы, анасы әп итмәк булган иде дә, тибеп кенә жибәрде.

– И, усал, Мамай калдыгы, – диде Елена горурлык вә канәгатьләнү аша. Улының теләсә-нинди кыланышы аңа бетмәс-төкәнмәс шатлык кына китерә иде.

Рәсәйнең тәүге рәсми патшасы Иван Грозныйның тамырларында, чыннан да, ике олуг жиһангир: Мамай мырза белән кенәз Дмитрий Донской каннары кушылып ага иде. Бу кан буталышы Донской токымына бик күп жинүләр дә, бәла-казалар да алып килде, ә Мамай кавемен дәүләтчелектән мәхрүм итте.

*2010 – 2012.*



Илдус
Диндаров

# САНЫЙ ТАТАР ВАКЫТЫН...

## Туфан сәгате

*(Иске Кармәттәге шагыйрь музеенда)*

**Дөньясына исе китми
(Әллә төн дә, әллә көн),
Гел бер көе йөреп тора
Иске өстәл сәгате.**

**Хуҗасы чыгып киткәнгә
Үтте күпме гомерләр!
Күңелгә тик шулай тоела:
Менә килеп керер дә,**

**Әйтер төсле: «Йә, канәтем,
Илдә нинди хәлләр бар?
Киләчәккә юл ачыкмы,
Яктырамы аралар?»**

**Ничек җавап бирергә дә
Гаҗиз булырмын сыман. —
Алдагысын кем дә белми,
Юлларда һаман томан...**

**Ә сәгать ваемсыз гына,
Һаман шулай акыртын,
Исәпли шагыйрь дәверен,
Саный татар вакытын.**

Илдус ДИНДАРОВ (1949) — *язучы, журналист; «Гомер фасыллары», «Күңел яктысы», «Җәй кайда кышлый?» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Нурлатта яши.*

## Тугызынчы дулкын?

Чакырдылар өлкән язучыны,
Мәктәп балалары алдында
Сөйләргә дип, район үзәгенең
Мәдәният йорты залында.

...Шигырь укый, изүләрен ачып,
Чыгып басты да ул сәхнәгә.
Кулы китми йөрәк турысыннан:
Җан әрнүгә, әллә нәрсәгә...

Сөйли ярсып, бар дөньясын онытып,
Күзләрендә тоташ ут кына;
Ялмар сыман залны сихри ялкын,
Әсәрләнеп алдук утырам.

Аны тыңлаганда ишетәм гүя,
Карурманның моңлы шаулавын;
Күрәм төсле ерак бабамнарның,
Төнгелеккә атлар каулавын.

Күңелләрне тәмам әсир иттең,
Син — тылсымчы, әдип, афәрин!
...Ләззәтләнеп тыңлап бетерергә
Насыйп булмады ла ахырын...

Хисләр кочагында тирбәлгәндә,
Артымдагын сизми калганмын:
Корт күчедәй гөжләп, урысчалап
Гәп коруын бала-чаганың.

Заман оланнары шигырь кичәсенә
Килмәгәннәр бер дә укталып;
Чыш-пыш килә болар, як-ягына
Колак салмый һич тә туктальп.

Күчкә генә чагыштыру көчсез
(Һич онытмам, ахры, ул көнне),
Хәтерләтте бу хәл диңгез шавын,
Ярга бәргән котсыз дулкынны.

Сискәндерде шул астыртын шау-шу,
Күңелемне яман шом басты:
Залда булган битарафлык җиле
Киләчәктә давыл кузгатырлык
Тугызынчы дулкын булмасмы?!

Татарлыкны, бөтен тарихыңны
Изеп китсә дулкын-өермә?!
Үткәндәге шөһрәт-данга оеп,
Татармын дип нигә йөрергә?!

...Әрнеп әйтте шагыйрь: «Ул заманны
Язмасын ла, Ходай, күрергә...»

## 2013 елга кергәндә

*(«Кечкенә Апуш»[1] рәсеменә карап)*

**Гади генә, илаһи бер мизгел:**
**Авыл өе... Тәрәз ... Яран гөл...**
**Киң сәкедә Апуш, кашык тоткан;**
**Коштабакта катык, бәрәңге.**

**Мөлдерәмә кара күзләр нигә**
**Бәгырьләрне өзә бу хәтле!?**
**Мәктәпләрдә элек укыттылар:**
**«Ятим ...мескен... Ә сез — бәхетле.»**

**Аңлаттылар тагы: ул нарасый**
**Фәкыйрьлектән мәэюс[2] карыйдыр.**
**(...Ул карашның асыл мәгънәсен**
**Хәзер генә һәркем аңлыйдыр).**

**Без «бәхетле» — Тукай варислары —**
**Өс–баш бөтен хәзер, тамак тук.**
**«Бөек»ләрне күккә чөергәндә,**
**Туган телгә генә кадер юк.**

**...Нәни Апуш дәшә төсле безгә:**
**«Кара көчләр, күрәм, буадыр.**
**Ана теленнән дә аерсалар,**
**Чын ятимлек шушы буладыр!»**

***

**Без яшьлектә яккан учак**
**Чатнап янды төнозын;**
**Күктә йолдызлар күп иде,**
**Киче айлы, тымызык.**

**Картаештык. Дуслык бетте —**
**Һәркемнең үз кайгысы.**
**Ялгыз җанга җылы җитми,**
**Ә төннәрнең −айлысы.**

**Тергезәсе иде утны,**
**Гыйбрәт итеп яшь чагын.**
**...Сыңар чыбык тоткан һәркем**
**Кабызырга үз учагын.**

[1] Рәссам Хажиморат Казаков эше.
[2] Мәэюс — өметсез.



Зәки
Зәйнуллин

# КУРСК ДУГАСЫ БАТЫРЫ

ДОКУМЕНТАЛЬ БӘЯН

1949 елның сентябрь азаклары иде...

Авылның төньяк тарафында, бик биек булмасалар да, текә таулар тезелеп киткән. Алар авылны төньяктан искән кышкы салкын җилләрдән саклаучы ихата булып сузылганнар. Таулар башына өч борынгы юл үрмәли. Шул юлларның берсе белән тау башына менсәң, андагы иген басуына барып чыгасың. Ел әйбәт килгәнгә, тау башындагы басуда иген күкрәп үскән. Ике чакрымга диярлек сузылган иген басуы буйлап, канатларын җилпеп, өч ат җигелгән ургыч килә. Ургыч утыргычында уң кулга дилбегә, сулына каеш чыбыркы тоткан мин — Зәки Зәйнуллин утырганмын. Өч ат җигелгән жнейкада солы урам. Ызан буйлап кып-кызыл төстәге, кара яллы, кара койрыклы Захмай исемле алаша атлый. Уртада көрән төстәге Әмәт исемле ат, сулга — Дорожный исемле, гәүдәгә кечерәк ат җигелгән.

Мин Байгара тавы ягыннан чыгып килгән иртәнге кояш белән бергә торып эшкә тотынган идем, шуннан бирле чапкычтан төшкәнем юк. Инде кояш күк гөмбәзенә менеп җитеп бара. Тыныч, рәхәт. Башта мине борчый торган бер генә уй да юк. Пошкыргалап атлаган өч ат ургычны тигез итеп тарталар. Күңел тыныч — өлгергән солыны чап та чап.

Нәрсәгәдер сагаеп алга карыйм. Әле чабылмаган солы ызаны буйлап мина каршы берәү килә. Әллә әти инде?! Ныграк текәлеп карыйм: әти! Гәүдәсе сул якка янтаеп, салмак кына атлап жнейкага каршы килгән кеше минем әтием Лотфулла карт иде. «Нәрсә эшләп йөри икән инде монда, тау башында?» — дип борчылып уйлап куйдым. Уң кулын артка куйган. Гражданнар сугышында Дутовның ак казаклары мылтык приклады белән сугып аның арка сөяген сындырганнар. Әти авыр эшкә ярамый, озак йөрсә, ике кулын артка куеп, билен тотып кына тора ала. Ә бу юлы артка уң кулын гына куйган: «Нигә икесен дә түгел?»

Килеп җитәргә берничә адым гына калгач, атларны туктатып, ургычтан төшәм:

— Нәрсә булды, әти, Нигә килдең?

— Бүген ничәнче синтәбер? Син шуны беләсенме?

— Әллә тагын? Ай азагы инде.

— Шул-шул менә, ай азагы. Ә син укырга бармыйча йөрисен. Токта кунып, өйгә кайтканың да юк. Ничек анларга боларны? Укулар башланганга ай тулып килә бит. Ә син жнейкада.

Ярдәм эзләгәндәй, артка борылып карыйм. Анда беркем дә юк.
— Укырга бармыйм мин башкача. Ташладым укуны.
— Сәбәбе нәрсәдә?
— Укыганга түләргә кирәк. Елына 150 сум. Юньләп ашарга, киярга юк. Мин колхозда эшләп, урлашып яши башлыйм.
Әти артка куйган ун кулын алга чыгарды.
— Син, машинник малай, менә моны күрәсенме? — Әтинең ун кулында бөкләп тоткан каеш чыбыркы. — Хәзер мин сине каеш чыбыркы белән ярып алып төшәм авылга. Ышкулына илтеп бирәм...
Күнелле итеп елмаям...
— Әллә син мине, әти, кыйнарга итәсенме чыбыркың белән?
— Укуына барам дисәң, тимим. Инде бармыйсың икән, чыбыркылыйм мин сине. Барам диген, мин кызмас борын...
— Юк, бармыйм.
Әти мина таба атлап, чыбыркысын күтәрә башлады. Мин ургыч платформасы артына табан атлыйм. Әти — минем арттан. Араны, чыбыркы белән сукса житмәслек итеп, жнейканы, ана жигелгән атларны бер мәртәбә урадык. Туктадым. Әтигә дәшәм:
— Ташла чыбыркыңны! Суксаң, хәзер әнә Юкәле күл ягына йөгереп китәм дә, өйгә башкача кайтмыйм. Син беләсең минем холыкны, үзенә ошаганмын мин.
— Ышкулга барам, диген!
— Бармыйм.
Әти Дорожный янында туктады. Дәшмичә азрак басып торды да, чыбыркысын ат тояклары янына ташлады. Бернечә адым читкә атлады да, чабылган солы өеменә тезләнеп утырды.
— Кил, улым, утыр әле. Миннән нинди сугу булсын ди инде. Куркытырга гына итеп караган идем. Тик сине куркытып буламыни инде?!
Мин әти каршысына, солы камылына тезләнеп утырдым. Ул сагыш тулы күзен мина текәде.
— Бүген иртән, ышкулына укытырга барышлый безгә Ураев абыең кергән. Математик укытучы. Сине сорый, нигә Зәки унынчыга укырга килми һаман, ди. Синтәбер бетеп бара бит инде, ә ул юк, ди.
Мин, Бикмәт тау башыннан кыйбла ягына агылган күгелҗем болытларга карап, дәшмичә генә әтинең сөйләгәнен тыңлыйм. Табигать тарафыннан бирелгән үҗәтлекне күрсәтәм әтигә:
— Әти! Ул уку нәстәмә хәҗәт инде? Институтка кереп укырга безнең рәт юк. Ашарга юк, өскә киярга юк — хәерчеләр бит без. Колхозда эшлим мин. Кешеләр яшиләр бит колхозда урлашып. Мин дә өйрәнермен шулар кебек урлашырга. Хет азрак мал, кош-корт тотарбыз. Бармыйм мин укырга.
Әти авыр итеп көрсенде. Каушый төшеп, аптыраган зәнгәр күзләрен мина текәде. Ярдәм сорагандай, артына борылып, мин карап утырган Бикмәт тавына карап алды. Мина карап сөйли башлады:
— Син беләсең, улым, мин кырык беренче елның май аенда Пинзә каласына, абыең Гарифулла янына барган идем. Ул анда хәрби училищеда камандирлыкка укый иде. Шунда абыең әйтте: «Әти! Бу ел Гитлер белән сугыш башланыр, пажалый! Шул сугышта минем һәлак булуым бик ихтимал. Мин бит танкларга каршы ата торган артиллерист булам. Шуңа укыйм. Шунлыктан сиңа, әтиебез буларак, минем бер генә үтенечем бар. Син ничек кенә булса да Зәкине укыт инде, аңа белем бирдер. Безнең Зәкидә кеше башы түгел, шайтан башы. Бик тә сәләтле малай ул. Азакки ыштаныңны сатып булса да укыт инде син аны. Шул минем соңгы үтенечем сиңа...»
Әти көрсенде:

— Юк абыең бүгенге көнне. Кырык бернең үктәбрендә һәлак булды Ленинградны яклап...

Ә син менә үҗәтләнәсең укымыйм дип. Теге дөньяга баргач, мин Гарифулла абыеңа нәрсә әйтермен синең хакта? Тынлата алмадым Зәкине, укуын ташлады, диярменме?

Әтинең тавышы калтырап куйды. Ул сөйләгәннән минем йөрәк нык итеп суга башлады. Йөрәккә житәрлек итеп сөйли бел ә эти... Шулчак безнең артта «ургыч нәчәлнигы» Папай Нигъмәтулланың тавышы ишетелде:

— Лотфулла бабай, исәнме. Зәки, син нигә туктадың? Әллә тагын шатун сындымы?

— Исәнме, Нигъмәтулла улым. Сынмады бер нәстәсе дә. Төзек ургычыннның бар жире дә. Мин туктаттым. Менә бу машинник малай укырга барудан баш тарта. Укытучысы Урай кергән бүген...

Әти үзенә ярдәмче килгәнне күнеле белән сизенде, ахрысы. Пенза каласын да, лейтенант улы Гарифулланы да, минем укуга бик сәләтле икәнне дә бәйнә-бәйнә Нигъмәтуллага тагын бер кат сөйләп чыкты. Сул аягын камылга бөкләп, шуның өстенә утырган Нигъмәтулла абзый әтине бүлдермичә бик жентекләп, бирелеп тынлый. Шул ук вакытта әти сузган янчыктан тәмәке урый. Аны кабызып ныклап суыра да, зур ләззәт белән төтенен читкә өрә. Азрак өскәрәк каратып. Әти сөйләүдән туктагач, кабаланмый гына үз фикерен әйтә:

— Син, Зәки, давай, кит ышкулыңа. Укы! Бу калхузда без чиләнү дә житкән. Хет син укып кеше булырга тырыш...

Мин, риза түгеллегемне белдереп, каршы әйтергә чамалыйм. Сүзләре тулы жылылык белән ул мине сөйләтми дә:

— Әти кешене тыңларга кирәк. Кадерен белергә кирәк. Минем әтием Гобәйдулланы, «врак наруда» дип, утыз жиденче елда Уфа төрмәсендә атканнар. Авыл көтүчесе нинди «врак» була ди инде? Менә мин алты яшьтән бирле әтисез, ятим үстем. Тынлар идем — әти юк...

Әтигә карап өстәде:

— Бар, кайт, Лотфулла бабай. Хәзер үк жибәрәм мин аны. Син кайгырма, Лотфулла бабай. Бар, кайт, хәзер үк китә ул ышкулына...

Үрелеп минем кулдан чыбыркыны алды:

— Бир чыбыркынны миңа. Таборга төш. Ала тайны авызлыклап мен. Анда икенче чыбыркы бар — шуны ал. Кулында чыбыркын булмаса, Ала тай тынламый ул. Синең кебек ул да үҗәт!

Күнелсез генә табор ягына атлыйм. Арттан миңа өсти:

— Хирахауга әйт, монда менсен!..

Ала тайны менеп мәктәп янына барып житкәндә өйлә житеп килә иде инде. Аттан сикереп төштем дә, тезгеннән мәктәпкә керә торган баскыч тоткасына бәйләп куйдым да, эчкә үттем.

Кергән көйгә коридор, уң якта уку бүлмәләре. Ун метрлар чамасы коридор сузыла да, 90 градуска сулга борыла. Уң як диварда тау ягына караган унлап тәрәзә, сул якта уку бүлмәләре. Коридорның аргы башыннан миңа таба чибәр генә бер абзый килә. Ямь-яшел каеш белән билен буган гимнастерка, шундый ук төстәге галифи чалбар, аякларында ялтырап торган хром итек. Артка табан таралган, дулкынланып торган матур чәч. Күкрәгенең сул ягында, атлаган саен ялт-йолт итеп ялтырап китә торган Алтын Йолдыз. Ике кулын бөркет канатлары кебек читкәрәк жәеп атлый, миңа таба килә: Советлар Союзы Герое! Яңа директор килгән мәктәпкә, үзе Герой икән дигән хәбәр белән авыл тулган иде. Яңа директор, үзе Герой, кулына чыбыркы тоткан, ямаулы, катып беткән чалбар, күлмәк, туза башлаган чабата кигән малайны (мине инде!) күргәч, үзенчә атлаган унайга бәя бирә:

— Син, туган, мәктәпкә ягарга утын китерденме? Кая бушатырга белмисенме? Әйдә, чыгыйк, күрсәтермен.

Герой мишәрчә сөйләшә. Безнең «8 март» колхозы мәктәпкә утын ташыган көннәр иде.

— Юк! — мин әйтәм. Үзем Геройны җентекләп карыйм. Беренче мәртәбә тере Геройны күрәм бит! — Утын китермәдем мин.

— Ә нәстә эшләп, алайса, мәктәп коридорында чыбыркы күтәреп йөрисең? Ә?

— Укырга дип килгән идем мин.

— Син әллә көзге сынауга калганнарның берәрсеме?

— Түгел.

Герой миңа бик җентекләп карады да, сорый:

— Ничәнчегә дип килден инде син? Җидегәме?

Минем гәүдәм чыннан да җиденче сыйныфка гына туры килерлек иде. Эчкә кимсенү суыгы йөгерә. Тик мин Геройга бернәрсә дә сиздермәскә тырышам.

— Юк, җиденчегә түгел.

— Ничәнчегә ату? Кашык буе гәүдән белән әллә инде сигезенчегә димәкче буласыңмы? Бик бәләкәй бит буең. Ничәнчегә дип килден инде син?

— Унынчы сыйныфка дип килдем мин, абый!

Геройның аптыравы йөзенә бәреп чыкты. Мин тантана итеп эчтән генә елмаям.

— Нәстәгә дип күзеңнән чаткылар оча? Синме? Унгамы-ы?

— Мин! Унга!

— Һи-и!— ди Герой көлеп. — Унга-а!

Нәрсәдер исенә төшә. Йөзе үзгәрә. Житдиләнеп мине өр-яңадан карый башлый. Көрәнрәк матур күзләре мине тишәрдәй булып карыйлар. Телгә килә:

— Тукта, туган! Тукта! Тукта! Син әллә инде үзеңне Зәйнуллин диярга итәсенме?

Минем авыз колакта: «Мине белә бит бу Герой!»

— Инде уналты тулып, минем Зәйнуллин Зәки иканлеккә унжиденче ел китте.

— И-и! — дип суза Герой исе китеп. — Син чынлап та Зәки Зәйнуллинмы? Шаяртмыйсыңмы? Мин синең турыда ишеткәч, синең гәүдән буйга ике метр чамасы бардыр дип уйлаган идем. Ә син бит метр ярым гына икәнсең.

Аптыраган күз карашын миңа тери:

— Юк, туган! Берничә көн элек кенә синең турыда питсавитта (педсовет дими) абмин мнениелар булды, һәм сине унынчыга кертмәскә дигән тәкъдим булды. Юкка килгәнсең син!

Минем эчкә җылы йөгерә: «Алмыйлар!» Кызык миңа, сорыйм:

— Нигә алмыйсыз инде? Сәбәбе нәрсәдә?

— Бик үҗәт икән син. Аннан соң укытучылар белән бик тә ыспурлашырга яратасың икән дә, бик тә шаярасың икән. Гәүдән юк, ә үзең сугыш чукмары да икәнсең әле...

Каеш чыбыркыны уң җилкәгә салам да, чыгу ягына борылам. Үзем сөйләнәм:

— Ярар, алайса. Укуга алмавыгыз минем өчен бик шәп булды бит әле. Рәхмәт сезгә! Хушыгыз!

Герой җилкә аша артка салынып торган чыбыркыдан эләктереп ала:

— Туктале син. Кая китәсең? Мин бит сиңа бар кит дип рөхсәт итмәдем.

Минем авыз колакка хәтлек ерылган. Башны азрак бора биреп кенә сорыйм:

— Китәргә рөхсәт сорарга сез кем инде минем өчен?!
— Мәктәп директоры Мансур Абдуллин мин.
— Укырга алмагач, сез минем өчен мәктәп директоры түгел инде. Шунлыктан нигә мин сездән рөхсәт сорарга тиеш ди.
— Һм! Ату мин синең өчен кем инде?
— Әллә тагын. Тик Советлар Союзы Герое гынадыр инде...
Абдуллин кып-кызыл булып чыкты. Көлеп җибәрде:
— ...«гынадыр» гынамыни инде?
— Шулайдыр инде.
Мишәрчәсе көчәйде Геройның:
— Әйдә, сүләшик әле. Ни өчен минем сине укырга алмавым синең өчен шәп булды әле ул? Шуны аңлат әле миңа.
— Ач без, абый! Кияргә кием юк. Хәерчелектә яшибез. Әти гарип. Гражданнар сугышында аклар имгәткән кыйнап. Уку кайгысымыни миндә.
— Геройның йөзе каралып чыкты:
— Укымаска булгач, нигә килдең ату?
— Әти куа...
Кыска гына, күнелсез генә көлеп куйдым:
— ... чыбыркылап...
— Нинди чыбыркы тагын?
— Каеш чыбыркы.
— Синең әтиең Лотфулла Писер бит?!
— Әйе.
— Синең әтиең Лотфулла Писергә Миякәдән минем әтием Идиәт Купис бик күп итеп сәлам әйтеп җибәрде. Синең әтиеңнән, монда авыл советында секретарь булып эшләгәндә, теге НЭП заманында, минем әтигә бик нык ярдәме тигән икән.
— Әйтермен.
Геройның күзе тулы уйлану чагыла.
— Илләмә сине, туган, бик тә сәләтле һәм, теләгең булса, бик шәп укый диләр бит. Каюмов абый, Сания апа, математик Ураев абый, Мария апа...
Мин дәшмим.
Директор мин һич көтмәгән сорау бирә:
— Зәйнәп апа Дәүләтшина ни өчен яратмый сине?
— Дәлтүнме?
— Ничек инде «Дәлтүнме?»
— Кушаматы «Дәлтүн» аның.
— Нәстәне аңлата инде ул «Дәлтүн» дигән сүз?
— Химик галим булган — Дальтон. Ә Зәйнәп апа шуны дөрес итеп әйтә белми: Дәлтүн дә Дәлтүн!. Бездән алда укыганнар кушканнар аңа шул «Дәлтүн» исемен.
— Син җавап бирмәдең, нигә яратмый ул сине?
— Мин сигезенчедә укыганда аның улы Робесны кыйнаган идем.
— Әле тугызда укыган Сиражетдиновнымы?
— Әйе.
— Синнән гәүдәгә зур бит ул.
— Һы, зур?! Көче юк бит аның.
— Ә синең бармы?
— Бар. Мин бит күп эшлим.
— Ник кыйнадың инде?
— Минем Робесны кыйнау сезгә нәстәгә хәҗәт инде?
— Бик кызык шәхес икәнсең син. Сүлә инде.

— Мин сигезенчедә, ә Робес жиденчедә иде. Сыйныфларына шаярырга дип кергән идем, мине өчәүләшеп — Әнвәр, Робес, Риф идәнгә ектылар да, сырган чалбарны салдырырга тотындылар. Кызлар алдында. Нигә чалбарны салдыралар кызлар алдында?!

— И-и! Шуннан?

— Идәндә яткан жирдән ин көчлеләре Әнвәрне тибеп очырдым да, сикереп торып — са-ал берне Робеска. Китте бу тәгәрәп...

— И-и-и! Син шулай тәгәрәткәнче суга beлəсеңмени?

— Әйеме. Ике күз арасына уч төбе белән жеппәрсән, оча ул суккан кеше.

— Шуннан?

— Робес сикереп торды да, парта өстендәге әтәч белән тавык төшкән, түгелми торган фарфыр кара савытын алды да жеппәрде шуның белән мина...

— Тидеме?

— Тидертмәдем шул. Иелеп калдым. Тисә, әйбәт буласы иде дә бит...

— Соң?

— Кара савыты ике катлы тәрәзә пыяласын ватып, урамга чыгып очты. Пыялалары чәлпәрәмә килде. Өстәвенә, икесе дә өске зур өлгеләр.

— И-и, туга-ан! Күргәнсен икән! Шуннан?

— Шуннанмы?

— Әйе.

— Әбиттән соң педсоветка алып кереп бастырдылар. Ә Дәлтүн директор...

— Син Дәүләтшина апа дип сүлә инде...

— Дәүләтшина апа... Дәлтүн мине хулиган, ди, бандит, ди, ФЗУга жибәрик, ди. Ә ФЗУга жибәрергә мина әле унбиш яшь тулмаган. Дәлт... Дәүләтшина апа мине мәктәптән куарга тәкъдим ясады. Ә Робес турында бер сүз дә әйтми. Әйтерсең лә мин үзем белән үзем генә сугышканмын инде...

— Шуннан?

— Тавышка куя башлаган иде, физика укытучысы Каюмов абый сүз сорады. Ул минем ике абыйны, апаны укыткан кеше. Шул абый коткарды мине. Чыгыш ясап: «Зәки үсеп килә. Нигә анын чалбарын салдыралар кызлар алдында, ди. Каршы торып дөрес эшләгән, тик сугышырга ярамый иде, ди. Ә бит тәрәзәне Зәйнуллин түгел, Сиражетдинов ваткан, ди. Невыливайка кара савыты белән бәреп, ди. Нигә Зәйнуллин белән бергә монда Сиражетдинов та басып тормый, ди. Бер Зәйнуллинны гына гаепләп тикшерү педагогика кануннарына туры килеп бетми, иптәш Дәүләтшина, ди...

— И-и, карале әй! Вәт ичмаса Каюмов абый! Нәрсә булып бетте инде ул эш?

— Әйбәт булып. Каюмов абыйдан соң Дәүләтшина апа тагын сөйләде. Мин Зәйнуллинны азрак куркытыр өчен генә укудан исключить итәргә тәкъдим ясаган идем. Ул тәкъдимне снимать итәм, ди...

— Мәктәптә калдырдылармы?

— Калдым инде Каюмов абый аркасында.

Директорга елмаям:

— Шуннан соң айдан артык ник бер шаярыйм.

— Курыктыңмы?

— Куркуын курыкмадым. Илләмә шүрләдем инде.

— Нигә?

— Ул чакта минем укыйсым килә иде әле.

— Шулаймыни?

— Әйе.

Абдуллинга минем белән сөйләшү кызык иде, ахрысы. Сорады:

— Немец теле укытучысы Сәгыйтова апа белән дә конфликтта бит син. Ә?

— Әй, уйлап бетермичә әйтеп ташлаган идем бер нәстә, шуның өчен бик үк яратып бетерми.

— Нәрсә дигән идең инде?

— Мин немец телен укырга теләмим, чөнки ул фашистлар теле дигән идем.

— Синең шундый глупый чакларың да булгалыймыни?

— Яшәгәндә гелән генә акыллы булып булмый бит инде. Анысына үкенәм — юкка әйткәнмен.

Геройның күз карашы җылына башлады.

— Синең Гариф исемле бик шәп абыең булган икән. Өлкән яшьтәге укытучылар аны бик җылы итеп искә алалар. Сания апа, Мария апа, Каюмов абый. Укытучылар сине абыеңа охшаталар, тик бик шаянсың һәм... уҗәтсең, диләр. Лейтенант булган икән.

— Әйе, противотанковый артиллериядә иде.

— Бә-әй, мин дә противатанковыйда сугыштым бит. Ике елдан артык. Кайчан һәлак булды ул?

— Кырык бернең октябрендә. Ленинград оборонасында. Соңгы хатын сентябрьнең өчендә язган иде, тагын сугышка керәбез, дип.

— Укырга кирәк сиңа, Зәки. Белем алырга!

— Кирәктер дә ул. Тик хәерчелек бик көчле бит бездә.

— Әйдә, без синең белән болай итик. Син миңа бүлше мәктәптә шаярмыйм, башкача сугышмыйм дип сүз бир. Мин сине укырга кертермен.

Елмаеп җавап бирәм.

— Укыганда шаярмыйча түзеп булмый бит.

Директор житдиләнгән иде, елмаймады да. Ике елдан артык үлем белән фронтларда алышып исән калган бу абзый бик кешелекле булып чыкты.

— Син миңа шаярмыйм дип сүз бир, туган. Бик түзә алмый башласаң, шаярырсың — чурт с табуй. Без синең койрыгыңны ныклап борырбыз. Бер-ике айга житәрлек итеп. Басылып, койрыгыңны ике бот арасына кыстырып, шаярудан туктап йөреп торырсың. Аннан тагын шаярырсың, без синең койрыгыңны тагын борырбыз. Шулай итеп, киләсе ел аттестат алып, мәктәптән котылырсың. Дөнья ул. Сәләтең зурдан диләр, барыбер укыячаксың син. Сиңа Гариф абыең өчен дә укырга кирәк. Дөнья куласа, гелән генә, көн саен үзгәреп тора. Белем ал — кала ул! Гелән хәерче булмассыз — җае чыгар. Менә апаң киләсе елга институт тәмамлый. Ул ярдәм итәр.

— Ы-ы! Итәр?! Көт кызлардан ярдәм.

— Алай димә әле син. Килештек — син шаярмыйм дип миңа сүз бирдең.

— Ярар, шулай булсын да ди инде

— ...«да, ди» түгел, туган! Башкача шаярмыйсың, сугышмыйсың.

— Ярар, шаярмам, сугышмам.

— Вәт шулай диген син. Минем күрше бинага барасы бар, әйдә, киттек.

Мәктәп ишегеннән чыгып, бусагадан төштек. Мин Ала тайның тезгенен чишә башладым. Абый тайга карап көлеп куйды:

— Атың да үзең кебек алалы-колалы икән. Кызыллы-аклы бит, тач сыер төсе.

— Исеме дә Ала тай анын.

Директор минем киемгә карап алды:

— Мәктәпкә киеп килә торган киемен бармы?

— Юк, абый. Шушы гына.

— Төш атыннан. Әйдә, мина керик. Мин сина бер чалбар бирәм. Кыскартып киярсен.

Баш селким:

— Кирәкми, абый. Рәхмәт. Кешедән бушка алып яшәргә өйрәнгән бәндә ялкауга әйләнә ул. Каян соранып алыйм икән дип яши башлый. Сау булыгыз. Иртәгә киләм мин укырга...

— Исән-сау йөр. Кил иртәгә.

Өйгә кайткач, этигә Идиәт Куписнын сәламен җиткерәм. Сары мыегын сыпыргалап исенә төшерде:

— Ә-ә, ул икән. Егерме өченче елны Шафран стансасында трактирда дуслары белән гүләйт итә иде ул. Трактир янында урамда өч-дүрт яшьлек малае шушки кимереп утыра иде. Бик матур чиккән ак күлмәк, кәләпүш кигән түгәрәк йөзле чибәр малай иде. Шушы Гируй булган инде ул малай кисәге.

— Ничек ярдәм иткән иден син ана?

— Милитсия нәчәльнигы Рузайкин Ырымбурдан алып кайтып барган таварына арист ясаган. Бамбырнын авыл сәвитендә рәис чагы. Шушы Идиәт Купис белән япунга каршы бергә сугышканнар икән. Идиәт абзый Бамбырга килгән. Киттек анын белән Рузайкинга. Шулай-шулай, наш знакум. Тынлады безне Рузайкин, бирде таварларын...

Әти елмайды:

— Карале, ничәмә-ничә еллар узган, исенә төшергән бит әле...

Куанган күзләрен мина теки, елмая әти. Зур кулы белән аркамнан сөя:

— Рәхмәт, улым! Тынладын мине, укырга кереп. Укы син, тырыш! Эшкә дә, укуга да шәп син. Укып, хет син чыга алмассынмы икән бу нужамихнәттән. Бездән булмады. Укы син, улым!

Әтинен шушыларны сөйләгәндә тавышы калтырый иде...

Кичкәрәк Ала тайны тау башына илтә киттем. Тауга менгәч, канатларын җилпеп ызан буйлап килгән ургыч күренде. Ала тайны юыртып куып киттем. Ургычта минем дус Хирахау Халите утыра иде. Мине күргәч, болай да зур авызы чабата хәтлек булып жырылды. Кунихлыктан чыгып ургычка утырганына Халит шат. Туктатып, ургычтан төште.

— Укырга керденме? Әллә алдылармы!

— Алдылар. Нигә алай дип сорыйсын!

— Кичә Рубисны күргән идем. Өчкә хәтлек бергә укыган идек бит. Шул әйтте мина: Зәки барып та йөрмәсен ышкулга, әни аны кертмәячәк укырга, диде.

— Анын әнисе хәзер мәктәптә директор түгел. Яна директор килгән. Институт бетергән.

— Читнекедер инде?!

— Миякә районыннан. Советлар Союзы Герое. Абдуллин Мансур исемле абзый. Бик чибәр кеше.

— Ы-ы! Чибәрдер! Геройдыр! Жыен килмешәк тула безнен Эстәрлебашка. Үзебезнекеләргә урын юк, ә читләргә табалар.

— Укыган кеше булгач, урын да була инде.

— Дауай, Зәки, син дә укы инде! Укып кайтып үзебезнен ышкулда дириктыр булырсын. Мин хатын алгач, минем малай тугач, үскәч, син аны укытырсын. Минем улыма бер укытучыдан да икеле куйдырмассын. Ярармы?

Көләм:

— Эрләмәгән, сукмаган, Хирахауга ыштанлык дигәндәй була бит инде син әйткән. Мин әле директор булмаган, синең ул малаең тумаган да.

— Ничава-а! Туа ул, хатын алгач! Тумый кая барсын ди. Дөнья шул бала туу белән бара бит инде. Без туганбыз бит менә — солы чабабыз.

Стан ягына карап алды.

— Син нәрсә, Зәки? Әйберләреңне алырга килдеңме?

— Ала тайны китердем. Минем монда иске бер куфайка да сабын белән сөлге. Башка әйбер юк. Нигъмәт абый белән, синең белән саубуллашыйм дип тә килдем.

— Син килгәләп йөр монда. Ботка ашарга. Күп эшләдең — закунный хакың бар ботка ашарга. Хуш, дус! Әйбәт итеп укы. Кемнеке — Писер Лотфулла малае дисеннәр сине.

Халит ургычка менеп кунаклады да, атларны кузгатты:

— На-а, малкайла-ар! Наа! Чабыйк, әйдә, бу солыны! Гомер туймас бирән хөкүмәткә икмәк кирәк! Эшлик, чабыйк, сугыйк — тыгылсын өне...

Ала тайга мендем дә тезгенне унга тартып станга төшеп киттем...

Икенче көнне иртән мәктәпкә укырга киттем. Унынчы сыйныфка, татар мәктәбенә...

Минем унынчы сыйныфта укый башлаганга айга якын. Татар мәктәбендә урыс теле дәресе бара. Укытучы ябык кына Мария Николаевна Орлова. Жиденче сыйныфта безне урыс теленнән укыткан Леонид Калинович Ломако ике ел элек урыс телен укытырга күрше урыс мәктәбенә күчте. Ломако да килгән елындагы ябык, ертык эрзинкә итекле, гарип кулына җылы оекбаш кигән йолкышны танырлык түгел. Яхшы гына симергән шома гәүдә, бик шәп костюм-чалбар, каракүл якалы җылы пальто, ялтыравык кара ботинка-туфли. Очраганда:

— Привет, Зайнуллин! Учишься? — дип сәламли.

Җаваплыйм:

— Учусь, Леонид Калинович! По-русскому только пять!

— Учись! Учись! Способности у тебя хорошие. Не бросай школу. Учись!

Мин унынчыда Герой рөхсәт иткәннән соң укый башладым. Берничә көн узгач, урыс теле укытучысы Орлова, тактага язган жиреннән туктап, кулындагы акбурны идәнгә төшереп җибәрде дә, ыңгырашып, зур прическалы башын ике куллап тотып, идәнгә чүгә башлады. Тагын да ныграк ыңгырашып, диварга тотынып шуып төште дә, идәнгә егылды. Көчкә-көчкә торды да, диварга тотына-тотына акрын гына ишеккә юнәлде. Аны ачты да... ишек бусагасына аркылы егылды. Укучылар куркышып бусагада яткан гәүдәгә карап катып бастылар. Мин сикереп тордым да, сул ягымда утырган Рәвил Шаммасовның бөеренә төрттем:

— Йөгер балниска!

Икенче якта утырган Әнвәргә дәштем:

— Тор! Әйдә, укытучылар бүлмәсенә алып керик күтәреп.

Күтәреп алып кереп, укытучылар бүлмәсендәге диванга салдык. Сыйныф кызлары аның изүләрен чишеп, маңгаена сулы чүпрәк куя башладылар. Мин сигезенче сыйныфта тарих укыткан директорны коридорга чакырып чыгардым:

— Абый! Бик сручны сез кирәк.

Абдуллин чыккач, бүлмә ишеген япмыйча гына ризасызлыгын белдерде:

— Син нәрсә инде, туган?! Дәрес бара, ә син врыватся итәсең. Ул хәтлек...

Үрелеп колагына пышылдыйм:

— Аб-бый! Орлова апа дәрестә һушын җуйды. Укытучылар бүлмәсендә диванга салдык. Сания апа белән кызлар ярдәм итә. Шаммас балниска йөгерде...

Орловага укол ясадылар да, лачинкага салып якында гына урнашкан хәстәханәгә алып киттеләр. Өч көн узгач, һушына килә алмыйча, баш өянәгеннән урыс теле укытучысы Орлова шунда вафат булды.

Без урыс теле укытучысыз торып калдык...

Ике көн узгач, безнең сыйныф җитәкчесе Сания апа Кәримова белән мәктәп директоры Абдуллин абый килеп керделәр.

— Утырыгыз, балалар! Сезнең белән киңәш итеп карарга булдык.

Сания апаны өстәл артына кертеп утыртты да, үзе өстәл янына басты. Урыс сүзләрен кушып сөйләргә ярата иде Герой абзый. Тик ул урыс сүзләренең әйтелеше, янгыравы татар сүзләре кебегрәк иде.

— Сезгә, балалар, урыс теле укытучысы юк бүгенге көндә. Сигез белән тугызга урыс мәктәбеннән Елизавета Ивановна килеп укытырга риза булды. Ә сезне укытырга риза түгел. Атвитствинность зур — чыгарылыш сыйныфы, минем көчем җитми, ди. Яңа урыс теле укытучысын сорап запрус Уфага ясарга булдык. Пака, урыс теле сәгатьләрен бүлеп, башка придмитларга биреп торырга уйлыйбыз. Яңа укытучы килгәч, ул дәресләрне кире ана бирербез. Безнең беләсебез килә, сез, балалар, нәрсә диярсез шушы уйга?

Арткы өстәлдән Равил Байморатов тавыш бирде:

— Үзегез карагыз инде. Безгә барыбер. Сез бит директор.

— Шулай дисезме?

— Әйе.

— Тагын кем нәрсә уйлый, балалар?

Үзем дә көтмәгәндә торып басам:

— Абый! Минем бик шәп тәкъдимем бар. — Сыйныфка кушылып Герой да көлде:

— И-и, туган! Син әллә самахвал инде? Шәп тәкъдим, имеш! Шулай да әйтеп кара шәп тәкъдимеңне. Акча түлисе түгел бит, тыңлап карыйк.

— Мине һәм Равил Байморатовны җиденче сыйныфта Леонид Калинич Ломако урыс теленнән укыткан иде. Хәзер ул урыс мәктәбендә укыта. Илләмә дә шәп укытучы ул. Бик белемле дә. Урыс мәктәбенә, РОНОга барып сөйләшегез — шул укытсын безне урыс теленнән.

— Карале, туган! Бу чыннан да шәп тәкъдимгә ошаган бит. Тик риза булса ярый ла инде...

— Ә сез аңа, Вас ученики десятого класса просят, диегез.

— Син, туган, мине ничек сүйләшергә дә үрәтә башладың инде. Ученики просят, диярга индеату. Ә?

— Әйе.

Баскан хәлендә бераз уйланып торды да, Сания апага мөрәҗәгать итте:

— Сез нәрсә диярсез, Сания апа?

— Барыгыз, сөйләшегез соң. Без бит бернәрсә дә югалтмыйбыз. Тем более, Зәки Зәйнуллин биргән киңәш бит. Аны тыңламасаң, шаярып үч алу гадәте бар аның.

Көлделәр.

— Ярар, алайса. Мин бүген үк киттем урыс ышкулына. Директоры Юлдашев агай минем кебек фронтовик. Аңлашырбыз дип уйлыйм...

Башта ике мәктәп директоры үзләре генә сөйләшәләр. Урыс мәктәбенең директоры үзе математика укытучысы. Башкорт. Сугышны погранзаставада

каршылап, Берлинны алып тәмамлаган капитан. Дүрт хәрби ордены һәм әллә ничә медале бар. Юлдашев Тимербулат Миңнегали улы. Башкорт инәһе ягыннан Пугәч патша полковнигы Каранай Мораты нәселеннән. Абдуллинның тәкъдимен зур игътибар белән тыңлый да, үз фикерен әйтә:

— Ломаконың дәресләре җитәрлек. Сер итеп кенә әйтте: татар мәктәбе балалары урыс теленнән бик арттa. Анда миңа эшләве бик авыр булды, киткәнемә шатмын, ди. Үзе белән сөйләшеп кара. Тик ул фронтовик түгел. Бүген дә под надзором НКВД. Нәрсә кылгандыр, белмим. Бик авыр җинаять ясаган булса, укытырга рөхсәт итмәсләр иде. Нииндидер аңлашылмаучылык, ахрысы. Аның белән килешә алырсыңмы икән, шигем бар...

Абдуллинның чакыруын Леонид Калинович сүзсез генә тыңлый, бүлдерми. Тик сул кулының (уң кулы йөрми, кара күн перчатка кидерелгән иде) бармаклары гына өстәл тактасына очлары белән тыпырдатып, суккалап алалар. Абдуллин сөйләп бетергәч, кистереп җавап бирә:

— Юк, бармыйм! Эшем болай да күп, вакытым юк!

Юлдашевның, барыгыз, диюенә дә җавабы кыска була:

— Ике урында эшләве авыр. Укытуның сыйфаты төшүе бик мөмкин.

— Абдуллин үгетләп караса да, нәтиҗәсе булмый. Саубуллашырга исәпләп, ул аякка басып кулын суза.

— Исән булыгыз! Укучылар бик үтенгәннәр иде, сезне укытырга килсен, дип. Нәрсә дип аңлатыйм инде мин аларга сезнең килмәүне?

Леонид Калинич, нәрсәнедер исенә төшерергә теләгәндәй, Абдуллинга кызыксынып карый. Сул кулын, өстәл өстеннән учын җәя биреп, азга гына күтәрә:

— Китми торыгыз әле. Сабыр итегез. Сезгә соравым бар.

— Сорагыз. Тыңлыйм.

— Ул унынчы сыйныфта минем исәп буенча Зәйнуллин фамилияле, сипкелле битле, кечкенә буйлы малай булырга тиеш. Малай! Атныкы кебек зу-ур башлы.

Абдуллин битен тоташ балкытып елмая. Аңарда өмет туа башлаган инде.

— Бар андый малай. Шул тәкъдим итте дә инде сезне чакырырга. Икәү алар, җиденче класста сездә укыганнар. Тагын Равил Байморатов дигәне бар.

Леонид Калинич сул кулын һавада селти:

— Байморатов? Курносый. Живой такой. Переросток он немножко. Зайнуллин и Баймуратов. Вот оно что-о!

Юлдашевка борыла:

— Барам мин татар мәктәбенә укытырга. Зәйнуллинны укыту бик тә кызык миңа. Ул гади малай түгел. Сәләтле малайның ничек итеп урыс телен үзләштергәнен күзәтү кызык миңа. Килештек!

Абдуллинга кулын сузды.

— Мин риза.

Юлдашев урыныннан торып, аның кулына тотына.

— Көтеп торыгыз, Леонид Калинович! Мәктәп директоры буларак, мин дә үземнең теләкне әйтеп, Абдуллинга бер шарт куйыйм әле.

Герой күңелле итеп көлә:

— Нинди шарт ди инде? Леонид Калиныч риза бит.

— Ул ризадыр, тик мин риза түгел. Ә мин менә ничек уйлыйм. Урыс мәктәбендә математиканы унынчы сыйныфта мин алып барам. Башка сыйныфларда да дәресләрем байтак. Директор эше дә бик катлаулы. Авыр. Өлгер генә! Мин сиңа, син миңа, диләр яһүдләр. Без дә шул принцип

белән эш итик бүген. Абдуллин туган! Мин сиңа Ломаконы бирәм, ә син миңа математик Ураевны бир. Ул да минем унынчы сыйныфны гына математикадан укытсын.

— Һы! Урысча математиканы укыта алырмы икән соң?

Юлдашев көлде:

— Хәйләләмә, Абдуллин. Урысчаны йомшаграк белсән дә, математиканы бик шәп укытып була. Без бит икебез дә фронтовиклар. Күп тапкырлар үлем белән очрашып, аны алдалап, җиңеп чыккан егетләр. Килешик!

— Ураев нәрсә әйтер бит әле үзе. — Юлдашев елмая.

— Өч көн элек мин аның белән сөйләшкән идем инде. Абдуллин каршы төшмәсә, киләм, ди ул. Син Ломаконы сорый башлагач, мин эчтән генә көлеп утырдым: «На ловца и зверь бежит!» Ломаконы көйли идем мин сезгә барырга.

— И-и, шулаймыни?!

— Шулай! Килештекме?

Кул кысыша.

— Бүген кичкә Ураев белән миңа килегез. Ломако да булыр. Бик зур эш эшләдек — юыйк. Уңышлы булсын укытулары!..

***

1972 ел. Октябрь азагы. Мәскәүдән Ригага, мин 1949 елда унынчы сыйныфта укыганда Эстәрлебашта татар мәктәбе директоры булган Советлар Союзы Герое Мансур абый Абдуллин телефоннан шалтырата:

— Зәки туган, исәнме? Мәскәүдән Мансур абыең Абдуллин әле бу.

— Исәнмесез, Мансур абый? Сезнең тавышны ишетүемә шатмын.

— Син, туган, ишеткәнсеңдер инде, март аенда улыбыз Әсгатьне самосвал машинасы таптап үтерде бит. Инде ярты ел вакыт үтеп китте, шул самосвалны һаман таба алмыйлар. Менә инде Мәскәүләренә килгән идем. Министр внутренних делга приемга. Кабул итте итүен, тик өметле бернәрсә дә әйтә алмады. Уфага, Фәния апаңа шалтыраткан идем, ул әйтә: «Ригага бар. Зәкиләрдә берәр атна тор. Ригада йөр, Зәки белән сөйләш — аңа хәлебезне сөйлә, — ди. — Бераз кайгыңны бушатып, чит җирдә торып кайт. Зәки нәрсә киңәш итәр, тыңла!» — ди.

— Килегез, Мансур абый. Көтәбез сезне.

— Рәхмәт, туган! Бүген кич юлга чыгам, алайса. Шалтыратырмын.

Икенче көнне Мансур абыйны тимер юл вокзалында каршы алдым.

Мансур абый килгәч, училищеда дүрт көнгә ял алдым да, Латвиянең башкаласы Риганы күрсәтеп йөрдем Геройга...

Кибетләрдә йөртәм. Абый әйтә:

— Син, туган, мине хатын-кыз киеме сата торган магазинга алып бар әле, — ди.

Хатын-кыз киеме сата торган бик зур кибеткә керәбез. Кием-салым карыйбыз. Дөресрәге, абый карый, мин инде ияреп кенә йөрим. Кая ул хатын-кызга, үземә кием сайлау ягыннан да бик булдыксыз түгел мин.

Мансур абый пальто төймәләрен ычкындырып, сул түшендәге Герой йолдызы күренерлек итеп алдан ачып куйган. Латыш сатучылары белән сөйләшә. Урысчалатып инде, татарча акцент белән. Ә кибеттә зәңгәр күзле, сары чәчле сатучылар бар да латышлар. Аларга Геройның мөрәҗәгате болайрак:

— Пакажите мне, пжалуйста, щелкувый жинский бусгалтыр, тритий размир, пятый полнаты...

Мин дә өйләнгән ир-егет, ике балам бар. Тик ими капчыкларының ни размерын, ни «полнотасын» белмим дә, белмәячәкмен дә!

Абыйның татар акценты белән урысчалатып сораганына чибәр латыш

кызларының йөзендә хет бер мускул селкенсә икән. Әллә бар алар өчен абыйның түшендәге Алтын Йолдыз, әллә юк! Арттан абыйның колагына пышылдыйм:

— Абый! Татарча сорагыз!

Абый миңа таба борылып, гаҗәпләнү тулы күзләре белән миңа текәлә:

— Бу латыш хатыннары монда, Ригада татар телен каян белсеннәр инде. Юкны сүләмә, Зәки!

— Беләләрме, юкмы — татарча сорагыз! Күрерсез нәрсә булганын.

Абый бик теләми генә татарчага күчә.

— Миңа хатын-кызларга өченче үлчәмле, бишенче тулылыктагы ими чүлмәге күрсәтегез әле.

Шунда тынлык урнаша. Сатучы хатыннарның юанрагы телгә килә, тик беренче сүзе генә латышча, калганнары бар да урысча:

— Лудзу! (Рәхим итегез!) Ви не русский. Что Вам нужно?

— Татарин мин.

Латышларның китте авызлары ерылып:

— О-о! Татарин! Как хорошо! Можете говорит и на русском! Мы вас слушаем!

— Мине бусгалтер нужен шелковый! Тритий размер, пятый полнота.

Мансур абый зур осталык белән бюстгалтерлар, трусиклар, эчке күлмәкләр, тагын әллә нәрсәләр, әллә нәрсәләр сатып ала. Һәрбер чүпрәкне, берәмтекләп сәрмәп, тикшереп, зур игътибар белән карап ала. Ул сайлаганга миңа нилектәндер унайсыз кебек... Бик сиздермәскә тырышып читкәрәк китеп басам... Нихәл итәсең, кибеттән кибеткә ияреп йөрим инде. Күп итеп Латвиядә тегелгән (ул елларда ук Латвиядә затлы тегә беләләр иде) хатын-кызга кирәкле әйберләр ала. Зур төен күтәреп, автобус тукталышына карап атлыйбыз. Түзмим, сорыйм:

— Абый! Хатын-кызларга эчке киемнәр, хушбуй-духилар, сөртә торган әллә нинди крем-майларны аласыз икән. Мин хатын-кызга баш яулыгы да ала белмим. Бик оста. Кайчан өйрәндегез сез моңа?

Абый елмаймый да:

— Син, туган, учуный, подполковник булсаң да, ир-егет булып житлегеп житмәгәнсең әле. Юк, житмәгәнсең! Моны сиңа мин әйтәм, Мансур абыең! Мин ул нәстәләрне сатып алып Уфага алып кайтам. Фәния апаңа, балдызга, кызым Нәфисәгә. Бердән, аларга бу зур шатлык. Икенчедән, Фәния апаңа алган затлы бустгалтерны, ефәк эчке күлмәкләрне ... э-э-э... һәм дә башка нәстәләрне ин тәүдә кем сәрми? Ә? Мин сәрмим. Һәм аларны сәрмәү минем кулларга ял вә ләззәт бирә. Бел, белмәсәң!

Мансур абый бездә атнага якын яшәде. Шул вакыт эчендә минем алда фаҗигале бер гаилә тарихы ачылды. Абый кабаланмый гына сөйли дә сөйли:

— Безнең әти Идиәтулла революциягә кадәр Кыргыз Миякәнең иң бай сәүдәгәре булган. Каргалы, Ырымбур, Семипалат, Ташкент байлары белән аралашкан, бик яхшы итеп сәүдә итә белгән. Утыз беренче елны йортын тартып алып, безне куып чыгардылар. Авыл читендәге яртылаш жимерек, өй дисәң өй түгел, абзар дисәң, ике тәрәзәсе бар, сарайкы, мунчамы, шуңа күчендек. Колхоз рәисе, бабай ягыннан бераз туган — әтине колхоз келәтләре сакларга куйды. Миңа уникe яшь тулып узган гына, укуны ташлап колхозда эшлим. Бәрәңге утыйбыз, печән җыябыз, ашлык тазартабыз. Элекләре бай булганлыктан, әтинең колхозда дошманнары байтак. Шулардан миңа да эләгә иде. Утыз алтынчы елда әтине кулга алып Казакъстанга сөрделәр. Әни, мин, дүрт сенелкәш торып калдык. Сеңелкәшнең олысына 13 яшь, кечесенә яшь ярым. Ач, ялангач, кимсетелү һәр көн, хәерчелек. Әти бай

чагында бик юмарт булып, күпләргә ярдәм иткән. Яхшы кешеләр дә аның яхшылыгын онытмыйча безгә ярдәм иткәлиләр. Төнен, кеше күрмәгәндә, безнең авыл читендәге өйгә ашарга ит, он китереп киталәр иде.

Исемдә, шул әтине алып киткән утыз алтынчы елның декабрь урталарында Әкчүн тимер юл станциясына атлы чана белән иген илттек. Өстә иске генә бишмәт, аякта тула оек-чабата, үзем ач. Игенне тапшыргач, кайтырга чыктык, дүрт атлы. Бергә кайтырга чыкканнарда кемдә толып, кемдә тун, кемдә чикмән. Ә минем өстә тузып бетә язган сырган бишмәт. Шунда Хәммадулла исемле абзый өстеннән тунын салып мина кигезде. Үзенең толыбы бар иде, шуны киде. Шул тун булмаса беткән идем юлда — тун коткарды. Кайтып життем өшесәм дә. Төшеп чана артыннан йөгерергә хәл юк — ач, ашамаган. Әтине алып киттеләр. Безгә тимәделәр. Кемдер ярдәм итеп, яклап, авылда калдырдылар. Биш бала, мин — зурлары, унжиде белән барам. Сенелләр дүртәү. Укуны әллә кайчан ташладым — сенелләрнең тамагын туйдырырга кирәк. Әтине Казакъстанга илтеп, бер совхозга эшкә куйганнар. Җәен кырда эшли, көтү көтә, карбыз кырын саклый икән. Ә кышын сарык карый. Елына бер хаты килә.

Кырыгынчы елның августында Кызыл армиягә алдылар. Белем — бетермәгән дүрт сыйныф. Брест дигән калага эләгеп, шуның крепостенда мин. «Сорокопятка» дигән пушканы ат жигеп тарттырып йөрибез. Көн коры булса, бер пар ат җигәбез, янгыр явып юллар пычранса, ике пар ат жигәбез. Артиллерист-наводчик мин. Белем юк дәрәҗәдә, урысча ныклап белмим бит инде. Илләмә тырышам. Минем кызыләрмис булуым өйдәгеләр өчен бик тә әйбәт. Кызыләрмис гаиләсе дип өйдә калганнарның һәрберсенә колхоз аена бер пот он бирә. Өйдә бишәү: дүрт сенелкәш тә әни. Димәк, биш пот һәр айда. Ач утырмыйлар инде.

Сугыш 22 июньдә иртән дүрттә башланды. И-и туга-ан! Нәрсәләр генә күрмәдек инде ул сугыш юлларында. Бресттан алып Мәскәүгә хәтле немец басып алган жирләр аша отступать итеп качтык. Алтмыштан артык частьтан жыелган төрле халык. Пехота, саперлар, артиллерия, танклары янган берничә танкист, немецлар һавадан бәреп төшергән ике очучы... Тагын әллә кемнәр, әллә кемнәр инде менә. Бер капитан безнең белән командалык итә. Илләмә дә боевой егет иде инде. Өстәвенә үзе татар. Фамилиясе Нигъмәтуллин иде. Үзе әйтмешли, «Нәкъ Казан артыннан» икән. Тәки алып чыкты бит безне окружениедән.

Август урталарында чыктык. Ул бетләдек, сакал-мыек үскән, ул аяктагы итек-ботинкалар тузган, өстәге гимнастерка-чалбарлар тетелеп беткән. Ике аягы да җәрәхәтле бер пехота генералын кайда күтәреп, кайда плащ-палаткага салып өстерәп, үзебез белән алып чыктык.Килеп төштек окопка. Генерал носилкада ята. Иплән кенә окоп төбенә куйдык. Күзе йомык генералның. Нигъмәтуллин иплән кенә кулбашыннан тотып, акрын кына селкетә моны:

— Товарищ генерал! Чыктык чолганыштан. Үзебезнекеләрнең окобында без.

Генерал күзен ачты. Авырлык белән кузгалып утырды. Тирә-ягына карана бу. Окоптагы кызылармеецларны күрде дә... тотынды чукынырга, тотынды такмакларга:

— Слава тебе, господи! Слава тебе, господи! Живой я! У своих! Слава тебе, господи!

Елмаешабыз инде «Бох»ны исенә төшергән коммунист кызыл генералга карап.

Мунча кертеп, беттән аралап, өр-яңа киемнәр биреп, ике тәүлек ашатып, йоклаттылар да, төрле частьларга таратып сугышка тыктылар.

Кырык өчнең кышында февраль азакларында Харьковтан ары

Синельниково тимер юл стансасы янында безне немец фельдмаршалы Манштейн туздырып ташлады. Курск — Белгородка кадәр тагын качтык инде. Шунда хәтле чигенеп, Курск белән Белгород калалары арасында ике фронт зур дуга ясап, көчкә-көчкә оборонага күчә алдык. Чигенгәндә Харьковтан шул Курск Дугасына кадәр тагын безнең сугышчыларның үле гәүдәләре ятып калды. Ул ташлаган техниканың, коралның исәбе-хисабы юк. Дала тулы. Харьков каласы янында ике катастрофа булды безнең өчен. Берсе — кырык икенең язында. Сталинградка кадәр «драпали». Икенчесе — кырык өченең февраль-апрелендә. Курскига кадәр тагын качтык. Язгы пычрак коткарды. Немец танклары баттылар язгы пычракта. Курск, Белгород җирләрендә кара туфракның калынлыгы метр-метр ярым. Танклар тоташ чумалар иде шул кара пычракка.

Курск Дугасында бик нык әзерләндек без. Көн-төн көрәк-кәйлә кулда. Окоплар казып, бруствердар ясап кояшта кызынабыз. Синельниководан чигенгәндә, пушкаларны ташладык. Снарядлар юк, атлар ачтан тәгәрәп үлеп беттеләр — чын-чынлап «драпали». Частьлар кайда — белгән кеше юк, тәртипнең әсәре дә юк. Җәяүләп чигенеп, шул Курск Дугасы янына, сай гына окопларга килеп коелдык. Ике көн сортировать иттеләр дә, мине танкларга каршы ата торган бер батареяга старшина итеп билгеләделәр. Сержант званиесе бирделәр. Белем аз дип каршы торып маташкан идем, кая ул! Полк командиры майор Бобров әйтә: «Кырык бернең июненнән бирле ут эченнән чыкмыйча сугышасың. Син сугышның профиссыры инде хәзер, — ди. — Синдәге тәҗрибә миндә дә юк, — ди».

Батарея командиры — яшь лейтенант. Ә артиллеристларның яртысы минем кебек сугышкан халык. — Елдан артык сугышканнары да бар.

Немец танклары килә башлагач, түземсезлек белән якынайганнарын көтәбез тегеләрнең. Безнең пушка позицияләреннән 25 метрда гына алда кечкенә елгачык ага. Исеме Куриная иде. Елга тавык сикереп чыгарлык кына шул инде, суының тирәнлеге ярты метр да юк. Ә ярлары текә. Шул елга ярында каршы алдык без немец танкларын. Без позициядә окопта яткан урынга каршы елга аша бер ялан юлы уза. «Перекрестный огонь» белән ике пушканы шул юлга каршы, җиргә күмеп диярлек утырттык. Өченче пушканы елга ярының сөзәгрәк җиренә каршы куйдык. Ул да окопта инде. Окопның дошман ягы бруствер дип атала. Анда инде туфрак нык өелеп, үләннән маскировка ясала. Корып саргаймасын дип көн дә төнгә каршы брустверга су сибәбез. Шунлыктан үлән яшел. Маскировка шәп!

5 июльдә китте кырылыш-сугыш. Яр буйлап окоплар казып, пехота — автоматчылар тулды. Болар инде немец автоматчыларын, танкларыннан автоматтан атып аерып, юк итәргә тиешләр. Нык сугышты алар да. Өч көн эчендә 5—6сы гына исән калган иде. Яралылар шул окоплар эчендә үлеп беттеләр.

Иң әүвәл теге юл белән елгага төшеп җитә язган алдагы танкны бәрдек. 76 миллиметрлы, озын көпшәле, танкка каршы ата торган өч пушка бездә. Ике пушкадан берьюлы атып китереп чәпәгән идек тегенәргә, башнясын ук алып очырдык. Елгада утырып яна! Немец танкистлары да бик тәҗрибәле иде, ахрысы. Ярның сөзәгрәк җиреннән сикергән кебек елгага шапылдап килеп төшәләр дә, елга буена хәрәкәт итеп, бу якка менү өчен ярның сөзәк җирен эзлиләр. Шул елга эченнән алабыз тегеләрне...

Тәүлектән артык сугыштык инде. Минем сул кул йөрми. Батарея халкы кырылып бетте диярлек. Лейтенант рөхсәте белән мин төнлә безнең пехота окопларына киттем. Окоплар тулы үлек солдатлар аунап ята. Рота командиры булып бер сержант калган. Алты солдат сорап алдым үзебезнең пушкаларга снаряд биреп торырга...

Батареяда 76 миллиметрлы өч пушка. Снарядлар күп — ат та ат! Немец 5 июльдә һөҗүм итә башлаган иде — китте көн-төн сугыш. Атыш та атыш, үтереш тә үтереш. Өч көн йокы юк, ашау юк — атабыз да атабыз. Курск Дугасында артиллеристлардан немецның иң күп танкларын бәргән безнең батарея булып чыкты. 18 танкны юк иткәнбез. Ул турыда госпитальдә беллек инде. Бөтен батареядан өч кеше исән калдык. Өчебез дә яраланган. Башкача яралылар юк. Бер землянкада җыйган идек, өстенә немец «Тигр»ы менеп, барысын да изеп үтерде. Исән калганнар — батарея командиры лейтенант Кузьмин, батарея старшинасы мин — сержант Абдуллин һәм бер рядовой — Николай Самойлов. Минем сул кул салынып төшкән — күтәреп тә булмый. Бармаклар яньчелеп беткән. Башта да бар корыч кый пылчыгы, аякта да, аркага да кыйпылчык эләккән. Кырык дүртнең гыйнвар уртасына кадәр госпитальдә яттым. Самойлов иртәрәк чыкты, ә лейтенант Кузьмин миннән соң тагын бер ай аунады әле госпитальдә...

Частька кайттым. Миңа өлкән лейтенант званиесе бирделәр. Белем юк дип тормадылар, батарея командиры итеп куйдылар. Тик контузия бик көчле булган минем. Якындарак снаряд шартласа, анны җуеп тәгәрим дә китәм.

***

Кырык дүртенче елның апрель уртасында безнең өчебезне дә Мәскәүгә командировкага җибәрделәр. Апрельнең егермесендә Кремльдә Калинин бабай безгә Советлар Союзы Батыры таныклыклары тапшырды. Ленин ордены белән Алтын Йолдыз такты күкрәкләргә. Кулларыбызны кысты, кочаклады. Мине беләктән, билдән бармаклары белән тоткалап карады Калинин. Монсу гына елмаеп, сакалын селкетте.

— Бигрәк ябыксың бит. Ай-һай! – диде.

Мин, елмаеп:

— Сугышта симезлек кирәкми, көч кирәк! – дидем.

Банкет ясап, бик яхшы коньяк эчерделәр. Шунарчы минем коньяк эчкәнем юк иде. Бик шәп икән ул!

Май уртасында комиссовать итеп, кайтарып җибәрделәр мине. Курск Дугасында алган яралар ачыла башлады, контузия бик көчле булып чыкты. Атлап барган җирдән тәгәрим дә китәм бит, малай.

Ярар. Бер ай Мәскәүдә госпитальдә яттым. Кайттым Башкортстанга. Мине Геройга тәкъдим иткәч, Башкортстанга, обкомга хәбәр иткәннәр. Әтине Казакъстаннан авылга кайтарганнар. Безнең элекке йортта район башкарма комитеты урнашкан. Мин май уртасында авылга, Миякәгә кайтканда яңа өй салып, әти-әнине, дүрт сеңелкәшне шул яңа йортка яшәргә керткәннәр иде инде.

Кайттым. Җәй буена мине Башкортстан калалары, район үзәкләре буенча йөрттеләр. Иң беренче исән Советлар Союзы Герое кайткан бит Башкортстанга! Белем дүрт сыйныф — юньләп чыгыш та ясый белмим. Трибунага чыксам, кызарам, тотлыгам — чак сөйлим. Илләмә тырышам инде. Июнь-июль йөрттеләр инде мине халыкка күрсәтеп. Түштә — Алтын медаль, Ленин ордены белән Кызыл Йолдыз ордены, тагын өч түгәрәк медаль.

Август житеп килә — нәрсә эшләтергә мине? Белемем дә, һөнәрем дә юк. Берничә ел колхозда атлы эштә йөрдем — шул гына миндә. Герой булып тагын атлы эшкә тотынып булмый бит инде колхозда. «Уфа» кунакханәсендә аерым бер бүлмәдә яшим. Калаларга, район йөртүдән туктадылар. Ресторанда ашаталар, эчертәләр үзе. Теләсәм, коньяк, аракы бирәләр. Тик эчмим генә.

Август башы. Обкомга чакырдылар. Зур бер кабинетка алып керделәр. Ишегенә «Инструктор по идеологии» дип язып куйганнар. Кердем. Утырттылар. Мин утырган өстәлнең икенче ягында яшел йон гимнастерка-чалбар кигән бер егет утыра.Сул кулы төптән үк юк. Капитан погоннары таккан танкист бу. Ике Кызыл Байрак, бер Кызыл Йолдыз ордены түшендә. Шуларга өстәп тагын дүрт медале бар — шәп сугышкан бу егет.

Инструктор безне таныштыра.

— Бу — Герой егет Мансур Абдуллин була. Артиллерист. Ә бу иптәш — Тәминдар Ибәтуллин, танкист, — ди.

Кул кысып танышабыз.

— Егетләр! Икегез дә зур батырлыклар күрсәтеп сугышкансыз. Икегез дә Курск Дугасын үтеп, каты яралангансыз. Без монда, обкомда, сезнең язмыш турында махсус утырышта сөйләштек, һәм карар кылдык: сезнең икегезне дә Уфадагы Тимирязев исемендәге педагогика институтының беренче курс студентлары итәргә. Ибәтуллин иптәшнең ун сыйныф белеме бар. Икегезгә гомуми тораклан бер бүлмә бирәбез. Институттан икегезгә дә аена бишәр йөз сум стипендия. Иптәш Абдуллинга Герой булган өчен өстәмә 900 сум түлиләр. Анысы билгеле инде...

Сөйләвеннән туктап, икебезгә дә сынаулы күзләрен текәде.

— Абдуллин иптәштә урта белем юк. Белеме — алты сыйныф...

Мин: «Дүрт сыйныф, ансы да тәмамламаган...» дип әйтергә телим.

Сул кулын күтәреп туктатты бу:

— Кирәкми, бернәрсә дә өстәмәгез, иптәш Абдуллин. Сездә алты сыйныф белем и шуның белән килешегез. Иптәш Ибәтуллинны сезгә махсус беркетәбез. Укырга ярдәм итәр, авыр урыннарын аңлатыр.

Ибәтуллин сорау бирде:

— Иптәш инструктор! Безне кайсы факультетка укырга тәгаенлисез инде?

— Тарих факультетына. Иптәш Абдуллинга математика, физика, рус телләрен ерып чыгу бик авыр булыр. Географиядә дә терминнар, атамалар бик күп бит. Ә тарих ул бик авыр фән түгел. Менә шул сезгә, иптәш әфисәр-фронтовиклар. Килештекме?

Кул биреп саубуллаштылар.

Минем шатлык зурдан иде: институтта укыячакмын!

Обкомнан чыккач, кабаланмый гына Уфа каласы урамнары белән «Уфа» кунакханәсенә таба атладык. Тәминдар шунда тәкъдим итте:

— Әйдә, Мансур, ресторанга керик. Танышуны һәм студент булганны юыйк! Бик тә зур шатлык бу сина да, миңа да. Алда инде җиң сызганып белем алу тора. Без, фронтовиклар алдында...

Яңа дус белән бергә, аның ярдәме белән дүрт ел укыдым мин. Уйлап кара, Зәки туган, укыган башың белән миеңне эшләтеп. Утыз беренче елдан бирле (унөч ел) мин, Мансур Абдуллин, парта артында утырган кеше түгел идем. Гел генә кара эштә ат белән, бер елга якын Брест янында кызылармис-әртиллерист, аннан ике елдан артык фронтта. Атыш та үтереш, үлем дә атыш, кан кою, кеше үтерү...

Башта укый алмый яфаландым. Кердем ректорга. Уңайсызланып кына телгә киләм:

— Иптәш ректор! Мин сезгә авырлык китерә торган кеше түгел. Белем юк бит миндә. Бетермәгән дүрт сыйныф минем белем...

— Алты түгелмени?

Кул селтим:

— Түгел. Обкомнан куштылар алты сыйныф дип әйтергә дә, таныклык та бирделәр. Дүртенче сыйныфны мартта ташладым мин. Купец-сәүдәгәр малае бит мин.

— Анысы билгеле.

— Билгеле булгач. Мин гариза язып, институттан җибәрүегезне үтенәм. Контузия бик көчле бит миндә — баш һаман да авырта. Китим мин гариза язып, укыр өчен исәнлегем юк дип.

Ректор елмая:

— Юк инде, Мансур туган! Бернинди дә гариза язмыйсыз. Мин бер карт профессор белән киңәштем, сезнең белән нәрсә эшләргә дип. Ул бик яхшы киңәш бирде. Сез иптәш Тәминдар Ибәтуллин белән сынауга, зачетка бергә керәсез. Бер-бер артлы, һәрберегез үзенә тиешле билет аласыз. Икәү бергә бер өстәл артына утырасыз. Башта Тәминдар сез, иптәш Абдуллин, алган билетка җавап яза. Сез шуны укып сынау бирергә чыгасыз. Ә сез сынау бирергә чыккач, Ибәтуллин үзенең билетына әзерләнә. Икегезгә дә стипендия ай саен. Педагогларга күрсәтмә бирелер — икегезгә дә «өчле« билгесе куймаслар...

Шулай итеп, ике курсны укып, сынаулар биреп яшәдек Тәминдар белән. Өченче курста баш бераз эшли башлады кебек. Көн-төн китап өстендә утыргач, баш та аңлады, ахрысы: «Уйлый башларга кирәктер, барыбер көчләп булса да укыталар бит!»

Укырга кергәндә мина егерме биш яшь тулып узган иде инде. Фронттан кайтканга ике ел үтте. Контузиянең тәэсире һаман бар, бетми. Башта бер кечкенә снәрәт кыйпылчыгы утыра, һава үзгәрә башласа, башның авыртуына чыдап булмый.

Мине Кызыл Армиягә 1940 елның августында алдылар, Мәскәү аша Брест крепостена алып барып төшерделәр. Противотанковый әртиллериягә эләктем мин. 45 миллиметрлы, ике эрзинкә тәгәрмәчле танкка каршы ата торган пушка. Юллар коры булса, ике ат җигеп йөртәбез. Ялан кырдан өстерәтергә булса, яисә көн яңгырлы булса, парлап дүрт ат җигәбез. Башта мине атлар йөртергә куйдылар. Ат йөртүчеләр татар, башкорт, чуаш егетләре. Атны яхшы белә безнең халык. Үзе ач йөрсә йөри, атка ашата, аны карый...

Ике ай йөрдем ат менеп. Пушка тарттырып. Аткан чакта наводчиклар янында уралам — пушкадан атарга өйрәнәсе килә бит. Синцов дигән бер Себер егете өйрәтте мине төзәп атарга. Прицел ватылса, пушка көпшәсенең эченнән карап атарга да өйрәтте ул мине.

Әрмиягә киткәнче, шул кырыгынчы елга кадәр, үзебезнең авылда колхозда эшләдем мин. Ат белән йөреп. Кышын печән, салам ташыйм. Язын сабан белән җир сөрәм, иген чәчәм. Косилка белән печән чабам, кибән коешам, жнейкада арыш, бодай, солы, тары, борчак чабам. Әти Казакъстанда бер совхозда высылкада. Ә без өйдә — инәй, мин, дүрт сеңелкәш. Сеңелкәшләр үсә баралар, колхоз эшенә җигелә баралар. 16-17 яшькә җитеп, чибәр генә егеткә әверелә башладым мин. Сугышка хәтле дә, сугыштан соң да егетләр, кызлар аулак өйләргә җыелып, җәен авыл читендә уен, җыр-биюләр оештыралар иде. Шул елларда кызлар белән куну гадәте бар иде. Егет тә, кыз да өсләрендәге киемнәрен салмыйча, берәр урын табып, шунда кочаклашып кына йоклыйлар. Кызны егет сәрмәштерә инде, тик кулны билдән түбән уздыру юк...

Минем дә кызларга күз төшә башлады. Тик кызларның берсе дә минем белән кунмый да, йөрми дә. Кулак, купис малае! Дустым Хаммат сөйләшеп карый кызлар белән, Мансурның синең белән кунасы килә, дип. Күпчелеге кызларның: «Аллам сакласын кулак малае белән кунарга!» — дип кенә җавап бирәләр. Шулай да бер көзе бик тә кылый Кәшифә исемле, үземнән ике яшькә олы бер кыз белән «куну бәхетенә» ирештем бит, әй. Үзе кулымнан тотып алып менде бу мине печәнлекләренә. Миңа 18 яшь. Дәрт дигәнең

шартлап тора. Ярар. Мендек печәнлеккә. Юрган, мендәр — бар да бар монда. Яттык юрган астына кереп. Мин моны ипләп кенә, оялып кына кочаклыйм. Азрак яткач биленә генә тотынып, бу миңа пышылдый:

— Түшләремне дә тот инде! — ди.

Изүләрен чишеп куйган — таш кебек ике кызган түш моңарда. Тоттым уң кул белән моның бер түшен. Тән буйлап яшен үтте. Азрак кына ятты да, пышылдый тагын миңа:

— Чишендер мине! Нәрсә эшләтсәң дә мин риза!

Нишләргә? Хәзер моңа «тисәң», өйләнергә кирәк бит инде. Ә минем кылый хатын белән яшисем килми. Тиз генә башны эшләтеп алдым. Пышылдыйм моңа: «Мин төшеп «тышка чыгып» алыйм инде. Хәзер менәрмен кире». Җавап итеп пышылдый: «Ярар! Тиз мен! Мин чишенә башлыйм!»

Төштем печәнлектән баскыч белән һәм... тай боларның бакчасы аша тыкрыкка. Йөгерәм җан-фәрманга кайту ягына...

Айдан артык качып, Кәшифәне күрмәмешкә салынып йөрдем инде...

Сугышта янда снәрәтләр шартлаганда гел генә шул печәнлекне, кызу тәнле Кәшифәне искә төшерә торган идем: «Нигә шунда «нитмәскә» инде шул Кәшифәне?» Снәрәт ботарлап очырса, мин бит хатын-кызның ләззәтен белмичә «китеп тә» барам бит инде?! Татар акылы төштән соң дигәндәй булды бу. Ә инде сугыштан исән-имин кайткач, уй үзгәрде: «Әле дә тимәгәнмен. Сугыш башланасы елның язында Баязит исемле, авылда хатыны үлгән бер иргә кияүгә чыккан Кәшифә. Ике ятим балага әни булган, ире сугышка киткәндә үзе авырлы булып калган. Ире кырык өчтә бер аягын өздереп кайткан. Өч бала белән көтеп алган ирен. Бик матур яшәделәр. Илле өченче елда Миякә базарында кочаклый бу мине, рәхмәт әйтә миңа тимәгәнгә. Бик чибәрләнгән. Кылый кебек тә түгел...

Ярар. Кырык дүрттә кайттым сугыштан. Миңа 25 яшь. Ә хатын-кызның берсен дә чынлап тотканым юк әле. Ул яктан да «наданмын».

Тәминдарга фабрикада тегүче булып эшләгән бер татар кызы ияләште. Ул безнең бүлмәгә кил дисә, мин китәм киногa чыгып. Кино карап кайтканда ул кыз юкка чыккан була инде. Ике-өч ай килеп йөри торгач, миңа әйтә бу:

— Мансур! Минем фабрикада бик әйбәт татар кызы бар. Әйдә, сине таныштырам шуның белән, — ди.

Ә мин, Габдулла Тукай кебек, кызлардан куркам.

Сугышлар бетеп, күп үлемнәр күреп исән кайтсам да, кызлар белән юньләп сүз кушып сөйләшә дә белмим, кызарам, тел әйләнми. Алар минем өчен башка планетадан килгән әүлиялар кебек инде менә...

Шулай итеп, студент булып кышны житкердем. Бер мәртәбә кинодан чыктым. Кичке сигезләр тирәсе бу. Кайту ягына атлый идем, берәү куып житеп миңа дәшә:

— Сезнең белән бергә кайтырга рөхсәт итегез әле миңа. Сез яшәгән гомуми торакта яшим мин дә.

Кызлар тавышы. Башны борып карасам, эндәшкән кызның чибәрлегенә тәгәрәпләр китә яздым. Матур якалы пальто кигән, мамык шәл ябынган. Бите алсуланган суыктан. Күзләре энже кебек. Үзе миңа карап елмая. Йөрәк әллә ничекләр итеп, рәхәт итеп, нык итеп тибә, сулкылдый ук башлады. Тамак кипте дә куйды. Бер генә сүз дә әйтеп булмый. Баш кына селки алдым моңарга. Бераз дәшмичә атладык. Көн бераз гына суык. Матур итеп, күнелләрне моңсуландырып акрын гына ак кар ява. Ике-өч квартал узгач, тагын телгә килде бу кыз:

— Сез бик кино яратасыз, ахры. Киногa еш йөрисез. — Көчкә бер сүз чыкты миннән:

— Әйе! — мин әйтәм.

— Әле караган кино ошадымы сезгә?

Кино — «Два бойца» иде. Миннән янә шул ук сүз чыга.

— Әйе.

Сүзсез атлый башлады кызый. Анарга минем «әйе»дән уза алмау бик үк ошамый иде булса кирәк. Кайтып җиттек. Хушлаша бу.

— Бик эчтәлекле сөйләшеп кайттык сезнең белән. Рәхмәт сезгә. Сау булыгыз.

— Сау булыгыз.

Ике көн узгач, Тукай урамыннан өске якка, үзебезнең институтка таба, үргә атлыйбыз. Тиз-тиз адымнар белән ике чибәр кыз узып китте безне. Ике-өч адым узып атлагач, берсе борылып, мина карап елмая:

— Сәлам кино яратучы абый кешегә!

Йөрәгем шинель эченнән китте аска тәгәрәп. Баш кына кагам: «Сәлам!»

Кызу-кызу атлап киттеләр кызлар. Болар белән ара ераклашкач, Тәминдар сорый миннән:

— Ул кыз сине беләмени?

— Ике көн элек кинодан бергә кайткан идек.

— Ә-ә, алай икән. Исеме ничек?

— Белмим бит, әй.

— Ничек инде белмисен? Кинодан бергә кайткансыз бит.

— Юл унае булгач, кайттык инде. Кая барасын?

— Юлда сөйләшмәдегезмени?

— Юк.

— Ну, Мансур! Сугыш беткән. Син — студент. Кызлар белән бер тулай торакта яшисең. Сиңа бит 25 яшь. Үзең Герой! Башыңны күтәреп, күзеңне ачып кызлар күзли башларга әллә кайчан вакыт бит инде сиңа...

Ике көн узгач, Тәминдар теге кыз турында миңа мәгълүмат бирә:

— Ул кызның исеме Фәния. Дәүләкәннән килгән укырга. География факультетында беренче курста укый. Бик горур тота үзен. Тик тәкәббер түгел. Бер бүлмәдә алты кыз бергә торалар. Әти-әнисе бар.

— Каян белеп бетердең син бу хәтлек яналыкны?

— Минем күз хәтере шәп бит. Лекцияләр беткәч, гардероб янында басып тордым. Ярты сәгатьтән артык. Пальтосын киеп, Тукай урамы белән кайтып китте бу. Мин киттем ана ияреп. Тулай торакка кайттык. Икенче катка менгәч, каршыдагы бүлмәдә яши икән. Ул кереп киткәч, ишек шакып кердем бүлмәләренә. Таныш түгел бер кызны коридорга чакырып чыгарып, сораштым кем икәнен. Башта әйтмәскә боланды. Мин турыдан ярам: «Минем дус егет бик ошата аны. Танышырга тели. Әйт инде», дим. Әйтте. — Елмая Тәминдар күнелле итеп:

— Бар, киного ике билет ал да, бүлмәләренә кереп кинога чакыр.

— Кит, сантый! Нәрсә дип мин аларның бүлмәсенә керим инде?

— Кызларга нәрсә әйтергә белмисенмени?

— Белмим.

— Өйрәтим, алайса. Һәрбер кыз үзенә ошаган егетне очратып, шунарга кияүгә чыгарга хыяллана. Сиңа алар өмет белән карыйлар. Кер: «Исәнмесез, кызлар! Хәерле кич!» — диген. Күзенне ныклап ачып карап, Фәнияне тап. Һәм әйт: «Фәния туташ! Мин сезне бүген кичке сигезгә кинога чакырам. Әзер булыгыз, сигезенче яртыда мин сезне алырга керермен! — диген. Ризамы ул, түгелме, башыңны и дә, чыгып кит. Сигезенче яртыда ишекләрен шакы.

— Барыр дисенме?

— Бармый булдыра алмас. Син институтта төсе-кыяфәте белән дә, буең белән дә иң шәп егетләрнең берсе!

— Хараплар гына булам бит инде.

— Без, Мансур, хатын-кыз тарафыннан бу дөньяга харап ителергә яратылган мәхлүк җаннар. Син дә харап бул. Егерме биш яшең узган — өлгергәнсең харап булыр өчен.

— Белмим. Минем аяк тыңлармы икән соң?

— Тыңламаса, ишек төпләренә хәтлек мин сине күтәреп алып барыйм да, ишекләрен шакып, сине бүлмәләренә төртеп кертим, һәм Фәниягә әйтим: «Фәния! Бу егет сезне кинога чакырырга тели, тик теле әйләнми. Мин гарантия бирәм: шәп егет бу! Барыгыз аның белән бүген кинога». Шулай итик, алайса.

Мансурның авызы китте ерылып:

— Карале, Тәминдар дус! Шәп уйлап чыгардың бит син моны. Әйдә, шулай эшлик. Син миңа ярдәм ит инде Сиңа кирәк чакта, мин дә сиңа шулай ярдәм итәрмен.

— Һы! Булдыра алырсыңмы соң?

— Үзем өчен булдыра алмасам да, синең өчен булдырам мин аны. Әйдә, киттек.

Билетлар алынды. Менә Тәминдар ишек шакый. Эчтән кызлар тавышы ишетелә:

— Ишек ачык! Кем бар анда? Керегез.

Кызлар исе белән тәмле итеп пешкән бәрәңге исе таралган бүлмәгә. Тәминдар көр тавыш белән исәнләшә:

— Кызлар, исәнмесез?

Аңарга ишетелер-ишетелмәс тавыш белән Мансур да кушыла:

— Исәнмесесс!!!

Сул якта, икенче караватта китап тотып утырган Фәнияне күзе белән эзләп табып, Тәминдар аңа дәшә:

— Фәния туташ! Менә бу егетнең исеме — Мансур. Фамилиясе — Абдуллин. Сез аның белән почти таныш, бер мәртәбә кинодан бергә кайткансыз да икән. Аның сезнең белән чынлап танышып, бергәләшеп кинога барасы килә. Сезнең исемегез Фәния икәнне белә инде. Сезне кинога чакырырга кыюлыгы җитеп бетми. Мин сезне дустым Мансур белән кинога баруыгызны үтенергә кердем. Сезнең белән кинодан кайтканда бу егет үзенең йөрәген югалткан. Әллә юлда төшереп калдырган, әллә инде ул йөрәк хәзер сезнең тарафта. Кинога барышлый, кайтышлый шул йөрәкне дә табарга ярдәм итә алмассызмы икән?

Мансурга борылды:

— Шулай бит, дус?!

Мансур, каушап калса да, тулы җавап бирә алды. Баш какты:

— Ы-ы!

Фәния урыныннан торды. Матур күзләрендә туп-тулы ирония иде:

— Нигә сез башыгызны авырттырып, вакытыгызны әрәм итеп, башка кеше өчен мине кинога барырга кыстыйсыз әле? Әйдәгез, сезнең белән икәү киттек кинога! Бик кино карыйсы килсә, дустыгыз Мансур безнең арттан ияреп барыр, ияреп кайтыр, карап, өйрәнеп йөрер кызлар белән кинога ничек барырга икәнен.

— Ярар, телегезгә салынмагыз инде. Барыгыз — үлә бит!

Фәния күнелле итеп елмайды:

— Ярар. Шулай килеп чыга инде. Сынау булсын — бер барып карыйк әле. Алдагысын, нindирәк егет икәнен бүгенгесе күрсәтер.

Мансурга елмаеп карады:

— Билетлар алдыгызмы?

Мансур баш какты:

— Әйе.

— Кинодан кайтып житкәнче «әйе» дип ике мәртәбә әйткән идегез. Инде өченчегә тагын «әйе» дисез. Тагын башка сүзләр беләсезме?

Сөйләшеп киткәнен Мансур үзе дә сизми калды:

— Беләмме, юкмы — киногa барганда, кайтканда күрерсез.

Бүлмә эчен шаулатып кызлар көлде. Көлү эченнән берсенен тавышы ишетелде:

— Бар, Фәния! Сөйләшә белә бу егет — бар! Бар! Пәпә түгел!

— Ярар! — диде Тәминдар. — Бер мәсьәләне хәл итик. Кичкә кадәр без юкка чыгып торыйк. Сезне бу егет монда килеп алсынмы, яисә кинога үзегез килерсезме?

Фәния күнелле итеп елмайды:

— Ялгызым гына булсам, юлдан читкә алып китүләре бик мөмкин. Кереп алсын инде. Кинога баргач-баргач, тоташ шартына китереп барыйк. Моннан башлыйк баруны.

— Булды бу, Мансур. Кыз синеке булачак. Ну, асыл булып житешкән бу, әй. Ай-һай! Күз тимәсен!

Кичен кинога барганда да, кайтканда да гәпне Фәния алып барды. Кинодан кайтып житәрәк, Мансур үзенең фажигасен анлады: ул егет буларак та, студент буларак та Фәния белән сөйләшергә сүз таба алмый иде. Кыз бик күп китап укыган. Уфадагы татар, урыс театрларында барлык спектакльләрне караган, бар яктан да яхшы тәрбия, белем алган замана баласы иде ул.

Кайтып життеләр. Тулай торакка кереп китәр алдыннан Фәния, бераз уңайсызланган кебегрәк елмайды да, акрын гына тавыш белән сорады:

— Мансур абый! Сезгә бер соравым бар иде. Мөмкинме бирергә?

— Сорагыз.

— Миңа бүген институтта сезнең турыда бер хәбәр әйттеләр.

Туктады.

— Нәрсә диделәр икән инде институтта минем турыда?

— Сезне бит Советлар Союзы Герое диләр. Дөресме?

Коңгырт күзләрен туп-туры Мансурга текәде.

— Дөресме бу?

Мансур тамагына утыра башлаган төерне йөткергәләп юк итте. Баш какты:

— Дөрес ул, Фәния. Мин чып-чын Герой.

— Советлар Союзы Героемы?

— Советлар Союзы Герое.

— И-и! Нәрсә өчен бирделәр?

— Курск Дугасында Гитлер танкларына каршы сугышкан өчен.

— Сез Курск Дугасында булдыгызмыни?

— Булдым.

— Сезнең Герой булуыгыз минем өчен һич тә көтелмәгән хәл. Мин нәрсә эшләргә тиеш инде хәзер?

— Нәрсә эшләргәме? Минем белән кинога, театрларга, концертларга йөрергә тиешсез. Бик ошыйсыз сез миңа, Фәния.

Кыска гына күңелле итеп көлде:

— Безнең полк командиры әйтмешли, сезнең хәзер бүгенгә должностегыз: сез минем күз төшереп йөргән кызым булырга тиешсез.

Фәния кып-кызыл булды. Һәм хушлашмыйча да торак ишегеннән кереп китте.

Урта мәктәптә алган төпле белеме юк Мансурның. Физика, геометрия, алгебраның ул исемнәрен генә ишетеп белә. Урыс, татар классик һәм бүгенге тере язучыларның берсен дә белми диярлек. Фәния белән кинога барып кайту Герой Мансур башында яңа уйлар уятты. Белем юк. Төс? Ир-егеткә җитәрлек төс-чырай бар. Анысы ярарлык.

Эчтән генә көлеп куйды:

Коңгырт куе чәч дулкынланып, хәтта көдрәләнеп тора. Белгәнрәк егетләр хатын-кыз башта гәүдәгә, биткә-күзгә, чәчкә карый диләр бит. Дөрестер. Фәния белән бер мәртәбә кинога барып кайтуга Мансур бер нәрсәне аңлады: укыган, чибәр кызлар өчен ул чын егет түгел. Ул, инде лекцияләр тынлый башлагач, бер нәрсәне аңлады: белем алу чыннан да энә белән кое казу! Ә аның кулында «белем» дигән сихри көчне казып алу өчен кечкенә энәсе дә юк. Ул бит лекцияләрдә бернәрсә дә аңламый диярлек. Беренчедән, урысча, икенчедән, катлаулы. Әгәр институттан китсә? Берәр җирдә авыл советы рәисе итеп куярлар инде. Ни яза, ни сөйли белми бит. Томана надан! Нәрсә эшләргә?'»

Ике айга якын кино-театрларга, музейларга йөрделәр. Хәтта бер мәртәбә «Уфа» ресторанына да бардылар әле. Икесе дә чибәр, икесе дә матур итеп киенгән иде...

Геройга аена 500 сум стипендия бирәләр. Шуңа 900 сум Герой акчасы өстәлә. Ялгыз башына 1400 сум. Герой гаиләсе булганлыктан, әтисенә ай саен бер центнер бодай бирәләр. Гөлсылу исемле сеңлесе кырык алтынчы елга кадәр колхозда ХТЗда тракторчы булып эшләде. Яшәүләре уртача булып, ачыкмыйлар инде. Әтисе төнен элекләре үзенеке булган ике кибетне саклый һәм шуңа 420 сум акчалата хак түлиләр.

Ресторан Фәниягә бик ошамады. Авылда үскән, чын татар гаиләсендә саф татар кызы итеп тәрбияләнгән Фәния көчкә-көчкә генә ресторан тулы майлы күзле ирләрнең күз карашларына түзеп утырды. Ике сәгать чамасы узгач, Мансурга китәргә тәкъдим итте:

— Әйдә, китик инде, Мансур абый? Бер мәртәбә танцевать итик тә, кузгалыйк. Мин мондагы бик нык тавышлы музыкадан арый башладым...

Мансур кып-кызыл булды:

— Мин бит, Фәния, танцевайт итә белмим.

Фәния бик мөлаем итеп елмайды:

— Бернәрсәсе дә юк аның. Уң кулыгыз белән минем билдән тотасыз, ә сул кул белән тотынышабыз. Музыка уңаена җайлап кына, вак кына, аякларны шудырган кебек иттереп йөрибез. Минем сезнең кулбашыгызга салган кулымны тынлагыз.

— Беткән баш беткән. Әйдә, киттек танцыга. Ярый әле теге Герой медален такмаганмын.

Чыга башладылар. Фәния пышылдады:

— Бу — танго дигән танец. Салмак кына танцы ясарга кирәк.

Мансур баш селкергә дә көч таба алмады. Көч-хәл белән кеше күбрәк урында «танцывайт» иттеләр-таптандылар. Фәния йөртте инде Герой «абзыйны»!

Өч көннән Фәния Дәүләкәндә иде...

Ишектән килеп кергән, йөзе матур булып алсуланган кызын әнисе басып каршылады.

— И-и, бал-ла! Бүген шимбә бит. Бер-бер хәл булдымы әллә? Уку көне түгелмени бүген? Әллә дәрес ташлап кайттыңмы?

— Әй, әнкәй! — диде Фәния. — Нәрсә эшләргә дә белмичә, сина кайттым. Башым әйләнә, бернәрсә дә уйлый белми.

— И, бала-ам! Синең шундый елларың инде хәзер. Башында берәр егет-җилкенчәктер инде.

Кичен әтисе, энесе, сеңлесе йокларга яткач, әнисенә кызы серен чиште:

— Әни! Минем бер таныш егетем бар. Фронтовик, үзе Герой Советского Союза...

Әнисе анламады:

— Кем дис-сен?

— Советлар Союзы Герое дим.

Анасының исе китте:

— И, тере Героймы? Алтын Йолдызы да бармы?

— Әйе. Тере инде, нишләп тере булмасын ди.

— Йә, Ходай! И бала, бала!

— Син тыңла әле, әнкәй! Синнән башка миңа бер кеше дә ярдәм итә алмаячак. Монда синең киңәшең кирәк.

— Сөйлә, кызым! Тыңлыйм.

Фәния сөйләп бирде:

— Төскә-башка чибәр егет үзе. Тарих факультетында укый. Икенче курста. Миякә районыннан. Элек әтисе бик зур сәүдәгәр булган. Кырык дүртенче елда гына «высылкадан» кайтарганнар. Үзеннән кече дүрт сеңлесе бар. Әйбәт кеше ул үзе.Мансур Абдуллин. Тик...

Кыз туктады.

— Син, Фәния кызым, ничек бар, шулай чыгарып сал. Без бит синең белән әнкәле-кызлы утырабыз.

— Аның, әни, бөтенләй диярлек белеме юк. Сөйләвенә караганда, татар мәктәбенең дүртенче сыйныфыннан ташлаган укуын. Герой булганга аны кырык дүртенче елны институтка кертқәннәр. Өйрәтергә, ярдәм итәргә сынар куллы, бик белемле бер капитан егетне беркеткәннәр. Бергә бер бүлмәдә яшиләр, бергә укыйлар, бергә ашыйлар.

— Укуы ничек соң?

— Ничек дип инде? Сынауларда алган билгеләре бар да дүртле икән. Куялар инде — Герой бит.

— Алай икә-ән! Соң? Миннән нәрсә кирәк инде сиңа, кызым?

— Әнкәй! Мин аның наданлыгыннан, тупойлыгыннан шушы бер ел эчендә гарык булдым, анарга әйләнеп тә карыйсым килми. Соңгы мәртәбә авырыйм дип кинога бармаган идем, үзен карый торган госпитальдән хәрби врач алып килгән. Полковник.

— Яралары бармыни?

— Бар. Курск Дугасында сугышкан. Өч пушка белән немецның 18 танкын яндырганнар. Сул кулының ике бармагы кәкре, күкрәгендә, башында корыч кыйпылчыклары бар икән.

— Башы авыртамы соң?

— Зарланганы юк.

— Син киңәшкә кайттыңмы?

— Әйе. Бик тә ябышып бара миңа. Соңгы ике очрашуда өйләнү турында сүз кузгатты. Миңа бит инде егерме җиде яшь тула, ди. Ә мин ана карата суынганнан суына барам.

— Кызым?!

— Әйе, әнкәй.

— Алай-болай диюем... ялгыш эшләп ташламагансыңдыр бит? — Фәния уңайсызланды:

— Юк, әнкәй. Моннан киткәндәге кебек сафмын.

— Бик зур уй салдың бит әле син, бала, минем башка... — Күңелле итеп көлде:

— Әтиең егетнең елгыры иде. Чукынчык нәстә, миңа бик ныклап

тотына башлагач, әбиен белән мин дә кинәштем. Шулай-шулай, әнкәй, ныклап бәйләнеп, сәрмәнә башлады, дим. Нишләргә, дим. Көлде дә, мәрхүмә, кыска гына итеп әйтте: «Син аны, кызым, азлап-азлап кына түш тирәләрендә сәрмәштер! Сәрмәштер! Өйләнүгә барып житәрлек итеп! Читкә китмәслек итеп сәрмәнсен! Мин атаңны шулайлар итеп өйләндердем. Түш тирәләрендә түзә алмаслык булганчы сәрмәнде-сәрмәнде дә... аталары яучы жибәрделәр.

Син, кызым, бераз гына түгел, кыз бала буларак нык ялгышкансың.

— Ничек инде, әнкәй, ялгышканмын ди? Юк, әнкәй!!!

— Ялгышкансың! Менә миннән ишет ялгышыңны. Син институт шаулатып елдан артык Герой белән кино-театрларда, танцыларда, төрле концертларда култыклашып йөргәнсең. Синнән көнләшкән кызларның исәбе-хисабы юктыр инде институтта. Герой бит! Үзе төскә дә чибәр генә дисең.

— Әйе.

— Йә, ул Геройны ташладың да ди. Аны ташлау гына да айдан артык барачак әле. Вә һәм дә...

Әнисе күңелсез генә елмайды:

— Синең Герой белән бер ел бергә үткәргән вакытыңнан, бергә йөргән кино-театрларыгыздан көнләшеп иза чиккән кызларның сез аерылышканнан туган шатлыклары иксез-чиксез булачак, һәм алар бөтен институтка, бөтен Уфага, хәтта Башкортстанга гайбәт таратачаклар: «Теге борынын күтәреп йөргән Фанияне Герой Мансур Абдуллин ташлаган бит!» — диеп.

— Әнкә-әй! Бу бит дөрес түгел.

— Дөрес түгел! Шуңа күрә гайбәт диләр аны. Гайбә-әт!!! Һәм кешеләргә дөреслеккә караганда гайбәт ныграк кирәк. Холыклары шундый кешеләрнең. Көнче холык. Син Герой белән араңны үзең өзсәң дә, сиңа, кызым, Уфа пединститутыннан көченеп китәргә туры киләчәк. Казан институтына күчсәң, ул гайбәт анда тагын да ныграк, пычраграк булып барып житәчәк. Ә инде зур түземлек белән Уфада калсаң, синең яныңа бер генә егет тә килмәячәк һәм сиңа карамаячак. Герой ташлаган кыз! Ничек итеп ташлагандыр — чурт белсен!

Фәнияне шом били башлады.

— Әнкәй! Син бик тә куркыныч әйберләр сөйлисең бит.

— И, бала, бала! Уйламыйча эшләгәннән күпме кызның язмышы фажигале бүген.

— Әнкәй! Мин нишлим инде хәзер?

— Син, кызым, ул Герой егетенне алып кайт әле монда. Киләсе атнага, яисә бер атна аша. Атаң белән мин дә күз салыйк аңарга. Егермең тулды — кияүгә бирергә була сине. Уйлый белергә башында миең сыек, чөнки нужа күрмичә үстең. Азрак иркәрәксең шул... Алып кайт! Карарбыз, кунак итәрбез!

Ике атна үтүгә кайттылар Фәния белән Герой. Жомга көнне кичләтеп кайтканнар иде, якшәмбе көнне өйләдән соң киттеләр...

Фәниянең әти белән әнисенә ошады татар егете Мансур Абдуллин. Икенче көнне әтисе, кичен йокларга ятканда, хатыны сорамаса да, үз уен әйтте:

— Бу егетне мин дә күрсен дип алып кайткандыр инде кызың. Уку бик тәтемәгән моңа, илләмә нужаны күп күргән, үлем белән бик нык алышкан ышанычлы егет бу. Кызыбыз хур булмас, чыксын шушы егеткә!

Шимбә кич Мансур мунчага киткәч, әнисе дә үз сүзен әйтте:

— Фәния, кызым! Бик әйбәт, сабыр холыклы кеше бу егет. Чык шушынарга. Белеме юк икән, жайлап аз-мазга өйрәнер, кеше арасында

шомарыр. Үзе дә укыта башлар. Китап укый-укый булыр аз-маз булса да белем дигән нәстә. Аннан нәстә ул белем? Ана Галләм абзаң йөри инде райком партиядә инструктор отдел пропаганда булып. «Ленин» дип, аның «Что делать?» дигән труды дип ала да – бөтен белгәне шул. Районда иң белемле кешеләрдән санала инде менә. Нәстә белә ул? Әлепне таяк дип тә белми.

Чык шул егеткә. Үзең әйбәт укыйсың, белемең шәп — гаиләдә һәрчак синеке өстен булачак. Холкың белән һәрчак беренче булырга яратасың. Гаиләдә дә һәрчак синеңчә булачак! Шул сиңа! Киреләнмә! Бу Геройны ташласаң, ир таба алмыйча изаланачаксың. Тормышта күп вакытта без хатын-кыз дигәнчә булмый бит. Шуны гел исеңдә тот!

Бу серен бер очрашканда Фәния апа миңа үзе сөйләгән иде.

***

Югары белемле, берсе утыз, икенчесе егерме өч яшьлек ике чибәр, матур, заманча пөхтә, модный киенгән ир белән хатын 1949 елда Эстәрлебашка эшкә килделәр. Фәния апа география укыта. Үзе дә, сөйләве дә матур, җыйнак. Дәресләре бик тә күнелле үтә.

Мин, Зәки Зәйнуллин, Герой абыйдан тарих фәненнән бары тик дүрт кенә дәрес алдым. Ул чакта мин аның урта мәктәптә тулып житмәгән дүрт кенә сыйныф укыганын белми идем. Уфа пединститутында алган дипломы буенча белеме югары бит абыйның! Безгә, ул елларда чабата кигән, арыш умачы белән бәрәңгегә дә туймаган ач татар балаларына, биек үкчәле төрле төстәге туфлиләр киеп, авыл урамнарыннан «фырт» кына атлап үтеп киткән нечкә билле, әллә нинди әйберләрдән теккән костюм-күлмәкләр кигән Фәния апа изге бер җан иясе, әүлия булып тоела иде.

Ә Герой Мансур абый Абдуллин?! Куе яшел төстәге әйбердән теккән гимнастерка, галифе чалбар, ялтырап торган кара хром итек, дулкынланып торган, артка таралган куе чәч. Күкрәгенең сул ягында Герой Алтын Йолдызы. Йөзе көләч, нурланып тора һәм сөйли башлар алдыннан Мансур абый ап-ак тешләрен күрсәтеп башта елмая. Шуннан соң гына кешегә, бераз мишәр акценты белән, дәшә. Кечеләргә:

— Туганым!

— Иркәм!

— Энем!

— Сеңелкәш! – ди.

Үзеннән олыларга:

— Бабай!

— Абзый!

— Апа!

— Әбекәй!

Герой! Югары белемле! Мәктәп директоры!

Тик!..

Абый дәрескә уң кулына 10нчы сыйныф өчен тарих китабын тотып керә. Урындыкка утыра да, дәрес башлый...

Беренче ике дәрестә сорап тормады — уку елының башы гына бит. Утырган жиреннән тарих китабын ачты да, безгә мөрәҗәгать итә:

— Менә, балалар, тыңлагыз әле, тарих китабында ничек язганнар...

Кабаланмыйча, җайлап кына ике битне укып чыкты. Бу инде безгә тиешле тарих дәресе иде. Китапны ябып урыныннан торды.

— Мине, балалар, директор эшләре көтә. Сез тыныч кына, шауламыйча гына утырыгыз.

Укытучы абый чыгып китте...

Беренче дәрестер. Директор эше бардыр. Вәләкин...

Икенче дәрес тә шулай булды. Абый, бер бит тарихны китаптан укып чыкты да, урыныннан торды:

— Сез, балалар, сораулар биреп тормагыз инде миңа. Киләсе дәрестә бирерсез.

Чыгып китте, тарих китабын тотып. Ул чыгып киткәч, минем уң якта утырган Әнвәр Хәсәновка төртәм, пышылдыйм:

— Әнвәр! Мин хәзер тарих китабын күтәреп коридорга чыгам. Мин керергә дип ишек ачканда син тавыш бир: «Басыгыз! Абый кереп килә», — дип.

— Нәстә уйлап чыгардың инде тагын?

— Мин сезнең белән тарих дәресе үткәрәм хәзер.

Азрак гөрелдек чыгарып сөйләшеп утырган сыйныф минем чыгып киткәнгә әһәмият тә итмәде. Керергә ишек ачтым, әле үзем күренмим. Әнвәр баскан да сөрән сала:

— Басыгыз! Абый кереп килә.

Мин оек-чабатадан, ямаулы чалбар-күлмәктән. Геройның атлавына охшатып атлап, кулларны канат кебек җәя биреп, миңа исләре китеп баскан классташларга сул кулны селкеп, абыйча дәшәм:

— Утырыгыз, кадерле укучылар!

Күләргә яраткан Әнвәр пырхылдый, башкалар елмаялар. Бар да утыра, минем керүне матур кабул итәләр. Өстәл артындагы урындыкка утырам да, мишәрчәләп дәвам итәм:

— Узган дәрестә без, балалар, Рәсәйнең бөек патшасы Пютыр Пирвый турында китаптан укып үткән идек инде. Бүген без сезнең белән Палтава дигән сугыш турында белем алыйк. Ул турыда китапта менә нәрсә язганнар...

Ике көн узгач, тарих дәресен Мансур абый шулай ук китаптан укып үткәрде дә, безгә эндәште:

— Минем карыйсы документлар бар. Сез, укучылар, тавышсыз гына үз эшегез белән утырыгыз, миңа комачауламагыз...

Дүртенче дәресне дә Мансур абый үткәрде. Һәм... мине такта янына чыгарды:

— Сине, туган, бик актив тарих өйрәнә икән дигән хәбәр килеп җитте миңа. Син даже мин булып дәрес тә үткәрәсең икән.

Мин авыз ерам:

— Каян белдегез, абый?

— Белдем инде. Саескан китерде койрыгы очына элеп!

Алдында ачык яткан дәфтәргә карап алды:

— Яле, сөйлә миңа Пютыр Пирвыйның швед короле Карлга каршы Нарва янында һәм Палтава янында сугышканын...

Мин сөйләп бетергәч, сорый:

— Нигә мишәрчә, миңа ошатып сөйләмисең.

— Мин бит сез булып түгел, үзем булып сөйләдем.

— Шулаймыни? Утыр, зур өчле сиңа.

— Абый! Ул бит бишкә сөйләде, ә сез өчле генә куясыз.

Абый күңелле итеп елмая:

— И-и, балалар! Бу, Зәйнуллин, мин юкта мин булып сезне мишәр акценты белән укытып болашкан. Мин шуның өчен аңардан үч алырга тиешме? Тиеш! Менә алдым, ике баллга ким куйдым. Инде булды — яшибез.

Киләсе тарих дәресенә безне бишенче сыйныфтан ук тарих фәненнән укыткан Сания апа Кәримова керде. Без аның язучы, шагыйрь Фатих

Кәримнен сенлесе икәнен сугыш беткәч кенә белдек. Укучылар арасында исеме Дөя Сания. Чөнки ул башын дөя кебегрәк итеп, азрак артка чөеп тота. Сания апа кергәч өстәл артына утыра һәм дәрес беткәнче тормый. Сөйләгәндә хәтта картадан күрсәтәсе булса да, тормыйча гына, указка-күрсәткеч белән кирәкле җиргә картага күз дә салмыйча төртә.

— Менә сезгә, балалар, атаклы Казан каласы...

Керде, утырды. Нилектәндер күзе белән мине эзләп тапты. Чем-кара бу күзләр тулы ирония иде.

— Бүгеннән тарих дәресен, балалар, сезгә мин укыта башлыйм — Сания Кәримова. Директор Мансур Идиәтович мина әйтә:

— Сания апа! Сез унынчы сыйныфтагы балаларны бишенчедән үк укыткансыз. Унынчыда да укытып чыгарылыш ясагыз инде үзегез, ди. Мин риза булдым. Тем более, анда бик тә тарих яратучы Зәки Зәйнуллин дигән укучым бар минем, дидем... Зәки! Дөрес әйткәнменме мин?

— Нәкъ өстенә баскансыз, апа! Дөрес!

— Өстенә басарга мин ат, син тавыкмыни инде?

Сыйныф көлә. Мин түзеп, җавапсыз калам.

— Ярар. Башладык дәресне. Кем тели Полтава сугышы турында сөйләргә?

Күз йөртеп ала да:

— Син чык инде, Равил Байморатов. Синнән башлыйк! Чык! — ди.

Равил такта янына чыга.

— Полтава сугышы Ворскла елгасы ярларына утырган Полтава каласы янында 1709 елда булган...

Сания апа белән аның ире, 6-7 сыйныфларда физика укытучы Фатыйх абый Каюмов минем яраткан укытучыларым иде. Пенсиягә чыккач, алар Уфадан йорт сатып алып, шунда күченеп киттеләр. 1990 елның февраль аенда мин аларны шул йортларында эзләп таптым. Аларча, мин инде иксез-чиксез унышларга ирешеп, «зур кеше» булганмын, полковник, олы галим һәм татар язучысы, прозаик. Мин барып кергәч, шатлыкларының иге-чиге булмады. Бер шампанский, бер коньяк эчеп, берничә сәгать сөйләшеп утырдык. Сания апа болай дип сөйләде ул чактагы хәлләрне:

— Мансур Идиәтович сезне унынчы сыйныфта укыта башлады. Берничә дәрес үткәрү белән күрәм: Геройның кәефе бозыла бит. Кеше юкта сорыйм:

— Сезне, Мансур туган, нәрсәдер борчый бугай? Сөйләгез мина борчулы уйларыгызны. Мин бераз сизенәм. Укучы Зәки Зәйнуллинмы?

— Әйе, Сания апа! Мине падражайт итеп, унынчы сыйныфта мин булып дәрес үткәргән. Һәм сыйныф аны паддиржайт иткән, — диде директор.

— Мин аны бишенче сыйныфтан бирле укыттым. Ул биргән сорауларның яртысыннан күбесенә хәтта мин дә җавап бирә алмыйм. Мин анардан бу сорауның эчтәлеге программадан тыш дип кенә котыла идем. Ә бит мин утыз дүртенче елдан бирле укытам. Сезгә ул Зәйнуллиннан котылырга кирәк, Мансур туган...

— Ул баланы мәктәптән исключайть итәргә һич тә ярамый. Бик сәләтле бала дисез бит үзегез дә.

— Әйдә, без болай итик. Сез мина унынчы сыйныфны бирегез укытырга, ә үзегезгә мин укыткан бишенчене алыгыз. Зәйнуллин белән сезнен проблемалар көннән-көн артачак кына. Сораулар биреп, сезне тупикка куып кертәчәк ул.

— Сыйныфларны алышыйк дисез инде?

— Әйе. Нагрузка тигез — атнасына бишәр сәгать. Финанс ягыннан беребез дә оттырмый. Ә юк-бар гайбәткә җавабыгыз әзер булсын: «Сания

апа үтенде, шул сыйныфны укытып чыгарыйм инде!» — дип.

— Килештек, Сания апа. Бу изгелегегезне мин беркайчан да онытмам. Рәхмәт сезгә!

— Рәхим итегез! Үзегезгә рәхмәт!

Шампанский эчә, елмая Сания апа:

— Рәхмәт, Зәки, сиңа! Иң яраткан укучым, синең абыең Гариф Зәйнуллинны күргәндәй булдым. Елмаюың тач Гарифныкы! Аның кебек син дә күзгә карап елмаясың икән. Элекке елларда шуны чамалый алмаганмын. Зу-ур рәхмәт сиңа безне онытмыйча килгәнең өчен. Күңелең киң синең!

— Ярар инде, Сания апа! Бик мактап та җибәрмәгез. Китәрмен ирәеп аннан соң!..

***

1976 елда Ригага килеп бездә бер атна торып киткәч, Герой Мансур абый белән минем дуслык үсте, ныгыды, төпле булды. Иртәгә кайтып китәсе көнне Мансур абый миңа болайди:

— Мин, туган, сиңа бер сорау белән килдем бит. Аны миңа телефоннан Фәния апаң әйтте. Менә мин Министр внутренних дел СССРда приемда булдым. Улым Әсгатьне самосвал белән таптатып үтергән шоферны табуда чара күрүен үтендем. Ачык кына бер вәгъдә дә бирмәде. «Буран булган, тәгәрмәч эзе дә юк, не за что хвататься при следствии!» — ди миңа. Безгә хәзер Фәния апаң белән нәрсә эшләргә инде бу мәсьәлә турында. Улым Әсгать бик шәп иде.

Мин байтак кына дәшмичә утырдым. Абый да аз-маз сыра капкалап сүзсез генә миннән җавап көтә. Ә мин икеләнәм: «Гомер буе, кырык дүртенче елдан бирле яхшы, тук, киенеп яшәгән бу Герой мин әйткәнне аңлармы, юкмы? Аңламаса, безнең дуслык бетәчәк». Икеләнгәннән соң, Мансур абый белән Фәния апаны кызгану өстенлек ала һәм мин тәвәккәллим:

— Мансур абый! Брежнев җитәкчелек иткән хакимият өчен безнең илдә бер генә җинаять тә, бер генә кеше үтерү дә, бер генә тәртип бозу да кирәкми. Бар да ал да гөл булырга тиеш. Әсгатьнең һәлак булуы министр өчен вак эш ул, ул җинаятьне ачу аңа нәстәгә хаҗәт? Безнең ил, СССР бик нык таркала. Озакламый Брежнев төркеме зур бер авантюра китереп чыгарып, СССР халкын шуңа тыгачак. Болар ил белән җитәкчелек итә белмиләр һәм боларга бәләкәйме, зурмы берәр сугыш кебек бәрелеш кирәк. Халыкка: «Әнә СССР дошманы! Юк итик аны!» — диячәкләр. Һәм халык шатланып риза булачак: «СССР дошманы! Урра, алга!»

Минем сезгә киңәш! Туктагыз хакимияттә утыручылар кабинетларына йөрүдән. Әсгать үлгән һәм аның үлемен тикшерү бүген хакимияттәгеләрнең берсенә дә кирәкми. Аларның барлык уйлары ничек кенә булса да үзләре утырган урындыкларны саклап калу. Курск Дугасы батыры сез! Дөрес! Ләкин алар өчен сезнең батырлыгыгыз шул Курск Дугасының кара туфрагында калган. Сез аларга, үзегезнең Алтын Йолдызыгыз белән, бүген артык йөк. Сезне карарга, сезгә, Герой буларак, юк-юк та ярдәм итәргә кирәк. Ә ул ярдәмгә алар үз кесәләреннән чыгарып үз акчаларын биргән кебек итеп карыйлар...

Абый дәшми генә тынлый. Мин рюмкаларга коньяк салам.

— Әйдә, абый! Тотыгыз! Әсгать рухына эчик әле. Урыны оҗмахта булсын!

Рюмка белән абыйга үреләм һәм... тетрәнеп китәм. Абыйның ике күзеннән дә туктаусыз, берсе артыннан берсе, эре-эре яшь тамчылары чыгып, бите буйлап тәгәри, иягеннән күлмәк якасына тама...

Мин төкәштерми генә рюмкадагы коньяк беткәнче эчәм. Абыйга

карамаска тырышып, чәнечке белән эләктереп алып нәрсәдер чәйним. Абый тулы рюмка тоткан килеш, бер ноктага карап, бик озак утырды. Байтак вакыт узгач, яшьләре агудан тукталды. Рюмкасын эчеп куйды да, бер кисәк ит алып, шуны чәйни башлады. Телгә килде:

— Безнең хакимияткә кирәгебез беткәнне бик дөрес атмичайт иттең син, Зәки. Мин аның шулай икәнен житмеш икенче елда ук сизгән идем, тик аның дөреслеген үземә дә признавайть итәсем килмәде ул чакта.

Уфада Советлар Союзы Герое летчик Соколов яши. Бу урыс егете бүген дә исән. Шул геройның өч баласы бар, үзенең әнисе, хатынының әнисе. Жиде кеше ике бүлмәле фатирда, «хрущевка»да яшиләр. Сугыш беткәнгә егерме жиденче ел бара. Ә бу Герой Соколов икенче группа инвалид. Берлинны алганда самолеты эчендә янган ул. Язып та карый, йөреп тә карый — юк, бирмиләр моңа фатир. Ә бу Геройның именной пистолеты бар икән. Һава армиясе белән командалык иткән Хрюкин атлы генерал бүләк иткән. Мәскәүләргә барып фатир сорап кайткан бу. Кайткан, көтә биргәннәрен. Кайткач, Башкортстан обкомына чакыртып моның белән «воспитательное» собеседование как с коммунистом» уздырганнар. Әйткәннәр моңа: «Бирербез фатир, йөрүеннән тукта! Әгәр туктамасаң, чарасын күрербез, партбилетыңны да, Алтын Йолдызыңны да алырбыз. Иң яхшысы — тынычлан! Тукта таләп итүеннән! Башкача Мәскәүгә барма!»

Чыннан да, бик шәп летчик-истребитель икән бу Соколов. Тәвәккәл зат. Обкомнан өенә кайткан. Йөргән берничә көн уйланып. Бер көнне дустын чакырган. Өй эчендәге юк-бар мебелен йөк машинасына төягәннәр дә, киткәннәр төшеп Уфаның тимер юл вокзалына. Пассажирлар залының бер почмагына шкаф-диван, шифоньерларын кертеп тезгәннәр дә, шул почмакны чаршау белән уратып, аерып алганнар...

Вокзалда урнашкач, бер дусты аркылы обкомга записка язган: «Шулай-шулай. Мин, Советлар Союзы Герое өлкән лейтенант Соколов, гаиләм белән Уфа тимер юл вокзалында яши башладым. Мәскәүдән корреспондентлар чакырдым. Сәлам белән, Соколов».

Обкомнан килеп житкәннәр милиция ияртеп. Милиция моны вокзалдан төяп өенә алып китәргә боерык алган. Милиция моның мебеленә тотынырга исәпләп якынлаша башлаган. Соколов теге бүләк именной пистолеттан ике мәртәбә түшәмгә каратып аткан да, өченче мәртәбә дүрт милиционерның баш очына атып жибәргән. Берсенең башындагы фуражкасы идәнгә очып төшкән...

Ике көн яшәгән тимер юл вокзалында Советлар Союзы Герое Соколов. Милиционерлар боерык алган: кире кайтарырга! Ә Соколов милиционерларны, атам дип куркытып, вокзалдан урамга куып чыгарган. Милиция вокзал эченә пассажирларны кертми икән — күрмәсеннәр, белмәсеннәр Герой Соколовның вокзалда гаиләсе белән яшәгәнен. Ә вокзал алдында Соколовның 3-4 дусты агитация алып барып халыкка аңлата: Герой! Фатиры юк!

Икенче тәүлек киткәндә, вокзалга обкомның икенче секретаре килгән. Чыбылдык артында Соколов өстәл куйган. Теге секретарь ике тән сакчысы белән килгән. Соколов аларны кертмәгән. Обком секретарен керткән чаршау артына. Соколов үзе өстәл артында урындыкка утырган, икенче секретарьга утырырга урындык юк. Соколов кырыенда уенчык автомат тоткан дүрт яшьлек малае басып тора икән. Әтисен саклый! Соколов нәрсәдер сөйләргә болашкан икенче секретарьның авызын да ачтырмаган:

— Сезгә, обкомга, уйларга бер тәүлек вакыт бирәм. Үзең яшәгән фатирны бушатып, минем гаиләгә бирәсең. Үзең башка урынга күчен. Все! Пошел отсюда вон!

Обком биргән Соколовка ул сораган фатирны. «Икенчене» күчергәннәр, бер атнада ремонтлаганнар. Үтенеп караганнар, фатирына кайт, ремонт тәмамланганны шунда күр, дип. Соколов әйткән: «Мин ремонт ясаганыгызны вокзалда көтәм. Әгәр үземнең иске фатирга кайтсам, сез мине алдаячаксыз.»

Ремонт ясап, жиде бүлмәле фатир бирделәр Соколовка. Мәскәүдән: «Соколовны яңа фатирга күчерер алдыннан ремонт ясап, яңа мебель алып, фатирына кертегез!» — дип обкомга шалтыратканнар.

Күчендe Соколов яңа фатирга.

Соколов белән инцидент барган чакта Башкортстан җирендә 22 Советлар Союзы Герое исән иде әле. Обкомның беренче секретаре Шакиров шул Геройларны «сөйләшергә» чакырган. Обкомның актовый залында җыйдылар безне. Тагын 12 Дан орденының тулы кавалерын да чакырганнар. Җыелдык, утырабыз. Шакиров килеп керде. Берничә кеше торып баса башлаган иде, алда утырган Соколовның көчле тавышы ишетелде:

— Всем сидеть! Не вставать!

Басканнар да кире утырдылар;

Шакиров сәхнәгә узды. Өстәл артында берүзе. Торды, сөйли башлады. Урысча.

— Дорогие товарищи, Герои Советского Союза и Полные кавалеры Ордена Славы! Решили Вас всех собрать и поговорить с вами по душам. На днях произошел инцидент с бывшим старшим лейтенантом Соколовым. Он соизволил себе...

Шулчак беренче рәттә утырган Соколов торып басты. Шакировны бүлеп, каты тавыш белән әйтте:

— Слушай, ты, Шакиров! Не надо давать оценку моему действию. У меня пистолет именной с собой. В кармане брюк. Ты довел своей тупостью меня до крайности. Пристрелю как собаку, сейчас же, здесь же. Если собрал нас мораль нам читать, мы уйдем отсюда. Через пару часов тебя снимут с должности. Лучше заткнись!

Актлар залы тып-тын. Шакиров трибунадан төште, президиум өстәле кырыена килеп басты. Үзенең бите кып-кызыл. Акрын гына тавыш белән сөйли башлады:

— Аудитория, күрәсең, минем белән сөйләшергә бик теләмидер. Шунлыктан мин хәзер китәм. Өстәл артына мин делопроизводительне утыртып калдырам. Сез Геройларга, Кавалерларга нәрсә кирәк, әйтегез, ул язып алыр. Дүрт-биш ай эчендә сезнең үтенечләрне исәпкә алып, без аларны тормышка ашырырбыз...

Хушлашып чыгып китте Шакиров. Уртак тел таба алмады безнең белән.

Мансур абый үзе сөйли, үзе елмая:

— Шакиров чыгып китте. Минем башта бер генә уй: «Нәрсә сорарга?» Чөнки мин шушы соңгы ун елда обкомнан соранып улым Марат белән кызым Нәфисәгә «Жигули» машинасы, яхшы фатирлар алган идем инде. Үземә Дим елгасы буенда бик шәп дача төзеп бирделәр. Кызыл кирпечтән, ике катлы. «Нәрсә сорарга?» Теге нәфсе дигән шайтан утыра бит һәркемнең эчендә. Тәвәккәлләдем. Шау-шу бара. Соколов Шакировның котын алды — Мәскәүдән нык курка. Нәрсә сорасам да, бирер болар. Сорыйм:

— Миңа дача салып бирегез. Дачам юк минем.

Дөрес исәпләп эш иткәнмен. Бармы дачам, юкмы дачам — тикшереп тә тормадылар. Ярты ел дигәндә миңа дача ачкычын тоттырдылар — Мансур абый матур итеп елмая:

— Әзер дачаны Фәния апаңның бертуган сеңлесе Нажиягә бүләк иттем.

Бик шәп балдыз бит ул минем — син беләсен аны. Эстәрледә укытканда Нажия, кайниш Фоат, минем сенелкәш Кәримә сигезенчедән алып унны тәмамлаганчы бездә торып укыдылар бит. Фәния апаң белән икәү нык ярдәм иттек без эти-әниләргә. Өчесен дә укытып чыгарып, Уфа институтына укырга керттек...

Мансур абый истәлекләргә чумып, үзенен Мәскәүдә кунакта булганын да сөйли:

— Минем батарея командиры лейтенант Кузьмин да Герой алды бит инде. Исән калган өчәүнең берсе булган рядовой Самойлов та Герой. Кузьмин Жинү көненә кадәр сугышты. Самойлов та шулай ук. Кузьмин урта белемле. Сугышны тәмамлагач та моны Хәрби академиягә укырга жибәргәннәр. Герой бу — күкрәк тулы орден. Полковникка кадәр үстереп, Кузьминны Генштабка эшкә күчергәннәр. Бу инде Фрунзе исемендәге академияга өстәп Генеральный штаб академиясен дә тәмамлаган. Генштабта генерал була торган урында эшли икән. Зазнаватся итмәде ул. Безне биш елга бер мәртәбә кунакка чакыра башлады. Самойлов белән мона беренче мәртәбә кунакка бардык. Дүрт бүлмәле фатирда яши. Ике улы да хәрби икән. Берсе старший лейтенант, икенчесе академиядә укый икән.

Өч кич кундык. Барган көнне кабинетына алып керде Кузьмин безне. Диварда «Боевой путь второй батареи третьего дивизиона 182-го артиллерийского полка» дигән карта эленеп тора. Безнен икебезгә күрсәтеп мактана Кузьмин:

— Күрәсезме безнең узган сугыш юлларны. Безнең батарея беркайчан да немецлардан качмады, чигенмәде. Без һәрвакыт алга бардык.

Мин дә, Самойлов та дәшмибез. Тик минем күз карашыннан, йөздән нәрсәдер сизенде бит безнен командир. Миннән сорый:

— Син, Мансур, бу картада төшерелгәннен кайсыдыр жире белән риза түгелсең бугай?

— Николай Васильевич! — дим мона. — Без бит язын Синельниководан алып Курск Дугасына хәтлек «пешодрапом» отступали. Снәрәтләр бетте, пушкалар ватылды. Золотоножка исемле авылда, таң атып килгәндә авылга немец танклары белән пехота килеп керде. Ак кальсоннан тәрәзәдән чыгып качтык. Икебез дә яланаяк, итек, гимнастерка-чалбарлар кулда. Киенеп торырга вакыт юк — капкадан немец автоматчылары кереп килә...

Самойлов исе китеп тынлый. Ул безнең батареяга сонрак, Курск Дугасына пополнение белән килде. Минем сөйләгәнгә Кузьминнын хатыны Мария Акимовнаның китте авызы ерылып.

— И-и! Коленькам мине-ем! Син дә немецтан качкансын икән. Мин бит бу турыда белми идем...

Полковник кызарып, бүртенеп чыкты. Кулындагы тулы рюмкасын кире өстәлгә куйды да, мина карап ачулы тавыш белән әйтә:

— Иртәгә иртән монда исең дә булмасын. Вокзалга тай и кайтып кит Уфаңа. Башкача мина килеп йөрмә.

Мин торып бастым да тост әйтәм:

— Шул чигенгән чакта һәлак булган безнең полкташлар истәлегенә бу тост.

Мария Акимовна белән Самойлов та торып бастылар. Йорт хужасы башын күтәрми генә басты. Эчте рюмканы сүзсез генә. Утырды. Мин утырмадым, өстәдем:

— Сезнең капризга карап мин иртәгә бернинди вокзалга да, Уфага да китмим. Без чигенгән чакта һәлак булган егетләрне ин беренче итеп искә алырга тиеш. Һәм һәр очрашуда. Китмим мин, кусаң да китмим.

Башын күтәрде хужа. Туп-туры мина карады:

— Безнең армиядәге замполитлар йогынтысы белән мин үземнең чигенгәнне онытырга тырышам, ахрысы. Дөрес, Мансур! Чигенгәндә кырылган халыкны без, фронтовиклар, искә алмасак, кем алсын инде. Ул бичараларның үле гәүдәләрен күпме ташлап китәргә туры килде бит. Тирәякны тутырып аунап ятып калдылар бит алар...

Торды, рюмкаларга салды да күтәрде:

— Тагын бер күтәрик әле рюмкаларны. Искә алыйк полкташ сугышчыларны. Һәлак булганнарны...

Икенче көнне иртән кабинетына тагын алып керде безне командир. Төнлә белән йокламыйча безнең артиллерия батареясының чигенгән юлын күрсәтеп, яңа карта төшергән. Чигенгән юлларны кара тушь белән, алга барган юлларны яшел тушь белән сызган.

— Менә, Мансур! Син кичә әйткәнне тормышка ашырып, яңа карта ясадым. Басыгыз шул картаның ике ягына — фотога төшерим әле сезнең икегезне дә...

***

Мансур абый белән сөйләшеп туеп булмый иде. Бер тапкыр сорыйм аңардан:

— Мансур абый, сез берәрсеннән куркасызмы?

Җинел генә итеп көлде, мәрхүм. Мишәрчә акцент белән сузыбрак җавап бирә:

— Һи-и, туг-га-ан! Кемнән куркыйм ди мин? Юк-ук андый кеше! Курыкмыйм мин берәүдән дә...

Туктый мактануыннан. Бераз дәшмичә үзенең фикерләрен барлый, шуннан таба курыккан кешесен:

— Бар андый, хәтта мин дә курка торган кеше, туган. — Миңа кызык, сорыйм:

— Кем инде ул? Юктыр, абый, андый кеше!

— Бар шул, туган, бар!

Сүзләре тулы шатлык янгыраган кебек моның.

— Ышанасы килми! Юктыр, юктыр андый кеше!

Миңа таба өстәл аша иелә. Кухня ягына тиз генә карап ала да, пышылдауга күчә:

— Фәния апаннан куркам мин, туган. Би-ик нык куркам.

— И-и, Мансу-ур абый! Фәния апа бит ул киң күңелле, бөтен кешегә ярдәмчел. Сезне бит ул үлепләр ярата.

Абыйның йөзе яктыра, нурлана, елмая:

— Шулай дисеңме, туган? Үлепләр ярата, дисеңме?

— Әйе. Нигә куркыргадыр аңардан? Аңламыйм мин.

— Курыкмас җирдән куркам шул менә, туган. Бик тә чибәр бит үзе. Илләмә дә акыл дигәнең — иге-чиге юк. Бик тә акыллы бит Фәния апаң. Аннан соң бик тә белемле дә бит. Ыспур чыкса, мине акылы белән, белеме белән китереп кыса — унга да, сулга да хут бетә дә куя. Хатының үзеңнән акыллы, белемле булса, яшәү һәрчак уйланып уза. Ну, илләмә дә җан тыныч инде. Күбрәк вакыт юк-барны уйламыйча тәк кенә йөрисең: «Фәния бар. Ул берәр нәрсә уйлап, хутын табар әле бу вапрусның!» — дип йөри бирәсең. Таба да ул.

Минем Уфада яшәгән апам сөйләгәннән (ул мәктәп директоры иде. Институтта Фәния ападан бер курска гына соң укыган):

— Фәнияне Уфаның Орджоникидзе районына район башлыгы урынбасары итеп куйдылар. Җыйнаган бу мәктәп директорларын нindидер күрсәтмәләр бирергә. Абдуллин абый да бар ул җыелышта,

беренче башкорт балалары интернат директоры иде ул. Фәния сәхнәдән сөйли, күрсәтмәләр бирә, без тынлыйбыз, истә калсын дип язгалап та утырабыз. Мансур абыйга зампред Фәния Абдуллинанын сөйләгәннәре ошамый иде. ахрысы. Утырган урыныннан аваз салып, Фәнияне бүлдереп туктатты бит сөйләвеннән. Ә Фәния үзен тота белә. Елмая Мансур Абдуллиннын үзен бүлдергәненә. Әйтеп карады ике мәртәбә: «Иптәш Абдуллин! Анламаган жирегез булса, бу совещание беткәч, калыгыз. Сөйләшербез, мин сезгә анлатырмын». Юк бит, Мансур абый Фәнияне өченче кат бүлдерде. Фәния залны кабаланмый гына карап чыкты, кулындагы язулы кәгазьләрен трибунага куйды да, залда басып торган Геройга ирония тулы күзләре белән карады да, әйтә татарчалап:

— Кич булгач, ашарга кайткан хайван кебек син дә өйгә кайтасын бит инде барыбер. Шунда мин синен изменне измэсэмме?

Залда утырганнарнын яртысыннан күбесе татар-башкорт иде — зал көлүдән шартлады. Мансур абый акрын гына утырды урынына, башын бер генә чайкап алды да, тынды. Теге кинәшмә бетмичә ник бер сүз әйтсен, ник бер кузгалсын. Кичен эләккәндер инде дип уйлыйм..

1997 елда мина Уфада булырга туры килде. Телефоннан шалтыратам абыйларнын фатирларына. Трубканы Фәния апа ала. Язучы буларак таныла башлаган күнелле еллар бу.

— Фәния апа! Мин Уфада. Зәки Зәйнуллин бу. Бик күрәсе килә сезне. Рөхсәт итсәгез, керер идем мин сезгә.

— Хәзер үк кил. Көтәбез.

Күчтәнәчләрне күп итеп алыш, киттем абыйларга. Кызы Нәфисә шул ук подъездда, аерым фатирда яши икән. Ире Саша исемле чибәр генә урыс егете.Мин барып житкәндә ул анда иде. Уллары Марат та әтиләрендә. Өстәлләренә коньяк, аракы, вино куелган. Ашау татарча мул, пары чыгып торган пешкән ит байтак иде.

Фәния апа элеккечә яшь, чибәр, көләч йөзле, матур. Мансур абый бик нык бирешкән. Ана 78 тулып узган. Чәче тоташ агарган, көләч йөзен жыерчыклар баскан. Өстәл янына утырыр алдыннан үз хәлен әйтеп алды:

— Бирешәм, туган! Нык итеп. Башта аскулкы бар. Шул жәфалый. Аннан йөрәктә аритмия. Дөрес итеп сукмый икән. Кайсы вакыт туктап куйган кебек була. Китәргә жыйналам, ахры

Бөтен эчкәне ярты рюмка коньяк булды. Сәгатькә якын утыргач, мин абыйдан үгенәм:

— Абый, жырлагыз әле. Сез бик матур жырлыйсыз бит...

— И-и, тугг-га-ан! Жырлаган, биегән чаклар әллә кайларда, еракеракларда торып калды инде алар. Онытыла барган төш кебек кенә булып, искә төшәр-төшмәс томан эченнән генә күренеп калгалыйлар. Булмый инде хәзер жырлаулар...

— Абый! Зинһар! Бер генә куплет булса да?..

Фәния апа урыныннан торып, абыйнын урындыгы артына килеп басты да, ике кулын абыйнын кулбашларына сала, иплэп кенә аны кочаклый. Иркәләп акрын гына дәшә:

— Мансу-ур! Яраткан укучын, талантлы татар язучысы, син горурланган Зәки Зәйнуллин үтенә бит синнән. Кабаланмый гына, акрын гына жырла, зинһар! Монда, табында, бар да үзебезнекеләр бит. Гаеп итәр бәндәләр юк. Жырла, бәгърем! Зәкинен күнелендә, исендә жыр булып торып кал. Жырла!

Абый кузгалып куя. Монсу гына елмая.

— Шулай дисеңме, җанкай?!

— Шулай дим, Мансур бәгърем.

Абыйның кечерәеп бөрешкән гәүдәсе утырган урынында турая, зурая башлый Тирән итеп тын ала. Ике кулын өстәлгә куя да, акрын гына тавыш белән, бик тә моңлы итеп җыр башлый. Миңа карап җырлый:

Йөгереп бардым, тоталмадым
Су буенда пибикне.
Күп эзләдем, табалмадым
Син дускаем кебекне.

Аг-гыйде-ел күпере,
Чуенмы мәлә, чылтырый.
Каш астында ике күзең
Энҗе кебек елтырый.
Фәния апага табарак борыла:
Нигә зәңгәр яратам мин,
Әйт, иркәм, белсәң әгәр.
Шуңа сөям сине, иркәм,
Күзләрең синең зәңгәр.

Аг-гыйде-ел күпере,
Чуен мәллә, чылтырый.
Каш астында ике күзең
Энҗе кебек елтырый...

Ак күлмәк кигән, агарган, дулкынланып торган, артка тараган матур чәчле, коңгырт күзле Советлар Союзы Батыры, мин укыган татар мәктәбе директоры, чын татар абзые «Агыйдел күпере»н җырлаган хәлендә минем күңелемдә мәңгелек якты истәлек булып торып калды. Җыр булып!!!

Абый шул 78 яшендә мәңгелеккә китеп барды...

Фәния апа әле дә исән. Уфада, Василий Блюхер урамында яши...

**Редакциядән.**

*Зәки Лотфулла улы Зәйнуллинга 10 июльдә 80 яшь тула.*

*Зәки ага Башкортстанның Эстәрлебаш районы Эстәрлебаш авылында туа. Татар урта мәктәбен тәмамлаганнан соң бер ел ат җигеп авылда эшли, аннары... җидееллык мәктәптә математика, физика һәм рус теле укыта. Бер ел үтүгә тагын укый башлый: Хәрби авиация-техника училищесын, Югары хәрби ракета инженерлары училищесын һәм бу училищеның адъюнктурасын тәмамлый, боларга хәрби хезмәт һәм фәнни тикшеренүләр, гыйльми ачышлар ялгана.*

*Техник фәннәр докторы профессор Зәйнуллин — Латвиядә яшәүче татарларның «Идел» исемле милли җәмгыятен оештыручыларның берсе (1988). Казанга кайткач (1989), ул тулаем татар милли азатлык хәрәкәте әйдәрләренең берсенә әйләнде. 1978 елда әдәби әсәрләр яза башлап, 1994 елда Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителде. З.Зәйнуллин — «Үрләр аша», «Сугыш алды малайлары», «Ник ямансу бу күзләр?», «Агыйделнең аръягында» кебек проза китаплары авторы. Камал театры 2010 елда аның «Кырык бернең арбалы хатыннары» дигән драмасын куйды.*

# КЫТАЙДАН ЗӘҢГӘР ТАУГА КЕМ ЯУЛЫК БОЛГЫЙ?

Кытайга мине... Казан мунчасы якынайтты. 10нчы мунча. Бер тапкыр шулай элек анда күзгә чалынмаган ике егеткә дикъкать иттем. Бу мунчада (хәер, башкаларында да) яшь-җилбәзәк арасында сирәк була торган хәл: алар үзара теттереп татарча сөйләшәләр иде. Егетләрнең берсе тавышының йомшаклыгы, ягымлылыгы һәм сөйләменең саф татарча булуы белән әсир итте. Каян килгән икән бу гаҗәеп зат, заман шаукымыннан могарәдә качып ятмагандыр бит?



Таныштым мин Габделәхәт атлы бу егет белән. Бик ерактан, Кытайдан ук килгән булып чыкты ул. Казанда укып ятмышы икән — Энергетика университетында. Шулай аз-маз очрашкалап тордык. Мунчада сөйләшү җиңел, ихлас була. Чишенгән җирдә ял иткәндә дә, юынганда да, ләүкәдә дә сүз каттым Габделәхәткә.

Мине иң гаҗәпләндергәне «Сарман» җыры булды. Миннән аның үзе төгәл белеп житкермим дип уйлаган җирен сорады ул. Белгәне дөрес иде юкса. Аннары «Зәңгәр таудан яулык болгарым» дигән юлга тукталып, «Ул тау нигә зәңгәр тау икән?» диде. «Ерактан зәңгәрсу булып күренгәнгә шулай атап йөрткәннәрдер», — дидем инде. Җәйге якта егеткәй күзгә чалынмады. Каникулга өенә кайтып киткәндер дидем. Шуннан соң беренче тапкыр очрашкач, Габделәхәт янә ошбу җырдагы тауны искә төшерде һәм, янгырдан соң зәңгәр булып күренә икән ул, диде. Өйдәге хәлне күршедән сора дигән кебек булды инде бу.

Менә шушы хәлдән соң ерактан безнең тауларга текәлеп гомер кичергән милләттәшләребез турында күбрәк беләсе килә башлады. Ләкин Кытай кадәр Кытайга җиңел генә китеп барып булмый бит әле ул.

Форсат чыкты тагын. Кайда диген, шул мунчада ук! Көннәрдән бер көнне шулай ләүкәгә менгәч, аста утырган Габделәхәтне һәм аның янында утырган, тәненә кояш тирән сеңгән чандыр бер агайны күреп алдым. Габделәхәт белән исәнләшкәч, себеркемне болгап, шундук сорап та куйдым:

**— Абзый, сез дә Кытайдан килдегез мәллә?**

Һәм, «Әйе, Кытайдан килдем» дигән җавап алдым. Габделәхәтнең әтисе булып чыкты бу. Таш дивар аша гына әнисе дә мунча кереп ята икән әле! Баксаң, уллары янына килгәч, озаклаганнар, Ибраһимов проспектында фатир алып торып, ике ай ярым өчәүләп шунда яшәгәннәр дә, әти белән әни иртәгә китәселәр дә икән... Икенче көнне көндез без шул фатирда гәпләшеп утыра идек инде.

Килсә килә бит ул, мина Кытай кунакларының асыллары эләккән: Фәүзи әфәнде — мөгаллим, Әдибә ханым исә Бөтенкытай Халык Мәҗлесе депутаты булган кеше икән. Алар белән әңгәмә сумкалар һәм тулы пакетлар янында, вокзалны хәтерләткән бүлмәдә барды. Табигый ки, теләгән бөтен сорауларны да биреп өлгерә алмадым. Беренче соравым милләттәшләребезне Кытайга китергән юл турында иде.

— Без борынгы кешеләр инде, әтиләремез дә, бабаларымыз да дөньяда юк, — диде Әдибә ханым. — Кайчан булгандыр, ишетеп кенә беләбез — бабаем, әтиемнең әтисе,

Чистай районындагы Каргалы авылыннан килгән Кытайга. Тимергали Исхаков инде бу.

**— Ә сезнең, Фәүзи әфәнде?**

— Минем Хисмәтулла бабаем һәм Мәһбия әбием Казанның үзеннән. Әтиемнең әтисе белән әтиемнең әнисе болар. Бабам хәзрәт булган. Зур салымнар сала башлаячаклар дип хафаланып Кара күлгә киткән (хәзерге исеме Пржевал, Кыргызстан бу). Беркадәр вакыттан Кытайга күчкәннәр. Әйтүләренчә, бабам һаман бер кайтырбыз дигән өмет белән йөргән. Кайталмады инде.

**— Кайда гомер кичерәсез?**

— Өремчедә. Татарларның төп яшәү урыны булган Шенжан-Уйгыр автоном районының баш шәһәре бу.

**— Казанга килдегез менә. Ике ай ярым яшәгәннән соң тәэсир нинди инде? Күңелдә булганын гына сөйләсәгез иде, төче сүзләр кирәкми. Әдибә ханым, сездән башлыйкчы.**

— Сөйләшәсем килмәгән дә иде. Чөнки мин үзем бер кәсби (практик) ханым. Сәяси эшләргә беркайчан да кызыкмадым. 36 ел медицинада эшләдем. Профессорлык алдым, шул кешеләргә табиблык кылып инде. Сәяси сүзләргә колак салмый идем — аны ун Кытай әйтсә дә, сул Кытай әйтсә дә, ә менә Казанга килү мине бик дулкынландырды. Мин монда бер килгән идем инде. Казанның меңьеллык хатирләш мәрәсименә мине Татарстан тәклиф кылды. Кытай делегациясе белән шул бәйрәмдә катнашу күңелемә бер куаныч, онытылгысыз бер тарихи вакыйга булды. Дөньядан килгән бөтен татар кардәшләр белән күрештем. Үземнең татар булганыма горурланып, куаныч белән яшәп киттем.

Мин үзем музыка яратам, жыру яратам. «Казан кичләре»н өйрәнеп килгән идем, монда аны артистлар белән, башкалар белән бергә жырладык. Кайткач, Өремчедә сабантуйда малаем гармун тартып, кызым белән янә «Казан кичләре»н жырладык. Бөтен татар кардәшләремез елап тыңлаганнар, шундый куанып. «Син үз күзең белән күрдең, без синең жыруынны ишетеп күргәндәй булдык, рәхмәт сиңа, татарның хисләрен безгә апкайткансың», — шулай дип әйттеләр миңа.

Беренче тапкыр килгәндә Казанның, Татарстанның кормышлары булсын, юллары булсын әле бу дәрәжәгә житмәгән иде. Чаллыга барган юл бик тә начар иде. Быел Чаллыга кунакка чакырдылар. Юл киңәйтеп, әйбәт итеп ясалган, шундый күңелле бардык. Инде Казан эчендә дә үзгәрешләр, яңа кормышлар күп күреп сөендек. Татарстан гел шулай тәрәккый кылсын, бай булсын. Без кайда гына булсак та — татарлар. Без тырышып яшибез. Татарстан үзенең дөньядагы урынын югары тотсын.

**— Фәүзи әфәнде, сез нәрсә дисез инде? Казанга килгәч, ни хис иттегез?**

— Казанга беренче тапкыр килүем. Гүзәл икән. Авылларга да бардык. Чаллыда, Сарманда булдык. Бик ошады.

*Әдибә ханым:*

— Авылда кечкенә балалар да «Әссаләме галәйкем! Исәнмесез!» дип күрешәләр икән. Татарча бик шәп сөйләшәләр икән. Без моңа бик куандык. Казанда татар телен табуы кыенрак икән. Татарстан булгач, борынгы Казаныбыз бәйрәменә килгәч, докладлар, безнең фикер алмаштырыш, сөйләшү һәммәсе татарча булу тиеш дип уйлаган идем. Инде читтә яшәгән татарлар да әбиләремез, бабайларымыз Тукай теле дип калдырган телдә сөйләшә. Казанда татарча сөйләгән кешеләр аз икән. «Мин татарча белмим!» дип мәгърурланып әйтте берәүләр. Онытылгысыз бер тәэсир бирде бу хәл.

Без Кытайда хәзер 4 мең 500 генә татар яшимез. Шул килеш тә телемезне саклап калдык. Телне югалтмыш милләтне югалтмыш дип карыймын мин.

**— Ничек саклап кала алдыгыз? Кытай хакимияте башка халыкларны кытайлаштырырга омтылмыймени? Татарча укыту бармы балаларны, Фәүзи әфәнде?**

— Мәктәп юк. Мин бала чакта бар иде татар мәктәпләре. Татарлар азайды. Австралиягә киттеләр, Америкага киттеләр. Англиягә киткәннәр, Төркиягә киткәннәр булды. Казакъстанда төпләнүчеләр күп.

**— Ә сез нинди телдә укыттыгыз?**

— Уйгыр телендә, математика. Хәзер пенсиядә инде.

**— Тыю булдымы татарча укытуны дәүләт тарафыннан?**

*Әдибә ханым:*

— Безнең хәзергәчә жирле мәгариф бетмәде. Уйгырлар да, казакълар да, калмыклар да, монголлар да үз телләрендә укыйлар. Милли мәктәпләр аерым иде, хәзер алар Кытай мәктәпләре белән бер курада, балалар бер бинада укыйлар. Һәм инде милли мәктәпләрдә дә дәүләт теле дип кытай теле дәресе керә, балалар кытайчадан да имтихан бирәләр. Инде хәзер, шундый дәрес кергән әхвәлдә дә, кытайча телне безнең 80 процент кеше генә белә. Безнең менә институтка имтихан биргән вакытта да һәрберсенә үз телендә сөаль чыгарыла. Университетта укыган халәттә дә уйгыр балаларга — уйгыр, калмыкларга — калмык, казакъларга — казакъ, кыргызларга кыргыз профессоры дәрескә керә. Мин үзем медицинадан кытайча, уйгырча, казакъча дәрес бирәм. Шушыларның һәммәсенең класслары аерылган. Кытайча укый алганнар кытайча укый.

Үзенең теле белән генә укыганнар дөньяда басып тора алмый дигән сүз мөмкин имәс. Бездә кытайча бөтенләй белмәгән килеш түбәндәрәк эшләгәннәр күп. Мәсәлән, авыл табиблары, өлкә табиблары бар. Алар кытайча белмәсәләр дә, үз кәсепләрен беләләр, милләттәшләрен дәвалап, хәзергәчә күп хезмәт күрсәтәләр. Үз телеңне гаиләдә өйрәнмәк, укымак кирәк. Хикәятне (әкиятне — Р. Ю.) безгә әниләремез татарча сөйләгән. Әбием безне «Сандугач жыруын жырлыйм дип үз жыруынны онытма», — дип тәрбияләде гаиләдә. Бу — хак сүз, мин балаларымны да шулай тәрбияләдем. Без менә безнең гаиләдә мәктәптә кытайча укыдык, ләкин өй бусагасын үтү белән һәммәбез татарча гына сөйләштек.

**— Татарча уку мөмкинлеге булмадымы?**

— Татарча уку 50нче еллар килгәндә юк булды. Азайдык шул, күбебез Кытайдан китте. Ул дүрт ярым мең дә бер урында гына яшәми. Кытайча укыдык, уйгырча укыдык, казакъча укыдык. Өремчедә менә алты йөзләп татар бар. Алар белән дә күрешә алмыйбыз адәм күк. Шул сабантуйда жыелабыз инде бергә. Хезмәт кылган вакытта аралашырга вакыт юк.

**— Кайда уза сабантуй?**

— Һәрбер шәһәр үзе үткәрә. Өремчедә дә, Голжада да, Чүгүчәктә дә — һәммә татар жәмгыяте оештыра халыкны. Мона Кытай хөкүмәте бик күңел бирә. Икътисади ярдәм кыла, күп бүләкләр әзерләнә, халыкны алып барырга машиналар бирә. Бер көн сине ял иткезә, махсус, сабантуй дип. Кытайлар да, уйгырлар да, казакълар да килә, бүләкләр, күчтәнәчләр алып, безне тәбрикләп, шигырьләргә кадәр укып. Бергә жырлап-биеп, куанып китәләр.

**— Сез, Әдибә ханым, Кытай депутаты булгансыз бит инде. Кем вәкиле идегез сез? Шенжан-Уйгыр автономияле районыныкымы?**

— Юк, мин 1998-2008 елларда Кытай татарларының дәүләтлек депутаты булдым. Кытайда халыклардан депутатлар бар: уйгыр депутаты, казакъ депутаты, татар депутаты...

**— Сезгә мөмкинлек булдымы соң менә чыгышлар ясарга, татарны якларга?**

— Әйе, булды. Чыгышлар ясарга вакыт аерып бирелде, халыклар эшләрен башкара торган министр белән дә күрештек-киңәштек.

— Безнең 56 милләт эчендә шушындый милләт булу белән, Кытай татарлары белән без горурланабыз. Сезләргә тәрәккыят кылырга, янә дә алга басарга без булыша алабыз, — министр сүзләре бу.

**— Мондый сүзне ишетү генә дә күңеллеләр. Әмма ярдәм дигәне дә булдымы соң?**

— Булды. Менә безнең татар мәчетебезгә йөз еллан артып киткән. Нык искерде. Бу хакта халык фикерен үзәккә житкергәч, халык жәмгыятенең милли эшләр комитетында моңга күңел бүлеп, яңалап салдылар. Өремчедәге иң зур, иң әйбәт салынган мәчет хәзер — татар мәчете.



Әсгат Исхаков. Пекин, 50нче еллар башы.

Безнен татар авылымыз бар. Пекиннан, милли эшләр комитетыннан килеп кордырып бирдерделәр бу Татар Чишмә авылын. Ничә министр гына килеп китте монда, үз күзләре белән күреп. Аерым мәктәп, духтырханә салдырып бирделәр күнел куеп. Юллар яхшы имәс иде, моны мин безнен Шенжан-Уйгыр автоном районынын рәисе Абләт Әбдерәшиткә житкергәч, авылнын бөтен юлларын шундый шәп, матур итеп ясап чыктылар. Авыл кешеләренең бик тә күнеле булды. Татарларның да, казакъ карендәшләремезнен дә. Татарлар биш йөз генә булып чыкты монда, казакълар күбрәк.

**— Мәктәптә уку нинди теллә инде?**

*Фәүзи әфәнде:*

— Казакъча укыталар.

**— Ә нигә казакъча?**

— Татарча укытудагы зур өзеклектән сон укытучыларын табып бетерергә кирәк бит. Аларын да табып булыр иде, татарда аерата белемлелек бар. Ул биш йөз татарнын уку яшендәгеләре аз шул...

*Әдибә ханым:*



Шагыйрь Хәмит Төхфи Голҗа һәм Өремче шәһәрләрендә газит редакцияләрендә эшли. Өремче, 1963.

— Татарча укытабыз, укытучылар бар дип авылны әйләнеп үтсәк тә, бик теләп тормыйлар. Балалар мәктәптән соң университетка керәбез дигәндә аларга анда татарча һичкем дә сүз бирми. Татарча укытмаганга күптән бит. Кытайда ул таләпне кую мөмкин дә түгел. Татарстан булып Татарстанда да бу яктан кимлекләр бар. Гел татарча сөйләгән бер канал юк телевизорда. Шуна күрә безгә якын казакъ телен уртак укыту теле кылдык инде...

*Диктофонга яздырылган бу әңгәмәне кәгазьгә төшергәндә күз алдымда гел мәрхүм Миркасыйм абый Госмановнын «Ябылмаган китабы»[1] булды (әңгәмәдән сон аны тагын бер кат укып чыктым мин). Үзе дә шушы Шәркый Төркестан дип, яки Уйгырстан дип атап йөртелгән, соңыннан Кытайның Шенжан-Уйгыр автоном районына әйләндерелгән жирдә, Голжа каласында туып-үскән олуг галимебез анда булган хәлләрне бик белеп бәян кыла. 40-50 нче елларда Голжадагы сигезьеллык татар мәктәбенен үзендә генә дә биш йөздән артык бала укыган икән бит! Китапка Голжада куелган «Башмагым» һәм «Галиябану»ны уйнаучыларнын фотоларына кадәр теркәлеп калган.*

**— Кытайда, СССРда һәм Русиядә милли сәясәт, уртаклык һәм аермалар күрәсезме?**

— Стратегиядә, минемчә, артык аерма юк диярлек. Чөнки расачылык, шовинизм, ягъни кешелексезлек һәр жирдә дә бертөсле икән. Максат — буйсындырып тоту, изү, «йотып бетерү». Аерма тактикада гына күзәтелә. «Бөек», ягъни күпсанлы халыкларнын күпчелегенә гаделлек аны, киң күнеллелек, тыйнаклык хисе житеп бетми шикелле. Бәдәне зур бәндә бирән була диләр бит...

**— Сезнең «Ябылмаган китап»та Мәскәүнең хәтта ерак Шәркый Төркестандагы эшләрне дә астыртын идарә итүе, анда аның җасуслары (шпионнар) мыжлап торуы бик шәп күрсәтелгән.**

— Бу ике зур империя — Русия белән Кытай арасында булу төрки халыкларнын күпчелегенен язмышын хәл кыла. Мен елдан артык шул дәвам итә.

*(М.Госманов белән әңгәмәбездән. Идел, 1999, № 1)*

[1] Ябылмаган китап, яки Чәчелгән орлыклар. Татар кит. нәшр., 1996.

**— Театр куюлар бармы ул хәзер?**

*Әдибә ханым:*

— Татарча театр куйсак, ничә кеше кирәк анда, юк, юк. *(«Ябылмаган китап...»тагы фоторәсемнән безгә барысы да диярлек яшь, берсеннән-берсе матур 18 «галиябанучы» карап тора! — Р. Ю.)*

— Концерт-фәлән кую жинелрәк инде.

— Өремчедә куйган юк. Кайбер шәһәрләрдә булгалый. Гөлжада балаларга татарча оештырып яталар.



*Хәзерге Өремче.*

**— Газета-журналлар чыкмый торгандыр инде. Кытай татарларын берләштеребрәк тора торган нәрсә бар?**

— Татар гыйльми җәмгыятебез бар. Кытай Фәннәр академиясенә карый ул. Рәисе — Илче Сайран. Могавин рәисе (рәис урынбасары) — Илдан Исхаков, минем абыем. Шушы җәмгыять, Кытай татарларының тарихын һәм хәзерге тормышын өйрәнеп, китаплар чыгарды. Журнал да, газит тә чыгарып тора. Кытай хөкүмәтенен рөхсәте белән, белем алмашу турындагы килешү буенча, конкурс белән сайлап алып, Кытайдагы татар балаларын Казанга укырга җибәрде. Бөтендөнья Татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Ринат Закировка рәхмәт, ул бик тырышты. Беренче төркемдәге 36 баланың бер өлеше үз университетларын тәмамлый алмады, төшеп калды, ләкин бу барыбер дә бик олы эш булды.



*Сулда – Шәдия Вәлиева. Ул татар җырларын татар, уйгыр, казакъ, кытай телләрендә җырлап бөтен Кытайга танылган җырчы. Уңда – Турсун Еникеев. Ул – Кытайга беренчеләрдән булып килгән татар сәүдәгәре нәселеннән. Өремче, 2013.*

**— Габделәхәт, син тәмамлаучыларның берсе бит инде. Энергетика университетын «кызыл» диплом алып тәгәлләгәнсең. Котлыйм!**

— Рәхмәт.

Шәп нәселнең дәвамчысы икән Габделәхәт.

Әдибә ханым бабасын әйткән иде инде. Тимергали Хәсән улы Исхаковның 1921 елны — Әсгат, 1923 елны Мәргуб атлы уллары дөньяга килә. Ул чакта Советлар иле кул астындарак яшәгән бу тарафта да 1937 елда репрессияләр башлангач, Тимергали агайны кулга алалар һәм күпмедер вакыттан «халык дошманы» гаиләсен Өремчедән кечерәк бер шәһәргә сөрәләр. Ул үзе төрмәдән 1944 елны чыга. Тимергали аганың ике улы турында Миркасыйм абый «аерата гыйбрәтле» язмыш ияләре буларак яза. Алар икесе дә 1944 елда баш күтәреп җиңү яулагач «Азат Шәркый Төркестан»га әйләнгән һәм биш ел шулай азат булып яшәгән җөмһүриятә зур постларда шәп кенә хезмәт итеп алалар. Әсгат Исхаков Кытайда



*Пекиндагы татар яшьләре. 2013*

«культура революциясе» башлану белән (1966) кулга алына һәм 1976 елны төрмәдә үлә (үтерелә, диде Әдибә ханым). Генерал Мәргуб Исхаков исә 1960 елны, беркем көтмәгәндә Советлар Союзына чыгып китә һәм «культура революциясе» аңа тими кала. Ул 1992 елны Алматыда вафат була...

Әдибә Исхакова Пекинда кытай телендә чыккан бер китапны ачып-ачып күрсәтте. «Кытай тарихының онытылмас сәхифәләре» диебрәк әйтте ул аны. Китапта 1980 елны бөтен гаепләре дә акланган Әсгат Исхаковка шактый зур урын биргәннәр. Исхаковларны рәсемнәрдә дә кат-кат күрәбез.




—Габделәхәткә Казанда университет бетергәнгә мин менә шушы китапны бүләк иттем. Кемлегеңне бел, дип. Әнинең вазифасы бу — балаларына кемлекләрен таныттыру... — диде Әдибә ханым.

**— Безнең күп кенә әти-әниләребез, әби-бабайларыбыз балаларына менә шундый тәрбия бирмиләр шул. Аларның тамырдан аерылуларына, әкренләп ят телгә, ят кавемгә күчеп баруларына отабыз дип сөенүчеләр дә бар хәтта. Моның үзләренә ничек каты китереп суга аласын уйлап та карамыйлар. Арткан, бомж хәлендә калган әти-әниләр дә бар бит хәзер!**

— Күкрәкне киереп, читтәге татарлар Татарстандагы татарларга өлге, диям мин... Безне, безнең бабайларны качып киткәнсез дип гаепләүчеләр бар. Татарлыктан качмадык, тамырдан өзелмәдек без... Сез биргән кайбер сорауларда, сөйләгән сүзләрдә миңа беркадәр көлкелек тә бар. Мин сезгә сораулар куйсам, ул шулай булу тиеш Татарстанда, диярсез. Шуңа күрә аралашу кирәк, төшенү кирәк. Бер-беребезне ихтирамлап аралашу кирәк. Салаватка мин букет бирдем сәхнәгә чыгып. «Энекәй, без татарлар, кайда яшәсәк тә, бер-беремезне хөрмәтлик, үземезне-үземез әтъварлыйк, кадерлик», — дидем...

Мавыгып һәм ашыгып гәпләшкәнлектән «Сарман» җырының Кытайдагы эзе турында сорарга онытканмын да. Ләкин саубуллашуыбыз барыбер җырлы булды. Әдибә ханым миңа тартма тышларына кытай иероглифлары һәм башкаручылар — ул үзе һәм кызы белән улының фоторәсемнәре төшерелгән дискет бүләк итте («Сөбханалла!» дидем тыңлагач). Мин исә аларга иң шәп башкаруда иң шәп татар җырларының (минем вариант инде) радио фондыннан яздыртылган дискетны бирдем. Һәм менә, «Казан утлары»ның сәламе итеп (бу үтә популяр роман әүвәл безнең журналда басылды), Гөлчәчәк Галиеваның «Газзәбану» китабын да өстәдем. Авторның ире Казан Компрессор заводын беренче итеп Татарстан карамагына күчергән һәм башка заводларны да күчерешкән Әхмәт Галиев булуы һәм аның гендиректор чакта Кытайга командировкага нәкъ менә Өремче шәһәренә баруы, анда милләттәшләребез белән дә очрашуы бүләкнең кыйммәтен тагын да арттыра төшкәндер...

Әңгәмәдән бер олы нәтиҗә дә ясадым. Шөкер, Кытайда соңгы чорда халыкларга мөнәсәбәт үзгәрә төшкән кебек.

**Рәфикъ ЮНЫС**

# «ЗӘҢГӘР КҮЛГӘ ТАШЛАР АТТЫҢ...»

МАРС ШАБАЕВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, шагыйрь, прозаик, тәрҗемәче Марс Шабаев — үткән гасырның икенче яртысындагы әдәби мохиттнен төп үсеш чалымнарын чагылдырган, аңык һәм тайпылышсыз үз гражданлык позициясе булган сүз остасы. Әдәбиятны кеше аңын формалаштыруда бөек көч дип санаган буынның бер вәкиле... Аның тәүге шигъри тәҗрибәләре вакытлы матбугатта узган гасырның илленче елларыннан күренә башлый. Кеше һәм тирәлек, шул рухи-әхлакый якынлыкта тереклекнең үлемсезлеген күрү — М.Шабаев лирикасының төп мәүзугъларының берсе буларак үстерелә. Алгарак китеп, шуны да искәртәсе килә: аның иманына, эчке ышанычына туры килгән Американың бөек гуманист шагыйре Уолт Уитменның «Үлән яфраклары» исемле күләмле шигырьләр китабын тәрҗемә итүе очраклы хәл түгел иде. Шагыйрьгә инглиз телле язучының табигатьне тыңлый белүе якын. У.Уитмен иҗатын татар укучысына ирештерүе әдәби вакыйга булып, М.Шабаевның шагыйрь буларак үсеп китүенә дә этәргеч көч бирә. Соңрак ул Е.Евтушенконың «Казан университеты», «Әни һәм нейтрон бомба», Р.Мирхәйдәровның «Иртәләгән сагыш», «Һәрнәрсәгә акчалата» романнарын тәрҗемә итеп, бу өлкәдә зур уңышларга ирешә.



***

«Рухы белән илленче елларга тугры калса да, нигездә ул — алтмышынчы еллар шагыйре. Яңа ритм-стиле, шигъри чаралары, публицистика һәм лирика кушылган шигырь, поэмалары белән...» — дип яза М.Шабаев турында Р.Гаташ. Алтмышынчы-житмешенче еллар сәяси, әхлакый, фәлсәфи, җәмгыяви яссылыклардан килеп бәяләгәндә, аеруча игътибарга лаеклы. «Хрущев жепшеклеге» дип аталган чорда әдәбият янара, алдагы елларда рәсми хакимият тарафыннан каһәрләнгән катламнары укучыга кайтарыла башлый. Тыелган Дәрдемәнд, С.Рәмиев, Ш.Бабич, С.Сүнчәләй, Н.Думави әсәрләре, Сталин режимы тарафыннан репрессияләнгән әдипләр (Х.Туфан, Ф.Бурнаш, Г.Мөхәммәтшин һ.б.) иҗаты халыкка ирешә. Әлеге хәлләр агымдагы сүз сәнгатенең үсешенә уңай тәэсир ясый. Нәкъ менә шундый вакыйгалар, үзгәрешләр чорында М.Шабаев поэзиягә шау-шусыз гына килеп керә, үз юнәлешен раслый.

Каләм иясенең иҗаты аның тормыш юлы белән тыгыз бәйләнгән. Шагыйрь С.Есенин, тәрҗемәи хәле һәм иҗаты арасындагы бәйләнешне билгеләгәндә: «Минем биографиям — шигырьләремдә», — дип әйткән һәм бу фикер үзен аклый кебек. Тормыш вакыйгалары, нинди дер хәлләр, һичшиксез, әдип иҗатына тәэсир ясый, үз яңгырашын бирә. Бигрәк тә лирик төрдә каләмен чарлаучы шагыйрьләр иҗаты аларның биографиясе белән тыгыз бәйләнештә була, монда шәхси хис-кичерешләр, автор, лирик герой кебек төшенчәләр әһәмиятле урынны тота. Шуна күрә теге яисә бу шагыйрьне, язучыны өйрәнгәндә, әсәрләрен тикшергәндә, аның тәрҗемәи хәле белән танышып чыгу кирәк.

Марс Садри улы Шабаев 1933 елның 14 июлендә Татарстанның Минзәлә районы Югары Тәкермән авылында укытучы гаиләсендә туып-үсә. Сугыш башланып, әтисе фронтка киткәч, сигез яшьлек Марс күрше Усай авылында яшәүче әнисенең бертуган апасы тәрбиясенә күчә һәм 1941-1945 елларда шул авылдагы башлангыч мәктәптә укый. Бишенче-алтынчы сыйныфларны Хуҗамәт мәктәбендә, гаиләләре белән Минзәлә шәһәренә күчеп киткәч, шундагы мәктәптә җиденчене тәмамлый. 1949-1953 елларда Минзәлә педагогия училищесында белем ала. Сонрак М.Шабаев Казан педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә, аны уңышлы тәмамлаганнан соң, Татарстан радиокомитетында әдәби-драматик тапшырулар редакторы булып эшли. 1961 елда — «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасының әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире, 1964 елдан башлап — «Азат хатын» (хәзерге «Сөембикә») журналының җаваплы сәркатибе. 1970 елдан Татарстан китап нәшриятында — баш мөхәррир урынбасары һәм 1972-1977 елларда нәшриятның баш мөхәррире вазифаларын башкара. Озак еллар дәвамында «Казан утлары» журналында бүлек мөдире булып эшли.

Алтмышынчы еллар дәвамында шигырьләре һәм поэмалары тупланган «Кына гөле» (1963), «Ашкыну» (1964), «Зәңгәр планетам» (1965), «Сине эзлим» (1966), «Әби-апа» (1967), «Гомерлек бәйрәм» (1968), «Ир-егет Идел кичәр» (1969) җыентыклары дөнья күрә. Бу чорда шагыйрь аеруча поэма жанрында уңышлы иҗат итә. Аның «Шәймәт карт», «Яна җыр», «Җирән Конрад», «Кына гөле», «Әби-апа», «Дие татарише фрау», «Сине эзлим», «Артист» исемле поэмалары, гади хезмәт кешеләренең истә калырдай кызыклы образларын тудыру белән бергә, шул заманны тасвирлаудагы актив гражданлык позициясе һәм форма-стильдәге үзенчәлекле шигъри табышлары белән дә игътибарны җәлеп итәләр.

Әдипнең проза өлкәсендәге эшчәнлеген дә билгеләп үтәргә кирәк. Ул — туган як табигатенең шигъри гүзәллегенә дан җырлаган «Салда сәяхәт» (1967) исемле повесть һәм байтак кына лирик хикәяләр авторы да. «Җикән камыш», «Онытма» һәм русча тәрҗемәдә чыккан «Ищу тебя» җыентыкларындагы шигырь һәм поэмалары өчен М.Шабаев 1976 елда Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

«М.Шабаевның лирик герое — чор мөмкинлекләре, каршылыклары эчендә яшәүче реалистик уйлы, сабыр кеше. Беренче карашка, ул бик үк зур куәт иясеннән түгел, икенче карасаң, аның әһәмияте дә шунда. Ул үз буынының, чорының киң таралган сыйфатларын чагылдыручы шәхес. Аның көче — туган җиренә, туган халкына эчкерсез мәхәббәтендә. Хисненң ихласлыгы, олылыгы шәхес масштабларын зурайта» , — дип яза Ф.Зөлкарнәй М.Шабаев иҗатының лирик герое хакында. Романтик ашкынулы рух, киләчәккә, үз көченә нык ышанганлык — беренче чор лирик героеның төп сыйфатлары. Аның фикерләвенә максималистик кискенлек, контрастлык хас. Шул чордагы бер шигырендә шагыйрь моның сәбәбе итеп яшьлекне атый. Әсәрләрдә оптимизм, киләчәк турындагы уйларның матурлыгы, яктылыгы көчле гәүдәләнеш ала. Шатлык хисе вакыты белән артык «кызыл» юллар тудыра («Йөрәктә — җыр»).

Космосны яулау башлангач, татар әдәбиятында шул темага багышланган шигырь-поэмалар күбәеп китә. М.Шабаев поэзиясендә ул үзенчәлекле бер тема булып калка, күп кенә шигырьләрендә урын ала («Малайлар», «Космонавт улы» һ. б.). 60 нчы еллар уртасыннан шагыйрьнең омтылышлары реальрәк, үз мөхитебез белән бәйле чалымнар кинрәк урын ала.

*Кояш таплы, ай таплы дип*
*Җырлауларым җитәрлек.*
*Юләрлек...*
*Җир тапларын юар өчен*
*Җиңнәремне сызганам,*

— ди шагыйрь «Соңлый язган тәүбә» (1967) шигырендә. М. Шабаев иҗатында романтик ашкынуларга гына нигезләнгән, реаль җирлеге аз булган вәгъдәләр,

декларацияле шигырьләр күренми башлый. Дөньяны, халыкны, шәхесне ныклап өйрәнергә, анларга теләү омтылышы алгы планга чыга. Шагыйрь иҗатына дөньяны шигъри танып белүнең тирән, колачлы агымы килеп керә.

Алтмышынчы еллар азагыннан М.Шабаев поэзиясендә публицистик һәм фәлсәфи-лирик башлангычлар тирәнәя һәм көчәя төшә, билгеле бер күренешкә, вакыйгага мөнәсәбәт алгы планга чыга. Шагыйрь заман кешесенең тормышта тоткан урыны, эш-гамәле турында уйлана, тирә-як мохит һәм табигатьтәге үзгәрешләр белән тыгыз бәйләп, заман проблемаларынын кеше психологиясендәге катлаулы чагылышын сәнгатьчә сурәтләп бирергә омтыла һәм бу юлда уңышлы нәтиҗәләргә ирешә («Соңгы җырым түгел», «Чәчелеп киткән җиләк түгел...», «Кинәт кенә...», «Чатыр таудагы уйлар», «Тормыш әлифбасы» һ. б.):

*Безгә туры килде Атом чоры,*
*Күрдек Хиросима шәүләсен.*
*Җир, бу синең соңгы җырың белән*
*Ахырзаман көтик мәллә соң?*
(«Чорлар хакында»)

Шагыйрь халык тарихында тирән эз калдырган Бөек Ватан сугышы, ул китергән бәхетсезлекләр хакында уйлана. 30 нчы елларда туган М.Шабаевлар буыны өчен сугыш — чын мәгънәсендә дәһшәт. Алар үз-үзләрен аңлый, яшәүнең бәхет икәнен тоемлый гына башлаган бер чакта сугыш кузгала. Әйләнә-тирә дөнья капыл үзгәрә, бәхетле балачак өзелә, кайдадыр кала, югала. Шуна күрә дә алар иҗатында шул чор белән илһамлану кебек мотивлар гомумән юк. Искә төшсә дә, ул бары әрнү генә уята. Сабыйлыкка юл бөтенләй өзелгән.

М.Шабаев күңелендә Минзәлә якларынын матур һәм игелекле образы яши. Табигать шагыйрь җанынын, рухи яшәешенең мөһим бер өлешенә әверелә. Туган як табигатенә булган җылы, эчкерсез хисләр анын иҗатында үзәк урынны ала. Алар бигрәк тә алтмышынчы елларда язылган «Җикән камыш» циклында тулы гәүдәләнеш таба. Бу цикл — М.Шабаев иҗатынын әһәмиятле өлеше. Ул бик вакытлы, тормышнын заман тудырган үзгәрешләре нәтиҗәсендә шәһәрләшү процессына эләккәндә, табигатьтән ераклаша төшкән вакытта языла. Әдип табигатькә нисбәтән ихлас хисләрен шигырь юлларына чыгара («Кара туфрак, туган туфрак», «Ык печәне», «Янгыр үтте», «Чишмә», «Шәфәкъ җиле», «Шаһит усаклар», «Ай Ыкка төшкән дә шаяра»):

*Урман тавышларын тыңлый-тыңлый,*
*Атлап килә́м тап-тар сукмактан.*
*Иңнәренә алсу яулык салып,*
*Ык ягыннан туа йомшак таң.*

Житмешенче еллар уртасыннан М.Шабаев поэзиясендә сагыш мотивы күбрәк урын ала башлый. Тормышнын тиз үтүе, картлык житүе турында уйланулар, күңел төшенкелеге шигырьләрдә моң булып агыла («Язы үтте...», «Тупылларда көзге яфрак яна», «Яңгырлы җәй...», «Җаныңны як», «Үзе генә белгән берәүгә» һ.б.):

*Тыңлап ятам...*
*Йөрәк тигез тибә*
*Юк, канәгать түгел үземнән:*
*Чөнки күңел-оркестрның*
*Иң кирәкле кылы өзелгән...*
*Бары бер кыл!*
*Һәм уйнамый күңел...*

Күңел лирикасы, мәхәббәт темасы шагыйрь иҗатында аерым урынны били, аерым көлтәне тәшкил итә, бирелә романтик башлангыч зур әһәмияткә ия. Лирик

герой хисләрен кайчак талгын, йомгак сүткән шикелле салмак кына житкерә («Вәгъдә йөзеге», «Ак күгәрченмени...», «Бер исемне...»), кайчак ул сөйгәненә булган мәхәббәттән дөрләп яна, аның хисләре ярларына сыеша алмый агыла («Назга сусау», «Меңнәр арасыннан табышырга» һ.б.).

Күпчелек татар әдипләре үзгәртеп корулардан соң хәрәкәт һәм эзләнү заманы килеп житүен, ижат кешеләре өчен яңа мөмкинлекләр ачылуын дөрес сиземли, халыкның бәйсезлек өчен көрәшенә юнәлеш бирү, ярдәм итү рухы белән яши, халыкның үткәне, бүгенгесе, киләчәге турында уйлана. М.Шабаев та газиз халкы, аның тарихы белән кызыксына, язарына азыкны ул Болгар хәрабәләреннән, Биләр якларыннан таба, тарих безгә китереп житкергән истәлек-хатирәләрне, ядкарьләрне хыялы, рухы, зиһене аша үткәрә, алар өчен борчыла («Кичке эңгер», «Шәһри Болгар» һ.б.):

*Көл-күмергә калып вәйран булган*
*Канлы ярам — Шәһре Болгарым,*
*Хәрабәләреңнән күтәрелмәк,*
*Тормак була соңгы улларың...*
*Үлгәннәрнең рухы тынлык сорый...*
*Дөнья кумак була исәннәр.*
*Шәһре Болгар!*
*Хәрабәләреңдә*
*Тик битараф җилләр исәләр...*
(«Шәһри Болгар»)

Башлангыч ижатына хас акланмаган оптимизм, күтәренке рух, соңрак фәлсәфи юнәлеш алып, кеше, язмыш, сугыш, халык, галәм турында уйлануларның кичереш үзәгенә чыгуы, көчле яңгыраш алуы күзәтелә.

***

М. Шабаевның шигъри дөньясында лирикасы белән поэмалары үзара тыгыз мөнәсәбәттә тора, берсен-берсе тулыландырып үсә. 1956-1987 еллар арасында гына да әдипнең унбер поэмасы дөнья күрә. Лиро-эпик әсәрләре тематик яктан шактый үзенчәлекле, аерым игътибарга лаек булып, ижатында тарихи, мәңгелек мәүзугълар аеруча зур урынны алып тора.

Бөек Ватан сугышы башланганда шагыйрьгә нибары жиде-сигез яшь булган, шулай да ул аның авырлыгын күргән, тойган, үз авылдашлары, үз гаиләсе язмышында сугышның дәһшәтлеген, фажигалелеген аңлаган. Балачакта алган тәэсирләр хәтер тактасыннан юылмый, мәңге истә кала. Аларның бер чагылышы булып «Жирән Конрад», «Дие татарише фрау», «Сине эзлим», «Артист», «Әби-апа», «Ярты Төн Бәйрәме» поэмалары тора. Жанр хасиятләре ягыннан бу поэмалар лирик башлангычлы, аларда, вакыйгадан бигрәк, хис-кичереш, мөнәсәбәт алгы планга чыга. «Сине эзлим» поэмасының каһарманы — сугышта югалган әтисен эзләүче автор үзе. «Сабантуй» газетасына биргән интервьюсында М.Шабаев болай ди: «Мине шагыйрь буларак «Сине эзлим» дигән поэмам белән таныдылар. Сугышта югалган әтисен эзләүче малай — мин ул, шуңа кичерешләр дә табигый, жаңга үтәрлек. Хәтта авыл исемнәрен дә үзгәртмичә, шул килеш калдырдым». Поэмада сугыш аркасында әтисеннән мәхрүм калган баланың хис— кичерешләре үзәктә тора. Монда тәгәлләнгән вакыйга да, катлаулы характерлар да юк. Үзәктә лирик халәтнең алышынуы, кичерешнең эзлекле үсеше, шәхеснең уйланулары ята. Шагыйрь кеше рухында барган хәрәкәтне чагылдырырга, лирика алымнары белән кеше хисенең иң нечкә тармакларына үтеп керергә омтыла:

*Үләннәрдә чыклар күптән кипкән,*
*Күзләрдән дә чыклар киткәннәр.*
*Кайда,*
*Нинди үлән булып шыткан икән*
*Кырык бердә чыгып киткәннәр.*

Сугышта югалган әтисен эзләүче лирик герой тынычлана алмый, аның күңелендә билгесезлек, сагыш, әрнү хисләре һәрвакыт яши, гомере буе озата. Лирик герой өчен әтисе — үзе бер дөнья. Ул бер үк вакытта кояш та, туган як та, кайтаваз да, буран да... Әсәр дәвамында «чыклы үлән», «эз» кебек образлар еш кабатлана. Биредә «чыклы үлән» — лирик геройның сагыш, билгесезлек тулы күңеле кебек аңлашыла, «эз» образы әтисе турында юылмас хатирәне гәүдәләндерә:

*Ел томаны аша сине эзлим,*
*Томаннарда ялгыз эз генә...*
*Чыклы үләннәрдә ярылып калды*
*Шул ялгыз эз –*
*Синең эзләрең.*

Әдипнең сугыш темасын уңышлы яктырткан әсәрләренең берсе — «Жирән Конрад» поэмасы. Биредә, башка шагыйрьләрнең әсәрләреннән аермалы буларак, халкыбызның киң күңеллелеге, фашизм белән немец халкын тигез куймавы күзәтелә. Поэманың үзәгендә сугыш белән бәйле вакыйгалар нәтиҗәсендә лирик герой күңелендә туган хисләр, аларга карата булган мөнәсәбәт ята. Поэмада вакыйга контрастлы, драматизмга бай. Бөек Ватан сугышы елларындагы татар авылы кешеләренең немец фашизмына каршы нәфрәт хисләре, мәктәп балаларының тере немец Конрад белән очрашкандагы каршылыклы уйлары поэмада гаҗәеп җанлы, психологик яктан үзенчәлекле, шигъри буяуларга бай итеп бирелгән. Аның соңгы юллары кан коюлы, гадел булмаган сугышларны оештыручыларга, дөньяның тынычлыгын кабат бозарга теләүчеләргә ачы нәфрәт булып, сугышка каршы көчле набат булып яңгырый.


*Марс Шабаев һәм Мирсәет Яруллин. Узган гасырның 60нчы еллары*

1964 елда иҗат ителгән «Дие татарише фрау» поэмасы «Жирән Конрад» поэмасына аваздаш, алар арасында шигъри һәм идея уртаклыгы, бердәмлеге сизелеп тора. Биредә дә сугыш вакыйгалары тудырган хис-кичерешләр, халкыбызның шәфкатьле булуы турында фикер үзәк урынны ала. Поэма врач Зәйнәп Бәхтияровага багышлана. Татар хатыны немец әсирләрен, күңелендә барган каршылыкларга карамастан, терелтүгә зур көч куя. Ул дәвалаган немец әсирләре, сугыш тәмамлангач, хат язып, аны үзләренә кунакка чакырганнар. Марс Шабаев иллюстрацияләү юлына басмыйча, хисләрне киеренке, тәэсирле итеп җиткерә алган. Врач хатын образында татар хатыннарына хас булган сыйфатлар тулы чагылыш таба. Эшенә гаять җаваплылык белән карау, теләсә нинди очракта да вак хисләрдән өстен кала белү, авырлыкны үзенә алу — болар барысы да врач хатында бар, шуңа күрә ул дәвалаган немецлар сугыштан соң да аны онытмыйлар. Автор әсәрендә кешелеклелек, шәфкатьлелек кебек сыйфатларны олылый, шул хасиятләргә ия булган татар хатынына дан җырлый:

*Баш иик,*
*Кешеләр,*
*Без аңа:*
*Ул –*
*Ана,*
*Иң олы гуманист.*

М.Шабаев гаделлек, халыкка хезмәт итү мотивларын халык мифологиясенә нигезләнгән «Айзирәк ханбикә кыйссасы» (1972-1987) поэмасында ачып сала. Биредә

дә, вакыйгалардан бигрәк, хис-кичерешләр үзәк урынны алып тора. Әлеге поэманы Марс Шабаев Иван Бунин тәрҗемәсендәге Альфред Теннисонның (1809-1892) «Годива» исемле әсәре сюжетына нигезләнеп язган. Әдип герой исемнәрен милли җирлеккә утырта һәм аларга аерым бер мәгънәви йөкләмә бирә. Айзирәк исемендә кызның ай кебек матур, якты булуына һәм зирәклегенә укучының игътибарын юнәлтсә, Җаһил дигәндә, геройның явызлыгына басым ясый.

Поэмада Җаһил исемле явыз ханның идарә иткән вакыты тасвирлана. Ул халыктан зур салымнар җыйган, үзе исә кәеф-сафа корырга яраткан. Аның хатыны Айзирәк исә аңа капма-каршы образ буларак сурәтләнә. Ханбикә халыкның авыр хәлен күрә, аңлый, аңа ярдәм итәргә тели. Илен, халкын күп санлы салымнардан, җәбер-золымнардан коткару өчен, ул явыз хан куйган шартны үтәргә була: Җаһил Айзирәккә шәһәр буенча шәрәтән узарга куша. Халык, кызның сафлыгына баш иеп, ул урамнардан шәрә килеш үткәндә, күзләрен йома, өйләреннән чыкмый. Айзирәк образына бәйле автор биредә Коръәндә урын алган нур фәлсәфәсенә мөрәҗәгать итә. Шунысы кызыклы: оригиналда һәм русча тәрҗемәдә кыз нур белән бер тапкыр тиңләнсә, М.Шабаев поэмасында исә җиде тапкыр чагыштырыла. Татар шагыйре поэманы шәркый, милли нигезгә якынайта. Нур фәлсәфәсе түбәндәгечә ачыла: Аллаһыдан, пәйгамбәрдән, изге, саф кешеләрдән яктылык сибелгән шикелле, Айзирәктән дә якты нур бөркелә, автор кызны «нур-шәүлә» дип атый. Әсәр яхшылыкның, гаделлекнең һәрчак өстен чыгуын дәлилли, халык, ил турында кайгырту, алар өчен борчылу кирәклеге турында сөйли.

Мәхәббәт сынавы — мәңгелек тема, ул һәр заман кешеләре өчен уртак, һәр аерым шәхес өчен яңа, уттан алып суга салучы, күкләргә күтәреп, караңгылык базына ташлаучы мәңгелек хисләрнең берсе. М.Шабаев фикеренчә, сөю сәгадәтен татымаган кеше — бәхетсез. «Кына гөле» (1962-1972) поэмасында вакыйгалылык зур әһәмияткә ия. Әсәрнең каһарманнары Рәшидә белән Галимҗан бер-берсен ошатып йөриләр. Рәшидә әнисе белән генә үсә, әтисен бер дә күрми. Әнисе кызын ярлы тормыштан коткару нияте белән аңа бай кияү эзли. Рәшидәнең исә байлыкка исе китми, ул Галимҗанны сөя. Үз-үзенә бикләнә, башкалар белән аралашмый, шуңа күрә кызга «Кына гөле» дигән исем кушыла. Шагыйрьнең, әкияттәге серле таяк шикелле, төрле могҗизалар ясарга сәләтле «илһам таягы» Галимҗанны юлдан алып ташлый. Рәшидә яратмаган, әмма акчалы кешегә — Әнвәргә тормышка чыга. Мәхәббәт җимерелә... Күргәнебезчә, монда мәхәббәт темасын яңача ачу күзәтелми, тапталган, ясалма сюжетка ияреү ачык чагыла. Вак вакыйгаларга игътибар итү, аларны җентекләп тасвирларга тырышу психологик анализның көчсез булуына китергән. Бу урында шуны да билгеләп үтик: мәхәббәт темасы шагыйрьнең «Ярты Төн Бәйрәме», «Сине эзлим», «Дие татарише фрау», «Әби-апа», «Яңа җыр» кебек поэмалары тукымасына да өлешчә үтеп керә, аларда ул өстәмә мотив ролен үти.

Марс Шабаевның шигъри дөньясы үзенчәлекле, һичкемне кабатламый, аерым алганда, лирикасы романтик башлангычлы, фәлсәфи юнәлешле булуы, поэмалары идея-тематик яктан оригиналь, үзенчә булуы белән җәлеп итә. Шагыйрь иҗаты — татар поэзиясе диңгезенә коючы үзенә генә хас моңы, яме булган җырлы елга. Аның татар әдәбиятында, үз чоры шигъриятендә лаеклы урыны бар.

**Алсу МОСТАФИНА,**
*КФУ аспиранты*

# Марс Шабаев

## Мизгел

**Бәхет һәрчак тик бер мизгел була,**
**Бәхет мизгелләре бик тиз уза.**
**Ә кайгылы мизгел буламы?**
**Әллә сузыламы кайгы**
**айлар,**
**еллар?..**
**Әвереләме аннан язмышка?..**
**Тормыш тукып тора —**
**әйтерсең лә укытучы апа! —**
**ялгышма...**
**ялгышма...**
**ялгышма...**
**Бу тукулар ай-һай нык туйдыра!**
**Тыңламыйбыз барыбер:**
**абынабыз тагын ялгышка**
**һәм сылтыйбыз аны язмышка.**
**Абынулардан җаннар канаса да,**
**яшәү —**
**бер бәхетле мизгел!**
**татлы авыртынулы мизгел.**

* * *

**Әй, егет чак,**
**Гыйшык тоткан вакыт!**
**Искә төшерәм дә елмаям:**
**Тәмле телләр,**
**Яхшы кыланышлар**
**Табылып тора иде ул каян?**

**Кайнарланып сөйли һәрбер гашыйк,**
**(Әйләндерә диген кем телен?)**
**«Ефәкләргә генә төрермен дә**
**Кулларымда гына йөртермен...»**

**Үзе дә бит ышанып, нык инанып**
**Сөйли менә шундый сүзләрне.**
**Өйләнгәндә уйлый:**
**«Эләктердем**
**Дөньяда тиң чыкмас гүзәлне».**

**Әй, егетләр,**
**Кулларыңда йөртү**
**Гүзәл ярны —**
**Ул бит шаяру.**

**Сөюеңне тукми-чәчми генә**
**Еллар аша илтү —**
**Һай, авыр!**

*** * ***

**Кояш кебек балкый, диләр,**
**Көләч булса, кешегә дә.**
**Ә бит кояш бик еш кына**
**Яндыра да, пешерә дә.**
**Тик барыбер борынгыдан**
**Табынганнар шул ут-шарга.**
**Гашыйклар да тартынмаган**
**Сөйгәненә:**
**— Кояшым! — дип сүз кушарга.**
**Гөрләвекләр йөгерешендә**
**Уйнакласа кояш язын,**
**Җәен чәчәк чыкларында**
**Тирбәлә ул, биреп назын.**
**Көзен җиләк-җимешләрдә**
**Алсулана, уттай яна.**
**Салават күпере төсенә**
**Кышын боз тәрәзне мана.**
**Кояш белән бергә торам,**
**Юлга чыксам —**
**Баш түбәмдә.**
**Нурларыннан илһам алып**
**Күтәреләм**
**Зәңгәрлеккә мин түбәннән.**
**Юк, кояшсыз тормыш бармый,**
**Көн туа алмый, яшәрми җир.**
**Үлсәм дә мин,**
**Үлән булып сузылырмын:**
**— Ах, кояш! — дип дәшәрмен бер.**

## Куан, каләм!

**Керфекләрдән яшьләр кипмәгән,**
**Күңелләрдән курку китмәгән...**
**Ил өстеннән томан тарала:**
**Җимереклек — кая карама.**

**Хәбәрдарлык үзенең пәрдәсен**
**Чынлап күтәрәме әллә соң?**
**Карашларда әле шөбһә-шик:**
**Сүзне үлчәбрәк сөйләшик —**

**Дөнья хәлен әле кем белә...**
**Авыз пешмәгән бит бер генә!**
**Әмма инде апрель җилләре**
**Айкап үтте барлык җирләрне.**

**Онытылган кырлар-басулар**
**Апрель ташулары ярсудан**
**Чистарынып калды, юылып:**
**Сөр, чәч, үстер! —**
**Башка юлы юк.**

Сөр, чәч, үстер ирек гөлләрен!
Ничә еллар хөрлек күрмәдең...
Күңел яралары,
Рәнҗешләр,
Түбәнсетелүдән әрнешләр
Юылып төште инде быел яз —
Куан, каләм!
Куан, кыю яз!

Гүя борын төрткән яшь үлән,
Безнең ерак калган яшьлектән
Илле алтынчы еллар түреннән
Өмет чәчәкләре терелә.

Ирек — онытылган сүзләргә,
Ирек — куркытылган сүзләргә!
Һәрнәрсәнең исем-җисемен
Әйтер хакың бүген бар синең.

Яңа инкыйлаби быел яз —
Куан, каләм! Куан, кыю яз!

---

## Хөрмәтле укучыларыбыз һәм авторларыбыз!

Журналыбыз белән даими танышып баручылар белә булыр: бездә «Казан утлары» архивыннан» дигән рубрика бар. Бу сәхифә байтак еллар гамәлдә булса да, элегрәк елларда материаллар сирәгрәк чыга иде. Соңгы вакытта «архив» активлашты, журналның һәр санында диярлек татар тарихыннан иҗтимагый әһәмияткә ия булган фотосурәтләр басылып килә. Теләгебез—алга таба да рубриканы кызыклырак һәм мәгънәлерәк итү. Бу эшне уңышлы дәвам итү өчен сезнең дә булышлык кирәк. Сезгә мөрәҗәгать-гозеребез шул: үзегезнең шәхси, гаилә альбомнарында яки оешма-учреждение архивларында сакланган кызыклы, тарихи-иҗтимагый кыйммәте булган (әдәбият һәм сәнгатебезнең мәшһүр шәхесләре, истәлекле мәдәни вакыйгаларга караган күренешләр, Казан һәм Татарстан тарихын яктырткан сурәтләр һ.б.) фоторәсемнәрне безгә юлласагыз икән! Шул рәсем турында аңлатма-комментарийларның булуы да шарт, әлбәттә. Без аларны журналда файдаланганнан соң, кире иясенә кайтара алыр идек.

Әйдәгез, кадерле укучылар, мөхтәрәм милләттәшләр, кайдадыр киштә-шкафларда, альбом-папкаларда ябылып яткан истәлекле ядкярләрне яктыга чыгарыйк, халкыбызның рухи елъязмасы сәхифәләре булып киләчәк буыннарга хезмәт итсен алар! Сездән кызыклы фотоматериаллар көтәбез.



*Татарстанның халык язучысы Гариф Ахунов яшәгән йортка истәлек тактасы кую мәрәсиме. 2000 ел.*

*Классик язучы Галимҗан Ибраһимовның сирәк фоторәсемнәренең берсе. Үткән гасырның 30нчы еллары.*





*Космонавт Юрий Севастьянов «Чаян» журналы редакциясендә. Сулдан уңга: шагыйрь Зөлфәт, журналист Рафаэль Хәлиуллов, Юрий Севастьянов, язучы Әхәт Сафиуллин, журналның баш мөхәррире Рәшит Зәкиев. 1996 ел.*



*Язучы Ләбибә Ихсанова музыкант башкаручы Гали Җәмлиханов (сулда) һәм Фәйзи Биккинин белән. Үткән гасырның 60нчы еллары.*



*Язучылар – Зөлфәт Хәким (сулда) һәм Фәнзаман Баттал шаярышалар, якалашып бәхәсләшәләр!.. 1991 ел.*



*«Казан утлары» журналы журналының 70 еллыгы уңаеннан үткәрелгән кичәдән бер күренеш. Алгы планда язучы Гомәр Бәширов, җырчы Фәридә Кудашева. Г.Камал исемендәге Дәүләт театры залы. 1992 ел.*

# «ШУНДЫЙ МАТУР АНЫҢ ШИГЫРЬЛӘРЕ...»

— Сездә Илсөяр Иксанованың «Кырык кыл» исемле китабы бармы?— дип соравыма каршы, авылыбыз китапханәчесе Фирдания ханым:
— Ба-ар! — диде дә, хисләнеп, яттан сөйләргә кереште.

*Серләр тулы кара урман булдың —*
*Кердем дә мин шунда адаштым.*
*Син серлерәк була барган саен*
*Мин көчлерәк сине яраттым.*

Аннары, китапханәдәге кешеләрнең гаҗәпләнүен күреп:
— Ник аптырадыгыз, шундый матур бит аның шигырьләре, элеккедәй хәтерем булса, күбрәк тә ятлар идем әле, — дип куйды.

Шундый матур бит! Матбугатта күренә башлауларыннан соң Илсөяр Иксанова шигырьләренә карата мондый сүзләр ничә йөз тапкыр әйтелде икән инде? Ә бәлки ничә мең тапкырдыр. Китапханәче Фирдания яттан сөйләгән строфаны шагыйрәнең кулыбыздагы өч китабыннан («Ышанасы килә», «Кышкы канәферләр», «Кырык кыл») табып булмады. «Мин аны бик күп еллар элек кайсыдыр газетадан укыган идем, шуны укыганнан соң гына Илсөяр Иксанова исемле шагыйрә барлыгын белдем. Китаплары сонрак күренә башлады», — ди Фирдания ханым.

Турысын әйткәндә, әлеге строфадан бүгенге Илсөяр Иксанованы танып булмый да кебек инде. Рифмаларына гына игътибар итик, бүген «адаштым» белән «яраттым»ны рифмалаштырып язса, без хәзер белгән нәфис шигъриятле Илсөяр булмас иде ул. Дөньяга гүя шигъри сүз белән матурлык тудырырга килгән, өстәвенә каләмдәшләренең иң зәвыклыларыннан булган шагыйрәнең һәр шигыре диярлек камиллек үрнәге хәзер. Сайлап тезелгән сүзләре генә түгел, сүзләрдәге авазлары да үзләренә бертөрле көйгә килеп, моң бөркеп тора:

*Иделләргә карап Идел булмам,*
*Урманнарга карап, шау урман...*
*Тик урмансыз, болыннарсыз җирдә,*
*Иделләрсез илдә мин булмам.*

Илсөяр шигырьләрендәге рифмалар, бер яктан, шулкадәр табигый булсалар, икенче яктан, һич көтелмәгән, әмма шигъри табыш саналырлык тирән мәгънәле сүзләр белән укучыны сөенечле гаҗәпләндерәләр. Менә аның «Бәхет таңы» исемле иҗат җимешеннән бер строфа:

*Минем халкым, күпме өметләнеп,*
*Шул таңына каршы йөгергән лә.*
*Туды гына диган сәгатьләрдә*
*Сабый-таңын урлап өлгергәннәр.*

Бер җөмләдән бер строфа ясап, шунда ук гаҗәеп яңгырашлы вәзендәшләрен дә матур гына килештереп куя алу сәләте шулай ук бик аз шагыйрьләргә генә

биреләдер, ахры. Шул бер җөмләдә ин-ин шигъри җанлылар гына әйтеп бирә алган күпме асыл фикер!

*Беркөнне йөзләрдә соң кабат*
*Шәфәкънең яктысы чагылыр,*
*Һәм җаның*
*Син күпме йөгереп*
*җитмәгән*
*Офыкка кагылыр...*

Камил бер строфа-җөмләдә күкләрне инләрлек зур мәгънә үрнәген «Илдарыма» исемле шигырьдә дә очратабыз:

*Тагын бер кат гомер бирсә Ходай,*
*Тагын бер кат бу дөньяга килсәк,*
*Киек казлар,*
*безгә юл сабыгыз,*
*Табышалмый адашыплар йөрсәк!*

Әйе, нибары бер җөмләдән торган, әмма төзелеше белән һәръяктан килгән, шул бер җөмләгә олы фикер, гаҗәеп шигъри сурәт сыйган строфалар Илсөяр Иксанова китапларында байтак. Аларны уйлап чыгарырга мөмкин түгелдер, шагыйрьлек дигән илаһи көч ярдәмендә алар үзләреннән-үзләре туадыр, шуна күрә шагыйрь булмаганнарга моның сере чишелеп тә бетмидер, бәлки.

*Әйләнә дә кайта тарих,*
*Җилкетеп, алдап ала.*
*Ашкынган күңел алдауны*
*Соң гына аңлап ала, —*

ди ул Г.Тукайдан эпиграф алып («Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңелем кошы») язылган «Өзелү» шигырендә. Әйе, бөек Тукайны уйлап язылган шигырь форма ягыннан да, эчтәлек ягыннан да камил булырга тиештер, анысы. Шагыйрә иҗатыннан «моңнарым — тын агым», «җан янды−ялганды», «ымсына — мин сина», «янасың күк — ягасым күп», «булып там — болыттан» кебек, шигырьләргә матурлык биргән вәзеннәрне кинәнеп укыганда Г.Тукайның «Сәгъде Вәкъкас әфәндегә» исемле мәкаләсе хәтергә килә. Мәгълүм булганча, шагыйрь Сәгыйть Сүнчәләй, Сәгъде Вәкъкас тәхәллүсе белән «Шура» журналында бер мәкалә язып чыгарып, Г.Тукайның «Мияубикә» шигыренә унай бәя бирә дә, житешмәгән яклары итеп, «рифмаларының (ахыр сүзләренең) ямьле оеша алмаулары»н күрсәтә, «ике юллы татар шигырендә бер юлның ахыргы сүзе «нәрсәгә» булып, икенчесенең ахыры «мәсьәлә» булуын вәзне шигырь җәһәтеннән дөрес күрми» (Г.Тукай.) Габдулла Тукай исә «нәрсәгә» белән «мәсьәлә»нең вәзен булырга яраганлыгын дәгъва итә. «Һичбер шагыйрь,− дип яза ул,− шигыренең бер юлы ахырын «такмак» дип язгач та, каләмен колагына кыстырып, мич арасыннан кыштыр-кыштыр «шакмак» эзләп йөрергә мәҗбүр түгелдер. Шулай ук һичбер назыйм бер юл ахырын «сукмак» дип туктаткач та, өйалдына чыгып, «тукмак» эзләргә бурычлы түгелдер». Күренә ки, шигырьдә рифмалашкан сүзләрнең нинди булырга тиешлеге хакында Тукай кебек бөек шагыйрьләр дә матбугат битләрендә сүз куертканнар, бәхәсләшкәннәр. Рифманың нәкъ менә көтелмәгән, строфаның төп мәгънәсен туплаган сүз булырга тиешлеген, строфаның беренче яртысын укыганнан соң үзеннән-үзе укучының теленә килеп торган шома рифмаларны хуп күрмәвен заманында рус шагыйре В.В.Маяковский да язган иде. Хәзер ул хакта тәнкыйтьчеләр дә язмый, кайбер шагыйрьләр дә аңа вак, әһәмиятсез, әллә ни кирәге булмаган бернәрсә итеп карый кебек. Бу җәһәттән соңгы еллардагы байтак җыр текстларының «шигырьлеге» турында сүз башларга да кыенсындыра, күп очракта «җырчылар моны җырларга алынганда ни уйладылар

икән?» дип гаҗәпләнергә генә кала. Ә иң матур жыр тексты үрнәкләренең берсен әлеге дә баягы Илсөяр Иксановада очратабыз:

*Сагышларым бураннарга салдым,*
*«Китәр юлларына ят!» — дидем.*
*Ап-ак буран җаннарыңны урар,—*
*Сөюләрем сине хак минем.*

Шул ук вакытта Илсөяр Такташны уйлап Такташча да яза белә. Аның «Такташка хат» исемле мини-поэмасының һәр строфасы, җаннарны сыкратып, бик иртә дөньядан киткән бунтарь шагыйрьне хәтерләтә. Менә монда тагын бер җөмлә — бер строфа:

*Аһ, ул еллар,*
*Моңлы, шомлы еллар,*
*Син белмисең, Такташ,*
*Ярый белмисең,*
*Сөргеннәрдә гомер сөргәннәрен,*
*Ә аннан соң җирдән сөргәннәрен*
*Җырчы дусларыңның күбесен.*
*Бөтенесен...*

И.Иксанова шигырьләрен укыганда МАТУРЛЫК төшенчәсе һәрдаим күз алдыбызда торганлыктан, шагыйрәнең шул исемдәге иҗат җимешен аерым бер игътибар белән укып чыгабыз. Шигыреннән аңлашылганча, Илсөяр өчен матурлык ул — язга елмайган йөз дә, мес-мес итеп әнисен имеп яткан нарасый да, нәфис гөл-чәчәкләр һәм аларны таплатмый сакларлык нечкә күңел дә, салкын кышның һичшиксез узачагына ышану да, кеше җаннарын нәфис бөреләргә яшереп кыш чыгара алган серле могҗиза да.

*Күзләрнең дә яктылыгын күрдем,*
*Җылылыгын тойдым кышларның.*
*Иң зәмһәрир ачы суыкларны*
*Бөреләргә посып кышладым, —*

ди ул «Матурлык» исемле шигырьдә.

Чү, Илсөяр шигырьләренең, сайрар кошлар җырыдай, искиткеч табигый яңгырашына, алардагы җете сурәтләргә: офыкта янган баланнарга, миләшләргә, ап-ак бураннарга, гөрелтесе ераклаша барган таңгы яңгырларга, Сараланның тәпи пешерерлек сары кайнар комнарына, җанының кырык кылы өзелер мәлләрдә дә «Туган ил!» дип, «милләтем!» дип җан аткан фидаиларга соклануыбыз күпкә китмиме һәм... шул соклануыбыз белән шагыйрәне кабат үпкәләтмибезме без? Назланып-наянланыпмы, әллә чын күңелдән үкме, шундый сокланулары өчен укучыларына бер үпкәләде кебек бит инде ул. Әйе-әйе, «Мин — хатын кыз» исемле шигырен күз алдында тотып әйтүем:

*Ал таң булып кундым офыкларга*
*Һәм көн булып төштем өзелеп.*
*Шагыйрь, диеп сокландылар бар да —*
*Мин хатын-кыз идем иң элек!*

Ләкин Илсөяр Иксанова атлы хатын-кызны бары тик шигырьләре аша гына белгән, аны бер тапкыр да күрмәгән меңнәрчә укучылары да бар бит әле, авторның әлеге шигыре аларга да адресланганмы? Шагыйрьнең кемлеген белүдән бигрәк, шуны белмичә генә шигырен укучылар, әйбәт язылган булса, сокланучылар уннарча тапкыр күбрәк булачак һәм шулай булуы яхшы да бит инде. Өстәвенә, Илсөяр

ханымның шигырьләре, бигрәк тә мәхәббәт лирикасы болай да әллә кайдан «мине пәрәвез җебедәй нечкә җанлы, үтә нәфис табигатьле, шул ук вакытта баласын, мәхәббәтен яклап ана арысландай дошманына ташланырга әзер шагыйрә — хатын-кыз иҗат итте» дип кычкырып торалар, аларда шагыйрьлекне хатын-кызлыктан аерып карау һич мөмкин түгел. Шулай булгач, үпкәләвендә бераз арттырып җибәрмәде микән шагыйрәбез?

Ә менә бүтән бер очракта, аның белән бәхәсләшүче зур талантлы кыю шагыйрьне түгел, Илсөяр сеңелне яклыйсы килә. Бирелә Илсөяр Иксанованың «Төшенкелек»(!) исемле шигыре, төгәлрәге, аның бер строфасы һәм шул строфаны эпиграф итеп алып, зур шагыйрь язган җавап турында сүз бара.

*Ул бөек идеаллар — сафсата —*
*Күңелнең үз-үзен алдавы.*
*Галәмдә син — тузан бөртеге.*
*Кыенмы, йә, шуны аңлавы?! —*

дип яза Илсөяр. Бәхәсләшүче шагыйрь исә, ана кискен каршы килеп:

*Нәрсә уйлап язасыздыр?*
*Максат нидә? Төшенмим.*
*Күрмисезме, сеңелкәем,*
*Тузан түгел Кеше мин! —*

дип белдерә. Шигыре азагында тагын «Тузан булыр өчен генә / Нигә яшәп торырга?» дип тә әйтеп ташлый. Бәлки ул «Төшенкелек»тәге «галәмдә» сүзенә игътибар итеп тормагандыр? Югыйсә «уйлый торган, яза белгән» бер горур зат кына түгел, шундый миллиард Адәм балаларын сыйдырган Җирнең дә иксез-чиксез Галәм киңлегендә әллени тормаганына отыры ышана барабыз түгелме? Күптән түгел Чиләбе, борынгы Чибәркүл өсләрендә хәвефле шартлап метеорит коелган көннәр моңа кабат ышандырды: без Җирне үзе кебек үк «галәм тузаны» бәрелеп һәлак итүдән берничек саклый алмыйбыз икән бит, рәхимле Алла сакласа гына. Үтә нечкә шигъри җанның нинди чагы булмас, кем-кем инде, каләмдәше шуны аңламыймы (шагыйрәнең бер шигырендә «Таулар холкын таулар гына аңлар» дигән гыйбарә бар)? Әнә лачын карашлы Дәрдемәнд тә көннәрдән бер көнне «Зәгыйфь кырмыскамын мин юлда яткан» дип яза, нинди хөр рухлы бөек Тукайның да «Өзелгән өмид»е бар. Сәгыйть Рәмиев, әлегеләрдән капма-каршы якка ташланып:

*«Мин!» димен мин, «мин» дидисәм,*
*Миңа бер зур көч кирә,*
*Аллалар, шаһлар, канүннар*
*Булалар бер чүп кенә. —*

дип яза да, бераздан, үзе кебек үк авыру, фәкыйрь, ач драматург Мирхәйдәр Фәйзине очраткач, «Бәхетсез кәсепкә тотынганбыз, толчукчы буласы гына калган икән» дип зарлана. Әйе, дөнья бу! Әлеге очракта, чынлап та, шигырендә «тузан» сүзен кулланучының шагыйрь генә түгел, «иң элек» хатын-кыз булуын истә тоту хата булмас иде, минемчә. Илсөяр Иксанованың «Төшенкелек» шигыре — үз төрендә бердәнбер ул. Хатын-кыз буларак, бала тудырган әни буларак кичергән зурдан-зур югалтулары соңында да мондыйны бүтән язмады, киресенчә, һәр шигъри юлында үзенең Җирдәге тузан бөртеге генә түгеллеген раслап килә.

*Китмә, дип,*
*китмә, дип өзелдем,*
*Син күчкән кукләрнең катына.*
*Аңладым:*
*Бу — язган язмышлар,*
*Мин тузам шул язмыш хакына.*

*Китмә, дип,*
*китмә, дип өзелеп,*
*Кулыма сарылыр балам бар.*
*...Кышларның суыгын җылытып*
*Кызара ап-ачы баланнар.*

Илсөяр Иксанованың бер-ике генә бөртек фикердәше белән шулкадәр дә милли рухлы альманах чыгарырга алынуы да матбугатыбызның кадере китебрәк торган бу заманда чын фидакарьлек дип бәяләнергә хаклы. Сүз «Түгәрәк уен» дип исемләнгән, баш мөхәррире Илсөяр Иксанова булган, татар халык иҗатын яктыртучы мәгълүмати-популяр альманах турында бара. Аның өч айга бер тапкыр чыга торган һәр саны татар халкының кемлеген, аның матур йолаларын, күңел җәүһәрләрен сөйләүче, бөтен татар дөньясыннан тупланган язмалар белән тулы була. Безнең аз санлы матбугат басмаларына гына хас булган, милләткә, аның киләчәгенә ышанып хезмәт итү үрнәге шушы, ләбаса. Илсөяр сенелнең «Юлга чыгам» исемле шигырен укысак, аның нилектән мөхәррир кебек «бәхетсез кәсеп»кә алынуын да, шагыйрьлек максатын да әйбәтрәк аңларбыз:

*Бу дөньяда күпме кеше җаны*
*Җырга-моңга сусау — санаусыз.*
*Юлга чыгам кабат,*
*Юллар, мине*
*Кай якларга алып барасыз?*
*Кай тарафка гына юл тотсам да,*
*Сагынып көтә мине татарым.*
*Үзе генә тойган,*
*Җырга сыйган*
*Мең гасырлык моңы бар аның.*
--------------------------------------------
*Уза гомер юллар-еллар санап,*
*Кая барма, җанда ашкыну.*
*Җырларыма кучә,*
*Сезгә күчә,*
*Җанымдагы хисләр ташкыны.*

Илсөяр шигырьләрендә «кар» төшенчәсе шулкадәр күп кулланыла, кемдер алардан салкынлык бөркелүен тоярга да мөмкиндер, бәлки. Ә чынлыкта аклык-сафлык билгесе икән бит алар. Үз күнеле хакында никадәр югары фикердә булса да, барыбер аклыкка мохтаҗ әле Кеше.

*Аклык җитми икән...*
*Әйтәм җирле*
*Торган саен күңел күшегә.*
*Беренче кар төсле сафландыргыч*
*Якты хисләр кирәк кешегә, —*

ди Илсөяр Иксанова «Аһ, кар яуган!» дип башланган шигырендә. Иҗаты белән күңелләребездәге аклыкны ишәйтергә омтылган шагыйрәгә уңышлар телик.

**Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ**

# «МИН АРЫЙ ТОРГАН КЕШЕ ТҮГЕЛ»

Йөздән артык әсәрне сәхнәгә куйган күренекле режиссер, Казан Мәдәният һәм сәнгать институтында,театр училищесында меңәрләгән укучыны сәхнә серләренә төшендергән мөгаллим, Г.Тукай премиясе лауреаты Равил ага Тумашев белән очрашып сөйләшү тиз генә насыйп булмады. Ул әле Жиңү бәйрәме чараларында, әле 90 яшьлек юбилее унаеннан оештырылган очрашуларда, әле «Дөнья драматургиясеннән үрнәкләр» исемле яна китабын тәкъдир итү кичәсендә... Борынгылык рухы сеңгән фатирга кергәч тә күзем Равил аганың үз кулы белән язган картиналарына, озын-озак бергә гомер иткән, бик күпләргә гыйлем биргән галимә — Диләрә апа Тумашеваның портретларына төште... Төрле ракурслардан ясалган әлеге портретлардагы карашлар жил-жил атлап бүлмәдән-бүлмәгә йөргән, монсу елмаюлы хужа белән бергә хәрәкәтләнә сыман... Түрдә — кабызып куелган заман техникасы — компьютер.



— Истәлекләр китабын яза башладым әле, — ди Равил ага, гажәпләнүле карашымны сизеп. «СөбханАллах!» — дим, соклануымны яшерә алмыйча. Күнелемдә Тукайның: «Булмамын, юк, картайсам да, чын карт кеби, утырмам тик, юк-бар теләк тели-тели», — дигән юллары янара.

— Әни һөнәрен дәвам итүче булып саналсам да, театр тормышы, режиссерлык безнең гаиләдә әтидән, — дип сүзен башлады Равил ага Тумашев. — Колчак тылында революцион эш алып баручы мөселман секциясе татар драма түгәрәге оештыра. Колчак бандалары таркатылып Өркеттә Совет власте урнашкач, беренче мөселман театр труппасы оештырыла. Труппаның режиссеры Рәхим Тумашев була. Әти үзе дә пьесалар яза иде. Әни — аларның труппаларында хатын-кызлардан беренче актриса, Зауральская фамилиясе белән күп рольләрдә уйный. Әти-әни өчен балаларының атасы гына түгел, якын дус, остаз да иде.Семипалат шәһәрендә туганмын,мина өч айлар тирәсендә әтиләр Казанга кайтып урнашалар.

***— ГИТИСта белем алу кайсы заман өчен дә зур дәрәҗә саналган. Әниле-уллы әлеге уку йортында укыган режиссерлар татар театр дөньясында башка юктыр...***

— Әнине үземнең остазым дип атасам да, ГИТИСка укырга баруымда сеңелем Зөмәрә сәбәпче булып тора. Үзе дә анда укый иде. Мин архитектор булырга уйлап йөри идем. Сеңелем белән кечкенәдән шахмат тактасын сәхнә итеп, борчакларны артистлар итеп тезеп, «спектакльләр» куя идек. 1939 елны әни Мәскәүдә укуын тәмамлап Академия Театрына эшкә кайтты. Диплом эше итеп алган Х.Фәтхуллинның «Күзләр» драмасын куйганда булышып та йөрдек әле.

***— Мәскәүгә укырга киткәндә сез инде утны-суны кичкән фронтовик булгансыз. Сугышта үлем белән күзгә-күз очрашкан вакытлар булмый калмагандыр? Кызыл Йолдыз ордены да жиңел генә бирелмәгәндер...***

— Булмыймы соң! Анда бит йоклаганда да үлемне кочаклап йоклыйсың. Сугышка алынганда — мәктәпне тәмамлаган яшь-яшь егет идем. Бервакыт шулай, рация аша хәбәр алып, аны төне буе расшифровать итеп, штабка кайтырга чыктым. Очраклы машинаны туктатып утырыуга, кузов идәненә ятып, йокыга киткәнмен. Шау-шуга уянып китсәм, янда беркем юк, баш очыннан гына дошман самолеты бомбалар яудыра. Минем хәтта пистолет та юк, учебкада корал бирмиләр. Утырам шулай баш түбәсен учым белән каплап. Сугыш беткәннән сон да, Польшада тагын бер ел хезмәт иттем әле.

***— Диплом эшегез итеп «Галиябану»ны сайлыйсыз. Режиссер булып эшли башлагач,***

***беренче хезмәтегез «Отелло». Икесе дә классик әсәрләр, алар арасында күпмедер дәрәҗәдә охшашлык та бар...***

— Авырлыклар булды дип хәзер инде әйтә алмыйм. Мин бит татарча укымадым. Авырлык, татар телен, татар мохитен белеп бетермәүдә булса булгандыр.

***— Режиссер булып эшләгән дәвердә, йөзгә якын спектакль куйгансыз. Академия Театрында сез сәхнәләштергән әсәрләрнең күпчелеге чит ил һәм рус драматургиясеннән. Күчмә Театрда исә үзебезнең драматургларныкы...***

— Күчмә театр бит элегрәк авыл тамашачысына йөз тотып эшли иде. Гастрольләрдә күп йөргәнлектән, репертуарны да гади халыкка аңлаешлы, якынрак темаларны күтәргән әсәрләрдән төзи идек. Тинчурин әсәрләрен бик яраттым.

***— Укып чыккач пьеса ошады да ди… «Чын мәхшәр әсәр сәхнәгә куелырга алынгач башлана», ди кайбер режиссерлар. Авторлар белән каршылыклар була идеме?***

— Бик үк түгел. Автор сиңа ошамаса, аңлашу булмаса, эшкә тотынудан мәгънә юк. Аяз Гыйләҗев, Әхәт Гаффар, Илдар Юзеев әсәрләре кызыклы иде...

***— Үзегез куйган спектакльләрне яңадан куярга мөмкинлек булса, кайсын куяр идегез?***

— Алешинның«Палата»сын куяр идем...

***— Режиссер буларак әниегез киңәшенә колак сала идегезме?***

— Әни бик акыллы һәм талантлы кеше иде. Күчмә Театрда мин бит аның эшен кабул итеп алдым. Мин куйган спектакльләрне, премьера вакытында, үзе куйган кебек бик җитди карап, дулкынлану хисләрен кичергәнен сизә идем. Әнинең ничек эшләгәнен сабый чактан ук күреп үстем бит, аның мәктәбен узуым белән бәхетле.

***— Сәхнә, театр тормышы үзеннән җибәрми, диләр. Сез, өлкән яшьтә булуыгызга карамастан, һаман да эштә, татар драматургиясен баету юлында. «Дөнья драматургиясеннән үрнәкләр» китабында У.Шекспир, О.Уайльд, Б.Брехт һ.б. сезнең тарафтан яңа гына тәрҗемә ителгән әсәрләре. Театрлар өчен әзер хәзинә.***

— Бу безнең Диләрә белән бергә уйланылган эш иде. Әлеге китапка алты классик әсәр керде. Кечкенәдән чит ил әдәбиятын укып үскәнгәме, үзем аларны күп сәхнәләштергәнгәме, чит ил классикасы бик якын миңа.

***— Әлеге китабыгызны тәкъдир итү кичәсендә «Хатынны ничек кулга алырга?» спектаклен сәхнәләштерү турында сөйләгәндә, шаярып: «Тормышта Диләрә үзе мине кулга алды» – дидегез. Диләрә апаны күпләр таләпчән, кырыс укытучы итеп искә ала. Фән — җитдилек таләп итә , ә сезнең эш киресенчә, хисләргә бай булуны өстенрәк күрә...***

— Вак-төяк аңлашылмаучанлыклар белән бер-беребезне борчымадык, көчебезне кирәклерәк гамәлләргә багышладык. Кайтсын иде әле ул чаклар кире!

***— Спектакльләрне нинди күзлектән чыгып карыйсыз?Режиссер буларакмы, әллә гади тамашачы булыпмы?Баргалыйсызмы театрга?***

— Еш булмаса да, баргалыйм. Ниндидер тәнкыйть күзлегеннән чыгып карамыйм. Кайвакыт уйлаганым бар: хәзерге артистлар әсәрдәге вакыйгага ышанып бетеп уйнамыйлар кебек. Үзең ышанмаган әйбергә кешене дә ышандырып булмый бит ул.

Югары сәнгатебезнең йөзек кашы, милләтебезнең горурлыгы булган Сәйдәшләрне, Мохтар Мутиннарны күреп белгән, бу якты дөньяда бер гасырга якын гомер кичергән аек акыллы, зиһенле, зыялы өлкән кешедән күп нәрсәне беләсем, ишетәсем килү теләге көчле булса да, ялыктыру булыр кебек тоелды. Ике-өч сәгатьлек сөйләшү барышында Равил ага гел аяк өсте булды, сөйләгәндә дә утырып торуны белми, кем турында сүз чыкмасын, йөгереп барып фотографиясен, ул кеше белән бәйле берәр истәлек-сувенир алып килә. «Мин арый торган кеше түгел, — ди ул, борчылганымны сизеп, — чөнки тормышымда терәгем булырлык көчле кичерешләрем күп булды». — Өлкән кешеләргә хас булган зарлану, кемнәндер канәгатьсезлек сүзләре дә ишетмәдем мин анардан. — «Эшлисе эшләремне иртүк планлаштырып куйсам да өлгереп бетеп булмый», — ди Равил ага ихластан. Өстәлендә журналыбызның соңгы санын күреп аның әле һаманда да безнең укучыбыз булуына да сөендем. — Гомер буе алдырдык, — диде ул киштәдәге журналларга ишарәләп,истәлек язмаларын да иң беренче «Казан утлары»на бирергә вәгъдә итте. Насыйп булсын!

**Гөлзадә БӘЙРӘМОВА**

Марс
Макаров

# ИКЕ ТӨР БӘНДӘНЕҢ ҮЛЕМЕ

*«Үлем — барын да тигезли...»*

Закир Чечен җирлегендә барган сугышларда бер аягын югалтып, гаиләсенә кайтып керде. Хатыны Фәридә бу фаҗигане башта бик авыр кичерде. Иренә күрсәтмичә генә кулъяулыгын чылата-чылата көн елады, төн елады. Бу борчуларның сәбәбе дә кирәгеннән ашкан иде шул...

Фәридә Каюмовна урта мәктәптә укытучы. Эш хакының яртысы диярлек фатир өчен түләүгә китә. Очын-очка гына ялгап яшәгән хуҗабикәгә тагын бер ярлылык бирәмлеге өстәлде; иренә, өченче группа инвалиды буларак, бары тик өч мең сум гына пенсия акчасы билгеләгәннәр, ә өстәмә мең сум компенсация акчасы исә Чечнядан бозылып кайткан Закирга аракы белән тәмәкегә генә җитәрлек. Җилкәсендә матди яктан тиешле тәрбиягә мохтаҗ ике баласы булган хатыны сәламәтлегенең зәгыйфь булуы да эш хакының бер өлешен кимереп тора.

Кайгы-борчулардан арып, Ходай шулай язгандыр инде, язмыштан узмыш юк диеп ул үзен ничек тә юатырга тырышты, чынбарлыктан барыбер качып булмас дигән фикергә килде. Әмма иң аянычлысы шул: инвалид булып кайткан иренең холкы танымаслык булып үзгәргәне ачыкланды. Элек аңа Фәридушка гына дип назлап дәшкән ире бөтенләй сөйләшми, дәшми торган булып кайтты. Элек көләч йөзле булган Закирның йөзе үзенең төсен җуйган иде. Ул минут саен балконга чыгып тәмәке пошкыта, салган көннәрендә генә бераз сүзгә керә. Аның өчен балалары әллә бар, әллә юк дигәндәй, ата тарафыннан сабый балаларга бернинди наз да, игътибар да күрсәтелмәде. Алай гына да түгел, ул юк-бар сәбәпләр табып, күзләрен иләмсез акайтып, кыргый җанвар тавышлары чыгарып акырынуларын ешайтканнан ешайта барды. Көн дә хатынынннан аракыга акча даулап тавыш куптарды. Әлбәттә, иренең эчүен ешайта башлавын сизмәде түгел, сизде Фәридә. Балаларның тынычлыгын бозмыйм дип ул кысылып булса да, гаилә бюджетыннан Закирга көн дә аракыга җитәрлек акча бирергә мәҗбүр булды.

Кичләрен анасымы, кызларымы телевизорны кабызса, эчүдән депрессиягә сабышкан Закир шунда ук кәшәкәсенең очы белән телевизорның кнопкасын басып сүндереп куя.

— Нәрсә байларның мактанганнарын, кызлар күтен, үтерешләр күрәсегез киләме, туйган инде мин ул үтерешләрдән, ә менә сезнен кан күрәсегез килә, — дип ул гел бер үк сүзләрне кабатлап, бар күршеләргә ишетелерлек итеп, ярсынып кычкырына башлый. Аннан соң шешәсендә калган аракысын эчеп, йокы бүлмәсенә кереп ава. Һәм, йокыга киткәнчегә кадәр: ата караклар,

бәдбәхетләр, Сталин кулы житми сезгә, дип, аты юллап бар дөньясын сүгеп, озак кына үзалдына мыгырданып ята да, шуннан соң гына тынычланып йокыга китә.

Хатыны аңа: «Берәр эш тап, балаларның киеме беткән, әнә, инвалидларга да эш бирәләр икән, — телевизордан әйттеләр», — дип ирен кабат-кабат кыстап караса да, уңай нәтиҗәсе булмады. Закир үзе дә берничә урынга эш сорап мөрәҗәгать итте, әмма сыңар аягына шикле караш ташлап, каравыл хезмәте бирүче хуҗалар аны кире борып җибәрәләр иде.

Шуңадыр ахрысы, бар фани дөньясына кул селтәп, ихтыяр көчен тәмам югалткан Закир, үз язмышына күнеп, җил кайсы якка иссә, шул якка борылып көн күрә башлады.

Иренең баш мие эшчәнлеге сугышта нарко-тәмәкеләр, төрле исерткечләр белән бозылган булуын Фәридә мәктәптә үзе белән бергә эшләгән укытучыларның сөйләве аша белгәнгә, эш табу мәсьәләсендә иренә башка сүз кузгатмаска булды.

Ә инвалидның бөтен юанычы — аракы иде. Хәмер куллангач, аңа дөнья яктырып киткәндәй була, әмма андый халәт бик озакка бармый шул, янә чигәсе кыса башлый, аны яңадан ярсулы хисләр били башлый. Баш миенең йокысын уяту нияте белән ул барлы-юклы акчасын бик тиз бетерә торган булып китте. Хәмер эчүдән каралган йөзләре белән гаиләсенә кайтып, көн дә җәнҗал куптара башлады.

Беркөнне ире дөнья байларын сүгә башлагач, Фәридә түзмәде:

— Син үзең кем, алкаш, әнә, бер аягы гына түгел, ике күзе дә сукыр кешеләр дә акча эшләп балаларына ярдәм итәләр, ә син?!. — диде.

Закир, хатынының каршы әйтүенә ярсуы чыгып:

— Ә... син әле олигархларны, байларны яклыйсыңмы, аларның шпионы түгелме әле син, — дип хатынына кәшәкәсен күтәрсә дә, ярсыган йөрәгенең хәле китүен тоеп, сугарга физик көче житмәде аның. Хәле китеп, ул йорт алдына чыгып тәмәке кабызды. Хатыны исә бу хәлләргә бер түзде, ике түзде, һәм, ниһаять, алкаш иренә шундый ультиматум ирештерде:

— Йә эчүенне ташлыйсын, йә өйгә кайтып кермисең, балаларның нервысын саклау өчен мин бөтен усаллыкка барачакмын, — диде өстәл өстенә йодрыгы белән каты итеп сугып.

Хатынының көтелмәгән бу сүзләреннән айнып киткән Закир, бер каршы сүз әйтмичә тиз генә кәшәкәләренә таянып, урамга ыргылды. Сигаретын кабызган иде — фильтр өлеше яна булып чыкты. Ул лач итеп жиргә төкерде, аннан тирә-юньгә күз салды. Урамдагы бар кешеләр дә аңа боевиклар булып күренә иде. Кулында шартлагыч граната кысып торткан сыман ул бар көченә йодрыгын йомарлады. Шулчак бөтен дөньясын шартлатасы килде кебек аның.

...Беренче атналарда ул ялгыз яши торган инвалид, шешәдәш дустында куныш йөрде. Фатир хуҗасы, анысы да алкаш, Закирдан да кызу канлырак булып чыкты. Беркөнне, пыяла чистарта торган техник спиртны кирәгеннән артык эчеп, ике дус бәхәскә керделәр дә, чак кына сугышмыйча калдылар. Закирга дустының фатир ишеген теге яктан ябарга туры килде.

Ничек кенә авыр хәлдә калса да, ул хатынына кайтып егылырга кыймады. Гаиләсендә булган җәнҗалларны искә төшереп, беравык аны үкенү кебегрәк хисләр биләде, балаларының куркынган күзләре күз алдына килде. Ул бераз йомшарып китте бугай, күзеннән чыккан яшьләрен җиңе белән сөртеп, шул кирәк мина, дип үз-үзенә пышылдады һәм кая барганын үзе дә белмичә кәшәкәләренә бөтен тән авырлыгын салып, күзе кая карый — шул якка юнәлде.

Закирның, әлбәттә, законлы рәвештә фатирны бүлү мөмкинлеге дә бар

иде, әмма ул үзенең гаебен танып, болай да матди мохтаҗлыкта яшәгән гөнаһсыз хатынын, балаларын кызганды, шуна да андый уйны вөҗданы кабул итмәде. Анын бары тик үлеп котыласы гына килде. Җинел үлем ысулларын да эзләп карады. Озак уйлаганнан соң, яши алган кадәр яшәргә инде, дигән төпле уйга килде. Шулай итеп, язмыш җиленә бирелде. Кайда туры килде — шунда кунды, кем ризык бирә — шуны ашады. Солдатка алынганчы баһадир кебек булган Закир, чын мәгънәсендә бомж тормышын башлады. Сүнеп бара торган күнелен күтәрү өчен буш шешәләр тапшырган тиен акчаларына кабымлыксыз спирт кушылган арзанлы сыекчаларны кулланганнан сон, тора-бара ул үзенең хәлсезләнә баруын сизә башлады. Бер чарасыз калган Закир хәтта шуңа кадәр барып житте ки, кибет кырына басып, сорана ук башлады. Әмма салмыш йөзен күреп, кешеләр аңа тиен-акчалар сузарга ашыкмыйлар иде.

...Бервакыт ул хәле бетеп, базар каршындагы чүплек өемендә аунап яткан буш аракы шешәсен иелеп алыргамы, юкмы дип икеләнеп, колак төбен кашып торганда, якында гына бик зәһәр көлү тавышларын ишетте. Гади көлү генә түгел иде бу, мыскыллап көлү тавышы иде. Бәс, караса, ун метр чамасы гына читтә ялтырап торган кара төстәге япон машинасы янында затлы киемнән ике ир-ат Закирга күз атып, буыла-буыла көлеп торалар. «Болар крутойлар, олигархлар токымыннан», — дип уйлап куйды Закир. Ә тегеләр анын ягына карап, көләләр дә көләләр. Шуларнын берсе — кырган башлысы:

— Кара әле, Николо, мин Америка бомжлары кебек безнен Россия бомжларын да кесә телефоны белән йөриләр ахры, дип ялгышканмын икән бит, — дип тагын да катырак, буыла-буыла шаркылдап көлүен дәвам итте. — Шушы чучело безнең якка яны белән баскан да, безгә күренми торган ун колагын кашып тора икән ләбаса. А...ха...х...ха...

Бу ачы, мәсхәрәле көлү тавышы, Закирнын иң тирәндәге җан кылларын сызландырып җибәрде. Кайчандыр үзендә булган, хәзер исә сүнеп бетеп бара торган горурлык хисләре җан түрендә янә туып, тышка бәреп чыкты һәм ул нишләргә дә белмичә, үзеннән көлүче адәми затларга ачулы карап, бер кәшәкәсен өскә күтәреп, мылтыктай төзәп: «Мин сезгә күрсәтермен әле, варюгалар», — дип пышылдады. Шул мизгелдә боевик дошманнарыннан да дошманрак күрде ул аларны. Утлы корал урлап кайтмаганына да үкенеп куйды хәтта.

Көн буе ашамаганлыктан хәлсезләнгән, жаны кыйналган хәерче пар кәшәкәләрен җиргә куеп, бүлтәеп торган чүплек өстенә «лык» итеп утырганын үзе дә сизми калды. Йөрәгенен ярсуын басарга тәмәкесе дә юк иде ичмаса. Ул янында гына аунап яткан, яртылаш кына тартылган сигарет төпчеген алып кабызып җибәрде һәм шулчак анын зиһенендә бер өметле уй чагылып китте. Бик ач көннәрендә ашатучы бер кешесе бар иде анын. Ул — Закирнын яшьлектәге беренче мәхәббәте — Зөлфия иде. Менә шул Зөлфия хәзерге вакытта бай, хәлле клиентлар гына кереп ашап-эчеп чыга торган кафеда официант булып эшли икән. Закирнын танышы житкерде аңа бу хәбәрне. Байлар йөри торган кафе булганга, ир ачлыктан бик интеккән чакларда гына, куркып кына залнын иң кырыйдагы өстәл янына кереп утыра торган иде. Зөлфия исә анын тормышынын фаҗигале булуын белеп, аны кызганып, үз исәбенә йә бәрәңге боткасы белән тавык ите, йә затлы солянка ашын алдына китереп куя торган иде. Сирәк кенә өстәмәгә тәмәкелек акча да биргәли иде. Шулай да Закир анда еш керергә яхшысынмый иде.

...Ә бүген исә ул, ачлыктан башы әйләнеп, тукланып чыгу өмете белән, Зөлфия эшләгән шул кафега юнәлде. Кафе каршында туктап торган кара

япон машиналары күзенә чалынды, һәм нигәдер йөрәге жу итеп китте. Шулчак аның колагында зәһәр көлү тавышлары яңгыраган кебек тоелды. Бу сәер мизгелдә якындагы бакчаның агачларына кунган эре-эре кара каргалар кинәт шомлы авазлар чыгарып каркылдый башладылар. Ул гына түгел, кайберләре Закирга күз атып, аның баш түбәсеннән үк каркылдап очып үтә башладылар. Алар очып китәләр дә, тагын Закирның баш өстенә түбәнәеп, янә иләмсез каркылдап очып югалалар. Шулчак Закирның нигәдер ашау теләге дә беткән кебек булды, ә йөрәге еш-еш тибә башлады. «Каргалар киләчәк мәетне сизеп, башка төрле иләмсез тавыш белән каркылдыйлар» дигән гыйбарә барын белә иде ул. Моның яхшы билге түгел икәненә инана башлады бугай ул. Шунадыр, аның бөтен эчке халәтен шомлы хисләр биләп алды.

...Ачлык хисе үзенекен итте. Закир шикле уйларны зиһененнән куаларга тырышып, кафе ишеген ачты. Клиентлар шактый иде. Байларның зал эчендәге иң кырый өстәлне сайлаганнарын белеп, ул бер атна элек үзе утырган урынына килеп утырды, әмма залда официант Зөлфия күренмәде. Авырып эшкә килмәгәндер, дип уйлады Закир. Башка яшь кыз өстәлдән өстәлгә йөгереп ниндидер аш-су ташып йөри иде. Төшке ашка кергән кайбер эшмәкәрләр ризыкларын ашап бетермичә ашыгып чыгып китәләр. Шуңа өметләнеп тәмам ачыккан Закир түземлелек белән балык эләккәнен көткән мәче сыман, кеше ашаганын карап, авыз суларын йотып утырганда, аш-су өләшүче яшь кыз Закир янына килде. Ул: «Абый, нинди заказ бирәсез», — дигәч, Закир каушап, ни әйтергә дә белми торганнан соң: «Ә... мин ашыкмыйм, бер кешене көтә идем», — диеп алдашырга мәҗбүр булды. Никадәр ач булса да, кафе хезмәткәрләре күрерләр дип шүрләп, чит өстәлдәге калган ризыкларны алып ашарга кыюлыгы җитмәде аның. Байлар кафесы аның өчен үз калыбы түгел иде шул... «Бистро»га керәсе калган, анда үз кешеләр, дип уйлап куйды ул. Анда ул үзен иркен тота, оялмый, калдык-постыклар белән азмы-күпме булса да туенып чыга. Сирәк кенә ярты бокал сыра да тәтеп куя иде аңа. Урта хәлле мужикларның кайбер мәрхәмәтлеләре аны хәтта йөз грамм аракы белән дә сыйлап чыгаралар иде.

...Шулай уйланып утырганда, Закир каршысына яңак битләре бүлтәйгән таза гына ир заты килеп утырды. Ул тәкәббер кешеләргә хас күз карашын официант кызга юнәлтеп, кулын изәп аны үз янына чакырды һәм заказ да бирде. Озак та үтми, аның алдына салат, нәни матур графинга салынган коньяк, ә сонрак кызарылып куырылган дүрт тавык боты китереп куйдылар. Такыр башлы ир, коньягын йота-йота, авызын чапылдатып, ашарга керешге. Ул тиз арада ике тавык ботын тәвәккәлләп, калган ике ботын салыр өчен целлофан пакет эзләп, портфеленә казына башлады. Шулчак ачлыктан түземлелеге беткән Закир:

— Әфәндем, шул калган ике ботыгызның берсен миңа бирегезче, зинһар, әнә шул калган бер кисәк ипи белән! Ходай сезгә икенче яктан кайтарыр, — дип әйтеп кенә өлгерде, такыр баш Закирга усал карап: «Кайсы яктан кайтарыр икән синең Ходаең миңа ул тавык ботын? Мин тавык ботын эшләп алам, синең кебек кешедән теләнеп йөрмим. Дармоед, менә кем син. Бюджет акчасын пенсия дигән булып, эшләмичә ашап ятасыз сез, гарип-горабалар. Ә менә минем хәтта этем дә эшли, ул минем йортымны саклый. Шуңа күрә дә мин менә бу ике тавык ботын этемә ашатам», — дип тавык ботларын целлофан пакетка сала башлады. «Әфәнде, мин бүген бер тамчы ризык капмаган, бер ботын гына бирегезче, һич булмаса, бер кисәк ипиегезне генә алыйм», — дип Закир өстәлдәге ипи кисәгенә кулын сузуы булды, шулчак такыр баш аның кулына сугып:

— Пошёл вон, чучело, тавык ботын сина биргәнче, мин этемә бирәм, — дип ул кулын изәп, официантка китәргә җыенганын белгертте.

Шушы минутта ач гарипнең барлык булган нерв күзәнәкләре хәрәкәткә килде. Ул мәсхәрәләнүгә түзмичә, кинәт кенә кызып китеп, такыр башның кулыннан целлофан пакетын тартып алды да тавык ботының берсен пакеттан чыгарып:

— Мә, монысын да үзең тыгын, нигә эткә бирәсең? — дип ияген кысып алып, такыр башның авызын ачтырды һәм тавык ботын тамак төбенә кадәр зур көч белән этеп кертте. Шулчак теге бичараның күзләре акаеп калды һәм ул шул секунд эчендә тын ала алмыйча, хырылдап утыргычыннан идәнгә авып төште. Кафеның залында хатын-кызлар чинавы, ыгы-зыгы башланды. Шул ук минутта теге бәндәнең кулына пистолет тоткан тән сакчысы кафе залына йөгереп керде. Ул башта идәндә үлеп яткан шефының тамагыннан тавык ботын тартып чыгарды. Аннан үтерүчене кем икәнлеген шунда ук төшенеп, йөзләре агарган, бармаклары таш кебек катып калган Закирның гурласыннан буып алып, пистолет түтәсе белән чигәсенә бар көчкә китереп сукты. Бичара, гөрселдәп идәнгә ауды, берничә тапкыр ыңгырашты һәм мәңгелеккә тынып калды.

Ризык бүлешүнең фаҗигасы шулай тәмамланды. Беркем дә, ни прокурор, ни Аллаһы аларга ярдәм итә алмады.

...Икенче көнне, ике төрле тормыш кичергән — бай да, хәерче дә — җир куенына иңдерелде. Икесенең дә үле гәүдәләре өстенә салынган туфраклары бер төсле — кара туфрак иде...

Бай адәмне бик зурлап, зиратның иң алгы рәтенә җирләделәр. Кабер ташлары да кыйммәтле гранит таштан эшләнгән иде. Ә хәерче адәмне зиратның иң ерак коймa буендагы җиргә күмделәр. Аның кабере урынында узган-барганнарны җәлеп итәрлек берни дә юк иде...

...Мәрхүмнәр күмелгән көнне башта җәйге җылы янгыр сибәләп узды, аннан соң балкып Кояш чыкты. Байның да, хәерченең дә кабер өстенә мәрхәмәтле Кояш үзенең нурларын тигез сипте...

---

## Авторлар игътибарына

Редакциягә кульязма җибәргәндә түбәндәге документлар булу мәҗбүри:

1. Паспорт күчерелмәсе (титул, прописка бите).
2. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы күчерелмәсе.
3. ИНН күчерелмәсе.
4. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез.
5. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп).

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Кызыл Чапчак

Кызыл Чапчак авылы Түбән Кама районында, район үзәге Түбән Кама шәһәреннән – 33, жирле үзидарә үзәге Югары Чаллы авылыннан 6 чакрым ераклыкта утырган.

Авыл атамасы тарихи белешмәләрдә, географик-статистик хезмәтләрдә искә алына. Авыл янында борынгы болгар чорларына мөнәсәбәтле шәһәрлек һәм Имәнкискә кабиләләренә нисбәтле авыл хәрабәләре билгеле.

1870 елда Кызыл Чапчакта 103 йорт булып, аларда 372 ир-ат һәм 364 хатын-кыз яшәгән, бер мәчет һәм мәдрәсә булган. Авыл халкы умартачылык белән шөгыльләнгән.

Кызыл Чапчак авылында күренекле кешеләр дә яшәгән. «Татар әдәбияты тарихы»нда (Т. 1. Казан 1984, 443 – 444). Тажетдин Ялчыголның бөтен эшчәнлеге Татарстан жирлеге белән бәйләнүе күрсәтелгән. Ул башта Кече Сонда, соңыннан Жирекле, Кызыл Чапчак, Мәлем авылларында балалар укыта, халык арасында табиблек итә һәм әдәби ижат белән шөгыльләнә.

Кызыл Чапчак авылы халкы Сары айгыр җыены үткәргән. Жыенда иң кызык мизгел ат чабыштыру булган.

Авыл аксакаллары сөйләвенә караганда, авылның беренче урыны монда түгел, бәлки Олы Саз кырыйлап Кече Аты (Үчкә) авылы белән ике арадагы ызанга якын төштә булган. Авылны Олы Саз кырыйлап Кече Атыга таба сузылган дип тә әйтәләр. Анда хәзер дә баз урыннары беленеп тора, әвен ташлары күренә. Зиратны ызан кырыенда ук булган дип сөйлиләр. Бу жирне хәзер Йортлар өсте дип йөртәләр. Ул заманда авыл бик кечкенә һәм бу тирәләр суга ярлы булган. Шуңа аны Коры Чапчак дип йөрткәннәр. Су аз булу сәбәпле, халык Зәй суы буена күчәргә мәҗбүр булган. Монда да юан-юан агачлар, калын урман үскән. Халык агач төпләп чәчүлек жир ачкан.

Зәй елгасының аргы ягы тоташ урман була. Элекке урман калдыклары булган ауган агачлар әле хәзер дә Зәй ярыннан урыны-урыны белән тырпаеп тора. 1880 елларда Югары әрәмәдә (тау аслатып Зәйгә кадәр) куе шомыртлык булган. Атларны эзләп-эзләп тә таба алмагач, аларның кайдалыгын белү өчен туры юлга менеп караганнар.

Авыл аксакаллары сөйләвенә караганда, авыл шактый борынгы. Моны тарихи мәгълүматлар да раслый. Кызыл Чапчактан бер ярым чакрымда гына археологлар борынгы болгар чорларына мөнәсәбәтле шәһәр хәрабәләре билгеләгән. Һ.В.Йосыпов бу авыл зиратында XIII – XIV гасырларга караган кабер ташы язмалары таба. Кызыл

*Дәвамы. Башы 2006 елның 6нчы санында.*

Чапчак басуында Кала Тау дип аталган урын бар. Кала Тауның бу ягында Изгеләр зираты булган. Бу топонимнар да авылның борынгы икәнлеген күрсәтеп тора.

Кызыл Чапчак дигән сүз нәрсәне аңлата?

Авыл халкы кисмәк ясап сата торган булган. Ә кисмәкне чапчак дип йөрткәннәр. Чапчак атамасы шуның нигезендә барлыкка килгән дигән фикер яши. Ләкин тарихи чыганаклардан күренгәнчә, авыл Чапчакка кадәр Кыпчак дип йөртелгән, ә «кызыл» сүзе аңа соңыннан гына тагылган. Кыпчак атамасы шул рәвешле Чапчакка әйләнгән дә куйган.

Тарихтан билгеле булганча, кыпчак дип йөртелгән кабилә-кавемнәр күп төрки халыклар, шул исәптән татарлар этногенезына да катнашкан. Шуңа күрә хәзерге Татарстан һәм аның белән чиктәш төбәкләрдә кыпчакларга мөнәсәбәтле атамалар табылу гаҗәп түгел. Шундый атамаларның берсе — Кыпчак елгасы. Ул — Мөшеге кушылдыгы. Мөслим районы Исәнсеф авылындагы Кыпчак чишмәсе, Сарман районы Рангазар авылындагы Кыпчак күле атамалары кыпчак этнонимына барып тоташа. «Кыпчак»лы атамалар тарихи чыганакларда, халык авыз иҗаты әсәрләрендә искә алына. Ык һәм Сөн тирәсендә XVIII йөздә Кыпчак һәм Сарыш-Кыпчак волостьлары булган. Тарихи чыганакларда Казан ханлыгы дәверендәге Кыпчак бушлыгы (пустошь) билгеләнгән.

М.Әхмәтҗановның шәҗәрә мәгълүматларыннан күренгәнчә, Азнакай районы Сарлы авылы халкының хәзер инде юкка чыккан Кыпчак авылы кешеләре белән кардәшлеге ачыклана. Сарлы атамасы шулай ук кыпчаклар белән бәйләнешле. Академик В.В.Бартольд фараз итүенә караганда, сары — кыпчак этнонимы. Кайчандыр хәзерге Баулы районындагы Урыссу һәм Әлмәт районындагы Елховой авылы янында яшәгән, кыпчакларга мөнәсәбәтле уйгыр кабиләләренең бер өлеше, монгол яуларыннан соң урыннарыннан кузгатылып, көньяктан килгән кыпчак кабиләләренең басымына түзә алмыйча, төньяк һәм төньяк-көнчыгышка таба күчә.

Кыпчаклар турында беренче хәбәрләр VIII йөзгә карый: уйгыр каганы Моюн-Чура истәлегенә куелган һәйкәлдә «төрки-кыпчаклар» дигән язма бар. VII йөз ахырларында кыпчаклар Саян-Алтай таулары тирәсендә яшәгән. Аларның борынгы ватаны — Иртеш елгасының югары һәм урта агымы. Кыпчакларның ыру-кабилә төркемнәре ак һәм кара нугайларда, кырым татарларында, татарларда, башкортларда, каракалпакларда, кыргызларда, үзбәкләрдә, алтайлыларда, госманлы төрекләрендә, гагаузларда һ.б. билгеләнгән.

«Кыпчак» сүзе төрки халыклар антропонимиясенә дә нык үтеп кергән. Мари антропонимиясендә чыгышы белән төрки исемнәр аз түгел. XVIII йөздә дә әле мари исемнәре арасында Копчак антропонимы кулланылган. Гәреч юлы өстендәге Өченче хусирмә волостенда (1678 елгы халык саны алу материалларында) Ямолка Копчаков, ягъни Кыпчак улы Ямол теркәлгән. Галимнәр фикеренә караганда, кыпчак антропонимы урта гасырларда марилар арасында киң кулланылган. Бу исә бер өлеш мариларның килеп чыгышында кыпчак компоненты катнашуын күрсәтә. Борынгы мариларның кыпчаклар белән бәйләнеше иске кыпчак теленнән алынып, мариларның көндәлек тормышына һәм мари теленең төп сүзлек фондына кергән башка исемнәрдә һәм сүзләрдә күренә.

Менә шул рәвешле без, Чапчак атамасының килеп чыгышын, ягъни этимологиясен тикшерә торгач, Мари Иленә, Каракалпакстанга, Алтайга, Кырымга һ.б. төбәкләргә барып чыгабыз һәм атаманың төбендә кыпчак этнонимы ятканлыгына ышанабыз.

## Кызыл Яшьләр

Кызыл Яшьләр авылы Питрәч районында, район үзәге Питрәч авылыннан 7 чакрымда, җирле үзидарә үзәге Күн авылыннан — 2, Казаннан 52 чакрым ераклыкта урнашкан.

Кызыл Яшьләр колхозлашу чорында (1928 елда) оешкан. Авылларда колхозлар төзелә башлагач, күрше авыллардагы яшь гаиләләр бергәләшеп

(колхозга оешып) аерылып чыккан. Шул нигездә кечкенә бер авыл барлыкка килгән.

Олылар сөйләвенә караганда, авыл исеме болайрак килеп чыккан. Күрше авылдан килүчеләр кызыксынып: «Бу авылның исеме ничек?» — дип сорагач, аларга: «Монда кып-кызыл яшьләр генә яши», — дип җавап кайтарганнар. Шуннан бу авыл Кызыл Яшьләр булып киткән.

Кызыл Яшьләр авылы кечкенә, бары бер генә урамнан тора. Ул ике яктан урман белән чорнап алынган. Авылның Кардон дип йөртелә торган өлеше урман эчендә. Урман эченә кереп торган өлешендә төзү материаллары эшкәртү цехы эшли. Монда эшләүчеләрнең тору урыннары шул цехка якын гына.

Авыл тау башына урнашкан. Болынны икегә ярып Мишә суы ага. Алда әйтеп үтелгәнчә, авылга урман бик якын. Урманда күбрәк ылыслы агачлар үсә. Шулай ук шомырт, юкә, каен, усак агачлары да очрый. Урманның кайбер урынын Усаклык, икенчесен Саз яки Шомыртлык дип тә йөртәләр. Урман юлларының да исемнәре бар. Питрәчкә бара торган якны Караклар юлы, ә капма-каршы яктагысын Фәрзәнә юлы дип йөрткәннәр.

Авылның хуҗалык көтүе йөри торган болыны Бутиркә болыны исемен алган. Элекке елларда Кызыл Яшьләр авылына якын гына Бутырька авылы булган. Бу авылда урыслар яшәгән. Авылда бик каты янгын була, ул халыкка зур зыян сала. Шуннан соң авыл кешеләре калган йорт-җирләрен сатып читкә китәләр. Бу болын атамасы шушы авылга бәйләнешле рәвештә барлыкка килгән. Авыл утырган тауны Әби тавы дип йөртәләр. Ике авыл уртасында Тегермән чишмәсе бар. Монда элек тегермәнче үзенең гаиләсе белән яшәгән, ә тегермән аның үзенеке булган. Чишмә тегермән янында булганга, Тегермән чишмәсе дип аталган.

## Уразай

Уразай авылы Кукмара районында, район үзәге Кукмара эшчеләр бистәсеннән 26 чакрымда, җирле үзидарә үзәге Сәрдекбаш авылыннан — 2, Шәмәрдәннән — 19, Вятка Аланыннан 34 чакрым ераклыкта утырган.

Авылның тирә-ягында таулар, аларга менеп карасаң, авыл ярым ай рәвешендә күренеп тора. Аның икенче ягында зур иген басулары җәйрәп ята. Авыл уртасыннан Сәрдек суы ага. Ул Бөр елгасына килеп кушыла.

Олылар сөйләвенә караганда, Уразай авылына нигез салучы кеше Вилданов Ногман Вилдан улы булган. Ул 1889 елда гаиләсе белән монда килеп төпләнгән. Әкренләп авыл зурая башлаган.

Хәзерге көндә авылда 100ләп хуҗалык исәпләнә.

Авылда мәчет 1900 елда салынган була. Аның манарасы киселми кала. Кисәргә кеше таба алмыйлар. Бер кеше дә манара кисәргә риза булмый. 1987 елда авыл халкы мәчетне янарта, һәр җомга саен мәчеттән азан тавышлары ишетелеп тора.

Элек авылда мәдрәсә дә булган. Мулла дин сабагы укыткан. Соңыннанрак Харрас исемле абзый гарәп графикасын өйрәткән.

Авыл яныннан бик матур чишмә ага. Суыннан авыз итсәң, бөтен кайгы-хәсрәтләрең, сагыш һәм моңнарың бетә диләр. Авыл янында урманнар да шаулап үсә. Авыл халкы көзен анда гөмбә җыя, җәй көне җиләккә йөри.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# Р

**РАБГУЗИ** Насреддин бине Борһанеддин (13 йөзнең 2 нче яртысы – 14 йөзнең 1 нче яртысы), язучы. Төрки телендә язган. Чыгышы б-н Алтын Урданың көнчыгыш төбәкләреннән. Хәрәзм өлкәсенә караган Рабат Угызда казый булып тора. Тәхәллүсе шул урын исеме б-н бәйле. Аннан соң Насыйр әд-дин Тукбуг әмиренең яраннары арасына эләгеп, Мәвараэннәһернең үзәгенә күчеп китә. Кульъязма күчермәләр рәвешендә татарлар арасында киң таралган «Кыйссасел-әнбия» («Пәйгамбәрләр турында кыйссалар», 1310-11) исемле дини әсәр авторы. Иң беренче күчермәләреннән 1698 дә Бимәк-суфи тарафыннан күчерелгән нөсхә санала. 1859 да әсәрне Р.Әмирхан бастыра. Аннан соң ул Казанда берничә тапкыр кабат басыла. Мәдрәсәләрдә дәреслек рәвешендә кулланыла. Т.Ялчыгол, Г.Утыз-Имәни иҗатларына йогынты ясаган.

Әдәб.: Татар әдәбияты тарихы. К., 1984. 1 том; Каюмова И. Ар-Рабгузи // Ислам на территории бывшей Российской империи: Энцикл. словарь. М., 2001. Вып. 3.

**РАДЗИЕВСКАЯ** Софья Борисовна (12.6.1892, С.-Петербург – 17.7.1989, Москва), язучы. Петербургта Бестужев Югары курсларын тәмамлый (1918). Урта Азия, Себер, Манчжурия, Урал, Кавказ буенча экспедицияләрдә катнаша. Ташкентта үсемлекләрне саклау ин-тында (1925-33), Мәскәүдә СССР Җир эшләре халык комиссариатында (1934-36) эшли. 1937 дән Казанда: икмәк элеваторында, азык-төлек складларында инспектор-этномолог, 1944-49 елларда производствода химик булып эшли. 1950-58 елларда Республика лекцияләр бюросында методист, Казан ун-тының фәнни китапханәсендә кульъязмалар бүлеге мөдире. 1986-88 елларда Севастопольдә, 1988 дән Мәскәүдә яши. Китапларының күпчелеге балалар өчен язылган (төп тема – табигать). «Хайваннар турында хикәяләр» («Рассказы о животных»), «Пуш» (икесе дә Ташкент, 1932), «Сазлык Робинзоннары» («Болотные Робинзоны», 1959), «Алтын эзләп» («За золотом», 1962.), «Балалар, сезнең өчен» («Для вас, ребята!», 1965), «Пум» (1966), «Рам и Гау» («Рам һәм Гау», 1967), «Батырлык утравы» («Остров мужества», 1969), «Буй-буй сырт» («Полосатая спинка», 1979) һ.б. китаплар авторы. Хикәя һәм повестьларында Р. мавыктыргыч формада үсентеләр, хайваннар, төрле табигать күренешләре турында бай мәгълүматлар бирә. Халыклар дуслыгы ордены б-н бүләкләнә (1982).

Әсәр.: Избранное. К., 1972; Повести и рассказы. К., 1982.

Лит.: Ихсанова Л. Олы бәхет иясе: Софья Радзиевскаяга 60 яшь // Казан утлары. 1982. №6; Ахунов Г. Родник добра: К 90-летию со дня рождения С.Б.Радзиевской // Лит. Россия. 1982. 2 июля.

*Р.Мусабәкова.*

**РАДИЩЕВ** Александр Николаевич (20.8.1749, Мәскәү – 12.9.1802, С.-Петербург), инкыйлаби фикер иясе, язучы. Чыгышы б-н Конай (Кунай) бәк нәселеннән. «Иреклек» («Вольность», 1783), «Ф.В.Ушаков тормышы» («Житие Ф.В.Ушакова», 1789), «Петербургтан Мәскәүгә сәяхәт» («Путешествие из Петербурга в Москву», 1790) исемле әсәрләрендә патша самодержавиесен һәм крепостной хокукны тәнкыйть итә. 1790 Себергә (Илимск төрмәсе) сөрелә. Сөргенгә барганда һәм кире кайтканда Идел һәм Кама буйлап Пермь ш. хәтле бара. Юлда алган тәэсирләрен «Себергә сәяхәт язмалары» («Записки путешествия в Сибирь», 1979; 1907 дә басыла) китапларында чагылдыра. Беренче китабында Вятка елгасы, Арча, Казан шәһәрләре, татарлар һ.б. халыклар турында мәгълүмат урнаштырылган, икенчесендә Алабуганың истәлекле урыннары (Шайтан каласы), «юл унаенда очраган табигать матурлыгы» («Осланда: кич алдыннан биек тауга мендек, аннан

*Дәвамы. 2005 елның 4нче санынан басылып килә.*

бик матур күренеш ачыла») җентекләп тасвирлана, 1797нен 25 маеннан 9 июньгә кадәр Казанда булып, анда алган тәэсирләр бирелә («... сокланып шәһәр буйлап йөрдем... Арча кырында атна буе бәйрәм булды... Болак күле, андагы көймәләр... Казансудагы Адмиралтейство бинасы... Күкерт заводы. Кремль, Болактагы пристань... Уң якта Казансуның боргаланып аккан ермаклары, алардан ерак түгел тау башында куе булып үскән агачлар арасыннан Зилант монастыреннән чиркәү манаралары күренеп тора; аның артында Казан күренеше ачыла. Иң башта ак Кремль диварларының бойницалары; Кремль тирәсендә төрле корылмалар, өйләр башлана...»).

Әсәр.: Полн. собр. соч.: В 3 т. М.-Л., 1938-52.

Әдәб.: Знаменитые люди о Казанском крае. К., 1990.

*Б.А.Канеев.*

**РАДУДИ** (Рәдүди) Гобәйдулла Габделмөэмин углы (1885, хәзерге Оренбург өлкәсе Сакмар р-ны Рәдүт а. – 28.11.1912, шунда ук), шагыйрь. «Кыйссалы вә хиссалы шигырьләр» (1907), «Гөлзаре сыйбиян» («Балаларга чәчәк түтәле», Оренбург, 1907), «Мәктәп өчен шигырьләр» (Оренбург, 1909) исемле шигъри җыентыклар авторы. Аерым шигырьләре «Дин вә мәгыйшәт», «Шура» журналларында, «Бәянелхак» h.б. газеталарда басыла. «Табигатькә сәяхәт, яки тарихы табигыйә» (Оренбург, 1908), «Тәсһиле җәгърафия» («Гадиләштерелгән география», Оренбург, 1911) исемле дәреслекләр төзүче.

Әдәб.: Гилазев З.З. Татарская литература начала XX века в книжных изданиях. К., 2005.

**РАЗОВ** Мирһади Мирзаян улы (22.10.1960, Актаныш р-ны Аеш ав. туа), шагыйрь, тележурналист. Казан ун-тын тәмамлый (1991). 1979 елдан КамАЗ төзелешендә эшли. Яр Чаллы шәһәрендә чыга торган «Нур» газ-сы редакциясендә башта корректор, соңрак әдәбият, сәнгать һәм тел бүлеге мөдире (1989-93) вазифаларын башкара. 1995 тән Яр Чаллы шәһәр советы халык депутатлары һәм мэриясенең телерадиотапшырулар редакциясендә (2006 дан «Чаллы-ТВ» дәүләт телерадиокомпаниясе) әдәби-нәфис һәм иҗтимагый-сәяси тапшыруларның өлкән мөхәррире. «Кыйбла», «Әйлән-бәйлән», «Чаллы утлары», «Шигъри дулкын» исемле телевизион тапшырулар алып бара. Р.ның шигырьләре «Идел» альманахында (1978), «Беренче карлыгачлар» (1988) күмәк җыентыгында басылып чыга. «Моңлы биләү» (Чаллы, 1993) исемле җыентык авторы. Аның шигырьләренә композиторлар И.Закиров, В.Әхмәтшин, А.Якшембәтев, З.Хәйретдинов, В.Агапов тарафыннан көйләр язылды, популяр җырлар булды («Җиләкле җәй» җыентыгы, Чаллы, 2003). 1997 дә «Чаллы сиреньнәре» исеме белән аның җырлары тупланган аудиокассета дөнья күрде.

**РАМАЗАНОВ** Габдерәшит (19 йөз ахыры - 1919), шагыйрь. 1910-14 елларда шигырьләрен «Шура» ж-лында, «Йолдыз», «Кояш», «Идел» h.б. г-таларда бастыра. «Габдерәшит Рамазанов шигырьләре» (1910), «Дәртле уку» (1912), «Уку гөле» (1912).

Әдәб.: Татар шигърияте: XX гасыр башы. К., 2004.

**РАМАЗАНОВ** Гыйлемдар Җиһандар улы (16.6.1923, Башкортстан АССРның Бәләбәй кантоны Иске Балак ав. – 25.8.1993, Уфа шәһ.), шагыйрь, әдәбият белгече, филол. фәннәре докторы (1966), Башкортстан АССРның атказ. фән эшлеклесе (1983). Башк. пед. ин-тын тәмамлагач, (1949) Бөре шәһәрендә укытучылар ин-тында һәм педагогия уч-щесында башкорт теле һәм әдәбияты укыта. 1955 тән «Совет Башкортстаны» г-тасы баш мөхәррире. 1958-89 да СССР ФАсе Башк. филиалының Тарих, тел һәм әдәбияты ин-ты фәнни хезмәткәре. Матбугатта 1937 елдан басылып килә. Күп әсәрләрендә сурәтләнгән үзәк тема – Бөек Ватан сугышы. Шагыйрь сугышчы геройның күңел кичерешләрен ачып бирә («Беззең быуын», Уфа, 1947; «Якты юллар», Уфа, 1952; «Һөйөү һүзе», Уфа, 1955; «Йәшлек юллары», Уфа, 1958 җыентыклары), сугыш эпизодларын күз алдына китертә (рус теленә тәрҗемәдә «Разговор с отцом», Уфа, 1966; «Разговор гор», Уфа, 1967; «Две реки», Уфа, 1978 поэмалары), яу батырларына һәм сугыштан соңгы хезмәт казанышларына дан җырлый («Атай янында», Уфа, 1966; «Заман еле», Уфа, 1970; рус теленә тәрҗемәдә «Полвека», М., 1974; «Илле яшьтәгеләр», Уфа, 1975; рус теленә тәрҗемәдә «В стране Салавата», М., 1975; рус телендә «Звёзды за бой, звёзды за труд», М., 1979 җыентыклары). Р.ның поэзиясенә публицистик интонация һәм ачык чагылып торган гражданлык позициясе хас. Аның балалар өчен язылган шигырь-поэмалары да патриотизм һәм гражданлык хисләре белән сугарылган («Гәжәп сәйәхәт»,Уфа, 1959; «Ерән кашка», Уфа, 1975 җыентыклары). 1980 еллар ахыры – 1990 еллар башы иҗат чорында

Р. үткән вакыйгаларга тәнкыйди күзлектән кабат бәя бирә. Шигырьләрендә Ватан, халык, дуслык, милләт кебек төшенчәләргә күбрәк мөрәҗәгать итә, заман психологиясен ачырга тырыша. Р. - әдәбият белгече буларак та танылган шәхес. Анын башкорт әдәбияты турында матбугатта басылган мәкаләләреннән тыш, «Башкорт поэзияһендә совет кешеһе образы» (Уфа, 1956), «Мәжит Гафури ижады» (Уфа, 1965), «Сайфи Кудаш: Литературный портрет» (М., 1989) дигән хезмәтләре дә бар. Башкорт теленә А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, Н.А.Некрасов әсәрләрен тәржемә итә. Р.нын әсәрләре укр., белорус, казах, кырг., чуваш, груз. телләренә тәржемә ителгән. Салават Юлаев исем. Республика пр. лауреаты (1982). Бөек Ватан сугышында катнашкан. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике тапкыр Кызыл Йолдыз, «Почёт Билгесе« орденнары белән бүләкләнгән.

Әсәр.: Һайланма әсәрзәр: 2 томда. Өфө, 1972-73; Алтмыш язым. Өфө, 1983; Яшьлектә кунакта. К, 1983; Хәтер. Өфө, 1998.

Әд.:Хөсәйенов Г. Шагирзар. Өфө, 1981; Сафуанов С. Тынгы белмәй торган юлсы мин // Агизел. 1983. № 6.

**РАСИХ** (псевд., чын фам. Рәсүлев) Атилла Кадыйр улы (16.9.1916, Истанбул шәһ., Төркия – 9.5.1996, Казан), язучы, зоотехник, а.-х. фән.канд. (1950). 1929 елдан Казанда яши. 1931 дә М.Вахитов исем. Казан сабын з-ды каршындагы ФЗӨ мәктәбенә укырга керә. 1934 кә кадәр шунда эшли, күптиражлы «Вахитовец» г-тасы редакциясе каршында оештырылган татар әдәби түгәрәгенә мавыгып йөри, шигырьләр, хикәяләр яза. Казан вет. ин-тын тәмамлый (1938). 1940 елга кадәр ТАССР Жир эшләре комиссариатында зоотехник булып эшли. 1947-64 тә Казан вет. ин-тында доцент. Сугышка кадәр үк юмористик хикәяләре белән таныла: «Касса янында» (1934), «Таныш кеше» (1938), «Кызыл чүлмәк» (1940). Бөек Ватан сугышы елларында матбугатта хикәяләре, очерклары, фронт темасына караган язмалары басыла, разведчиклар турында «Бәхет орлыклары» (1945) исемле мажаралы повесте дөнья күрә. Сугыштан соң Р.ны күбрәк авыл тормышы кызыксындыра. Ин уңышлы әсәрләреннән – «Дустым Мансур» (1953; русчага тәржемәдә «Мой друг Мансур», М., 1973), «Язгы авазлар», 1963; русчага тәржемәсе «Весенние голоса», М., 1977) романнары. Р. татар прозасында беренчеләрдән булып фән дөньясын сурәтләргә алына. «Ике буйдак» (1965; русчага тәржемәсе «Когда расходятся пути», М., 1968, 2 изд. 1971; Татар академ. т-рында шул исем. спектакль, 1967), «Сынау» («Испытание», 1981) романнарында институт хезмәткәрләре, фән өлкәсендә булган каршылыклар күрсәтелгән. Кабат мажаралы сюжетларга мөрәжәгать итеп, Р. балалар өчен «Урланган хәзинә» (1961), «Мажаралы повестьлар» (1966) әсәрләрен яза. Татар революционеры Х.Ямашевнын үзенчәлекле образын тудырып «Ямашев» (1 кит. 1968; русчасы 1975), «Айлы төннәр» (2 кит. 1977; русчага тәржемәсе «Лунные ночи», 1979), «Ямашев» (3 кит. 1984) роман-трилогиясен ижат итә. Өч китаптан торган «Елларны чигерсәм» («Ишан оныгы», 1996; «Кәгазьдәгеләр һәм хәтердәгеләр», 1996; «Тыныч еллар күләгәсендә», 1996) романнарында Р. үзенен нәсел шәжәрәсенә, балачак хатирәләренә нигезләнеп, драматик угызынчы һәм сугыш еллары чоры кичерешләрен сурәтли, күп кенә тарихи шәхесләрнен портретларын бирә. Э.Д-Эрвильинен «Тарихкача яшәгән малайнын күргәннәре» («Приключения доисторического мальчика», 1953), А.Беляевнен «Су кешесе» («Человек-амфибия», 1959) романнарын татар теленә тәржемә итә. Г.Тукай исем. ТАССР Дәүләт пр. лауреаты. Бөек Ватан сугышында катнашкан. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт Билгесе» орденнары белән бүләкләнгән.

Әсәр.: Әсәрләр: 3 томда. К., 1986-88; Сайланма әсәрләр. К., 2003.

Әд.: Зарипова Р. Атилла Расих: Тормышы һәм ижаты. К., 2006.

**РАХМАН** (Габдрахманов) Хәбра (Хәбибрахман) Габдрахман улы (1914, Вятка губернасы Малмыж өязе Янгул а. – ноябрь 1942, Калинин өлкәсе, Максатиха тимер юл станциясе), шагыйрь. 1936 елда Казан пед. уч-щесын тәмамлый. Алабуга пед. уч-щесында укыта. Бөек Ватан сугышында катнаша. Мәскәү өчен барган сугышта яралана, госпитальда вафат була. Очерклар, «Чәчәк ява» (1937) шигъри жыентык, тәмамланмаган «Шомырт чәчәкләре» повесте авторы.

Әдәб.: Алар сафта. К., 1961.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

Нурихан
Фәттах

# ЧЕТЕРЕКЛЕ БУЛДЫ БЕЗНЕҢ ЗАМАН

ИСТӘЛЕКЛӘР



*Нурихан Фәттахның безне ташлап киткәненә дә тугыз ел булды. Вакыт уза, тормыш дәвам итә.*

*«Ташлап» диясе килми. Ул вакытлыча гына каядыр киткәндер сымак. Өйдә фотолары, портреты эленеп тора. Төшкә керә, әйбәт керә. Ара-тирә булса да каләмдәшләренең истәлек-мәкаләләре басыла. Радиодан иссеме ишетелеп китә. Кыскасы, Нурихан безнең белән.*

*Нуриханның кулъязмаларын тәртипкә китергәндә, моннан 25 ел элек — 1988 елларда ук язылып, бер җирдә дә басылмаган «Истәлекләр»гә тап булдым.*

*Сугыш еллары, аннан соңгы дистә елларга сузылган ачлык, газап, михнәтне безнең буын кешеләре яхшы хәтерли. Әлбәттә, һәр чорның үз кыенлыклары була. Әмма бүгенгеләр арасында краннан 1-2 көн кайнар су килмәүне дә трагедия итеп кабул итүчеләр юк түгел.*

*Элеккеге белән хәзергене чагыштырып карау өчен, моннан тыш Нурихан Фәттахны бөтенләй үк онытып бетермәсеннәр әле дигән максаттан, язучының «Истәлекләр»еннән бер өзекне укучыларга тәкъдим итәргә булдым.*

**Руфина ФӘТТАХОВА**
*(Нурихан Фәттахның хатыны)*

## Граммнар турында

Бер көнне ашап утырганда тоз турында сүз чыкты. «Аш тозсызрак булса да ярый, кешегә көненә сигез грамм тоз житә», — диде хатын. «Каян беләсең син аны?» — дидем мин, киреләнеп, ачуланган сыман итеп. Белгәндер инде, хатын — врач. Институтта укыганда сөйләгәннәре исендә калгандыр, йә булмаса медицинага кагылышлы берәр мәкаләдә очраткандыр. Кешегә көненә сигез грамм тоз житүенә мин каршы түгел. Мин аны каян белгәнлекләрен дә беләм кебек. Моның бер дә катлаулыгы юк. Берәр галим тота да тикшерә, кешенең ашаган-эчкән азыгын анализлап карый, фәлән-төгән. Шуннан соң инде нәтижә дә чыгара: кешегә иң киме сигез грамм тоз житә, ди.

Аш-суга кагылышлы китапларда, бакчачыга һәм үзлегеннән дару үләннәре кайнатып-төнәтеп эчүгә кагылышлы кинәш-белешмәләрдә менә шундый жиде-сигез граммнар тулып ята. Дөньяда ин зур кыяр үстерәсең килсә, фәлән литр суга фәлән грамм калий тозы, төгән грамм магний тозы салып болгатасың да, фәлән сәгать, фәлән минут һәм фәлән секунд, фәлән температурада тоткач, бер квадрат сантиметр жиргә бер ярты грамм исәбеннән көненә өч мәртәбә сибәсең.

Мин, билгеле, юри арттырыбрак сөйлим. Ләкин чынлыкта һәр төрле акыллы киңәшләр менә шулайрак төзелгән була. Һәр төрле граммнарга, секундларга, бары лабораторияләрдә генә кулланыла торган микъдарларга тигезләнеп менә шундый киңәшләрне, белешмәләрне укыдыммы, миндә үзеннән-үзе бер каршылык

хисе барлыкка килә. Граммнарга, секундларга һәм шуларны язып ятучы акыллы кешеләргә карата.

Беренчедән, анын кинәшендә әйтелгән һәртөрле калий, магнийлары, азот-мазутлары, глицерин, теофедриннары сатуда булмый, булса, аларны өй шартларында төгәл итеп үлчәргә үлчәве, шарты булмый. Аннан соң беркем андый үлчәү белән булашып та тормый.

Менә шуна күрә минем еш кына граммнарга, вак-төяк саннарга бүленгән һәртөрле кинәшләрне җенем сөйми. Ләкин мондый яратмауның икенче төрле сәбәпләре дә бар. Сәбәп шул — сугыш елларында күп күрдек без ул граммнарны. Граммнар белән яшәдек, граммнар белән исән калдык. Ләкин шул ук граммнар безнен җанны кыйды.

1946 елны Казанга укырга килгәч, безгә ипигә, иткә, майга, тагын нәрсәгәдер карточка бирделәр. Ипие ярты кило иде бугай, ите-мае ничә грамм булгандыр — хәтерләмим. Тик шунысы гына хәтердә — укудан чыгу белән, ин элек үзебезнен магазинга ашыгабыз. Анда һәрвакыт кеше күп була. Бик озак чиратта кысылып, этелеп-төртелеп торасын да, үзенә тиешле граммнарынны алып, дөньяда ин бәхетле кеше сыман торагына кайтып китәсен. Сатучыларнын кулы уйнап кына тора. Кайчы белән ул тиз генә синен карточканнан тиешле номерны, тиешле числоны кисеп ала, ипине пычак белән кисеп, граммына кадәр төгәл итеп үлчәп бирә.

Карточка Янавылда да булды. Ләкин карточка анда бары эшчеләргә, урындагыларга һәм һәр төрле хезмәт ияләренә генә бирелде. Бакчасы, хуҗалыгы булган, беркайда эшләмәгән кешеләргә карточка бирелмәде. Янавыл карточкасынын нормасы, категориясе дә төрлечә булды. Ул елларда, карточка ягыннан, тимер юл эшчеләре ин бай кешеләр исәпләнелде. Ярма, тоз һәм тагын төрле кием-салым бирелде. Райком, райсполком кешеләренен дә карточкасы югары категорияле булды.

Без инде алар белән тиңләшү турында уйлый да алмадык. Алар гомумән тук булдылар. Янавыл райкомынын беренче секретаре Галиевнен хатыны безнен татар урта мәктәбендә башлангыч классларда укытучы иде. Мин анын укытучылар белән сөйләшә-сөйләшә ишектән чыгып барганын хәтерлим. Зур гәүдәле, юан һәм чибәр генә бер хатын иде ул. Бигрәк тә анын юанлыгы хәтердә калган. Ул елларда Янавылда башка юан, симез кеше булмагандыр кебек. Юан-симез татар хатыннарын мин бары Казанга килгәч кенә күрдем бугай.

Янавыл түрәләренен үзләре өчен ябык-яшерен магазиннары бар иде. Шулай бервакыт мин базар янындагы шул «ябык» магазинга барып кердем. Керсәм, ягымлы елмаеп сатучы хатын белән сөйләшеп шул Галиева апа басып тора. Сатучы ана май үлчи. Мае безнен әвәләнгән кечкенә кисәк түгел — таудай булып калкып тора. Үзе шакмаклы, үзе ниндидер катыргы тартмага салынган, тартма башына чит телдә нидер язылган. Шундый зур кисәкле май булуына мин шаккаттым. Бөтен магазинга тәмле май исе, колбаса исе таралган. Шунда ук шат, тук, ягымлы Галиеванын киеменнән җиңелчә хушбуй исләре дә килә кебек. Сатучынын майны пычак белән кискәнен, үлчәгәнен, шытырдавык ак кәгазьгә төреп бәхетле хатынга биргәнен мин күз дә алмый карап тордым. Галиев бичәсе магазиннан чыккач, мин дә анын артыннан чыктым һәм күпмедер җир анын артыннан ияреп бардым.

Өйгә кайткач инәкәйгә әллә нинди яналык әйткән кебек сөенеп: «Мин Галиев бичәсен күрдем!» — дидем. Бу вакытта ул инде мәктәптә укытмый башлаган иде бугай. Шуңа күрә бик сирәк күренә иде.

Хезмәт иясе булганлыктан, безнен инәкәйгә дә ай саен ипи карточкасы бирәләр иде. Ит, май, шикәр, тоз, ярма кебек нәрсәләр юк. Бары пешкән ипи генә. Кечкенә — өч йөз грамм. Мина, эшләмәгән кеше буларак, йөз илле грамм. Без ул җәйне бик җәдәштек. Мине нишләптер исемлеккә кертмәгәннәр. Өч йөз грамм чиле-пешле арыш ипиен инәкәй өч шакмакка бүлә дә, бер шакмакны тагын икегә бүлә. Кайчагында без аны иснәп кенә торгандай торабыз, күбесенчә инәкәй шакмаклардан аш пешерә. Аш дигәне шул — чуен чүлмәккә салып суда кайната, анын янына берничә чөгендер яфрагы сала. Безнен өй янында уч төбедәй генә җир бар иде. Инәкәй шунда кишер, чөгендер ише нәрсәләр утырта иде. Чөгендернен

яфрагын өзәрлек булгач та менә шулай көненә ике-өч мәртәбә аш пешереп ашый торган идек.

Авылда бернинди карточка-фәлән булмады. Сугыш елларындагы авылның хәлен сөйләп бетерерлек түгел. Авыл үзе иген үстерде, үзе яз көне черек бәрәңге ашады. Бөтен илне ачлыктан, дошманнан авыл саклап калды, үзе ачтан кырылды. Авылның чәчәргә җире, аты-коралы, мал-туары бар. Болай караганда, авыл бай, авыл хәлле. Ләкин авылның эшләр кешесе бетте, таза ирләрнең барысы да сугышта, өлкәнрәк яшьтәгеләре хезмәт армиясендә. Әзме-күпме буй җиткән малайларны армиягә алалар. Йә булмаса мәҗбүри рәвештә шәһәргә озаталар фезүгә (фабрично-заводское обучение). Ул елларда шундый сәер һәм куркыныч сүз барлыкка килде. Авылда бары хәлсез картлар да хатын-кыз, бала-чага. Менә шулар җир сөрә, чәчә, ура, ашлыгын ташый. Иң авыр эш алар өстендә. Эштән беркем карышмый, ләкин шунысы яман — эшләргә хәл юк. Хәл булыр иде — ашарга юк. Иң авыры язгы-җәйге айлар. Уракка төшкәнче. Бу бер биш-алты айга сузыла. Бу вакытта күпчелек авыл кешесенең бернинди граммы булмый. Граммнар бары чиле-пешле беренче көлтәдән генә башлана. Иң элек арыш урагына төшәләр. Арышның тулысынча өлгереп җиткәнен көтеп тору юк. Бераз ныгыды исә сабагы саргылт-яшькелт килеш уралар да, көлтәләрне сүтеп, мунча ягып, мунчада киптерәләр. Аннан аны уалар, ягъни табагач белән сугалар да, төтен исе килеп торган беренче ашлыкны тегермәнчегә алып китәләр. «Беренче ашлык — фронтка!» — икәнен һәркем белсә дә, беренче ашлыкны шулай да иң элек халыкка тараталар. Күпләп түгел. Граммлап кына. Тигез итеп фәлән грамм ашлык бирелә, йә булмаса он бирәләр. Шуннан соң инде халыкны эшкә әйдәп, куалап торасы юк. Халык үзе ашкына басуга. Урак шулай башлана. Урак башлану белән унбиш процент законы башлана. Беренче ашлыкны, әлбәттә, иң элек дәүләткә тапшырырга кирәк. Ашлык күбрәк тапшырылган саен халыкның тамагы туграк була. Әйтик, бер атнада колхоз 100 центнер ашлык тапшыра икән, унбиш центнерын председатель шул атнада эшләгән хезмәт көненә колхозчыга бүлеп бирә ала. Ашлык сугылып, дәүләткә тапшырып бетергәнче менә шушы унбиш процент законы дәвам итә. Дәүләт планын тутырганнан соң һәм киләсе елга чәчү фондын булдырганнан соң күпмедер ашлык калса, менә шул калдыкны хезмәт көненә фәлән грамм белән бүлеп бирәләр. Мондый колхоз иң бәхетле, иң бай колхоз була. Күпчелек хуҗалыклар дәүләт планын, йә чәчүлек фураж фондын да тутыра алмыйлар. Андый чакта авыл утырып ач кала, ягъни күздән үк. Ә кышын ничек чыгарга да, яна ашлыкка ничек барып егылырга?

Анысы беркемне кызыксындырмый. Ул елларда кайбер колхоз председательләре хәйләләп маташты. Колхоз уракка төшкән, беренче ашлык тапшырылган, ә ул, район җитәкчелегеннән яшереп, ачтан шешенгән колхозчыларга, граммлап түгел, килограммлап ашлык тараткан! Председательнең шәхси дошманы булса, «дошман» шундук районга чаба. Шундук районнан тиешле кешеләр килеп төшә, халык байлыгын әрәм-шәрәм итүче председательне шундук алып китәләр. Һәрвакыт шулай булды дип әйтәсем килми. Район үзәгендә дә ике куллы, ике аяклы кешеләр утыра. Ләкин шулай да булды андый хәлләр. Фәлән авылның председателен утыртканнар икән дигән сүзләр ишетелмәде түгел, ишетелде.

Бер елны яз көне «Октябрь юлы» газетасында колхозларда тары игене үстерү турында хөкүмәт карары басылды. Шул карарны җентекләп укыганым хәтердә. Карарда колхозларда тары игү звенолары оештыру кирәклеге, җирне ничек эшкәртү, ничек чәчү турында җентекләп, тәфсилләп язылган. Анысы мине бөтенләй кызыксындырмады. Мин гомумән шундый зур карарларда болай да билгеле нәрсәне җентекләп сөйләүне анламый идем. Мине барыннан да элек колхозчыга түләү мәсьәләсе кызыксындырды. Ул вакытта әлеге карарны зур яналык сыман мактап язганнар иде. Ләкин никадәр зур яналык күрергә тырышып укымыйм, шулай да һәр төрле процентлардан, граммнардан башка мин берни тапмадым. Иң нык истә калганы шул: тары җирен караган, көз көне тары унышын җыеп алуда катнашкан һәр кешегә бер кило тары өчен унбиш грамм тары яисә башка ашлык бирергә диелгән иде.

## Курку

Курку минем канга сеңгән. Бәләкәй вакытта мин караңгыдан курка торган идем. Төнлә, ялгыш күзне ачсаң, тирә-ягында серле караңгылыктан башка берни күрмәсәң, тормыш туктаган кебек була. Аннан соң дөбердәп күк күкрәвеннән, чатнап яшен яшьнәвеннән куркам. Бала вакыттагы бер күренеш хәтердә бик нык уелып калган. Җәй. Төн, караңгы. Йокы аралаш мин ниндидер ят, ямьсез, куркыныч тавыш белән күк күкрәвен ишетәм, уянып китәм. Көтмәгәндә кайдадыр, нәрсәдер чатнап, ярылып китә, тәрәзәдән бик көчле булып ниндидер шомлы яктылык бәреп керә. Яшен яктысы. Мин идәндә әткәй белән инәкәй арасында ятам. Кемдер минем башымнан сыйпый. «Курыкма, Алла бабай шайтаннарына кычкыра» — ди, аңлатып. Мин «алла»ның кем икәнен бик үк белмим, ләкин «бабай»ны беләм. «Бабай» булгач, «алла» да миһербанлы булырга тиеш. Шулай да мин Алла бабайдан куркам.

Аннан соң мин үлемнән куркам. Иң куркынычы — үлем. Аның нәрсә икәнлеген шулай ук аңлап бетермим. Ләкин үлгәннән соң җирдәгечә яшәп булмаганлыгын сизенәм кебек. Минем үлгән этләрне, песи, тавык ише нәрсәләрне күргәнем бар. Алар миндә һәрвакыт кызгану һәм кот алыну тойгысы тудырды. Кайчан да булса үземнен дә шундый ук булачагымны күз алдына китерәм дә, чәчләр үрә тора. Аннан соң мин ят этләрдән, ата каздан, урамнан үтеп барган хәерчедән, сәләмә киемле кешеләрдән, кулына капчык тоткан картлардан куркам.

Без кирәгеннән артык тузына-шаяра башласак, безгә гел әйтәләр: фәлән бабаң, яисә анда хәерче, капчыкка салып алып китәр, диләр, авылга килгәч балалар җыеп йөри икән алар, диләр. Берәр килешсез сүз әйтсәң, карышсаң, җыласаң, Алла бабай ишетер, Алла бабай башына сугар дип куркыталар. Ипи валчыгын яисә берәр изге нәрсәне идәнгә төшереп җибәрсәң, киреләнеп шуны иелеп алмый торсаң — бетте, шулай ук куркытып куялар, Алла бабай күрсә, кирәгенне бирер, диләр.

Монсы аның көндәлек, гадәти, «куркулар». «Курку»ның башка төрләре дә күп. Өйдә сызгырырга ярамый, сызгырганны олылар гомумән яратып житкермиләр. Сызгырган кеше сызгырып калыр, диләр. Сызгырып калу — ул нәрсәдәндер мәхрүм булуны, ятим калуны яисә ярлыланып калуны аңлата. Бигрәк тә безне судан куркыталар. Тирән суга карарга ярамый, суга төкерергә ярамый. «Су иясе тартыр», «тотып алыр». Авылдагы, авыл янындагы иң куркыныч урыннар — мәчет һәм зыярат. Мәчет яныннан тын гына, кычкырып сөйләшми генә үтеп китәргә кирәк. Зыярат яныннан үткәндә шулай ук кычкырып сөйләшергә, зыярат ягына бармагың белән төртеп күрсәтергә ярамый, төртеп күрсәтсәң — бармагың шешә. Шулай да төртеп күрсәтәсең икән, шундук бармагына төкереп куярга кирәк. Безне шулай ук урманнан, җыланнан, аю-бүредән, урман иясеннән, шүрәледән-фәләннән куркыттылар.

Иске, ташландык йорт урынында йөрмәскә кушалар. Иске йортның иясе тияргә, зәхмәт кагылырга мөмкин. Язгы ташу вакытында гел куркытып кына торалар. Фәлән авылда фәләннең малаен су иясе алган. Якын бармагыз — су тарта ул. Ничек тарта — һич аңлап булмый. Аңлатып тормыйлар.

Курка-курка, өркә-өркә әкренләп без курыкмаска өйрәндек. Ләкин без үсә барган саен, аңлы-белемле була барган саен яңадан-яңа куркулар, куркытулар барлыкка килде.

Кичләрен өйдә, өстәл янында ашап-эчеп утырганда яисә йокларга әзерләнеп йөргәндә кинәт кемдер урам як койма тактасына таягы белән китереп суга. Өйдә шундук шомлы тынлык урнаша. Тиз генә тәрәзә янына барып үзеннең өйдәлегенне белдермәсәң, ачулы тавыш ишетелеп китә.

— Вазифаттәй! Өйдәме? Клубка собраниягә барыгыз, — ди ачулы хатын-кыз тавышы, яисә бригадир кычкыра. Монысы гадәттә ир кеше була. Кычкыручы әллә ни куркыныч түгел. Иң куркынычы авыл советыннан яисә колхоз конторыннан килгән кешенеке. «Яңавылдан кеше килгән — заемга язылырга!» яисә «түләп бетермәгәнсең, итеңне түләп бетермәгәнсең», дип кычкырта башласалар, куркудан тыннарын кысыла.

Килеп кычкыручы кайчагында бер-ике сүз әйтә дә китеп бара, кайчагында тиргәшергә тотына: «кат-кат йөртмәгез, мин дә кеше, фәлән-төгән.»

Яшәби карангы тәрәзәгә капланып нидер анлата яисә «барырмын» дип шундук ризалык белдерә. Еш кына ул бармый кала, чөнки заемга түләргә акча юк, ит салымын түләргә бар куанычы булган сарыгын суясы килми. Авыл советы дежурные янадан килеп житә, кычкырына. Без инде ул вакытта йокыга киткән булабыз. Икенче килүендә бөтен өй эче уяна. Шомланып, тынны кысып без тынлап ятабыз — нәрсә булыр икән? Яшәби күз яше түгеп ала, карангыда мыштыр-чыштыр килеп киенә дә, чолан ишеген тыштан бикләнми торган богау йозагы белән элдереп китеп бара. Без инде анын кайтканын көтеп тормыйбыз, авыр тойгы белән йокыга талабыз.

«Заем», «салым», «налуг» сүзләре көздән кабатлана башлый, язга кадәр дәвам итә. Авыл советына, кантурга гына чакырсалар, ансы әле артык куркыныч түгел. Куркынычы Янавылдан кеше килсә. Кайчагында милиция килгән диган сүз дә ишетелеп куя. Алар килсә, төбенә төшмичә туктамыйлар. «Салым» ул мәжбүри еллык салым гына булмый. Анысын яшәби бернинди каршылыксыз түләп бара. Ләкин анын гадәти салымга, налуг, заемга катнашы булмаган өстәмә салымнары да күп була. Сугыш елларында төрле фондларга, «ярдәм»нәргә түләү аерча тенкәгә тиде.

Тапшырылган нәрсә, түләнгән акча өчен квитанция язып бирелә. Яшәби «кәпитәнсәләрне» күз карасы кебек сакларга тырышты. Ул үзе укый-яза белми, шуна күрә квитанцияләрне бары кәгазьнен төсе, формасы буенча гына аера. Аларны ул кырык кат чүпрәккә төреп, без үрелеп алмаслык жиргә — шүрлек башына кыстырып куя. Кирәк чагында чүпрәк янчыгын ала да, квитанцияләрне таратып ташлый да, үзенә кирәклесен эзләтә башлый. Ник? Чөнки иткәме, йонгамы өстәмә салым килеп төшкән, имеш. Кантурдагы фәлән кыз әйткән, фәлән ел өчен сезнен итегез түләнеп бетмәгән икән, диган. Мондый сүз ишетеп яшәби бик кәефсезләнеп кайта да, кәефсезләнеп кәгазьләрен актара башлый. Әгәр кирәкле кәгазь кисәген табып, фәлән кызга түләгәнлеген исбат итә алса, шунын белән тынычлана. Исбат итә алмаса? Жылый-жылый, каргаша-каргаша янадан түли. Булды андый хәлләр дә. Кантурда утыручылар халыкнын наданлыгыннан, куркаклыгыннан бик оста файдаландылар. Квитанциягә киметеп язулар, киметеп үлчәүләр, янадан түләүләр әледән-әле булып торды.

Безне бигрәк тә сөт белән тинтерәтәләр иде. Сугыш елларында бар карап торганыбыз сыер булды, ин кыен чакта да яшәби сыерны бетермәскә тырышты. Ин авыры, ин жаваплысы сыер өчен кышлык азык әзерләү булды. Жәй көне эш арасында, эштән сон качырып, хәтта төннәрен кеше әз-мәз печән юнәтергә тырышты. Кыш көне урлап бәләкәй чана белән басудан, колхоз эскертеннән салам ташыдык. Колхозчыга печән бирү, салам бирү ул елларда бөтенләй диярлек булмады. Барысы да — колхозныкы, барысы да колхоз өчен. Колхозчы теләсә нишләсен. Кайбер председательләр, бригадирлар «теләсә нишләгән» кешене күрмәмешкә салыштылар. Ләкин районнан кеше килеп төштеме, өй борынча йөреп, абзар-лапаслар тирәсендә эзләнеп, бар нәрсәне тентеп, нәрсән бар, шуны алып чыгып киттеләр. Ярый ла шунын белән исән калсан — «законсыз эш өчен» кайчагында каядыр төрмәгә дә алып киттеләр. Сөтне яшәби яздан башлап көзгә чаклы сауды. Бер сыерга норма ике йөз алтмышмы, ике йөз сиксәнме литр иде, ахрысы. Ул вакытта сөтне хәзергечә килолап түгел, литрлап үлчиләр иде. Сөтнен майлылыгы 3.2 процент булырга тиеш, шуннан ким булса, бер литрны киметеп язалар, артык булса, арттырып язалар. Янтыкта сөт заводы бар. Анда анын директоры, кабул итүчесе, Янавылга сөт ташучысы бар. Кабул итүче менә шул процентларны әвеш-тәвеш китереп, бөтен авыл халкы өлешен ашап ята иде. Сөт заводына яшәби еш кына мине жибәрә. Мин барысын да карап торам, сөт книжкәсенә язып куйганда да дөрес язылуына игътибар итәм. Яшәби үзе барса, кабул итүче еш кына алдап яза. Яшәби сизенә, ләкин берни эшли алмый. Безнен сөт гадәттә куе була, майлылык еш кына дүрт процентка житә. Яшәби хәйләне белми, сөтенә бер тамчы су кушмый. Гонаһтан курка. Чынлыкта дүрт процентны киметәләр, 3 яисә 2.8 процент итеп язылар.

Казанда укыган чагында, ялга кайткач, бервакыт яшәби мине сөт заводына алып китте.

Кабул итүчесе кайчандыр бергә укыган Тәгъзимә булып чыкты. Нишлисен, кирәк булгач, Тәгъзимә белән ачуланышырга туры килде. Ләкин ул, билгеле, дөрес язам дип кыешты. Хәтта яшәбинең үзен гаепләде бугай әле.

## Левитан

1942 елның кышында Сталинград янында бөек сугышның кискен борылышы булды. Дошман гаскәрләре җинелде, дошман арт бирде. Шул көннән сон безнен күнелләрдә өмет, ышаныч чаткысы уянды. Ачлык, мохтаҗлык, һәр төрле кайгы-хәсрәтләр һәм унайсызлыклар бер якка, читкә авышты. Ул вакытта мин әле шактый аңсыз булганмын, беркатлы булганмын. Ләкин яхшыга таба барганын мин дә бөтен җаным-тәнем белән тойдым. Ул елларда радио юк дәрәҗәсендә. Авылда ул болай да юк. Радио Янавылда гына бар. Радиоузелдан чыбык белән тапшырыла. Шул вакытта без көр, тантаналы бер тавышка игътибар итә башладык. Ул да булса, Левитан тавышы. Кайчаннан башлап колакка чалына башлагандыр, төгәлен әйтә алмыйм. Тик мина безнен гаскәрләрнен һәр җиңүе, зур шәһәрләрне алуы, зур елгаларны кичү, гомумән барлык әһәмиятле җиңүләр, унышлар Мәскәү үзәк радиосы дикторы Левитан тавышы булып анлашыла. Ягымлы, горур һәм тантаналы тавыш. Көр һәм көчле тавыш. Аеруча басым белән, бар көченә кычкырып әйткәндә Левитан тавышы бөтен илгә бирелгән илаһи бер команданы, хәтта йөзләгән туптан атучы салют бирүне хәтерләтә.

Левитан һәрвакыт сөйләми. Ул бары Совинформбюро карарларын, Генералиссимус Сталин приказларын гына укый. Ул сөйләр алдыннан көчле, дәртләндергеч сигнал тапшырыла. Шул сигнал ишетелү белән колаклар үрә тора, йөрәк тибеше туктап калгандай була. Үзеннән-үзе репродукторларга якынрак киләсең. Яналык, бик зур яналык ишетү өчен кешеләр җыелыштагы кебек радио тирәсенә җыелыша башлыйлар.

Мин әле дә Левитаннын кыска-кыска карар-боерыкларын гына түгел яртышар, берәр, икешәр сәгатькә сузылган белдерүләрне дә эһ тә итмичә, тортелмичә, бер тында укып чыкканын хәтерлим. Мин анын Совет гаскәрләренен Германия җиренә аяк басулары турындагы, Висла, Одер елгаларын кичүләре, Берлинны алулары турындагы, ниһаять, Җиңү бәйрәме турындагы тапшыруларын хәтерлим.

Нинди бәхетле, нинди горур һәм батыр идек без ул елларда!

Менә сугыш бетте. Яна җирләр, яна шәһәрләр алынды, җиңү-тантана турында хәбәрләр ишетелми башлады. Ләкин Левитан тавышы радиодан әледән-әле ишетелеп торды. Элеккечә ул бары әһәмиятле белдерүләрне генә укыды. Элеккечә үк анын тавышы көр-көчле, тантаналы. Ләкин бу тавышта хәзер куркыныч шом бар, кисәтү-куркыту бар. Янау һәм дәһшәт бар. Партиягә, халыкка каршы ниндидер корткычлар фаш ителгән. Алар иптәш Сталинны агулап үтермәкче булганнар!

Ин элек шул турыда Левитан хәбәр итә. Безнен белән бергәләп Гитлерны җинешкән, без ач-ялангач чакта безгә кукәй, сөт порошоклары, киптерелгән ботка концентратлары, кием-салым җибәреп яткан, Ленд-лиз килешүе буенча безгә хәрби корабльләр биреп торган американнар нишләптер ин явыз империалистларга әверелгәннәр. Алар безгә атом бомбасы белән, тагын әллә нәрсәләр белән яныйлар икән. Бу турыда шулай ук ин элек Левитан сөйли.

Бөтен илгә, бөтен дөньяга көтмәгәндә зур куркыныч килә. Иптәш Сталин үлгән! Иптәш Сталин... мөмкинме бу?! Юк, мөмкин түгел кебек иде. Америка империалистлары безгә атом бомбасы ташлап, безне җир йөзеннән себереп түгәргә мөмкин иде, ләкин мондый хәл... Юк, юк, мондый нәрсә була торган түгел. Күрәсен, монда да берәр төрле корткычлык булгандыр.

Ул көннәрдә мин Чистайда идем. Илле икенче елнын көзендә Татарстан АССР составында Казан һәм Чистай өлкәләре төзелде. Бөгелмә өлкәсе дә оеша башлады.

Шулай итеп татарның милли хокуклары кинәйде. «Сталин байрагы» — «Сталинское знамя» газетасы чыгарырга күченеп киттем. Чистай ул көннәрдә кара кайгыга батты. Башта авырып егылган Сталинның хәле турында сәгать саен белдерү биреп тордылар. Аннан соң үлем хәбәре әйтелде.

Радиодан сүзләрне Левитан гына укыды. Сүз арасында кат-кат кайгы музыкасы тапшырылды. Багана башларында туктаусыз репродукторлар ыңгырашты. Радиога, музыкага, Левитанга кушылып Чистай ыңгырашты, бөтен ил, бөтен дөнья ыңгырашты. Бер көнне безне клубка җыйдылар. Юлбашчының үлем хәбәре тапшырылгач, радиодан Мәскәүдәге политбюро утырышын тыңладык. Беренче булып Молотов сөйләде. Сүзнең эчтәлеге — кайгы, чиксез кайгы һәм кемнәргәдер янау, куркыту. Берияның грузин акцентлы тавышында күз яше сизелде. «Шайтан күзе сидекле була» — дигән сүз бар. Кирәк чагында шайтанның гына түгел, иблиснең дә күзе сидекле була ала икән.

Сталин үлгән белән генә Левитан тавышы тынып тормады. Левитанга туктаусыз эш арта гына барды. Югары дәрәҗәдәге берәрсен фаш итәләрме яисә океан артындагы, чикнең теге ягындагы берәрсенә бармак яныйлармы — Левитан сөйли.

Утыз-кырык ел эчендә фаш итүләр, янаулар, кисәтүләр, акыл өйрәтүләр күп булды. Барысын да Левитан сөйли. Кайчандыр яшәргә өметләндергән диктор тавышы куркыту, янау-кисәтү тавышына әйләнде. Урамда барганда, берәр өйдә утырганда сугыш елларында барлыкка килгән радиосигнал тапшыра башладылармы, Левитанның ашыкмыйча, үз-үзенә ышанып, дәһшәтле итеп «Гаварит Маскыва» дип әйтүе ишетелдеме, йөрәк жу итеп китә, чәчләр үрә тора һәм эч авырта башлый. Караңгыдан, тирән судан, милиционерлардан курыккан чакларда мин эч авыртуның, ашказаны бозылуның, йокысызлыкның нәрсә икәнен белмәдем. Безнең ашказаннар ул вакытларда чуерташны да эретерлек шәп эшли иде. Илленче еллардан эч авыртулар, йокысызлыклар, нервы авырулары башланды. Элегрәк мин врачларга андый нәрсәләрнең сәбәпләрен рәтләп аңлата алмаганмындыр кебек. Хәзер инде бик яхшы беләм: сәбәбенең берсе — Левитан тавышы. Ул тапшырган бетмәс-төкәнмәс шом-дәһшәт һәм янаулар, кисәтүләр.

Левитан кайчан үлгәндер — әйтә алмыйм. Ләкин ул үлгәч тә Мәскәү радиосы һәм телевидениесе аныкына охшаш куркыныч тавышлы дикторлардан сөйләтте. 1983 елда көз көне Ессентукига су эчәргә баргач коридордагы телевизор шомлы, куркыныч итеп Америка «Першинг»лары турында сөйләде. Гитлерга охшаган диктор бик озак сөйләде, бик усал итеп, янә дә Левитан сыман дәһшәтле итеп сөйләде. Ул көнне дә диктор мина шактый нык тәэсир итте. Куркудан, шомланудан мин рәтләп йоклый алмадым. Шулай да, бик әһәмиятле тапшыру булса да телевизор каршында дүрт-биш кеше генә утырды. Башкалар шау-гөр килеп коридорда буталып йөрделәр, кычкырып сөйләштеләр, хәтта җырлаган тавышлар ишетелде. Бәлки аларның куркыту һәм шом-дәһшәт тәэсиренә биреләсе килмәгәндер.

*Дәвамы киләсе саннарда*

# Фәннур Сафин

*Фәннур Сафин (1948-1992) – лирик шагыйрь. Шигырьләрендә яшьлек романтикасын, күңел кичерешләрен, туган җир, табигать матурлыкларын киң яктырта. «Хушлашырга ашыкма», «Җырымда юатырмын», «Ялгыз көймә» һ.б. күп кенә танылган җырлар авторы.*

## Сагынам

**Мин дәүләтсез падишадай булам**
**читтә ялгыз калган чагымда.**
**Кояшларга карап елмаям мин,**
**Сары айга карап сагынам...**

**Тентүләрдә туздырылган йорттай**
**тәртипсез уй түгел башымда, —**
**Ераклардан җәһәт кенә килеп,**
**Син торасың кебек каршымда!**

**Мин каладан авылыма таба**
**сузылып киткән юлга күз атам.**
**Тәрәзәмне ачып, уйларымны**
**туган якларыма озатам...**

**Ак күгәрчен булып оча хыял**
**Иң бәхетле узган чагыма.**
**...Кояшларга карап елмаям мин,**
**Сары айга карап сагынам.**

## Дүрт шигырем

**Дүрт шигырем бизәр дүрт көнеңне...**
**Берсе бизәр туган көнеңне.**
**Ләкин кайсы бизи алыр икән**
**Синең гүзәл бу яшь гомереңне?!**

**Дүрт шигырем бизәр дүрт көнеңне...**
**Берсе — гашыйк булган көнеңне.**
**Иңнәреңә, нәфис иңнәреңә**
**Бәхет кошы кунган көнеңне.**

**Дүрт шигырем бизәр дүрт көнеңне...**
**Берсе бизәр туйлы көнеңне.**
**Һәм йөрермен шунда мин каңгырып:**
**— Төшемме бу, — диеп, — өнемме?!**

Дүртенчесе әле язылмаган,
Ул еракта йөри, көрсенә.
Мәхәббәттәй ак кәгазьне куям
Баш очыңа...
Минем хисләр керсен төшеңә...

***

Син ялгыштың, сөю, сайлап мине,
Мин бит башка хәзер, мин бүтән. –
Ерак ярны сагнам, әйтерсең лә
Өзгәләнәм тамак кибүдән.

Яз сулышын өрмә минем җанга,
Оныттырмак булып үземне. –
Алтын толым уйный хәтеремдә,
Азга гына йомсам күземне.

Мәктәп юлы кебек истә һаман
Беренче саф назлау–назлану.
Яланаяк чыктан атлагандай,
Һәр мизгеле үзе мең дару.

Оялчан син, сөю, хыялый да,
Шаян да син — гүя төн кызы...
Ә мин менә... тын алырга куркам,
Курыккандай
Югалтудан ерак йолдызны.

## Синең якка карап...

Синең якка карап кычкырдым бер:
— Синсез килмәс инде миңа яз!!.
Биек тауга килеп бәрелде дә
егылып төште җиргә кайтаваз...

Өзгәләнеп беткән хатларым да
давылларда очып кайталар,
Яралы кош каурыйлары сыман,
йөрәгемдә тузгып яталар...

## Фәйләсүф җан

Казан капкасын ачып кергәндә ул дингезче киеменнән иде. Үзе белән таныштыруны Татарстан Язучылар берлегеннән, редакцияләрдән башлады. Кызыграк итеп әйтте:

— Сугышта һәлак булган шагыйрь әтием Рәхим Саттар улы мин. Исемем — Ил.

— Ничек Ил!?

— Шулай инде. Менә сезгә шигырьләремне китергән идем.

— Болай адмирал-фәлән түгелсеңдер ич, дип кинаяле шаяртты «Социалистик Татарстан» гәзите редакциясенең җаваплы сәркәтибе Зәйни Төхфәт.

— Киемемне әйтәсездер. Әйе, Севастопольдә хәрби-дингез флоты училищесын тәмамладым. Хәзер университетта имтиханнар тапшырып йөрим.

Сүзендә торды шигырьләрендә әтисенең тәхәллүсен алган Ил Саттар. Киемен алыштырды. Яшь булуына карамастан, бакенбардлап кара сакал, мыек җибәрде, һай, килешә дә иде соң үзенә! Озын буйлы, болай да чибәр егеткә өстәмә бизәк иде бу.

Казанга шагыйрь булам дип кайткан Ил Саттар университетны уңышлы тәмамлады. Ничектер, шигырь белән барып чыкмады. Аның каравы, вакытлы матбугат битләрендә теге яки бу авторның иҗатына карата тәнкыйть һәм публицистик мәкаләләре, рецензияләре әледән-әле басылып торды. Фәлсәфә фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗәгә ирешә.

...Аннары чибәр егетебез күп кенә шәһәр яшьләренең күзен яндырган гүзәлкәйне эләктерде. Яшьтән үк үзем яхшы белгән Нурания Зиннәтованы әйтүем. Алар бергә укыдылар. Соңыннан Ил Татар халык иҗаты йортында методист булып эшләде, югары уку йортында мөгаллимлек итте.

Рәхим улы Ил Саттар шигырь язуны вакытында туктатты һәм дәрес эшләде. Асылда ул фәйләсүф җан иде...

## Бабачы

Мәшһүребез Гаяз Исхакый аны «сөннәтче бабай» дияр иде...

Ә ул минем белән, бәлки, шаяртыптыр, «бабачы» дип таныштты. Чынлыкта үзе, медиклар телендә әйтсәк, травмотолог-ортопед, сынган, имгәнгән әгъзаларны дәвалаучы табиб.

Гарәп Мөхәммәд Хәмид белән танышуыбыз нинди дә булса шифа эзләп йөрүдән түгел, тел кычытудан килеп чыкты. Моннан бер-ике ел элек «Казан нуры» мәчетендә, өлкәннәр белән рәттән басып, җомга намазын

укыган «орчык кадәрле» генә бер малай белән кызыксындым. Аның әчен әтисе җаваплады:

— Ояла ул. Улым Әмир болай өч телдә сукалый, — диде.

— Һәл тәтәкәлләмү бильарабияти? — дип сораган булам сабыйдан. Ул тиклем оялчан түгел икән үзе.

— Калилән, беләм, — ди.

— Сөбханалла-машалла! Татарча беләсеңме соң?

— Беләм.

— А по-русский знаешь?

— Чуть-чуть...

Балалар бакчасына йөри башлагач, малай анысын да тулаем үзләштергән.

Гарәп дустыбыз Мөхәммәд Хәмид Ливанда туып-үскән. Урта белемне үз илендә алган. Дөнья хәлләре белән кызыксынучан егет Русиядәге Татарстан җөмһүрияте, андагы уңай үзгәрешләр турында ишетеп-укып, кайбер нәрсәләрне күзаллаган. Аны бигрәк тә Казанның медицина үзәге булуы кызыксындыра. Табиб һөнәрен үзләштерергә хыялланган 18 яшьлек гарәп баласы, бер авыз сүз урысча белмәгән килеш, танышбелешсез шәһәргә килеп төшә. Эшне «нүлдән», урыс телен өйрәнүдән башлый. Моңа бер ел вакытын сарыф итә, әмма бу телне сәгатьләр буе нотык сөйләрлек дәрәҗәдә үзләштерә. Вәгазен 2013 елның Мәүлет кичәсендә зур кызыксыну белән, йотлыгып тыңладык. Безнең үтенеч буенча Мөхәммәд әфәнде Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салаллаһу галәйһи вәссәламнең тормышын мавыктыргыч дәлилләр белән бәян кылды. Табиблык һөнәре өстенә аңа ораторлык таланты да бирелгән икән.

... Казан медицина университетында алты ел төпле белем ала. Һөнәре буенча Спорт хәстәханәсендә эшли. Һич көтмәгәндә язмыш аны Австралиягә алып китә. Бөтенләйгә дип уйлый. Тик алай ук булып чыкмый.

— Ризык йөртә кешене, — ди Мөхәммәд кардәш.

Украинага кайтып, Киев медицина институтында белемен камилләштерү курсларында укый. Шул чакта үзе белән булган бер вакыйганы кызык итеп безгә дә сөйләде. Институт моны күршедәге шәһәргә бер атналык командировкага җибәрә. Кереп утыра бу автобуска. Каршы рәттә ярым ачык тәнле кызлар чыркылдашып бара. Адәм баласына ике күз бирелгән бит. Мөхәммәд бер шәйләгәч, ул якка карамаска тырышып, гөнаһысыннан баш-аяк, сумкасыннан үзе белән йөртә торган, җыйнак итеп басылган Коръән-Кәрим китабын алып, укырга керешә. Берзаман аның белән рәттән утырган ир уртасы кешенең тынгысызлануын сизә. Теге күзләре белән бөтен машина салонын айкый. Торып китмәкче була, тагын утыра. Акшарлаган шикелле йөзе агарып чыга. Озаклап-озаклап Мөхәммәдкә текәлә.

— Сезгә берәр хәл булдымы әллә, ярдәм кирәкмиме? — дип кызыксына табиб. Юлчы шуны гына көткәндәй тезеп китә:

— Сез муджахитмы (әфган вакыйгалары тәэсиредер, күрәсең), мине үтерергә җыенасызмы, хәзер автобус шартлаячакмы? — дип, Мөхәммәднең беләгенә үк ябыша. Инде табиб шүрләп төшә. Мондый акылсыз кеше ни кылмас?! Ул юлдашын тынычландырырга ашыга.

— Бу — Изге китап, Коръән. Мин үзем мөселман. Ислам кеше үтерүне катгый рәвештә тыя. Адәм баласын юк итү беркайчан да кичерелми торган олы гөнаһлардан санала. Мин террорчы түгел, гап-гади табиб, Коръәнне укып, җаныма шифа алам, — дип аңлата Мөхәммәд.

Сәфәрләре алты сәгать дәвам итә. Шул вакыт эчендә гарәп юлдашына күп нәрсәләр турында сөйли. Ислам кануннарын, аның әхлагын аңлата. Автобустан төшкәндә инде хохол кешесе, үзенең наданлыгы, күзле сукыр булуы өчен гафу үтенеп, Мөхәммәдкә тулы ышаныч белдерә. Алай гына да түгел, аны үзләренә кунакка килергә чакыра.

— Минем бу чаклы рәхәтлек кичергәнем юк иде. Жаным эреде. Күп нәрсәне аңладым. Сезгә зур рәхмәт! — дип, ихласлык белән табибның кулын кыса.

Әйе, шул вакыйгалардан соң, Мөхәммәд Хәмид Казанга кайтып төпләнә. Бик тә чибәр Гөлия исемле татар кызына өйләнә. Гөлия ханым — итагатьле, инсафлы, сабыр холыклы мөгаллимә, берничә тел белә, балаларга гарәп, инглиз телләрен укыта. Әлегә ул декрет ялында. Мөхәммәд әфәнде белән Гөлия ханым өч бала тәрбияләп үстерәләр. Олы уллары, тәүге куанычлары, мин белгән Әмир, тиздән мәктәпкә барырга җыена. Телләр үзләштерү белән мәшгуль. Мәлика белән Йосыф гаиләнең өстәмә бизәкләре, әти-әниләре нинди телдә сөйләшсәләр дә аңлап, үзләренчә җавап кайтаралар.

Табиб дустыбыз туган якларына барып, өч тапкыр Хаҗ гамәлләрен үтәп кайтты. Ул хаҗиларга житәкче дә, табиб та буларак хезмәт күрсәтте.

Бабачылыкка килгәндә, бу аның төп һөнәре түгел, сөннәтчелек гамәлен Ислам кануннары нигезендә, җиренә житкереп башкаручы савап иясе, мөселман табибы ул.Очрашкан саен төрттерәм үзенә:

— Сез кем буласыз әле, Мөхәммәд әфәнде?!

— Ба-ба-чы.

Шаяртуы да ягымлы табибның...

## Илле мең истәлек

Ай-һай, малай, илле ел эчендә илле мең истәлек калдыр әле син!..

«Социалистик Татарстан» гәзитенең элеккеге фотохәбәрчесе Мидхәт әфәнде Шакирҗанов бу саннарны атагач, татар матбугатына куйган хезмәтен яхшы белсәм дә, тәгәрәпләр китә яздым. Хәер, гәзитнең бер генә саны да ул төшергән фотосурәтсез чыкмады, берьюлы дистәләп кертелгәннәре дә булды. Шул ук вакытта республикабызның башка басмалары да буш калмады. Чын мәгънәсендә тынгысыз, эзләнүчән, «озын аяклы» фотохәбәрче иде М.Шакирҗанов. Районнарны кат-кат әйләнде. Нәтиҗәдә, әнә, редакциядә эшләгән илле ел эчендә, вакытлы матбугат битләрендә илле мең данә фотосурәте басылып чыккан. Санаган бит! Төгәллек бар шул үзендә!

Эзләнүчән дигәннән, фото сәнгатендә ниләр генә уйлап чыгармый иде ул. Әйтик, авыл жирендәге гап-гади бозаулар карачы кызны, сәхнәдәге артистка кыяфәтендә, яулык почмакларын чеметтереп, канат җәйдереп төшерә иде. Дуңгыз караучыга килгәндә, анысын ак биләүдәге чучка «малаен» беләгендә тирбәткән килеш ала фотога. Сыер савучы апайлар «җаныйларының» башын кочып, битне биткә куеп төшәләр — болар барысы да фотохәбәрченең иҗади табышы инде. Ул кукуруз игүчеләрне нишләтеп кенә бетерми иде! Үзе үстергән чәкәннәрен үзләренә үк кимертә. Терлекләр ничек ашамасын ди мондый татлы ризыкны. Ышандырырлык итеп күрсәтә белә шул хезмәт иясе халкын.

Яңа төзелә башлаган Зәй шәһәренә командировкага бардык берчакны. Кала коручыларны мактап язарга. М.Шакирҗанов монда күп мәртәбәләр булган инде, ни-нәрсәне алырга кирәклеген белеп эш итә. Төнге сменада

эшләүче кызны элеккеге танышы, кран башыннан чакырып төшереп, карангыда иннек яктырып, чәчен үз кулы белән төзәткәләп, фотога алды. Алай гынамы соң, битеннән үбеп, аркасыннан сөеп озатты. Тегесе кран башына очып кына кунды. Ихласый мөнәсәбәт нәтиҗәсе. Фотоһөнәрче кешеләрне хөрмәтләп, үз эшен яратып башкарды.

Болары әле анын баласы гына, алдарак булды анасы. Шулай берчак гәзитебездә «Васильево» шифаханәсе эшен яктыртырга дип бардык. Электричкада ук юлдашым чибәр-чибәр хатын-кызның фотосын ала торды, имеш, кирәге чыгар. «Нигә аларны минем янга чакырып утыртасың?» дим. «Архивында чибәрләр күбәер», — ди. Чыннан да Шакирҗанов төшергән андый фотолар миндә шактый. Күренекле шәхесләрне аеруча кадерләп саклыйм. Алар тарих өчен кирәк булачак әле!..

Ниһаять, шифаханә. Баш табибә, ялгышмасам, исем-фамилиясе Сөембикә ханым Шорина иде бугай, дәвалау бүлмәләрен күрсәтеп йөри. Фотохәбәрче бит ул төшереп ала да алга таба китә. Ә минем блокнотымны тутырасым бар, кемнең кемлеге белән кызыксынып калам. Тизрәк кер, дигәч, ванна бүлмәсенә үтәм. Машалла, бу фотографлар нинди генә хәлгә юлыкмый икән! Әнә, Шакирҗанов, су тулы ваннаның ике ягына атланып баскан да озын чәчләрен тузгытып йөзеп йөргән «су анасын» фотога төшереп маташа. Шәп-шәрә килеш. Юк, тегесе аз гына да тайчанмый, киресенчә, куллары белән чәчен төзәткәндәй итенә.

— Язып ал! — ди Шакирҗанов.

— Кайчан? — дим.

— Якынрак кил, сораштыр үзеннән. Тоз ваннасы икән бу, бик файдалы, — дип, дәваланучыдан уздырып мактарга кереште фотограф.

Юк инде, бер күргәч, җитеп торыр, чытырдатып күземне йомдым да ишеккә таба атладым. Шакирҗанов ваннадагы «су анасына» сокланып, фотоаппаратын челт-челт иттерүен белде. Түз җаным, түз! Гөнаһысыннан баш-аяк! Минем бит әле өйләнәсем бар!..

Берәр елдан соң тәки өйләндерде үземне Шакирҗанов. Шәһәр ЗАГСында ул командорлык итте, яшьлегемнең иң матур, нәзакәтле фотолары Мидхәт әфәнде кулы белән эшләнде. Гел бушка. Табынчы буларак та талантлы шәхес ул, безнең фотохәбәрче. Бүген, сиксән биш яшендә дә гел шулай, ташып торган энергияле, җор телле, ачык йөзле инсан. Тарих өчен зур мәдәни мирас туплап калдырды.

Үземә теге чактагы су анасы дигәнем һич тә тынгы бирми, Шакирҗанов кыяфәтендә килә дә баса, килә дә баса күз алдыма...

**Госман ГОМӘР**

## Шарт

Үләренә бер атна кала, Һенрих Һейне үз янына нотариусны чакырткан да, иң соңгы теләген васыять итеп әйткән: «Бөтен байлыгымны, әсәрләремә тиешле каләм хакын хатыныма калдырам. Вәләкин бер шартым бар: ул янадан кияүгә чыгарга тиеш.»

— Ни өчен?! — дип сораган бу шарттан таң калган нотариус.

— Һич югы бер кешенең мине рәхмәт хисләре белән искә алуын телим! — дигән ана бөек шагыйрь.

## Бердәнбер

Шулай бер тапкыр король Фридрих Икенче Вольтерны көймәдә йөрергә чакырган. Бу тәкъдимгә язучы рәхәтләнеп риза булган. Әмма дә... Төбеннән су керә башлагач, ул тиз генә көймәдән сикереп тә төшкән.

— Батып үлмәгәем дип курыктыгыз, ахры — дип көлгән аннан король. — Ә менә мин курыкмыйм!

— Аңлашыла. Бу бик табигый, — дип җавап кайтарган ана акыл иясе. — Җир йөзендә хәзер корольләр күп, ә менә Вольтер — берәү генә. Бердәнбер!

## Чудакланырсың да...

Узган гасырның егерменче елларында Мәскәүдә «Чудак» дип аталган юмористик журнал чыгып килгән. Мөхәррире Михаил Кольцов икән дә, аның кабинетына кергәч, шушындый язу каршы ала икән: «Син — Гоголь түгел, сүзеңне кыска тот!»

Ә инде борылып кабинеттан чыгучыны ишектә түбәндәге язу көтеп тора икән:

«Син әле һаман чыкмадыңмыни?!»

## «Каләм сатучы»

Шулай берзаман Виктор Гюго чит илгә сәфәргә җыенган. Вәләкин иң әүвәле махсус анкета тутыру зарур икән.

— Ни белән шөгыльләнәсез? — дип сораган аннан жандарм.

— Язам.

— Юк! Яшәү өчен матди чыганакны ни рәвешле, ни белән табасыз дип сорыйм мин сездән, — дип үзенең сөален тәгаенләштергән чик сакчысы.

— Каләм белән.

— Алайсам, болай дип язып куйыйк: «Гюго — каләм сатучы!» — дигән, ниһаять, йөзенә канәгатьлек хисе иңгән жандарм.

## Ни кызганыч...

Марк Твен журналда мөхәррир булып эшләгән чагында аның бик күп вакыты кульязмалар укып үтә икән.

Шулай берчак кульязмалар белән туп-тулы чүп кәрҗиненә күз салган да бу, офтанып, үзалдына әйтеп куйган:

— Кешеләр таш плитәләргә язган заманнарда журнал мөхәррире булып булмады шул, ни кызганыч... Ул кульязмалардан шундый гаҗәеп вә мәһабәт вилла төзеп куйган булыр идем мин!

**Морад ДУСАЙ** *туплады*

## Сөббух Рәфыйковның тууына 100 ел

Шушы елның 15 июлендә язучы һәм шагыйрь Сөббух Рәфыйковның тууына 100 ел тула.

Кечкенәдән язучы булырга хыялланган егетнең язмышы фаҗигале сынаулар аша уза. «Соңгы талпыну» һәм «Үсмерчак» дигән ике китап чыгарып, инде укучыны үзенә җәлеп итәр көннәр җитә дигәндә генә, егерме дүрт яшьлек Сөббухны НКВД чекистлары кулга ала... 1937 елның 17нче октябре бу. Язучының «зур җинаяте» шул – бер төркем яшь язучылар белән бергә, татар әдәбиятының классигы Галимҗан Ибраһимовны илле яшь тулу уңаеннан котлап язылган хатка ул да кул куя. Г.Ибраһимов инде бу вакытта кулга алынып, хөкем карары булмаган килеш, халык дошманы дип игълан ителә.

Совет хәрби мәхкәмәсе, Сөббух Рәфыйковны ун елга ирегеннән мәхрүм итеп, тагын биш елга гражданлык хокукларын чикләргә дигән карар чыгара. Яшь әдип башта Соловки концлагерена, аннан Себердәге Металлургия комбинатына җибәрелә.

1951 елның җәендә шул ук элеккеге «җинаятьләре» өчен ул тагын кулга алына һәм Красноярск өлкәсенә гомерлек сөргенгә озатыла. Туган якларына ул егерме ел үткәч кенә, 1957 елда гына кайту бәхетенә ирешә.

Кырык дүрт яшьлек гомеренең репрессиядә үткән егерме еллык газаплары Сөббух Рәфыйковның иҗади рухын сындыра алмый. Сарман районының Нөркәй авылында туып-үскән егет «Социалистик Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасының төбәк хәбәрчесе булып эшли. Ул проза жанрына ныклап тотына.

1958 елда аның «Беренче яз» дигән тәүге романы дөнья күрә. Әсәрдә авторның язмышына турыдан-туры бәйле егерменче-утызынчы еллар, татар авылы кичергән кискен яңалыклар һәм күмәк хуҗалыкка күчү чорлары тасвирлана. Алга таба да бу теманы дәвам итеп, Сөббух Рәфыйков «Авыл иртәсе» (1966) романы белән популярлык казана. «Тын елга буенда» дигән романы исә «Казан утлары» журналында (1971, №№ 2-6) дөнья крә.

Егерме еллык тоткынлыкта җәфаланган язучының сәламәтлеге нык какшый. Ул 1971 елның 21нче ноябрендә Яңа Зәй шәһәрчегендә вафат була.

С.Рәфыйков – 1965 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.

# ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ ҖЫЕНЫ

2013 елның 24 маенда Татарстан язучыларының әдәби ел йомгакларына багышланган җыены булды. Көн тәртибендә, нигездә, ике мәсьәлә: берсе – ТР Язучылар берлеге рәисенең идарә эшчәнлеге турында чыгышы; икенчесе – хәзерге татар әдәби тәнкыйтенең торышы. Беренче көн тәртибе буенча Язучылар берлеге рәисе шагыйрь Рафис Корбан чыгыш ясады. Язучыларның алдагы Корылтаеннан соңгы бер ел вакыт эчендә идарәнең төп эшчәнлеге әдипләрне туплау, аларны иҗтимагый файдалы эшчәнлеккә тарту, китап укучылар белән якыннан аралашуга юнәлтелгәнлеген билгеләп үтте. Бу мәсьәләләрне унай хәл итүгә этәргеч бирүче шатлыклы күренеш буларак, Язучылар берлегенең Мөштәри урамындагы яңадан төзекләндерелгән, зәвыклы итеп бизәлгән бинада эшли башлавы ассызыклап үтелде. Шунда урнашкан Г.Тукай клубы, ишекләрен киң ачып, әдәби җәмәгатьчелеккә төрледән-төрле чаралар тәкъдим итә башлады. Бер ел вакыт эчендә, – дип билгеләп үтте Р.Корбан, – танылган әдипләр юбилее уңаеннан, яңа чыккан китапларны тәкъдим итеп, тәҗрибәле язучылар белән очрашулар һ.б. багышлап 20ләп әдәби кичә үткәрелде. Әлеге чаралар шактый зур финанс чыгымнары сорый. Без Татарстан хөкүмәтенең һәм Мәдәният Министрлыгының зур ярдәмен тоеп эшлибез.

Берлек рәисе тукталган мәсьәләләрнең тагын берсе – язучыларны социаль яклау. Төрле кичәләрдә чыгыш ясаган җырчылар, театр артистлары гына түгел, бәлки әдипләр дә гонорар ала башлаячак. Агымдагы елның 2нче яртыеллыгында пенсия яшендәге һәрбер язучы 1000 сум күләмендә матди ярдәм алачак. Тәрҗемә китапларны чыгару өчен хөкүмәт тарафыннан акча бүлеп бирелү дә билгеләп үтелде.

Әдәби иҗатка килүче яшьләр белән эшләү идарәнең мөһим бурычларыннан санала. Р.Корбан искәрткәнчә, бу мәсьәләдә активлык җитәрлек булмаган. Шулай да традицияне дәвам итү рәвешендә яшьләр иҗатыннан тупланган «Ак юл» җыентыгының икенче кисәге «Дәвам» чыгарылган. Язучылар идарәсе каршында Яшьләр Клубы эшли башлаган (җитәкчесе Гөлнур Корбанова). Нигездә университет студентларын үзенә туплаган һәм КФУ доценты, язучы Халисә Ширмән ярдәме белән эшләүче Клубка берлек рәисе зур өметләр баглый. Аерым алганда, Зиннур Мансуров, Рабит Батулла катнашында үткәрелгән мастер-класслар моңа нигез бирә. Мәктәпләрдә укучы яшь иҗатчыларны барлау максатында Татарстан Мәгариф һәм Фән министрлыгы белән берлектә шигырь язучылар конкурсы оештырылып, 26 апрельдә үткәрелгән Шигърият бәйрәмендә җиңүче 10 укучы тантаналы рәвештә бүләкләнгән.

Берлек рәисе язучыларның пассивлыгын, төрле чараларда аз катнашуларын искәртте. Иң борчыганы – әдипләребезнең җитди фәлсәфи, милли, әхлакый, социаль, сәяси мәсьәләләр белән вакытлы матбугатта аз чыгыш ясавы. Ә бу исә әдәби иҗатта да чагыла. Үткән бер ел вакыт эчендә вакыйга булырлык, киң җәмәгатьчелектә кызыксыну тудырып, бәхәсләр уяткан әсәрләр булмады, диярлек. Шулай да без Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән берлектә үткәрелә торган бәйгегә зур өметләр баглыйбыз, – дип белдерде



Р.Корбан. – Агымдагы елның 1 августына кадәр сездән авыл тормышын чагылдырган проза әсәрләре көтеп калабыз.

Икенче көн тәртибе буенча хәзерге татар әдәби тәнкыйтенең торышы турында доклад белән тәнкыйтьче Равил Рахмани чыгыш ясады. Ул әдәби иҗат белән тәнкыйтьнең бергә янәшә, үзара бәйләнештә яшәвен, бер-берсен тулыландырып торуга хезмәт итүен билгеләп үтте. Аның фикеренчә хәзерге татар әдәби тәнкыйте үзенең төп вазифаларын үтәп бетерми. Моның нигезендә бу өлкәдә эшләүчеләрнең теоретик әзерлеге җитмәү тора. Шуна да чыгыш ясаучы тәнкыйть теориясе мәсьәләсенә киң тукталды. Тәнкыйтьнең йомшак булуы әдәби иҗатта гына түгел, бәлки текстология, әдәби тәрҗемә белән шөгыльләнүчеләр эшчәнлегенә дә йогынты ясый. Мисал буларак, Г.Ибраһимов, Г.Исхакый мирасларын киң катлау укучыга кайтару, бу юлдагы кыенлыклар турында әйтелде. Г.Ибраһимов әсәрләренең һаман да совет чорындагы кыскартулар белән чыгуын, олы әдипнең тулы академик җыентыгын эшләү кирәклеге күрсәтелде. Тәнкыйтьче ачынып тәрҗемә китапларының камиллектән ерак булуына игътибарны җәлеп итте. Хәтта Г.Тукай әсәрләренең тәрҗемәләре дә әдәби таләпләргә җавап бирми. Ә, үз чиратында, аларга вакытында бәя бирелеп, унай һәм кимчелекле яклары күрсәтелми. Шул рәвешле хаталар бер китаптан икенчесенә күчеп тора. Р.Рахмани Язучылар берлегенә яна иҗатчылар кабул иткәндә дә, ел саен бирелә торган әдәби премияләргә тәкъдим иткәндә дә әдәби тәнкыйтьнең кирәклеген искәртте һәм бу өлкәне активлаштыру максатында «Әдәби тәнкыйть» дигән журнал чыгарырга тәкъдим итте.

Тәнкыйтьче-галим, профессор Тәлгат Галиуллин үзенең чыгышын тәнкыйтьнең әдәби процесстагы ролен күрсәтүдән башлады. Үз вакытында бөек шагыйребез Г.Тукайның «Тәнкыйть – кирәкле шәйдер...» фикере бүген аеруча актуаль янгырый. Тәнкыйтьне җанландыру традицияләргә таяну һәм яңа юллар, формалар эзләү рәвешендә барырга тиеш. Бу өлкәдә бер-беребезгә игътибарлы булу, актив иҗат итүчеләрне барлау, аларга ярдәм итү сорала. Гомәр Даутов, Фәрит Яхин кебек тәнкыйтьчеләрнең хезмәтләренә тукталып, аларга кыска гына бәя биреп үтте. Тәнкыйтьнең йомшак булуы бигрәк тә шигъриятгә үзен сиздерә. Аерым алганда, җыр текстларының әдәби таләпләрдән түбән булуына игътибар ителде. Тәнкыйть яшьләр иҗатын күз унында тотарга тиеш, дип саный Т.Галиуллин, безнең исә яшь иҗатчыларга тиешле бәя биреп, кайсыларының М.Цветаевага яисә В.Маяковскийга иярергә тырышуын, кайсыларының үз юлын, иҗат стилен эзләвен ачык итеп күрсәтеп биргәнебез юк. Галим татар әдәби тәнкыйтенең үсешен академик тәнкыйтьне җанландыру белән бәйләп карый.

ТР Язучылар берлеге идарәсе каршындагы тәнкыйть секциясе җитәкчесе Галимҗан Гыйльманов әдәби тәнкыйтьнең артта калу сәбәбен бу өлкәдә эшләүчеләрнең аз булуы белән бәйләп карый. Әлеге хәл-халәттән чыгу юлы

— яшь көчләрне тарту. Моның өчен традицияләрне янартып, «Казан утлары» журналы каршында «Яшь тәнкыйтьче клубы» ачу кирәк, дип саный ул. Г.Гыйльманов фикеренчә, әдәби журналларда классик тәнкыйтьчеләрнең ин унышлы язмаларын биреп бару да файдалы булачак. Бу, бер яктан, әдәбиятыбызның төрле чорларын барлауга, янартуга хезмәт итсә, икенче яктан, яшь авторлар өчен бер өйрәнү мәктәбе дә булып тора. Тәнкыйтьченең өченче тәкъдиме дә игътибарга лаек. Казан федераль университеты һәм Г.Ибраһимов исемендәге ТӘСИ каршында татар әдәбияты тарихы буенча аспирантура эшләп килә. Фәнгә килүче яшь галимнәр хәзерге әдәби процесска катнашмыйлар, диярлек. Аларны әдәби тәнкыйть мәсьәләләренә тарту да үзенең унай нәтиҗәләрен бирер иде.

Шагыйрә, прозаик Рифә Рахман чыгышында Язучылар берлегенә кабул итү Коллегиясе эшчәнлеге әдәби тәнкыйть белән тыгыз бәйләнештә каралды. Коллегиянең төп бурычы чын шагыйрьне яисә шигъри сәләте булган кешене такмакчыдан аерып карау белән бәйле, дип саный ул. Затлы кәгазьдә калын китаплар чыгару гына кешенең талантын күрсәтми. Бу мәсьәләдә бер-беребезгә җаваплы һәм таләпчән булырга тиешбез. Аеруча тәкъдимнамә язучыларга таләпчәнлекне арттырырга кирәк. Болар артында иҗатка мөнәсәбәт, тәнкыйди караш мәсьәләсе тора, шуна да әдәби тәнкыйтьне көчәйтү чын иҗатчыны һәртөр һәвәскәрдән аерырга ярдәм итәчәк. Тәнкыйтьче фикеренчә, акчасы булган һәркем китап чыгарырга алынган заманда бу аеруча мөһим.

Көн тәртибенә куелган мәсьәләләр буенча Р.Галиуллин, Н.Гыйматдинова, М.Галиев, Л.Газизова, Р.Фәйзуллин, В.Имамов, А.Хәлим һ.б. чыгыш ясады. Язучылар җыены, тикшерелгән мәсьәлә буенча резолюция кабул итеп, үзенең эшен тәмамлады.

---

## Электрон почта да төпсез түгел

**Редакциягә әсәрләр, мәкаләләрнең фәкать машинкада басылган яки компьютердан чыккан кульъязмалары гына кабул ителә. Бер биттә 30 юл (компьютер текстында да!), бер юлда (сүз араларын да исәпләп) 60 тамга булырга тиеш. Кәгазьнең бер ягы буш кала. Машинка текстының беренче нөсхәсе генә кабул ителә. Компьютер текстының дискеты да булу кулай.**

**Хатлар исә, җинел танылырлык итеп, кулдан да язылырга мөмкин.**

**Редакциянең электрон адресына фәкать кечкенә күләмдәге язмалар (хатлар, документлар, фикерләр һ.б.) гына кабул ителә.**

**Электрон адреска күләме 5 биттән арткан язмалар җибәрелгән очракта, почта аша аның оригиналын (кәгазьгә басылган вариантын) алгач кына әсәр кабул ителгән санала.**

### ИЗГЕ БОЛГАР ҖЫЕНЫ

26 май көнне традицион Изге Болгар җыены булды. Ул Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам дине рәсми кабул ителүгә 1124 ел тулуга багышланды. Анда катнашкан меңнәрчә кеше арасында татар дин әһелләренең IV форумы делегатлары, Россиянең төп мөселман үзәкләренә керән Диния нәзарәтләре рәисләре бар иде. Җыенны ачу тантанасында ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, ТР Дәүләт Киңәшчесе, Тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне торгызу республика фонды Попечительләр советы рәисе Минтимер Шәймиев, Россия мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте рәисе Тәлгат хәзрәт Таҗетдин, Россия Мөфтиләр шурасы рәисе Равил хәзрәт Гайнетдин, ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм башкалар катнашты.

Башта кунаклар Президент Рөстәм Миңнеханов җитәкчелегендә Ак мәчеттә булды, соңрак мөфтинең мәчеттә урнашкан резиденциясендә республика җитәкчелеге РФ мөселман дине лидерлары белән очрашты. Аннары Болгар цивилизациясе музее да урнашкан Елга вокзалы ачылды.

Президент Рөстәм Миңнеханов җыенга килүчеләрне сәламләп, аларны Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам дине кабул ителүгә 1124 ел тулу белән котлады. Ул татар дин әһелләренең Казанда IV форумы узуын әйтте, анда татар халкының телен, гореф-гадәтләрен саклау мәсьәләләре күтәрелүенә басым ясады.

«Менә инде берничә ел Болгар җиренә җыелып очрашабыз, бер-беребез белән аралашабыз. Бу — зур бәхет, бирегә килгәнегез өчен рәхмәт. Мондый очрашулар әле күп еллар дәвам итәр, дип ышанам, — диде ТР Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев.

Россия мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте рәисе Тәлгат хәзрәт Таҗетдин Болгарны мөселманнарның уртак йорты белән чагыштырды һәм аның янарышына шатлануын белдерде, аны татар дин әһелләренең даими очрашу урыны итәргә ниятләүләрен җиткерде. Россия Мөфтиләр шурасы рәисе Равил хәзрәт Гайнетдин татар халкының күпмилләтле Россиядә сан ягыннан 2нче урын алып торуын искәртте. «Совет чорында мәчетләр күп җимерелде, демократия юлына баскач, иман йортларыбызны, Болгарны яңадан торгызу мөмкинлеге алдык. Бу тарихи җир безгә татар халкының гореф-гадәтләрен һәм мәдәниятен саклауда ярдәм итәр», — диде ул. ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Камил хәзрәт Сәмигуллин да сәламләү сүзләрен җиткерде.

Соңыннан дәрәҗәле кунаклар Һөнәрчеләр шәһәрендә булып, халык һөнәрчелеге эшләнмәләре һәм сувенир продукция белән танышты. Аннан соң алар халыкара археологик тикшеренүләр үзәге эшчәнлеге белән танышты, «Габдрахман сәхабә коесы» комплексында булды, чишмә суыннан авыз итте, хан мунчасын карады. Җәмигъ мәчетендә өйлә намазында катнашты. Изге Болгар җыены кунаклары өчен күп төрле чаралар — Коръән укучылар чыгышы, мөнәҗәтләр, борынгы җырлар башкару, хәләл продукция сәүдәсе һ.б. каралган иде.

### ӘДӘБИ УНИВЕРСИАДА

Башкалабызда Универсиаданы каршылау чаралары башланып китте дияргә дә була. 14 июнь көнне Казанда БДБ илләреннән килгән язучылар, каләм әһелләре катнашында Әдәби универсиада булып үтте. Мондый чара үткәрү тәкъдимен «Дружба народов» журналы күтәреп чыккан. Ә Татарстан Язучылар берлеге каләм ияләренең очрашуы, аралашып торуы өчен барлык шартларны тудырды. Шулай итеп 14-16 июнь көннәрендә Казанда шагыйрь, «Новая газета»ның баш мөхәррир урынбасары Олег Хлебников, «ОГИ» нәшриятының баш мөхәррире, шагыйрь Максим Амелин, Украинада чыга торган «ШО» журналының баш мөхәррире, шагыйрь Александр Кабанов, Молдова шагыйре Лэо Бутнару, Кыргызстан шагыйрәсе Алтынай Жуманазарова, «Дружба народов» журналы хезмәткәре Алисә Ганиева һәм Фәрит Нәгыйм булып китте.

Г.Тукай клубында үткәрелгән очрашуда ТР Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рәмис Аймәт сәлам сүзе белән чыкты. Ә ТР мәдәният министры урынбасары Гүзәл Нигъмәтуллина үзенең чыгышында: «Казан

әле ул спорт башкаласы гына түгел, бирегә төрле халыклар әдәбиятлары очрашып, үзара уртак тел табу урыны да», — дип искәртте.

Очрашуда Фәрит Нәгыйм яңа элемтәләр урнаштыру, журналга яңа, яшь авторлар җәлеп итү уе белән килүен әйтте. «Халыклар дуслыгы — ул аерым кешеләр дуслыгыннан башлана. Безгә бер-беребезнең әдәбиятын тәрҗемә итмичә мөмкин түгел», — диде Фәрит әфәнде. Моннан тыш, ул үзенең кызыклы бер тәкъдимен дә җиткерде. Бу — татар халкы тарихына дөрес һәм лаеклы мөнәсәбәт тудыручы иҗат әһелләре өчен Равил Бохараев исемендәге премия булдыру. Аның бу тәкъдимен Татарстанның халык шагыйре, «Дружба народов» журналының редакция советы әгъзасы Ренат Харис та куәтләде. «Бездә яшь талантларны үстерә белү җитми. Яңа премия шушы максатларга да хезмәт итәр иде», — диде ул. Олег Хлебников: «Төрле мәдәниятләр кисешкәндә, алар бер-берсен баета. Мин бу аралашуны зур байлыкка саныйм», — диде. «Казан утлары» журналының баш мөхәррире, Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин бүгенге заманда иҗади хезмәтнең лаеклы бәяләнмәве, иҗат әһелләренә хөкүмәтнең дә, халыкның да игътибары җитмәве хакында әйтте. Гади халыкның әдәби аңын күтәрү, халыкны әдәбиятка, матбугатка тартуның кирәклеген ассызыклады.

Каләм әһелләре Татарстан Милли китапханәсендә «Заман әдәбиятында ислам» дигән темага түгәрәк өстәл сөйләшүендә дә катнашты. Халыклар дуслыгы йортында, В.Аксеновның музей-йортында әдәбият сөючеләр белән очрашты.

## АСТРАХАНЬДА ТУКАЙ ҺӘЙКӘЛЕ

Тарихи Астрахань каласының элеккеге Татар бистәсендә шагыйребез Габдулла Тукайга Казанда коелган бронза һәйкәл куелды. Аны ачу тантанасында өлкә губернаторы Александр Жилкин, Татарстан Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Астрахань өлкәсе Думасының беренче урынбасары, 80 мең милләттәшне берләштерүче «Дуслык» татар мәдәнияте үзәге җитәкчесе Әнвәр Алмаев катнашты. Тантанага җыелган митингта Татарстанның халык шагыйрьләре Равил Фәйзуллин һәм Ренат Харис үзләренең Тукайга багышланган шигырьләрен укыдылар.

Сынның идея авторы — күренекле рәссам Бакый Урманче. Ә аның хыялын укучысы Владислав Авдеев чынга ашырды.

Шулай итеп, адмирал Нахимов һәм Александров урамнары киселешендәге мәйданда урын алган Г.Тукай һәйкәле Астрахань шәһәренең үзенчәлекле бизәгенә әйләнде.

## «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» ЮБИЛЕЕ

«Корстон» кунакханә-сәүдә-күңел ачу комплексында «Ватаным Татарстан» газетасының 95 еллыгына багышланган тантана булды. Анда юбиляр басманы Татарстан Президенты, Хөкүмәте исеменнән Премьер-министр урынбасары — авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов котлады. «Ватаным Татарстан» — республикабызның төп газетасы. Аңа карап торабыз», — диде ул тәбрикләү сүзендә. Аннары М.Әхмәтов редакция коллективына ТР Президентының Рәхмәт хатын, ә журналистларга дәүләт бүләкләрен тапшырды.

Йөзьяшәр газета хезмәткәрләренә шулай ук Татарстан Журналистлар берлеге рәисе, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова, Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев, Дәүләт Советы комиссиясе рәисе Роберт Миңнуллин, ЮХИДИ идарәсе башлыгы Рифкат Миңнеханов, Бөтендөнья Татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров, Аксубай районы башлыгы Камил Гыйльманов, Башкортстанның «Кызыл таң» газетасы баш мөхәррире Фаил Фәтхетдинов һ.б.лар котлау сүзләрен ирештерде.

## «ЗУР ИДЕЛ» КҮРГӘЗМӘСЕ КАЗАНДА

XVII Бөтендөнья җәйге Универсиадасы уңаеннан, аның мәдәни программасы кысаларында Казаныбызда төбәкара XI «Зур Идел» күргәзмәсе ачылды. «Хәзинә» милли сәнгать галереясендә экспозицияне ачу тантанасында Татарстан мәдәният министры Айрат Сибагатуллин, Россия Рәссамнар берлеге рәисе Андрей Ковальчук, Россия Сәнгать академиясе вице-президенты Анатолий Любавин, Россия Рәссамнар берлеге сәркәтибе Алексей Суховецкий һәм Ульяновск, Түбән Новгород, Пермь, Самара, Саратов, Тольятти, Оренбург, Йошкар-Ола, Ижевск, Чабаксар, Саранск шәһәрләреннән рәссамнар катнашты.

Әгәр тарихка күз салсак, «Зур Идел» күргәзмәсе беренче тапкыр 1964 елда Самара (элекке Куйбышев) шәһәрендә уза. Шуннан соң 5 елга бер тапкыр Идел буе төбәге рәссамнарының иҗат эшчәнлегенә нәтиҗә ясау матур гадәткә әйләнә. Чарада Россия Рәссамнар берлегенең 13 бүлекчәсендә теркәлгән 2 меңләп рәссам катнашып килә. «Зур Идел» олпат кылкаләм осталарына иҗади куәт өсти төшә, яшьләргә канат куя. Үз заманында рәссамнарыбыз Х.Якупов, Л.Фәттахов, Ә.Мәҗитов, И.Зарипов, В.Федоров исемнәре нәкъ менә «Зур Идел» экспозициясе аша киң җәмәгатьчелеккә билгеле була.

## АНА ТЕЛЕ УКЫТУЧЫЛАРЫ ЖЫЕНЫ

Мәркәзебез Казанда 4нче тапкыр татар теле һәм әдәбияты укытучыларының Бөтенроссия форумы булып үтте. Чираттагы жыенга Татарстаннан, шулай ук Оренбург, Ульян өлкәләреннән, Мари Иле, Удмурт республикаларыннан, Санкт-Петербург һәм Мәскәү шәһәрләреннән җәмгысе 500ләп мөгаллим, төрле бәйгеләрдә һәм олимпиадаларда җиңү яулаган студентлар, мәктәп укучылары җыелды. Форумда ТР Мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов, ТР Дәүләт Советы депутатлары Разил Вәлиев, Роберт Миннуллин, ТР Министрлар кабинеты аппаратының идарә җитәкчесе Гөлшат Нигъмәтуллина, КФУ һәм Мәгарифне үстерү институты галимнәре һәм башка зыялыларыбыз катнашты.

## ПЕТЕРБУРГ ЭРМИТАЖЫ – КАЗАНДА

«Казан-Эрмитаж» үзәгендә Санкт-Петербургтагы данлыклы Эрмитаж музееның чираттагы күргәзмәсе ачылды. Универсиада хөрмәтенә оештырылган «Олимпия: вакытны җиңү» дип аталган күргәзмәне ачу тантанасына Эрмитажның генераль директоры академик Михаил Пиотровский килде. Ул ТР Президенты Рөстәм Миннеханов белән очрашты.

Яна күргәзмәгә 300 экспонат куелган. Алар арасында безнең эраның беренче гасырларында эшләнгән сыннар да бар, борынгы атлетларның бүләк-призларын да күрергә мөмкин.

## КОЛ ШӘРИФНЕ ЯКЛЫЙК

«Россия 10» проекты буенча, Кол Шәриф мәчете Идел буе федераль округының истәлекле урыннары рейтингында 5 нче урынга күтәрелде.

Исегезгә төшерәбез: әлеге проектта Идел буеның 14 субъекты көч сынаша. Алар һәрберсе үз җирлегендәге иң яхшы, иң матур һәм иң кызыклы тарихи урыннарны, археологик һәйкәлләрне, мәдәни объектларны тәкъдим итә. Әмма ахыр чиктә аларның язмышын тамашачылар хәл кыла. Шуңа да алдан ук тавыш бирүнең нәтиҗәләрен күз алдына китереп тә булмый. Соңыннан исә иң күп тавыш җыйган 10 истәлекле урынның кечкенә генә күчермәләрен ясап, аларны Мәскәү өлкәсендәге «Россия» ландшафт паркында урнаштырачаклар.

Кыскасы, 29 сентябрьгә кадәр Интернет кулланучы һәркем, теркәлмичә генә дә, www.10 russia.ru проект сайтына кереп һәм һәр 24 сәгать дәвамында бер IP-адрестан 3 тапкыр тавыш бирә ала.

## ФИЛЬМНАР ТИКШЕРҮ УЗА

Халыкара мөселман киносы фестиваленә 200дән артык гариза тапшырылган инде. Сайлап алу комиссиясе кинотасмаларны карау эшенә керешкән. Бар фильмнар да форумның идеологик кыйммәтләренә туры килү-килмәү җәһәтеннән тикшерү уза, алар Ислам белгечләре тарафыннан рецензияләнә. Жюрине кинорежиссер, сценарист, продюсер Карен Шахназаров җитәкләячәк. Моннан тыш Европа, Төркия, Иран, Һиндстан белгечләре белән дә сөйләшүләр алып барыла. Фестиваль быел Казанда 5-11 сентябрьдә узачак.

## ХЕЗМӘТЕНӘ КҮРӘ ХӨРМӘТЕ

Гаммәви мәгълүмат чараларын үстерүгә зур өлеш керткәне һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе дәүләт бюджет учреждениесе баш мөхәррире урынбасары, җаваплы сәркәтип **Ризванов Габделбәр Газиз улы** Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнде.

***

Мәдәниятне һәм сәнгатьне үстерүгә зур өлеш керткәне, нәтиҗәле хезмәте өчен «Бөтенроссия дәүләт телевидение һәм радиотапшырулар компаниясе» федераль дәүләт унитар предприятиесе филиалы «Татарстан» дәүләт телевидение һәм радиотапшырулар компаниясе» радиотапшырулар хезмәтенең әдәби-драматик, музыкаль һәм балалар тапшырулары төркеме тапшырулар алып баручысы **Акмалов Нәсим Рәшит улына** «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* яңа ачылган «Казан-Арена» стадионы.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы **Николай Алешков**.

## Яңа китаплар




**Лирон Хәмидуллин.** Буранлы төндә: хикәяләр, повестьлар, очерклар. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2012.—398 б. Тиражы 2100 данә.

Бу китапта язучы Л.Хәмидуллинның төрле елларда иҗат ителгән хикәяләре, күренекле шәхесләребезнең иҗатын һәм биографиясен чагылдырган ике повесте (Закир Рәмиев-Дәрдемәнд һәм Фәйзулла Туишевка багышлы әсәрләр), егермеләп очеркы урын алган. Күләмлерәк очерклары арасыннан «Казан утлары» журналының 90 еллыгына багышлап язылган «Милләтебез байрагына тиң басма», Россиянең беренче дин башлыкларына — мөфтиләргә багышлы «Ерак юл, якын тарих» һәм «Хөсәения мәдрәсәсе»нең утыз еллык тарихын чагылдырган очеркларны аерым атап китеп була.




**Фирдәвес Гарипова.** Татар топонимнары сүзлеге. − Казан, 2010. − 679 б.

Бу сүзлек филология фәннәре докторы, профессор Фирдәвес Гарипованың гомере буена җыйган географик атамаларының бер өлеше. Китапта тупланган атамалар татар халкының үсеш дәрәҗәсе, тарихы, тел тарихы, этнографиясе, мифологиясе, фольклоры һ.б. өлкәләренең үсеш этапларын күрсәтә торган кыйммәтле тарихи чыганак булып тора.

Сүзлек киң җәмәгатьчелеккә, укытучыларга, укучыларга һәм туган җирләренең тарихы, рухи байлыгы белән кызыксынучыларга атап чыгарыла.



Николай Алешков

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)